ISSN 0206—4189

# Казан утлары

8.1984



# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

8

1984


## *Бу санда*


А. М. ГОРЬКИЙНЫҢ КАЗАНГА КИЛҮЕНӘ 100 ЕЛ

Рухи яктан мин Казанда тудым . . . . . . . 3
М. ГАЙНУЛЛИН. Горький һәм татар әдәбияты . . 4
М. ЛОПАТИНА. Хәтер сөйли . . . . . . . . 13
С. ӘДҺӘМОВА. Бөек язучы рәхмәте . . . . . 16
Һ. ТАКТАШ. Килечәккә хатлар. Поэмадан өзек . 18
Р. ГАРИФҖАНОВА. Хатлар актарганда . . . . 18
Игелекле кайгырту . . . . . . . . . . . . 20

М. ХӘБИБУЛЛИН. Кубрат хан. Роман . . . . . 22

Р. ХАРИС. Гүзәл гөмбәз. Шигырьләр . . . . . 75

З. ФӘТХЕТДИНОВ. Ак «Жигули» эз югалта. Маҗаралы повесть . . . . . . . . . . . . . 82

Ш. МАННАПОВ. Күңелгә кага иген кыры. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 141

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Казанда Тукай урыннары . . . . . . . . . . 147
Ф. САФИН. Тукай АЭСта . . . . . . . . . . 148

С. ШӘМСИ. Шүрәлеләр кайдан таралган! . . 149

БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА

Ш. ХАММАТОВ. Муса Җәлил — халык күңелендә 159

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

Х. БӘДРЕТДИНОВ. Бишьеллыклар төсе . . . . 167

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Якты юл . . . . . . . . . . . . . . . . 172



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Ф. МИҢНУЛЛИН. Шагыйрьнең прозасы . . . . 173
Культура тоҗмышы көндәлеге . . . . . . . . 191
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия:*
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
СИБГАТ ХӘКИМ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ

Материалы к 100-летию со дня приезда А. М. Горького в Казань.
Статьи **М. Гайнуллина, М. Лопатиной, Р. Гарифзяновой.** Воспоминания **С. Адгамовой.** Отрывок из поэмы **Х. Такташа** «Письма в грядущее».
Роман **М. Хабибуллина** «Кубрат хан». Приключенческая повесть **З. Фатхутдинова** «Кто назовет убийцу?» Стихи **Р. Хариса, Ш. Маннапова.**
К столетию Г. Тукая. Рисунок **Т. Зуевой** из цикла «Тукаевские места в Казани». Стихотворение **Ф. Сафина** и статья **С. Шамси** «Родословная Шурале».
К 40-летию Великой Победы. Статья **Ш. Хамматова** «Муса Джалил — в душе народа».
Продовольственная программа — всенародное дело. Очерк **Х. Бадрутдинова.**
Статья **Ф. Миннуллина** «Проза поэта». Дневник культуры. На нашей обложке — творчество народного художника СССР Х. Якупова.

Техник редактор *Р. Сөләйманова* Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*

Производствога бирелде 31.5.1984 ел. Басарга кул куелды 27.7.1984 ел. ПФ 02288. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64049. Заказ К-219. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.

# РУХИ ЯКТАН МИН КАЗАНДА ТУДЫМ

*«Әйдәгез... Казанның данлы пекарен... искә алыйк!»*

В. И. Ленин (Истәлекләрдән)



...1884 елның августы. Казан пристанена Түбән Новгород ягыннан төшкән пароход килеп туктый. Күперчек аша ярга ашыгучы пассажирлар арасында уналты яшьләр чамасындагы бер егет тә күренә. Аркасына асылган җыйнак кына биштәрдә — берничә китап һәм ипи кыерчыгы. Шәһәргә таба зур-зур адымнар белән атлап китүче егет Алеша Пешков, бөек пролетар язучы Алексей Максимович Горький була.

Казанны М. Горькийдан да якынрак күргән бүтән берәр күренекле рус язучысы бармы икән?! Һәм аны үз әсәрләрендә шулкадәр калку итеп күрсәткән башка әдип юктыр. Бу табигый, чөнки ул нәкъ менә Казанда кырыс тормыш мәктәбен — беренче «университетлар»ын уза, «тормыш төбе» авырлыкларын үз башыннан кичерә, биредә беренче мәртәбә революцион рухлы кешеләр белән таныша, марксистик әдәбият укый, эшчеләр арасында пропаганда алып баруда, Федосеев түгәрәге прокламацияләрен бастыруда катнаша, «күмәчче-пропагандист» була, иҗтимагый-политик яктан чыныга башлый.

«...Мин Казан университетына укырга барам, шуннан да ким түгел». Алеша Пешков Казанга әнә шундый хыял белән килә. Әмма ул «кухарка балалары» өчен император уку йорты ишекләренең ябык булуын килүгә үк аңлап ала. «Мин нинди дә булса эш эзләргә керештем,— дип искә ала А. М. Горький.— Мин университетның буш хыял икәнен... төшендем».

Михнәтле тормыш «университетлары»ның Казандагы дүрт елы дәвамында Алексей Максимович, үзенең шәхес буларак характерын чыныктырып, авыр һәм газаплы эзләнүләр юлын үтә. «Миндә акрынлап

ихтыяр үҗәтлеге үсә барды,— дип язды ул соңыннан,— һәм тормыш авырлашкан саен мин үземне ныграк, хәтта акыллырак итеп сиздем». Нәкъ менә шушы елларда ул үз гомерләрен яңа тормыш өчен, дөньяны революцион үзгәртеп кору өчен көрәшүгә багышлаган фидакарьләр юлына баса.

Бик күп «ачы минутлар» кичерсә дә, М. Горький Казанны һәрвакыт сагынып яши һәм ул шәһәребезгә тагын дүрт мәртәбә килеп китә (1888, 1889, 1890 еллар). Соңгы мәртәбә Алексей Максимович Казанга 1928 елның августында, Советлар иле буйлап сәяхәт иткәндә кагыла. Хәтирәләрен яңарта-яңарта, шәһәрне әйләнеп чыга, күп кенә учреждениеләрдә була, тантаналы җыелышта чыгыш ясый, республика хезмәт ияләренә үзенең зур ихтирамын белдерә.

Чыннан да, Казан чоры булачак бөек язучы тормышында гаять зур роль уйный, һәм Алексей Максимович моны үзе дә раслый: «Физик яктан Нижний Новгородта, ә рухи яктан мин Казанда тудым».

Һәм менә А. М. Горькийның беренче мәртәбә Казанга килүенә 100 ел тулды. Бу сандагы материаллар шушы юбилейга багышлана.

**Мөхәммәт Гайнуллин,**
филология фәннәре докторы, профессор

# ГОРЬКИЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Бөтендөнья хезмәт ияләренең якын дусты, революция лачыны, даһи язучы Алексей Максимович Горькийның Казанга килүенә 100 ел тулган көннәрдә, илебездәге барлык халыклар кебек, татарстанлылар да үзләренең якташларын — «Казанның данлы пекарен» (Ленин) хөрмәт белән искә алалар. Казан — Горькийның рухи яктан туган каласы. Ул беренче тормыш университетларын шунда уза, даһи Ленин шикелле үк, азатлык өчен көрәш юлында беренче чыныгуын иң башлап Казанда ала.

Әдәбиятка революция хәбәрчесе булып килгән, тормышның кабәхәтлекләрен селкереп ташлап, җир йөзендә гадел, якты һәм шатлыклы тормыш төзү бәхетенә ирешү өчен аяусыз көрәшкән бу бөек художник, дөнья классик әдәбиятының алдынгы традицияләрен үстерә барып, яңа совет әдәбиятына нигез салучы, социалистик реализм методын тудыручы булды. Горький иҗатында, дөнья әдәбиятында беренче тапкыр буларак, яңа герой — алдынгы пролетарий, халыкның азат хезмәте һәм бәхете өчен көрәшүче герой образы туды. Бу геройның рухи матурлыгы, иксез-чиксез иҗади мөмкинлекләре Горький әсәрләрендә зур осталык белән бирелде. Язучы үзенең иҗатында сыйнфый көрәштә җиңеп, яңа социализм дөньясын төзергә сәләтле көчне — халыкның куәтле көчен гаять оста күрсәтте. Эшчеләр сыйныфының революцион көрәше, яңа җәмгыять төзүдә аның хезмәт батырлыгы Горький әсәрләрендә дөрес һәм тормышчан чагылыш тапты.

Бөек сүз остасы А. М. Горький гадел тәнкыйтьче һәм ялкынлы публицист та иде. Аның тынычлыкны, демократияне һәм социализмны яклап ясаган чыгышлары зур әһәмияткә ия булдылар. Горький, буржуаз дөньяны рәхимсез тәнкыйтьләп, империалистик реакцияне һәм ул тудырган фашизмны ярсып фаш итте, җир йөзендәге намуслы барлык кешеләрне

реакциягә каршы, халыкларның азатлыгы һәм туганлыгы хакына, бөтен җир шарында тынычлык урнаштыру хакына көрәшкә чакырды.

Горькийны Көнбатыш Европа һәм Американың прогрессив язучылары (Франциядә Р. Роллан, А. Франц, А. Барбюс, Америкада Т. Драйзер, Дж. Лондон, Даниядә М. Андерсен-Нексе һ. б.) белән ныклы иҗади һәм рухи дуслык берләштерде. Р. Роллан әйткәнчә, әле беркайчан да һәм Горькийдан башка беркемгә дә бөтендөнья культурасы гасырын революция белән шулай оста бәйли белү мөмкин булмады. Актив көрәшүчән гуманизм, әсәрләренең чын патриотизмы һәм халыкчанлыгы, социализм өчен барган көрәшнең көченә һәм тормышчанлыгына нык ышану, хезмәтне поэтик төсләрдә күрсәтү, уңай геройны сурәтләүдә новаторлык алымнары — болар барысы да бөтендөнья әдәбиятына Горький керткән бәһаләп бетергесез өлеш.

1907 елның маенда Горький Лондонда партиянең V съездында катнаша. «Ана» романы белән кульъязма хәлендә үк танышкан В. И. Ленин язучы белән әңгәмәсендә бу китапның бик вакытлы булуын, эшчеләрнең стихияле хәрәкәтен пролетариатның оешкан көрәшенә әверелдерү темасының бик мөһим икәнлеген билгеләп үтә. Озакламый «Ана» романы бик күп телләргә тәрҗемә ителә һәм миллионнарча укучыларның өстәл китабына әверелә.

В. И. Ленин һәм башка күренекле шәхесләр белән даими аралашып торуы һәм якын дус булуы Горькийга чынбарлыкны тирәнрәк аңларга, тарихи вакыйгаларны сәнгатьчә сурәтләгәндә партиялелек позицияләреннән чыгып эш итәргә, әсәрләрендә тормышның бөек дәреслеген чагылдырырга ярдәм итте. Аның иҗаты пролетариатның сыйнфый аңы үсешенә гаять зур йогынты ясады. Язучы иҗатының бу ягын билгеләп, Ленин болай дип язды: «Горький — һичшиксез, пролетариат сәнгатенең зур вәкиле, ул аның өчен күп нәрсә эшләде һәм тагын да күбрәк эшли алачак».

* * *

Илебездәге барлык халыкларның культурасы һәм әдәбияты үсеше турында А. М. Горький туктаусыз кайгыртучанлык күрсәтте. Аның талантлы иҗаты үрнәгендә бик күп язучылар үсеп чыкты. Безнең татар әдәбиятының барлык күренекле язучылары аның якты иҗатыннан үрнәк алып үстеләр. Татар телендә пролетариат әдәбиятының беренче үрнәкләрен биргән Г. Коләхметов 1908 елда басылган «Яшь гомер» драмасының титул битендә: «Бу әсәр мәшһүр рус мөхәррирләреннән Максим Горькийга тәкълидән язылмыштыр», — дип күрсәтте. Реакция еллары өчен бу — бик кыю белдерү иде. Чөнки бу чор патша хөкүмәтенең М. Горькийны аяусыз эзәрлекләгән, буржуаз матбугат, аның таланты сүнде, дип язып чыккан еллар иде.

«Яшь гомер» драмасы — гади ияру генә түгел, бәлки Горький мотивларын милли нигездә иҗади файдаланып язылган әсәр. Коләхметов та төп җиңүче тарихи көчнең эшчеләр сыйныфында булуын дөрес күрә. Ул татар әдәбияты өчен яңа образлар — революцион интеллигент Гали, эшче Йосыф, җитәкче-коммунист Вәли образларын иҗат итте. Әсәрдә Горький геройлары белән Коләхметов образлары арасында күп кенә авазадаш фикер йөртүләр күренә. Мәсәлән, «Мещаннар»да Нил Бессеменовка мондый сүзләр әйтә:

«В этом доме я тоже хозяин. Я десять лет работал и заработок вам отдавал. Здесь, вот тут, вложено мною не мало! Хозяин тот, кто трудится».

Үз нәүбәтендә Йосыф та шундый ук фикерләре белән чыга:

«Менә бу кәнәфидә дә минем хакым бар. Ничек бар?.. Бу кәнәфине кем эшләгән? Эшчеләр. Йосыф кем соң? Эшче»...

Алдынгы татар интеллигенциясе арасында марксистик идеяләрнең килеп керүен күрсәтүгә багышланган «Ике фикер» пьесасында да М. Горькийның «Соры турында» памфлеты һәм «Кеше» исемле әсәреннән алынган тәэсир сизелеп тора. Автор Кара фикерне реакцион көчләрнең символы итеп куйса, Кызыл фикерне киләчәкнең — көрәштә җиңә баручы революцион идеяләрнең билгесе итеп ала. Шуның белән бергә, Г. Коләхметовка, М. Горькийның үзенә дә ярдәм иткән шикелле, революцион идеяләрне үзләштерүгә, беренче нәүбәттә, большевиклар партиясе юл күрсәтә.



*М. Горький һәм А. Толстой совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездында катнашкан татар язучыларыннан К. Нәҗми, Л. Гыйльми, Х. Туфан, Г. Толымбай, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Нигъмәти арасында.*

А. М. Горькийның тормыш юлы һәм әсәрләре белән киңрәк кызыксына башлау татар әдәбиятында һәм вакытлы матбугатта 1906—1907 еллардан башлана. Г. Камал үзенең «Бәхетсез егет» дигән драмасының икенче редакциясенә Горькийның «Тормыш төбендә» дигән пьесасыннан җырлар (С. Рәмиев тәрҗемәсендә) алып урнаштыра. Кара реакция елларында бу җырлар татар хезмәт иясе арасында киң тарала, укучы яшьләр, завод-фабрика эшчеләре тарафыннан еш җырлана.

*Кояш чыга да, бата да,*
*Төрмәм мәңге караңгы.*
*Көннәр, төннәр зобанилар,*
*И . . . . . . . . . . . . х!*
*Тәрәзәмне караулый...*

Шул елларда татарча чыга торган газета һәм журналларда М. Горькийның Америкада да булуы һәм рус монархиясенә каршы көрәш алып баруы, хезмәт ияләрен яклаучы булуы турында хәбәрләр бер-бер артлы басылып тора. Бигрәк тә «Ана» романының кайда һәм нинди телдә басылуы турында күп кенә мәгълүмат бирелә. Мәсәлән, «Казан мөхбире» газетасының 1907 елгы 21 сентябрь санында: «Россиянең бөек мөхәррирләреннән Максим Горькийның «Ана» әсәре күптән түгел «Знание» мәҗмугасында басылып чыкты... Хәзер Максим Горький җавапка тартыла», — дип хәбәр ителә.

Татар матбугаты «Ана» романының Көнчыгышта популяр булуы турында да күрсәтә. Бу уңайдан «Вакыт» газетасының 1910 ел, 4 май санында болай диелә: «Каһирәдә рус язучыларыннан Толстойдан кала иң мәшһүре Максим Горький санала. Аның төрекчәдән гәрәп теленә тәрҗемә ителгән «Ана» романы Каһирәдә 7 мәртәбә басыла, меңнәрчә данәдә тарала. Чехов әсәрләре дә гәрәп сәүдәсен бизи башлады».

Тагын шунысы да игътибарга лаек: «Ана» романының төрекчәгә тәрҗемәсе Россиягә — Орск шәһәренә дә кайтарыла. Шул турыда «Йолдыз» газетасының 1913 ел, 11 апрель санында түбәндәге игълан бирелә: «Ана» — Максим Горький әсәре, төрекчәгә тәрҗемә ителеп басылып чыкты... Хакы 1 сум 80 тиен. «Ана» гүзәл әсәрдер». Шунда ук китап алдыручылар өчен түбәндәге адрес күрсәтелә: Орск шәһәре. Шәрык китапханәсе. Димәк, революциягә кадәр үк бу әсәрнең төрекчәгә тәрҗемәсе бездә дә сатыла башлаган.

Әдипнең бөек гуманистик идеяләр белән сугарылган әсәрләре татар яшьләре арасында зур ихтирам казана. Алар үзләренең әдәби-публицистик мәкаләләрен А. М. Горькийның рухландыргыч идеяләренә таянып яза башлыйлар. Бу яктан шул елларда ук революцион брошюралар тәрҗемә итүче — журналист Рәкыйб Рәкыйбиның «Казан мөхбире» газетасында (1907 ел, декабрь) басылган «Гали өметләр» дип исемләнгән мәкаләсе аеруча характерлы. Әлеге мәкаләдә Горькийның: «Инсан! Бөек Инсан! Инсан рухи хәле көчсез вакытта үзенә алла иҗат иткән булса, гали рухы... яңадан кувәтләнгәч, ул аны юк итәчәк», дигән сүзләре эпиграф итеп алына.

Безнең әдипләр үзләре генә түгел, геройлары да бөек язучыга хөрмәт күрсәтәләр. Шундый мөнәсәбәт Ф. Әмирханның 1911 елда басылган «Урталыкта» романында реаль чагылыш таба. Әсәрнең баш герое Хәсән үз бүлмәсен бизәгәндә өстәле каршындагы стенаның урта бер җиренә Маркс сурәте төшерелгән открытканы, уң ягына Тургенев һәм сул ягына Горький рәсемен урнаштыра. Шунда автор, сызык астына төшереп, Горькийны «Җәберләнүчеләр тормышын язу белән танылган мөхәррир», дип күрсәтә.

Татар халкының бөек шагыйре Г. Тукай, рус классикларыннан Пушкин, Лермонтов һәм Толстой әсәрләре белән рухланып язуы белән беррәттән, Горькийдан да идея йогынтысы алды. Аның «Максим Горькийны укыганда шуларга (мещан һәм мещанкаларга. М. Г.) нәфрәтем уяна», дип язуы, бер яктан, аның пролетар язучы әсәрләре белән яхшы таныш булуын күрсәтсә, икенчедән, Тукайның үзенең аннан идея йогынтысы алуын тануы да иде. Ул Горькийны иң яраткан язучысы итеп санады. Л. Н. Толстой вафаты уңае белән язылган «Мөбарәк тәсбих өзелде» нәсерендә дә Тукай ул елларда Италиядә яшәгән Горькийны бу югалту уңаеннан тирәннән борчылучы язучыларның берсе итеп күрсәтте.

Икенче бер классигыбыз Ш. Камал исә М. Горькийны үзенең укытучысы итеп санады. Аның Горький әсәрләре белән беренче очрашуы 1903 елларга туры килә. Күмер шахталарында, Каспий диңгезе буендагы балык промыселларында эшләп йөргән вакытларында ук ул «Макар Чудра» исемле хикәяне кулга төшереп укый. Бу әсәр аның күңелендә тирән эз калдыра. Соңыннан, иҗат эшенә керешкәч, без Ш. Камалның ничек М. Горький иҗаты йогынтысында үсә барганын күрәбез.

Шул рәвешчә Горький безнең революцион-демократик язучыларыбызның иҗатлары үсешендә зур таяныч булып торды. Ш. Камал һәм Г. Ибраһимовларның тарихи вакыйгаларга багышланган зур полотнолы роман язуларын да аның иҗаты йогынтысыннан башка күз алдына китереп булмый.

Үз чиратында М. Горький татар язучылары һәм журналистларының иҗатларын даими рәвештә күзәтеп бара. 1905 ел революциясеннән соң аларның ирешкән уңышлары турында рус матбугатында беренче тапкыр

М. Горький язып чыга. 1911 елда ук инде «Үзлегеннән өйрәнгән язучылар турында» дигән мәкаләсендә ул украин һәм белорус әдәбиятының тиз күтәрелүен әйтә дә, татар әдәбиятының да шундый ук уңышларына игътибар биреп: «Россиядә татар матбугатының һәм әдәбиятының тиз үсүен, Казанда... Уфада, Бакуда татар интеллигенциясенең культура эшчәнлеген күрсәтеп үтәм... Бу — кичәге көн күренеше; моннан ун ел элек ул мөмкин булмаган булыр иде» [1], — дип язды.

Татар әдәбиятында һәм публицистикасында яшь талантларның үсүен М. Горькийның зур игътибар белән күзәтүе, билгеле, язучының шәхси симпатиясе нәтиҗәсе генә түгел. Моның иҗтимагый характердагы тирәнрәк тамырлары бар. Беренче рус революциясеннән соң реакция дулкыны интеллигенциянең күп өлешен куркыткан бервакытта, Горький әдәбияттагы реакцион көчләргә каршы көрәштә төрле милләт халык массалары арасыннан үсеп чыккан яшь язучыларның яңа, сәламәт иҗатына таянды. Ленинның һәр милли культурада ике культура булу турындагы тәгълиматына таянып, ул Октябрь революциясе алдыннан рус һәм башка милләт культураларының прогрессив көчләрен бергә җыярга һәм тупларга омтылды. Үзенең оештыру эшендә Горький пролетар интернационализм позициясендә торды, «Русьны җыю» нинди дә булса милләт культурасын гегемон итү максатын куймый һәм куймаска тиеш, ул киләчәктә тигез хокуклы кабиләләрнең тыгыз союзы булып үсәчәк, дип күрсәтте.

Әдәби йогынтыны бер яклы гына түгел, бәлки үзара мөнәсәбәттә, үзара тәэсир итешү яссылыгында өйрәнү кирәклегенә М. Горький һәрвакыт басым ясап килде. 1911 елда татар язучыларының берсенә язган хатында ул болай диде: «Мне приходит все в голову такая мысль: хорошую услугу оказал и русским, и татарам, тот татарин, который взялся бы проследить, как влияло соседство татар на русский народ в его представлениях о жизни» [2].

Татар язучылары һәм татар әдәбияты белән рус җәмәгатьчелеген таныштыру идеясен дә М. Горький күтәреп чыга. Ул 1909 елда ук Г. Тукай шигырьләрен русчага тәрҗемә иттерү турында тәкъдим кертә, 1912 елда татар язучыларының әсәрләреннән русча җыентык чыгарырга планлаштыра һәм шул турыда аларның үзләренә хәбәр итә. Италиядә яшәгәндә дә Горький шул кызыксынуын дәвам иттерә. 1912 елның августында Капридан В. Вересаевка язган хатында түбәндәге сүзләр бар: «...Себер, белорус һәм украин язучылары, латыш һәм татар язучылары әсәрләренең җыентыкларын бик тиз оештырырга булыр иде. Шулай ук грузин, әрмән, фин һ. б. милләт язучыларының җыентыкларын төзү дә кыен булмас.

Бу эш... тулысынча үз вакытында эшләнгән бер эш булыр иде... Яхшы теләк белән эшләнгән һәм кирәкле бу эш рус әдәбиятының ... абруен... ныгытыр иде».

Мондый җыентык төзелә. М. Горькийның кулъязмалары архивында татар әдәбияты турында Нәҗип Думави тарафыннан язылган бер очерк саклана. Аны Алексей Максимович үз кулы белән редакцияләп чыккан. Шунда кертелгән редакцион төзәтмәләр бөек әдипнең татар тормышын, тарихын һәм әдәбиятын никадәр тирән белүе һәм нечкә аңлавы турында сөйлиләр. Шул очеркны редакцияләгәндә ул татар язучыларының берсенә хат язып, К. Насыйри, Ш. Мәрҗанилэр турында материал өстәүне, мәгърифәтче, тарихчы, журналист Р. Фәхретдиневнең биографиясенә караган һәм нинди газета-журналларда эшләве турындагы материалларны да җибәрүне сорый [3].

---

[1] Горький М. «О литературе», М., 1953, 123 бит.
[2] Горький и литература народов Советского Союза. Ереван, 1970, 482—486 битләр.
[3] Горький М. архивы, ПГ-РЛ, 17—22—2.

Капитализм һәм патша хөкүмәтенең кысуы шартларында Горькийның бу изге теләкләре — татар әдәбияты җыентыгын рус телендә чыгарып, киң җәмәгатьчелекне таныштыру планнары тулысы белән тормышка ашырылмый. Шулай да ул эзсез калмый. М. Горький татар әдәбияты, матбугаты, театры торышы турында үзе редакцияләгән бер очеркны 1911 елда «Современник» журналына җибәрә. Шул елның январенда «Современник» редакторына язган хатында ул очеркны: «Очень интересно, никому неведомо. Ново!»[1] — дип бәяли, басарга тәкъдим итәм, ди. Һәм очерк «Современник» журналының 1911 ел, 4 нче санында басылып та чыга.

Соңрак Тукай шигырьләрен тәрҗемә итү турындагы тәкъдим дә гамәлгә аша. 1914 елда Лазаревский институты тарафыннан чыгарыла торган «Көнчыгыш җыентыгы»ның бер санында «Мәхәббәт», «Өзелгән өмид», «Шүрәле», «Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре», «Мөбәрәк тәсбих өзелде» дигән әсәрләр, шунда ук шагыйрь турында кыска гына биографик белешмә басыла.

Тукайның авыр шартларда һәлак булуын, аның реакция көннәрендә кичергән фаҗигасен дөрес бәяләүче кеше дә М. Горький булды. Ул язучы Сергеев-Ценскийга, «Өзелгән өмид» шигырен истә тотып, түбәндәге юлларны яза: «Сез вәгазьчеләр художникларның бугазларыннан алалар, дип зарланасыз. Бу дөнья художниклар өчен түгел,— анда аларга һәрвакыт кысынкы һәм уңайсыз булды, — шуңа күрә аларның роле мактаулырак та һәм батыррак та. Ачлыктан һәм чахоткадан үлгәндә, казан татарларыннан бер шагыйрь:

*«Очты дөнья читлегеннән*
*Тарсынып күңлем кошы».—*

дип, бик шәп әйткән. «Очты» сүзенең кабатлануында (русча тәрҗемәсендә «очты» сүзе ике тапкыр кабатлана. — М. Г.) мин шатлык тавышы ишетәм. Ләкин мин үзем, әлбәттә, яшәү шатлыгын артыграк күрәм: яшәү бит ул бик тә кызыклы нәрсә!..» [2]

Рус классик әдәбияты үрнәкләрен тәрҗемә итүдә шактый күп эшләгән Солтан Рахманкулов 1909 елны М. Горькийның «Дружки» исемле хикәясен «Ике сукбай» исеме белән бастырып чыгара. Соңрак 1914—1915 елларда Г. Камал — «Тормыш төбендә», Г. Кәрам (Габдрахман Рәхматуллин) «Мещаннар» пьесаларын тәрҗемә итәләр.

* * *

А. М. Горькийның рухландыручы буларак зур йогынтысы татар совет әдәбияты матбугаты һәм сәнгатенең формалашуында аеруча ачык сизелә. Күренекле революционер М. Вахитов җитәкчелегендә чыккан «Кызыл байрак» газетасы үзенең беренче санында ук Горькийның «Иптәш» исемле нәсерен татарча бастырды. Октябрь революциясенә хәзерлек елларында бу әсәрнең татар теленә тәрҗемә ителүе бик әһәмиятле иде, әлбәттә.

Татар артистлары да Бөек Октябрь социалистик революциясенә әзерлек көннәрендә Горький әсәрләрен сәхнәгә кую өстендә эшләделәр. Бу хакта 1917 елның 15 октябрендә «Кояш» газетасында түбәндәгечә белдерелә: «Большой театр: Г. Кариев идарәсендә татар драмасы. Җомга көн 20 нче октябрьдә... «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан спектакль булачак. Тамашага куеладыр: татар сәхнәсендә беренче мәртәбә

[1] Юнович М. М. Горький в борьбе за равенство и дружбу народов. М., 1957, 98 бит.
[2] Горький М. «Әдәбият турында хатлар». М., 1957, 341 бит.

яңа әсәр: «Мещаннар». Драма 4 пәрдәдә, бөек мөхәррир М. Горький әсәре. Бу әсәрне труппа гаять җитди хәзерлек белән уйнаячак. Уйнаучылар: Синаева, Болгарская, Кариев, Шамиль...»

Икенче бер игъланда спектакльнең Мөселман социалистлар комитеты үтенүе буенча 25 октябрьга күчерелүе әйтелә: ә соңыннан аның билгеләнгән көнне булмый калуы гадәттән тыш вакыйга, ягъни революция җиңгән көндә урамнарда барган көрәш белән аңлатыла. Озакламый бу мәшһүр әсәр татар сәхнәсендә беренче мәртәбә уйнала. Димәк, татар артистлары Бөек Октябрь революциясеннән соң сәхнәгә беренче мәртәбә Горький әсәрләре белән чыгалар. Буржуаз интеллигенциянең саботаж ясарга маташкан вакытларында алдынгы татар интеллигенциясе вәкилләренең бу адымы, һичшиксез, мактаулы күренеш иде.

1928 елда Горький тагын бер мәртәбә Казанга килә. Татарстан хезмәт ияләре, язучылар, укучы яшьләр вәкилләре үзләренең сөекле язучыларын, якташларын, Кама тамагы пристанена кадәр барып каршы алалар. Язучы Кави Нәҗми: «Ул атнаны бөтен Казан Горький белән яшәде, ике сүзнең берсе аңа багышланды»,— дип искә ала. Горький, Казанда аз гына торса да, завод-фабрикаларда, уку йортларында, газета редакцияләрендә һәм башка культура учреждениеләрендә була. Казанның Зур театрында оештырылган тантаналы җыелышта речь белән чыга:

«Минем университетларым» китабында минем биредә, Казанда ничек яшәвем турында сөйләнә. Чынында исә, мин Казанда әсәремдә язылганга караганда күбрәк ачы минутлар кичердем. Ләкин яман яхшысыз булмый. Бүген инде мин Казандагы барлык кичергәннәрем йөз өлеше белән түләнде... Элек мин алар турында хыяллана гына алган кешеләр — хәзер инде яшиләр, эшлиләр, сөйләшәләр, бөек эшләрне иҗат итәләр... Сез үз хезмәтегезнең бөеклеген үзегез сизмисез, чөнки сез аны көн саен эшләп торасыз. Сезнең ихтыяр белән дөнья үзгәртелеп корыла, сезнең ихтыярыгыз кешеләрнең алга китүенә комачаулый торган барлык киртәләрне бетерәчәк».

Бөек әдипне күрү бәхетенә мин дә ирештем. Без ул чакта югары мәктәпләргә — институтларга хәзерлек курсларында (татрабфакта) укый идек. Рус әдәбияты буенча дәресләр барганда Алексей Максимович ишекне ачып, рөхсәт сорап, класска керде. Без аякка бастык. Шунда Горький кулы белән безгә утырырга ишарә итте һәм укытучыбыз доцент Неболюбовтан дәресне дәвам иттерүен үтенде. Ун-унбиш минут күзәтеп утырганда, татар эшче-крестьян яшьләренең укытучыга биргән җавапларын тыңлаганда, һичшиксез, бөек гуманист үзенең күп еллардан бирле көткән өметләренең чынга ашуын, ягъни барлык милләт халыкларына белем алырга бертигез мөмкинлекләр бирелгән көнне үз күзләре белән күреп куангандыр. Моны интернациональ язучының күз карашлары әйтеп тора иде.

Звонок булгач, ул, укытучыга рәхмәт әйтеп, безгә барыбызга сәламәтлек һәм уңышлар теләп, саубуллашу билгесе итеп, алдагы берничә укучының иңнәреннән сыйпый барды да ишеккә борылды. Без озатып калдык. Ләкин аның якты образы гомергә йөрәгебездә урнашты. Мин кулыма каләм алып яза башлагач, тәүге мәкаләләремнең берсен сөеклебез Горькийга багышлап язарга омтылуым да шуннан килә иде.

Горький Казанда булган чакта Кави Нәҗми аңа «Шобага» хикәясенең русча тәрҗемәсен бүләк итә. Мәскәүдән язган хатында Горький: «Әгәр дә рөхсәт итсәгез, мин Сезгә гадирәк язарга киңәш бирер идем. Чын матурлык һәм акыллылык һәркайчан гадилектә», — дип киңәш итә.

Шул ук елда Шамил Усманов та бөек пролетар язучы белән бәйләнешкә керә, аңа әсәрләрен җибәрә, хатлар алыша. Горький архивында Ш. Усмановның «Смерть подпоручика Данилова» һәм «Отступление» дип исемләнгән әсәрләренең кульязмалары саклана. Бөек язучының керткән

редакцион төзәтмәләренә караганда, аның кульъязмаларны гаять игътибарлы укыганлыгы күренә [1].

Горький татар язучыларына тормышны тирәнрәк өйрәнергә киңәш бирә. Аның тәкъдиме буенча бер төркем татар язучылары һәм журналистлары (К. Нәҗми, Ш. Камал, К. Тинчурин, Һ. Такташ, Г. Нигъмәти, М. Гали, Г. Кутуй, М. Әмир һ. б.) 1929 елның җәендә көньяктагы республикаларда һәм Украинада сәяхәттә булалар. Әйләнеп кайтканда Мәскәүдә Горький аларны бик җылы кабул итә. Безнең язучылар хакыйкатьнең үзе кебек бик тә гади Горький белән сөйләшә торгач ачылып китәләр, үзләрен борчыган һәм кызыксындырган мәсьәләләр турында киңәшләшәләр. Мирсәй Әмир шул очрашуда бөек язучының биргән киңәшләрен түбәндәгечә хәтерли: «Ул безгә, татар язучыларына, үзебезгә иң таныш булган тормыш турында, Татарстан тормышы турында язарга кушты. Татарстан хезмәт ияләренең культурасын күтәрүгә ярдәм итүне, иҗатыбызның үзәген татар хезмәт ияләрен социалистик рухта тәрбияләү эшенә юнәлдерүне безнең алдыбызга төп бурыч итеп куйды» [2].

Алдынгы татар язучылары бу кыйммәтле фикерләрне, әһәмиятле киңәшләрне истә тотып иҗат иттеләр һәм нәтиҗәдә, чыннан да, татар әдәбиятының гына түгел, күпмилләтле совет әдәбиятының үсешен күрсәткән «Матур туганда», «Язгы җилләр», «Намус», «Сүнмәс утлар», «Гади кешеләр» кебек күренекле романнар бирү дәрәҗәсенә күтәрелделәр.

Шул очрашуда катнашкан Г. Кутуй, Горькийның ни дәрәҗәдә игътибарлы булуына сокланып, түбәндәгечә язды: «Татар әдәбияты белән болай да таныш булган Горькийның татар культурасына мәхәббәте һәм аны тагын да күбрәк белергә тырышуы гаять зур иде. Татар җырларын яратып тыңлавы әле дә хәтеремдә. Тәнәфес вакытында банкетта: «Татар халкының талантлы Тукае бар», — дип кайта-кайта сөйләде. Шулай ук югары бәяне ул соңыннан (татар язучылары Москвада Максим Горькийда кунакта булганда) татар телендә шигырьләрен тыңлаганнан соң Һади Такташка да бирде» [3].

1932 елда А. М. Горькийның кырык еллык хезмәт бәйрәме уздырыла. Бөтендөнья прогрессив кешеләре белән берлектә, Татарстан хезмәт ияләре дә бу датаны зур шатлык белән билгеләп үтәләр. Газета һәм журналларда аңа багышланган күп кенә мәкаләләр басыла. Бөек әдипнең тормышы һәм иҗатына караган иң әһәмиятле хезмәтләр һәм В. И. Ленинның «Максим Горький турында» дигән мәкаләсе тәрҗемә ителә.

Тагын бер елдан соң М. Горький әсәрләренең алты томлыгын тәрҗемә итү эшенә керешелә. Бу кирәкле һәм җаваплы эшне башкаруда күренекле татар язучылары катнаша. Шулар арасында Ш. Камал, И. Гази, М. Әмир, К. Нәҗми, А. Шамов, М. Максуд, Ф. Хөсни, Ә. Исхак, С. Фәйзуллин, А. Гомәр һәм аеруча С. Әдһәмова зур активлык күрсәтәләр. Язучылар гына түгел, татар артистлары да әдипнең драматик әсәрләрен тәрҗемә итүдә үз өлешләрен кертәләр (З. Солтанов, Х. Сәлимҗанов һ. б.), һәм аның «Дошманнар», «Варварлар», «Соңгылар», «Васса Железнова» кебек драмалары татар сәхнәсендә гаять уңыш белән бара. Артистлар З. Солтанов, М. Мутин, Ф. Ильская, Х. Әбҗәлилов әсәрләрнең идея эчтәлеген тамашачыга зур осталык белән ачып күрсәтәләр. Безнең тамашачыларның аларны ничек кабул итүләре турында СССР язучыларының Беренче съездында (1934 ел) ясаган чыгышында К. Тинчурин болай дигән иде: «У нас, в Татарском государственном академическом театре, ставятся пьесы Горького... Их ставят так, что с большим удовольствием смотрятся нашими зрителями и воспринимаются ими не как пьесы дру-

---

[1] Горький М. архивы, КГ-Н п/а 24—6.
[2] «Яңалиф» журналы, 1932, 8 нче сан.
[3] «Кызыл Татарстан», Казан. 1941, 18 июнь.

гой национальности, а как произведения, дающие нам живую жизнь нашей общей социалистической стройки» [1].

М. Горький иҗаты үрнәкләрен тәрҗемә итү процессында татар совет язучыларының үзләренең дә рухи яктан үскәннән-үсә баруларын күрәбез. Бу хәл әсәрләрнең тирән мәгънәләрне эченә алган тормыш энциклопедиясе булуларыннан килә. Горький язучыларыбызның, артистларыбызның художество зәвыкларын үстерүгә, аларның әдәбият һәм сәнгать осталары булып формалашуларына зур ярдәм итте.

А. М. Горькийның турыдан-туры ярдәме белән 1930 елда Мәскәүдә «Альманах татарской литературы», 1931 елда «Сборник татарской литературы», 1933 елда «Современная татарская литература» дип исемләнгән җыентыклар дөнья күрә. Димәк, татар әдәбиятының киң аренага чыга башлавы да бөек әдип ярдәмендә була.

А. М. Горький илебез халыкларының экономикасында һәм культурасында булган үзгәрешләрне игътибар белән күзәтеп барды. СССР халыкларының үзара дуслыгы үсә баруына шатланып, Татарстан республикасының унъеллыгы уңае белән ул Италиядән болай дип язды: «...Мин хезмәт иясе татар халкының, рус эшче халкы белән бергәләп һәм дус булып, иркле рәвештә үз тормышын төзү хокукы булган вакытка кадәр яшәвемә шатланам.

Татар республикасы үзенең ун ел яшәвен бәйрәм итә. Хезмәт халкының энергиясе белән тудырыла торган тарихның бу яшүсмеренең баһадир булып үсүенә мин нык ышанам.

Минем бу ышануымны аек, чисталыкны яратучан, хезмәт сөючән, үзенең максатына ирешүдә эчке мөлаемлыкны зур түземлек белән бергә кушарга теләүчән татар халкы турында кечкенәдән үк бөтен белгәннәрем ныгыта. Минем бу ышануым Татарстан республикасының культура үсеше турында белгәннәрем белән дә раслана.

Яшәсен мин яраткан татар халкының Совет Социалистик республикасы!» [2]

А. М. Горький иҗаты кешелекнең иң бөек идеалы — коммунизм төзү өчен, илебезнең башка халыклары белән берлектә, Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә көрәшүче бөек рус халкының тарихи роле белән аерылгысыз бәйләнгән. Бөек язучының бөтен тормышы, партиягә һәм халыкка зур ышаныч белән сугарылган тормышы — художникның Ватанга үзен-үзе аямый тугрылыклы хезмәт итүенең матур үрнәге. Иҗатының халыкчанлыгы, интернациональ рухта булганы өчен дөньяның барлык милләт кешеләре бөек әдипкә тирән ихтирам саклыйлар. Горький бүген дә безнең белән.

---

[1] Стенографический отчет Первого Всесоюзного съезда советских писателей. М., 1934, 455 бит.
[2] «Коммунист Татарии», 1958, 3 нче сан, 33 бит.

**Маргарита Лопатина,**

Казандагы А. М. Горький музееның фонд секторы мөдире

# ХӘТЕР СӨЙЛИ...

Казанда яшәгән елларын М. Горький түбәндәгечә искә төшерә: «...һәр көн минем күңелдә кечле, үзәккә үткеч тәэсир калдыра». Менә шушы көннәрне ничек күз алдына китерергә? Бөек язучының рухи тууы турында экспонатлар теле белән ничек тулы һәм тәэсирле итеп сөйләргә? Әлеге сораулар безне — музей хезмәткәрләрен һәрдаим борчый, һәм алар музейның «хәтер офыклары»н киңәйтү буенча туктаусыз эзләнергә мәҗбүр итәләр.

Бөек якташыбыз М. Горькийның «тормыш университетлары»н өйрәнү егерменче елларда ук башлана. Туган ягыбызның тарихын өйрәнүче Н. Калинин тарафыннан Казанның 3 нче мәктәбе каршында оештырылган түгәрәккә йөрүчеләр Соррентода дәвалanучы Алексей Максимовичка хат җибәрәләр, шәһәр планында аның үзенә бәйле урыннарны билгеләвен үтенәләр. Язучы үзенең җавап хаты белән бергә автографлы фоторәсемен дә җибәрә. Шушы план нигезендә Н. Калинин Казанда Горькийга бәйле 15 ләп урынның тасвирламасын эшли.

Менә Кече Галактионов урамындагы ярым подваллы 24 нче йорт. Кайчандыр аңа Беляев хуҗа булган. Революцион-народник А. С. Деренков әлеге йортның подвалын пекарня итеп файдаланырга алып тора. Яшерен максатларны күздә тотып ачылган пекарняда алынган табыш түгәрәк ихтыяҗлары өчен билгеләнгән. Биредә Пешков пекарь ярдәмчесе булып эшли һәм нәкъ менә шушында ул Казанның революцион рухлы яшьләре белән аралаша башлый. Әлеге йорт шактый ук яхшы сакланган. Шуңа күрәдер дә биредә, бөек пролетар язучының истәлеген мәңгеләштерү максатыннан, музей оештыру теләге туа. һәм 1938 елның 7 апрелендә Казан шәһәр Советы башкарма комитетында музей ачу турында карар кабул ителә. Бинаны фәнни реставрацияләү эшләре башлана. Н. Калининның өлкән яшьтәгеләр, аерым алганда, элек пекарь булып эшләгән кешеләр белән сөйләшүе музей өчен кыйммәтле мәгълүматлар китерә. Узган гасырның сиксәненче елларында чыккан газеталарда, бигрәк тә «Волжский вестник»та пекарняларда эшләү өчен гаять авыр шартлар булуы, икмәк пешерүчеләрнең баш күтәрүләре турында сөйләүче хәбәрләр шул чорны мөмкин кадәр тулырак күзалларга ярдәм итәләр.

Язучының башка музейларыннан аермалы буларак, Казанда Горькийга багышланган экспозицияне төзүчеләргә шул яктан кыен булды: тарихи документлар, фоторәсемнәр һәм әдипнең «кул җылысын» саклаган башка әйберләр бик аз иде. Дөресен генә әйткәндә, Алексей Пешков Казанда яшәгән елларда әле Максим Горький түгел иде, һәм ул калдырган эзләрнең шактые вакыт тарафыннан җуелган. Менә шуңа күрә, музей оештыручылар экспонатларны бөртекләп җыярга мәҗбүр булдылар. Беренче коллекцияне язучының Мәскәүдәге музееннан җибәрелгән материаллар тәшкил итте. Фоторәсемнәрдә — турыдан-туры А. Пешков белән аралашкан кешеләр: А. С. Деренков, Г. А. Плетнев, Н. Е. Федосеев, Н. В. Евреинов... Алар арасында Алексей Максимовичның 1887 елда Казанда эшләнгән беренче фотосы да бар. Өлкән яшьтәге О. В. Праксин сөйләвенчә, А. Пешков Зур Проломный (хәзерге Бауман) урамында урнашкан Ундорский фотографиясендә рәсемгә төшкән.

Әллә ни бай булмаган менә шушы коллекция җирлегендә 1940 елның 12 мартында музейның беренче «чираты» ачыла. Тантанага А. С. Деренков пекарнясында Алешаның эшләгәнен үз күзләре белән күргән Надежда Щербатова да чакырыла. Менә шул көннән башлап музейда фәнни-тикшеренү һәм эзләнү эшләре киң колач җәя. Ерак Себердә А. С. Деренковның яшәгәнлеге мәгълүм була. Аның истәлекләре буенча пекарняны торгызу эшләре башкарыла, Алексей Максимовичның Казан чорына караган кайбер яңа фактлар ачыклана. Пекарня яңа табылган көнкүреш җиһазлары, савыт-сабалар, эш кораллары белән баетыла. А. С. Деренковның никдидер могҗиза белән сакланып калган самовары, реставрация вакытында табылган чәйнек һәм лампа... Болардан тыш,

Андрей Степанович музейга үзенең кайбер шәхси әйберләрен һәм фоторәсемнәр дә бүләк итте.

Кырыгынчы һәм илленче елларда музей хезмәткәрләре төп игътибарны А. Пешковның революцион юлда торган дусларын һәм танышларын ачыклауга юнәлдерделәр. Музейның элекке директоры М. Елизарова Н. Евреинов, Г. Плетнев, И. Картиковский, В Плюшковның туганнарын эзләп тапты. Музейга яңадан кыйммәтле материаллар алынды. Мәсәлән, А. Пешковны университетка керергә димләгән гимназист Н. Евреинов туганнары — сирәк очрый торган китаплар һәм документлар, ә булачак язучыны революцион яшьләр даирәсенә алып кергән Г. Плетневның кардәшләре Гурийның төрмә кимендә төшкән фотосын һәм аның Петербург төрмәсендә каен тузына ясаган рәсемен җибәрделәр.

Шушы ук кырыгынчы елларда музей бөек пролетар язучының хатыны Е. П. Пешкова белән элемтә урнаштырды. Ә Екатерина Павловна экспозицияне тагын да баетырга ярдәм итте. Музей хәзинәсенә язучының шәхси әйберләре, шул исәптән М. Горькийның 1928 елда Казанга киеп килгән костюмы, плащы һәм зәңгәр күлмәге, китапханәсеннән күп кенә китаплары һәм йөзләгән фоторәсем алынды. М. Горькийның Мәскәүдәге музее, СССР Фәннәр академиясенең М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты каршындагы архив хезмәткәрләре дә даими ярдәм күрсәтәләр. Һәм, ниһаять, язучының бөтен гомерен һәм иҗатын колачлаучы экспозиция төзер өчен җирлек тудырыла.

...Язучының балалык еллары турында сөйләүче беренче зал экспонатлары арасында Түбән Новгород чиркәвендә тутырылган метрика кенәгәсенең күчермәсе игътибарны аеруча тартып тора. Ул Алексей Максимович Пешковның туу датасын төгәл раслый: 1868 елның 16 (28) марты... Икенче бер экспонат безгә А. Пешков тормышының Казан чорына кагылышлы гыйбрәтле вакыйга турында сөйли. Бервакыт яратмаган кеше белән ярәшкән сәүдәгәр кызы — унтугыз яшьлек Дарья Латышева үзен-үзе атып үтерә. Яшерен түгәрәккә йөрүчеләрнең берсе аның истәлегенә шигырьләр язарга чакыра. Бер сәгатьтән соң экспромтларны укып карыйлар һәм шулар арасыннан дүрт кыска шигырьне сайлап алырга һәм, «Студент» имзасы куеп, аларны Гурий Плетнев аша «Волжский вестник» газетасына җибәрергә карар кылына. Сайлап алынган шигырьләр арасында А. Пешков тарафыннан язылган дүртьюллык та була һәм ул 1885 елның 26 гыйнварында басылып та чыга.

*Как жизнь твоя прошла, о, кто ее не знает?*
*Суровый деспотизм, тяжелый, страшный гнет...*
*Кто в этом омуте не плачет, не страдает?*
*Кто душу чистую невинной сбережет?*

Булачак бөек язучының беренче иҗат җимеше, матбугатта басылган беренче әсәре менә кайчан туган.

«М. Горький — бакчачы»... Рәссам Б. Житковның әлеге картинасы үзе бер хикәятне күз алдына китерә. 1885 елның маенда А. Пешков генеральша Корнэга урам себерүче һәм бакчачы булып яллана. Иске Комиссариат (хәзерге Гоголь) урамында урнашкан йорт хуҗасы — тупас холыклы тол хатын (милләте буенча француз) русча начаррак сөйләшә, ә менә сүгенүне бик оста булдыра торган була. Корнэ үзенең бакчасына еш кына салмыш хәлендә чыга һәм мәгънәсез боерыклары белән Алексейга бәйләнә. Үзендә фатирда торучы ятим кызларны бакчадан куып чыгарырга куша, аларны берниндә сәбәпсез мәсхәрәли. Ә беркөнне Алексей Пешков бу хәлгә түзеп тора алмый, кызларны яклап, генеральша Корнэга ташлана... Шуннан соң инде эштән китәргә мәҗбүр була. Ә ул башта бирегә озак эшләргә ниятли. Бакчаны тәртипкә китерә, соңгы акчасына бакчачылык турында китап сатып ала, аны җентекләп укып чыга, бик матурлап чәчәк түтәлләре ясый, агач үрентеләре утырта. Әлеге бакчада Алексей Максимович тарафыннан утыртылган агачлар хәзер дә саклана...

Менә элекке шәһәр театры фоторәсеме һәм кызыклы бер хәл турында сөйләүче газета кисемтәсе. Әле үзара таныш булмаган Пешков белән Шаляпин, үзләренә вакытлыча эш табу максатыннан, хорга язылырга баралар. Алексей сынауны уза, ә Федорның тавышын ... ошатмыйлар. Чынлыкта исә әлеге сынау булачак бөек җырчының яшүсмерләрдә күзәтелә торган «тавыш сыну» вакытына туры килә.

...1887 елның 14 декабрендә Казанның «Волжский вестник» газетасында түбәндәге-

чә хәбәр басылып чыга: «12 декабрьда, кичке сәгать 8 дә Казанка елгасы янындагы Подлужный урамында Нижегород цеховое Алексей Максимович Пешков үз-үзен үтерү теләге белән револьвердан үзенең сул янтыгына аткан. Пешков шунда ук земская больницага озатылды, анда аңа медицина ярдәме күрсәткәндә, врач яраның куркынычлы булуын ачыклады. Табылган язуда Пешков үзенең үлемендә берәүне дә гаепләмәүне үтенә».

Шундый фаҗигале адым атларга А. Пешковны нинди сәбәпләр мәҗбүр итә?

Кара реакциянең 1887 елы Алексей Максимович өчен аеруча авыр ел була. Шәһәрдә аның белән аралашкан күп кенә студентлар, шул исәптән эшче Н. Рубцов кулга алына. Революцион эш өчен файда китерү максатында үз-үзеннән канәгать булмау да, кадерле әбисе Акулина Ивановнаның үлеме, Мария Деренкованың Алексей мәхәббәтенә карата битарафлыгы да егетнең рухи кризисын көчәйтә. Хәтта көзге кара яңгырлар да аның бәгырь итен ашый шикелле. Күзгә күренми торган үрмәкүч җепләре, әйтерсең, бөтен дөньяны урап алган. Ул үткәннәрне, әбисен, күңелле итеп урманда йөрүләрен, укыган китапларын искә төшерә. Болары күңелне иркәли, ә калганнары аны көзге яңгырдай изә. Кайчакларда ничек булса да күңел ачасы, шәһәр бакчасына гына булса да барып кайтасы килә. Әмма сәламә киемле Пешковны бакчага кертмиләр. Бакча бары тик «чиста» кешеләр өчен генә. Төннәрен Алексейның кечкенә бүлмәсендә моңлы авазлар яңгырый — күңелсезлектән ул скрипкада уйнарга өйрәнә башлый. Һәм беркөнне егет базарга юнәлә, әч сумга Тулада эшләнгән револьвер сатып ала. Менә ул 12 декабрь кичендә Казанканың текә ярына таба атлый. Билгеләнгән урынга килеп җиткәндә мәче баласы белән «сөйләшеп» утыручы төнге каравылчы Мостафа Юнысовны очрата, каравылчыдан күшеккән миаубикәне куенына тыгып җылытуын үтенә дә үз юлыннан китеп бара. Һәм берничә минуттан соң ату тавышы ишетелә. Мостафа аны елгага төшә торган тау итәгендә, кар өстендә яткан хәлендә күрә һәм, тиз генә извозчик табып, каты яраланган егетне больницага озата...



*А. С. Деренковның әлеге подвал-пекарнясында Алексей Пешков 1886 елда пекарь ярдәмчесе булып эшләгән. А. М. Горький музее шушы йорт бинасында урнашкан.*

Чирек гасырдан соң А. М. Горький шундый адымга этәргән сәбәпләрне «Макарның тормышында булган бер вакыйга» исемле хикәясендә аңлатып бирде. Бу адым — очраклылык, ләкин фаҗигале очраклылык иде. Әлеге вакыйга А. Пешковның гаять авыр «Университетлар» үтүен тагын бер мәртәбә исәртеп тора.

Экспонатлар сөйли. Менә 1928 елда чыккан роман-газетаның (№ 1) титул бите. Бу санда М. Горькийның Казанда яшәгән еллары турында сөйләүче «Минем университетларым» повесте басылган. Әнә 1928 елда төшерелгән фоторәсемнәр. Алар М. Горькийның соңгы мәртәбә Казанга килүе турында сөйлиләр...

Соңгы вакытта М. Горькийның татар әдәбияты белән бәйләнешен чагылдырган экспонатлар җыюга зур игътибар бирелә. Билгеле булганча, Алексей Максимович бу юнәлештә дә игелекле кайгыртучанлык күрсәткән. Күп кенә татар язучылары, аерым алганда, Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Гадел Кутуй, Сәрвәр Әдһәмова, Газиз Иделле, Габдрахман Минский һ. б. лар белән очрашкан һәм хат алышкан. «А. М. Горький пьесалары Казан театрлары сәхнәсендә» кебек тема буенча да материаллар туплана. «Горький һәм Шаляпин» коллекциясе дә елдан-ел байый. Күренекле совет язучыларының автографлы китаплары да музей хәзинәсенә өстәлә тора.

Тормыш агышы музей хезмәткәрләре алдына яңадан-яңа бурычлар куя. Бүгенге көндә музейны реконструкцияләү һәм яңарту өчен хәзерлек эшләре алып барыла. Шушы уңайдан экспозициянең барлык юнәлешләре буенча да яңа экспонатлар җыю эше киң җәелдерелде. Коллекцияләргә яңа әйберләр өстәлә. Мәсәлән, Анжеро-Судженскидан М. Горькийның А. Деренковка язган хатлары һәм революцион-народникның кайбер шәхси әйберләре алынды. Идел елга пароходчылыгы ветераннары узган гасырның сиксәненче елларында йөкчеләр тарафыннан файдаланылган «арка ыңгырчагы» китерделәр. Мондый җайланманы А. Пешков та кулланган. В. И. Ленин исемендәге үзәк китапханә (Мәскәү), М. Е. Салтыков-Щедрин исемендәге китапханә (Ленинград) М. Горькийның үзе исән чагында чыккан басмаларын, шулай ук Казан тарихына кагылышлы китаплар җибәрделәр. Ә Казанда яшәүче коллекционерлар шәһәребезнең XIX гасырдагы йөзен чагылдырган фотооткрыткалар, Алексей Максимовичның фоторәсемнәрен, фотоальбомнар, элекке заманда киелгән киемнәр, иске өй җиһазлары китерделәр.

Эзләнү дәвам итә. Музейның «хәтер офыклары» киңәйтелә.


## Сәрвәр Әдһәмова

# БӨЕК ЯЗУЧЫ РӘХМӘТЕ

Утызынчы еллар башында М. Горький әсәрләренең татар телендә беренче тапкыр алты томлыгын чыгару планлаштырылгач, «Ана» романын тәрҗемә итүне язучы Фәтхи Бурнашка тапшырдылар, ә «Балачак» повестен миңа тәкъдим иттеләр. Ул чакта әле минем бернинди тәҗрибәм дә юк иде диярлек. (В. Катаевның «Акча туздыручылар» («Растратчики») китабыннан башка әсәр тәрҗемә иткәнем юк иде.) Шулай да тәвәккәлләдем һәм «Балачак»ка тотынган вакытта бу эш минем язмышымда хәлиткеч борылыш ясарга, үземнең төп профессиям булган юристлыкны ташларга сәбәп булыр дип тә уйламадым. Шуннан соңгы бөтен гомеремне тәрҗемә эшенә һәм аның да күбрәк өлешен М. Горький әсәрләрен тәрҗемә итүгә бирермен дигән уй башыма да килмәгән иде.

Бөтенесе шул «Балачак»тан башланды. Аны тәрҗемә итәргә тотынып алдыннан мин, бу бөек язучының стилен, иҗат алымнарын аңларга тырышып, аның байтак әсәрен укып чыктым. Һәм шунда, барыннан да бигрәк, Горькийның кешегә мөнәсәбәте, аның бөтенләй эштән чыккан, тормыш төбенә төшкән бәндәләрдә дә нинди дә булса кешелек сыйфатлары күрә белүе һәм шуларны укучы күңеленә барып җитәрлек итеп күрсәтә белүе таң калдырды. Бу үзенчәлек аның кечкенә хикәяләрендә аеруча калку булып күренә.

Шунысы да үзенчәлекле: Горький бер ягы белән дә күзгә ташланып тормаган гади кешеләрнең дә күп очракта бик киң күңелле, олы җанлы булуларын күрә белә. Менә «Кечкенә-ә генә» дигән хикәя. Язучы ерак Себердәге авылларның берсеннән Киевтагы «изгеләр» каберен зиарат итәргә баручы карт белән карчыкны искиткеч дәрәҗәдә җанландырып күз алдына китереп бастыра. Патша хөкүмәте тарафыннан сөргенгә җибәрелгән кечкенә генә буйлы бер кыз аларда фатирда торган чакта үлеп киткән, һәм аны үз кызларыдай яраткан карт белән карчык хәзер шуның рухына дога кылдырыр өчен ничә мең чакырымлык юлга чыкканнар! Дулкынланмыйча укып булмый бу хикәяне.



*Әлеге фоторәсем А. М. Горький Казанга соңгы мәртәбә килгән вакытта, 1928 елның 5 августында «Красная Татария» газетасы редакциясендә төшерелгән.*

Аннан тагын шуны әйтергә кирәк: Горький әсәрләрен кабат укыган саен аларның әлек игътибар ителмәгән, абайламаган якларын күрәсең.

Миңа аның «Балачак», «Малайлыкта», «Минем университетларым» дигән автобиографик повестьларын һәм «Фома Гордеев», «Артамоновлар эше», «Хуҗа» кебек зур күләмле әсәрләре белән бер рәттән, байтак хикәяләрен (барысы 20 дән артык) татар теленә тәрҗемә итәргә туры килде. Эш барышында (бигрәк тә 30—40 нчы елларда) без, тәрҗемәчеләргә, байтак кыенлыклар да очрады. Бу эштә кулланырлык теоретик материал булмавы да өстәмә авырлыклар тудырды.

Кыенлыклар димәктән, «Артамоновлар эше»н тәрҗемә иткәндә мин андагы төрле йолалар белән бәйләнешле җырларны татарча ничек бирергә белми аптырадым. Мәсәлән:

*Ой, свату великому*
*На ступень ступить — нога сломить,*
*На другу ступить — друга сломить,*
*А на третью — голова свернуть,*

— дигән туй җырының үзенчәлеген тәрҗемәдә ничек сакларга? Озак уйлаганнан соң, бу хакта автор үзе нинди киңәш бирер икән дип, Алексей Максимовичка хат язсам да, язучыларның Беренче Бөтенсоюз съездына кызу хәзерлек барган чакта аның җавап бирергә вакыты булмавы гаҗәп тә түгел. (Ә минем ул хатны бик күп еллардан соң Казандагы Горький музее директоры М. Н. Елизарова язучының архив материаллары арасында күреп кайтты.)

1934 елның җәендә язучыларның Бөтенсоюз съездына баргач, ничек тә булса Горькийның үзе белән сөйләшеп булмасмы, дип тә өметләнгән идем. Ләкин бу теләккә ирешү шактый катлаулы булып чыкты. Горький — зур тарихи съездның җитәкчесе. Аны һәрвакыт делегатлар уратып алган була. Алар арасында чит ил язучылары да күп. Бөек язучы, магнит кебек, бөтенесен дә үзенә тарта иде. Шулай да, Уралдан килгән хатын-кыз язучы белән бергәләп (ул үзенең китабының икенче басмасын чыгартуда Горькийның ярдәм итүен сорамакчы иде), бәхетне сынап карарга булдык. Бер тәнәфес вакытында сәхнә артында Горький ял итә торган бүлмәгә, «Безне рәсемгә төшерергә чакырдылар», дигән булып үтеп кердек.

Керсәк, ни күзебез белән күрик, бүлмә уртасындагы озын өстәл янында уңлап кеше чиратка тезелгән. Барысы да Горький белән очрашырга тели.

Мин, үземне кызыксындырган мәсьәлә турында бу урында сүз кузгату мөмкин түгеллеген аңласам да, чыгып китмәдем. Үз чиратым җиткәч, батыраеп:

— Мин Сезнең әсәрләрне татарчага тәрҗемә итәм, Алексей Максимович, — дип, Горький белән исәнләштем. Ул, ягымлы елмаеп, русча «о» хәрефенә басым ясагандай итеп:

— Рәхмәт. Ә соң кыенмы тәрҗемә итү? — дип сорады.

— Җиңел түгел, Алексей Максимович, ләкин мин Сезнең әсәрләрне бик яратам һәм кулдан килгән кадәр тырышам.

Ул тагын бер тапкыр:

— Рәхмәт! — дип кулымны кысты. Шул арада минем белән бергә кергән хатын-кыз язучы, җитәр инде, мин дә сөйләшим, дигәндәй, кабыргама төрткәч, бер кырыйга тайпылдым.

Шул чакта Алексей Максимович белән озаклап сөйләшә алмасам да, бөек язучының рәхмәтен ишетү мине тагын да тырышыбрак эшләргә канатландырды.

## Һади Такташ

### Киләчәккә хатлар

ПОЭМАДАН ӨЗЕК

Бер чакны без шулай Горький белән
Бер мәҗлестә бергә утырдык.
Әллә ничек аның сул ягына
Туры килде минем урындык...
Горький безнең чорның зур әдибе,
Аның даны
Бөтен планетага таралган,
Ә мин үземне бер бик кечкенә
Кеше итеп сиздем аңардан...

Башта аның белән сөйләр өчен
Зур гакыллы сүзләр эзләдем,
Тирләп беттем...
Ә соңыннан инде түзмәдем,
Башта булган гади уйлар белән
Башлап алып киттем сүземне,
Ә бераздан яхшы ук акыллы бер
Кеше итеп сиздем үземне!..

## Роза Гарифҗанова,

А. М. Горький музееның өлкән фәнни хезмәткәре

# ХАТЛАРНЫ АКТАРГАНДА...

Биографы И. А. Груздевка 1928 елда Соррентодан А. М. Горький мондый хат җибәрә: «Хатларны актарганда, ...минем архивымда казыначак кешегә кызыгып куям». Чыннан да кызыгырлык та шул — язучының архивында кырык меңнән артык хат саклана. Шулар арасында Казаннан килгәннәре дә очрый.

Унҗиде яшьлек Семен Аджамов 1928 елда Алексей Максимовичка үзенең шигырьләрен җибәрә. Җавап көттерми. Соррентодан җибәрелгән хатында язучы яшь авторга мондый киңәшләр бирә: «һәркемнән дә өйрәнегез һәм беркемгә дә ышанмагыз. Шулай яхшырак. Сүз сәнгате осталарын укырга кирәк. Пушкинны укыгыз, Лермонтовны, Баратынскийны күбрәк укыгыз! Прозаикларны да укыгыз: Толстойны,

Лесковны, Чеховны һ. б. шундыйларны. Басылырга ашыкмагыз. Бу хәзергә сезнең өчен зыянлы...»

«Семен Аджамовка. А. М. Горький. Сорренто. 10.IV.28 ел». Яшь шагыйрьгә әнә шундый сүзләр язылган «Мои университеты» һәм «Исповедь» исемле китаплар да җибәрелә. М. Горькийның хаты аның Мәскәүдәге архивында, ә китаплар безнең музейда саклана. Экспозициядә әдипнең шәхси китапханәсеннән алынган китаплар шактый, ә менә автографлылары икәү генә. Менә шуңа күрә алар безнең өчен аеруча кадерле, һәм бу китаплар М. Горькийның Казан белән даими элемтәдә торуын тагын бер мәртәбә искәртәләр.

Бөек язучы белән очрашу яки хат алышу, гадәттә, һәркемнең күңелендә тирән эз калдырган. Алексей Максимовичның таләпчән, әмма рухландыргыч хаты яшь авторга үзенә күрә бер мәктәп булып хезмәт иткән, мәшһүр әдипнең «университетлары» яшьләрне халык тормышын тагын да тирәнрәк өйрәнергә чакырган. Әдәбиятка гражданнар сугышы фронтларыннан, завод һәм фабрикалардан килүчеләр, әлбәттә, бөек остаз киңәшләрен нур өстенә нур буларак кабул иттеләр. «Кызыл юл» ширкәтендә итекче булып эшләгән Семен Аджамов та шундыйларның берсе иде. Иң элек аның шигырьләре стена газеталарында күренгәләде. Тора-бара ул «Красная Татария» газетасы каршында эшләүче әдәбият берләшмәсенең актив членына әйләнде. Соңрак химия-технология институтының механика мастерскоена эшкә кучә, рабфакка йөри башлый, Мәскәүдәге редакция-нәшрият институтына (хәзер М. Горький исемендәге әдәбият институты) укырга керә. Журналист Н. С. Пигузова (хәзер Минскида яши) сөйләвенчә, ул үзенең белемен күтәрүгә бөтен көчен биргән. Аның шәхси китапханәсендә Л. Н. Толстойның үзе исән чакта чыккан сайланма әсәрләренең ике басмасы була. Яшь язучы Лев Николаевичның үз әсәрләрен редакцияләү алымын өйрәнә. Бик күп укый, кыскасы, Алексей Максимович киңәшләренә тугрылыклы булып кала.

Татарстан Язучылар союзы архивын өйрәнгәндә бер кызыклы документ табылды — Беренче Бөтенсоюз съездына хәзерлек көннәрендә төзелгән язучылар активы исемлеге. Укыйбыз: К. Нәҗми, К. Тинчурин, Ш. Камал, Х. Туфан... Баксаң, әлеге исемлектә Семен Аджамов та теркәлгән. Икенче бер документ — яңа гына оештырылган рус язучылары секциясе исемлеге (1935 елга карый). Исемлектә — 11 кеше. Алар арасында Б. Зернит, М. Бубеннов, А. Алдан кебек танылган язучылар да бар. Һәр исемлеккә С. Аджамов та кертелгән. Бу чакта ул «Красная Татария» газетасы хезмәткәре булган. «Молодость» альманахында «Төн аша» исемле повесте дөнья күргән, китабы басылуга әзерләнгән. Архив документларында күренгәнчә, С. Аджамов секция эшендә актив катнашкан, туку фабрикасы каршында эшләүче әдәби түгәрәкне җитәкләгән, үзенең каләмдәшләре һәм эшчеләр алдында иҗат отчетлары белән чыккан.


Бөек Ватан сугышы башлануга ук С. Аджамов фронтка китеп бара. Аны артиллерия расчеты командиры итеп билгелиләр. Казанга хатлар язып тора. Менә саргая башлаган фоторәсем. Без анда Семенны, үзе әйтмешли, «бөркетләр»е арасында күрәбез. 1943 елның июлендә язылган хатында ул үзенең Кызыл Йолдыз орденына тәкъдим ителүе турында хәбәр итә, ә соңрак партия сафларына алынуы һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүе хакында яза.

Днепропетровск шәһәрен азат иткәндә (1943 елның 18 октябрендә) Семен Никитович Аджамов батырларча һәлак була. Якташыбызның гәүдәсе Днепропетровск поселогы янындагы туганнар каберлегенә күмелә. Хәзер поселок мәктәбендә Сугышчан дан музее эшли; анда С. Аджамовның да фоторәсеме һәм аның турында сөйләүче документлар бар.

Бөек пролетар язучы А. М. Горькийның фатихасын алган С. Н. Аджамовның яшь гомере менә шулай өзелә. Алексей Максимовичтан иҗат кыюлыгына өйрәнгән (әмма иҗатта үзен тулысынча расларга өлгермәгән) ир-егет тормышта исә кыю һәм патриот булып кала алды.

# ИГЕЛЕКЛЕ КАЙГЫРТУ

«Мин һәрбер ярдәмгә, һәрбер эшкә әзермен...» Бөек пролетар язучы А. М. Горький тарафыннан әйтелгән әлеге сүзләрдә аның татар әдәбиятына карата мөнәсәбәте аеруча ачык чагыла. Чыннан да, ул күпмилләтле совет әдәбиятының лаеклы вәкилләре — татар язучыларына гомере буе игелекле кайгыртучанлык күрсәтте, һәм әдипләребез үз чиратларында әлеге ярдәмгә бөтен халыкларның уртак хәзинәсе булырлык әсәрләр иҗат итеп җавап бирделәр. Түбәндә без мәшһүр язучының хатларыннан, мәкаләләреннән һәм чыгышларыннан кайбер өзекләр тәкъдим итәбез. Аңлашыла ки, әлеге кайгыртучан сүзләр алдында каләм осталарыбыз үзләрен хәзер дә җаваплы итеп тоярга тиешләр.



*Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, А. М. Горькийның беренче мәртәбә Казанга килүенә 100 ел тулуга багышлап, бөек пролетар язучының безнең җирлеккә таянып язылган әсәрләре нигезендә «Һаваларда йолдыз»... исемле спектакль әзерләде. Пьесаның авторы һәм сәхнәгә куючы — ТАССРның халык артисты, режиссер Празат Исәнбәт. Максим һәм Коновалов рольләрендә ТАССРның атказанган артисты Илдар Хәйруллин һәм РСФСРның халык артисты, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ринат Таҗетдинов уйный.*

Россиядә татар матбугатының һәм әдәбиятының тиз үсүен, Казанда... Уфада, Бакуда татар интеллигенциясенең культура эшен күрсәтеп үтәм...

*1911 елда язылган «Үзлегеннән өйрәнгән язучылар турында» исемле мәкаләдән.*

...Себер, белорус һәм украин язучылары, латыш һәм татар — казан татарлары язучылары әсәрләренең җыентыкларын бик тиз оештырып булыр иде...

*1912 елның 9 (22) августында В. В. Вересаевка язылган хаттан.*

Сез үгетчеләр художникларның бугазыннан тоталар дип зарланасыз. Бу һәрвакыт шулай булып килде. Бу дөнья художниклар өчен түгел,— анда аларга һәрвакыт кысынкы һәм уңайсыз булды — шуңа күрә аларның роле мактаулырак та һәм батыррак та.

Ачлыктан һәм чахоткадан үлгәндә, казан татарларыннан бер шагыйрь:

«Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы...» — дип бик шәп әйткән.

«Очты» сүзенең кабатлануында[1] мин шатлык тавышы ишетәм. Ләкин мин үзем, әлбәттә, яшәү шатлыгын артыграк күрәм: гаҗәп кызык бу яшәү.

*1927 елның 15 июлендә С. Н. Сергеев-Ценскийга язылган хаттан.*

---

[1] Г. Тукайның «Өзелгән өмид» шигырендәге «очты» сүзе тәрҗемәдә ике тапкыр кабатлана. Редакция.

Сезнең бүләк кулъязмагызны — «Шобага» хикәясен алдым. Әгәр дә рөхсәт итсәгез, мин Сезгә гадирәк язарга киңәш бирер идем. Чын матурлык һәм акыллылык һәркайчан гадилектә... Сүзләр дә гади һәм аңлаешлы булырга тиешләр...

*1928 елның 26 августында Кави Нәҗмигә язылган хаттан.*

Мин татар язучыларыннан кайбер иптәшләрнең әсәрләрен укыганым бар. Алар үзләренең татар язучылары икәнлекләрен онытып ялгыш итәләр. Татар тормышына хас булган специфик моментларны художество сурәтләре аркылы күрсәтү, формасы белән милли, эчтәлеге белән советчыл булган татар әдәбиятын тудыру, сыйнфый әдәбият аркылы татар тормышы белән бөтен дөньяны таныштыру татар язучыларының төп бурычлары.

*1929 елның 15 сентябрендә көньяктан кайтып килүче бер төркем татар язучылары белән очрашу вакытында әйтелгән сүзләр.*

Татар әдәбиятын русчага тәрҗемә итәргә кирәк. Хәзер сүздән бигрәк эш кирәк... Әйдәгез, бергә эшлик... Мин һәрбер ярдәмгә, һәрбер эшкә әзермен...

*1929 елның 6 октябрендә Г. Кутуй тарафыннан язылган «Язучылар арасында» исемле мәкаләдән.*

Әгәр бездә үткән заманда гигант Пушкин булган икән, моңардан әле әрмәннәр, грузиннар, татарлар, украиннар һәм башкалар әдәбият, музыка, рәсем һәм архитектураның иң бөек осталарын бирә алмаслар, дигән сүз килеп чыкмый.

*1934 елның 17 августында совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз утырышында ясалган докладтан.*

Татар поэзиясенең һәм прозасының көчле чәчәк атуын бик нык телим. Ләкин моңар әдәбият бурычларына бик җитди караш белән генә ирешергә мөмкин...

*1935 елның 30 маенда М. Н. Елизаровага язылган хаттан.*

## Мөсәгыйт Хәбибуллин

# КУБРАТ ХАН

РОМАН

### 1



Олыгая башлагач, греклардан күреп, Кубрат хан утрак тормышка күчмәкче итте. Кайчандыр греклардан калган Фанәгүрне [1] башкаласы итеп сайласа да, җәй килүгә, илханнарын ырулары белән җәйләүләргә куды, ә үзе Фанәгүрдә калды, кала төзетте. Византия [2] осталары, базилевсныкына [3] охшатып, ханга сарай салып бирделәр. Шул ук вакытта чиркәүгә нигез дә казый башладылар. Бу эшне башта Кубрат хан күрмәмешкә сабышты, әмма төптәнрә бик зарлана башлагач, нигезе салына башлаган чиркәү төзүне туктатырга боерды. Шул хәбәрне ишетүгә, Византия императоры Ираклий тиз арада Фанәгүргә бик күп бүләкләр белән илчеләр җибәрде. Болай да империя биләмәсенә әверелә башлаган Фанәгүргә көннәрдән бер көнне йөзләрчә коллар белән кораб-кораб бүләкләр төягән грек илчеләре килеп төште. Моның үзенә күрә сәбәбе дә бар иде. Заманында Кубрат хан берничә ел Патшакалада [4] тәрбия алган иде. Менә шул кеше, Фанәгүрдә чиркәү салуны туктатып, мәҗүси дингә табынуын дәвам итә. Базилевсның максаты изге иде: ханны тиз арада христиан диненә инандыру. Бу изге бурычны ул соңгы вакытта үзсүзләнеп киткән архиепископ [5], логофет [6] һәм философ Иоанн Фасианга һәм дин кагыйдәләрен үзенчә аңлатуда гаепләнгән дин әһеле патрикий Симеонга йөкләргә булды. Базилевс аларны болай да илдән сөрергә җыенып йөри иде, җае чыкты. Базилевсның алар алдында йөзе ак булачак. Ләкин философ моны илдән куу дип уйламасын иде, акыллы кешеләр Византиягә дә кирәк. Шул сәбәпле базилевс философ Иоанн Фасианны дәшеп алырга һәм сөйләшергә булды. Әйе, ул аны илдән сөрми, ә варварлар иленә олы миссия белән җибәрә: ничек кенә булмасын, философ Кубрат ханны христиан диненә аударсын.

Мәгәр каршысына философ үзе килеп баскач, императорны гаҗәп-

---

[1] Фанәгүр — Тамань ярымутравындагы кала.
[2] Византия — Көнчыгыш Рим дәүләте.
[3] Базилевс — Византия императорларының титулы.
[4] Патшакала — Константинополь, Византия империясенең башкаласы.
[5] Архиепископ — чиркәү башы.
[6] Логофет — чит илләр министры.

ләндереп, ул Болгарга теләп китүе турында әйтте. Ул гынамы: «Галиҗанәпләре бөек императорыбыз, мин, христиан диненә табынучы буларак, Болгар ханы Кубратны изге динебезгә күчерүгә бөтен сәләтемне җигәрмен»,— диде. Шул сүзләре белән император Ираклийның тәмам зиһенен чуалтты. Аның сүзләрендә тере ялган күреп, базилевс тәхетеннән үк торды, философны кочаклады, муеныннан алтын тәресен салып бирде.

Кайчандыр готларны[1] чукындырып, базилевс тарафыннан патрикий[2] титулы алган, әмма соңгы елларда гаепләнгән дин әһеле Симеонны базилевс кабул итмәде, яратып бетерми иде император Ираклий төче телле дин әһелләрен.

Сөрелүчеләрне базилевс илче Феофонга йөкләде һәм үзе белән улы Константинны да алырга боерды. Илчегә ул Кубрат ханга патрикий титулы бирелүе турындагы шатлыклы хәбәрне җиткерергә һәм хан кызы Чәчкәне улы Юстинианга ярәшеп кайтырга кушты. Бу чара, базилевс уенча, һичшиксез, Кубрат ханның христиан динен кабул итүен тизләтәчәк, дигән уй белән эшләнде.

Әнә нинди шатлыклы хәбәр белән килгәннәр иде греклар Болгарга. Шуңа күрә булса кирәк, илчеләрнең корабларын каршыларга диңгез буена хан үзе төште. Ярга кадәр келәм җәелде, басмалар куелды.

Менә кораблар берсе артыннан берсе яр буена ягирләрен ташладылар, күперчекләр сузылды.

Иң алдан алтын белән язылган калын китап тотып, озын кара чикмән кигән дин әһеле патрикий Симеон төште, аңа ияреп башына очлаеп килгән башлык кигән философ Иоанн Фасиан, илче Феофан, аның улы Константин, алар артыннан күп санлы хезмәтчеләр, бүләкләр күтәргән коллар чыктылар. Корабтагы сөрән салучы баскычка баскан һәр кешенең исемен, титулын кычкырып торды. Алдан атлаган патрикий Симеон иң әүвәл Кубрат хан каршына килеп баш орды, аның артыннан барчасы да шул ук хәрәкәтләрне кабатладылар.

Шуннан соң гына айбалта тоткан алыплар[3] уртасында сарайга таба кузгалдылар.

Илчеләрне Кубрат хан, базилевс кебек үк, тәхетенә утырып кабул итте. Барчасы да үз дәрәҗәләрен белеп утырышкач, илче Феофан Кубрат ханга базилевсның сәламен юллады, аннары Бөек Болгарның олуг ханы Кубратка империянең патрикий титулы бирелүе турындагы хәбәрне җиткерде. Титул бирелүе турындагы сүзләр әйтелгәч, хан алдына күп санлы бүләкләр китерелде. Гаҗәбе шул иде: илче император сүзләрен төрки телдә җиткерде, шуның белән сарай әһелләрен бераз аптырашта калдырды. Илче Феофан һәр сүзен чатлатып әйтә, ә күп санлы хезмәтчеләр аның әйткән бер сүзен үтәп торалар. Ахырда илче тавышын баса төште һәм Кубрат хан белән ханша[4] алдына килеп баш орды, хөрмәтләп каршы алуларына рәхмәтен белдерде.

Кубрат хан аңа әйтте:

— Болгар халкы киң күңелле, кунакчыл халык, үз дәрәҗәңне белеп утыр, илче,— диде.— Күктә йолдызлар күп булса да, тәңре бер генә, кешеләр аның йолдызлары, йолдызларның да урыннары кайсы уртада, кайсы офык читендә. Мин, илче, синең хәбәрләреңнән шатмын. Базилевска игелек телим, Бөек Болгарга игелекле илчеләр җибәргән.

Илчеләрне кабул иткәндә, ни сәбәпледер шактый соңга калып, сарайга төптәңре[5] Ирсан килеп керде. Килеп керде дә гадәттәгечә түргә узды, ә анда, Кубрат ханның уң кулында, элек һәрчак төптәңре утыра

[1] Готлар — герман кабиләләре.
[2] Патрикий — империядәге югары титул.
[3] Алып — сугышчы.
[4] Ханша — хан хатыны.
[5] Төптәңре — тәңренең җирдәге төп вәкиле.

торган тумәрдә гректан килгән философ Иоанн Фасиан утыра иде инде. Төптәңре моны күрде дә килгән җиреннән шып туктады, ни кылырга белми тирә-ягына каранды, ханны, ханшаны, кавханнарны күздән кичерде. Шул чак Кубрат хан кул чапты, төптәңрегә урын-тумәр китерделәр, бер читкә куйдылар. Һаман олуг хан янәшәсендә утырырга гадәтләнеп киткән төптәңренең, бу хәлне күреп, йөзеннән кан качты, кам таягын[1] тоткан кулы калтырана башлады. Шунда аңа янә хан ярдәмгә килде.

— Утыр, утыр, төптәңре. Утыр китергән урынга. Рум[2] императоры Ираклий, Болгарны хөрмәтләү йөзеннән илчеләр җибәргән, дәрәҗәләренә карап урын бирдек. Утыр китергән урынга. Кһм!— дип, олуг хан сакалын сыйпап алды, бу аның соңгы сүз билгесе иде.— Мин әйттем!

Боеру иде бу, төптәңре үткер күзләре белән олуг хан тирәли утырышкан илчеләргә, кавханнарга[3], илханнарга[4], тарханнарга[5] күз йөртеп чыкты...

Ул арада зөбәрҗәт ташлар белән бизәлгән табакка салып, энҗеләр тезгән такыя китерделәр. Илче әүвәл олуг хан каршына килеп баш иде, аннары ханшага, шуннан соң гына хезмәтче китергән табакны алып, хан каршына куйды. Аның артыннан төрле бүләкләр күтәргән коллар уздылар. Бүләкләр хан каршына күчеп беткәч, илче ярым иелгән килеш артка чигә-чигә үз урынына барып утырды, улы Константин аның артына басты. Бүләкләр шул хәтле күп иде ки, бу кадәр бизәкләп ясалган затлы әйберләр, хуш исе танауга бәрелеп торган ислемай шешәләре, келәмнәр, ефәк тукымалар, алтын җеп кушып тукылган билбаулар, энҗеле путаларны күреп, хан елмаеп куйды. Бүләкләрдән бик канәгать иде. Әмма бүләкләр моның белән генә бетмәгән икән. Иң ахырдан илченең улы Константин хан каршына алтын көбә китереп куйды. Константин үз янына килеп житкәнче, хан аңа текәлеп карап торды. Чандыррак гәүдәле, зәңгәр күзле бу илче улында үзенә тартып торган мөлаемлек бар иде. «Белекледер[6] бу углан»,— дип уйлады Кубрат хан.

— Олуг хан,— дип илче Феофан нидер сизенеп урыныннан күтәрелде.— Мин сездән император Ираклий хәбәрләренә җавап көтәм.

Олуг хан илче Феофанга күз төшереп алды, тәхет култыксасына кулларын куйды. Тәхет урындыгын аңа базилевсныкына охшатып, грек осталары ясаган иде, һәр як култыксада да тешләрен ыржайтып торган арыслан башы, алар алтынга буялган.

— Бөек Рум императоры, дустым Ираклий Болгарга бик күп бүләкләр җибәргән. Бәһале бүләк бәһале сүз сорый. Мин әйтәм: грек-болгар дуслыгы мәңгелек. Кубрат хан үз халкы исеменнән император Ираклийга житкерергә куша: хан исән чакта император җирләренә бернинди дошман да аяк басмас. Болгарлар аны яхшы яктан гына телгә алсыннар дисә, илче Феофан, император Ираклий безгә тагын төзүчеләр, һөнәрчеләр җибәрсен. Без, болгарлар, күп еллар каган кул астында яшәдек. Астылар да безне, кистеләр дә, кол итеп тә саттылар. Менә без Ашин ыруын җиңдек, яңа җәйләүләр яуладык, Румнар кебек үк утрак тормышта яшәү теләге белән башкалабыз итеп Фанагүрне сайладык. Диңгез буендагы калабызның барлык илләр өчен дә капкалары ачык. Рум сәүдәгәрләренә базарлардан иң яхшы урыннар бирелер. Әүвәл шуны житкерсәң иде императорга, илче. Дустым Ираклий миңа хат язган, ул минем кече оланым Асланны Патшакалага тәрбиягә сорый.

---

[1] Кам таягы — шаман кулындагы илаһи көчкә ия таяк.
[2] Рум — Византия.
[3] Кавхан — ханнан кала гаскәр башлары.
[4] Илхан — хан улы.
[5] Тархан — чит җәйләүләргә баш кеше.
[6] Белекле — укымышлы.

Мин үзем дә азмы-күпме Патшакалада тәрбия алган кеше. Кһм, оланымны, илче, синең белән җибәрермен. Болгарга да белекле илханнар кирәк. Инде хәзер, илче, син минем — Кубрат ханның үтенечен тыңла. Синең миңа угланың ошады, илче Феофан, ул аманәт-тотык булып Фанәгүрдә калыр, сарай мәктәбендә балалар укытыр. Императорга минем үтенечемне җиткерерсең. Мин әйттем, илче.

Бер тынга сарайдагы халык шым булды, ишегалды яклап этләр өргән тавышлар ишетелде. Көтелмәгән бу киңәштән, киңәштән битәр таләп куюдан, илче Феофан бер мәлгә телсез калды. Башта ул ике кулын алга сузып ханга таба омтылды, әмма хан тирәли баскан җансакчылар шундук кузгалып куйдылар, илче Феофан ярдәм итүләрен сорап, әүвәл патриций Симеонга, аннары философ Иоанн Фасианга карады, алар йөзендә дә яклау күрмәгәч, хан алдына килеп баш орды.

— Олуг хан, ятим итмә берәүне! Тотык итмә угланымны! Бердәнбер оланым ул минем. Анасына ни әйтермен, туганнарына?! Галиҗанәпләре император Ираклий, империя башы,— илче Феофанның карашы анасы артына килеп баскан Кубрат хан кызына төште, илченең күзләрен әйтерсең нидер кадаклап куйды, күрде дә таң калды. Варварлар иленә күпме йөрсә дә, аның беркайчан да мондый гүзәллекне күргәне юк иде. Ул әйләнеп улына карады, улы да гүзәллеккә таң калып, хан кызына карап тора иде. Феофан кисәк хан алдына егылды.— Олуг хан, миңа Бөек Ираклий... әйе,— диде каушый калып илче.— Император Ираклий, олуг хан, улы Юстинианга кызыгызны алып кайтырга кушты. Базилевс синең белән, бөтен Болгар белән кардәшләшергә тели, олуг хан.

Кубрат хан «дык» итеп таягы белән идәнгә төртте, шундук янына җансакчылары якынайды. Хан ярдәмче кавханына нидер әйтте. Күп тә үтмәде илханнар, кавханнар хан тәхетен уратып алдылар, илче Феофанны ике алып култыгыннан алды, урынына илтеп утырттылар. Ниһаять, илханнар, кавханнар урыннарына утырыштылар. Сирәк була торган хәл — олуг хан тәхетеннән торып басты.

— Йомышың кабатла, илче,— диде олуг хан.— Илханнар, кавханнар, анасы да ишетсен.

Халык арасында чышын-пышын сөйләшү китте. Кубрат хан янәшәсендә утыручы ханша ягына авыша төште, ханшадан нидер сорады. Ханшаның ризалыгын, бугай. Ханша шундук агарынып китте. Ханша Аппакның йөзе алышынып китүен күзәтеп торган Феофанның эченә җылы йөгерде. Хан аңа янә нидер әйтте. Шуннан соң ханша кызының кулыннан тотып, күзләренә карады. Хан кызы Чәчкә һични аңламый калды, еш-еш керфекләрен каккалап тик торды. Кубрат хан алостаз[1] Дәянга мөрәҗәгать итте.

— Алостаз Дәян, император Ираклий угланына кызыбыз Чәчкәне сорый. Киңәшең бир?..

Кемдер: «Тәңрем, сакла!»— дип, ахылдап алды, елап җибәрүчеләр, күз яшен сөртүчеләр күренде.

Кубрат хан урынына утырды, таягы белән идәнгә төртте, барысы да шым булдылар.

— Илченең теләге изге,— диде алостаз Дәян.

— Ханша, син ни әйтәсең?—диде олуг хан.

Ханша үсмер кызын кочагына алды, җавап бирмәде. Мәгәр олуг хан ханшадан җавап көтеп тормады, янә аягүрә басты, кавханына корбан балыгын китерергә кушты. Күз ачып йомганчы алтын табакка салып корбан балыгын китерделәр. Кубрат хан чәбәләнеп яткан ап-ак балыкны кулына алды, хәнҗәре белән чәнечте һәм алтын чокырларга җидешәр тамчы кан тамызды, аның өстенә эчемлек койды. Аннары ике

[1] Алостаз — шымчылар башы.

кулына ике чокырны алды да, берсен илчегә бирде, икенчесен күтәрә төшеп:

— Ант эч, илче!— диде.

Чит илләрдә йөри-йөри бик күп гәҗәпләр күргән һәм үзен алардан һәрчак бер башка өстен санаган илче Феофан гомерендә беренче тапкыр коты алынып чокырга үрелде. Чокырда корбан балык каны кушылган шәрап иде, Феофан эчемлекне исеннән үк таныды — Румныкы. Болгарлар шәрапны үзләре ясый белмиләр. Византиядән китерәләр, эчеп алалар да такмак әйтә-әйтә күңел ачалар. Шәрап кайгыны тарата, күңелне ача. Илче чокырны күтәреп эчеп җибәрде, эчкәннән соң телендә хуш исле балык төме тойды. Хан исә чокырга иренен генә тигезеп алды, Рум шәрабе аның саруын кайната иде.

— Император Ираклийга әйт, илче, кыз бирү — кол бирү түгел. Балигъ булгач, Чәчкәне алырга угланы белән үзе килер. Базилевска, императрица Мартинага, оланнары Юстинианга озын гомер, тазалык, илләренә иминлек телим. Иленә яу килгәндә Кубрат хан үз алае[1] белән императорның уң кулына басар. Мин әйттем, илче.

Һәммәсе дә аягүрә бастылар, ханга, аннары илчегә бил бөктеләр һәм янәдән урыннарына утырыштылар.

Кубрат хан төптәңре Ирсан ягына күз сирпеп алды. Төптәңре, сүз сиңа бирелә, дигән мәгънәне аңлата иде бу. Болгарда гадәткә кергән хәл иде бу — чит илдән килгән илчеләр белән сүз көрәштерү. Кайсының дине камил, кайсының өстен — четерекле сорауларга тапкыр җавап сорала иде сүз көрәшендә.

Төптәңре аягына торып басты, урыннарына утырышкан илчеләрнең һәммәсенә карап, ияк кагып исәнләшеп чыкты, аннары кызылга кара буй төшкән чапанын, түшендәге кояш сурәте сугылган алтын тәңкәне рәтләп куйды, шуннан соң гына:

— Болгарларга мәгълүм булганы шул, олуг хан. Рум дәүләте патшасы Ираклий Гайсә сурәтенә табына, ягъни христиан диненә. Алла күктә, аның илчесе Гайсә җиргә төшкән дип бара. Бу йола болгарлар өчен ят йола. Кеше алла илчесе була аламы? Юк. Шуны аңлатсын иде миңа илче.

Илче Феофан Румнан үзе белән килгән дин әһеле патрикий Симеонга карады, бу сорау сиңа, дип ым какты.

Патрикий Симеон салмак кына күтәрелде, күн тышлы алтын хәрефләр белән язылган китабын уңлы-суллы йөртеп алды, аннары китапны үпте дә иДәнгә куйды, шуннан соң гына олуг ханга, аннары төптәңрегә бил бөкте.

Патрикий Симеон кулларын китапка сузды, шунда бер могҗиза булды: китап битләре үзләреннән-үзләре ачыла башлады. Патрикий Симеон ят телдә моңлы итеп көйләп укып китте, ул бер тын укуга, битләр янә ачылды. Менә ул укудан туктады һәм саф төрки телдә:

— Тәңре дә, алла да бер, төптәңре. Гайсә пәйгамбәр җиргә төшкән алланың илчесе. Гайсә пәйгамбәр адәмнәрне гадел булырга, бер-берсенә ярдәм итәргә өнди. Денсезләр тарафыннан ул җәзалана, бик күп газап күрә, тау куышында яши, ахырдан аны тотып, дар агачына кул-аякларыннан кадаклап куялар. Бу җәзага аллаһы-тәгалә дә түзми. Гайсә пәйгамбәрне күккә ала. Кешеләр якыннарына изгелек кыларга өйрәнгәч кенә пәйгамбәр янә җиргә төшәчәк.

— Күктә алла бер — тәңре,— дип төптәңре Ирсан кайнарланып тәңре турында сөйли башлады.— Кем көнне тудыра, кем яктырта, кем...

Кубрат хан кулын күтәрде, кул хәрәкәте белән төптәңрегә тыелырга әмер бирде, утырырга кушты.

— Төптәңре хаклы, илче, күктә алла бер — тәңре,— диде хан, төп-

[1] Алай — гаскәр.

тәңренең сүзен куәтләп. Төптәңре шым булды, урынына утырды. Патрикий Симеон тагын нидер әйтергә дип авызын ачкан иде, хан йөзендә кырыслык күреп, тыелып калды. Дин әһеле белә иде — түрәләргә каршы дәшмә, түрәләр белән сүз көрәштермә. Хан — Болгарның мәҗүси динен халыкка таратучы төптәңре түгел, кирәк икән, хан — кеше башын кистерүче, кирәк дип таба икән, гаепләме ул, түгелме, ат коерыгына тактыручы, кирәк икән, янәшәсенә утыртучы. Түрәләрнең кулында таяк, күңелләрендә кылыч, дияр иде аңа остазы. Әйе, ханнарга, императорларга дәшкән — бер откан, дәшмәгән — ике откан. Дин әһеле философка карады, аннан ярдәм сорады. Кубрат хан да философка күз сирпеп алды. Хан шундук сиздe — иң белекле кеше аның кырында утыра.

Философ Иоанн Фасиан аннан ни көтүләрен аңлады, аягына торып басты.

— Олуг хан, мин берәүне дә теге я бу йолага үгетләргә җыенмыйм,— дип башлады философ сүзен, аның төрки телдә сөйләвенә барысы да шаккаттылар, сарайда шылт иткән тавыш калмады.— Борынгылар әйткәннәр: дошманнан яшерәсен дустыңнан да яшер. Хәтта дуслык та мәңгелек була алмый. Мәңгелек — изгелек.

— Хуш, философ,— диде хан, сакалын сыпырып.— Изгелек димсең. Әйт әле миңа, бу дөньяда нинди гыйлем иң камил гыйлем?

— Иң камил гыйлем, олуг хан, җүләрләр яратмаган гыйлем.

— Гыйлемнең камиллеген ничек белергә соң, философ?

— Чүлмәкне чиртеп, кешене сөйләтеп, олуг хан.

— Философ Иоанн Фасиан, тәңре бармы?

— Алла да, тәңре дә юк, олуг хан. Ул җирдә дә, күктә дә яшәми. Тәңре безнең күңелебездә. Ул — безнең рухыбыз, җаныбыз, олуг хан.

Олуг хан төптәңрегә ияк какты, янәсе сиңа сүз.

— Тәңре ул — кояш, күк йөзе. Кояш чыкмаса, күктән яңгыр яумаса, бар тереклек үләр, урман-болыннар көяр, елга-күлләр корыр. Моны ничек аңлатыр микән, философ?— диде төптәңре һәм, соравыннан канәгать калып, түшендәге алтын тәңкәсен сыйпап куйды.

— Җиһан бөтен дөньяны эченә ала: кояшны да, күкне дә, айны да, йолдызларны да, адәм баласын да. Без яшәгән җир дә — җиһан баласы. Җирнең бер тузаны булып адәм баласы яши. Әмма адәм күңеле җирдән дә, кояштан да, хәтта җиһаннан да киңрәк, кеше күңеленә бар нәрсә дә сыя. Димәк, алла, тәңре, бары тик кеше күңеленә кем тарафындыр салынган рух кына икән.

— Бер төрле сөйләшәбез, икебез ике ярда басып сөйләшәбез. Шулай аңладым мин сине, философ. Хикмәт ышануда икән,— хан күбрәк философка тартылды, моны илче Феофан да, патрикий Симеон да күрделәр.— Алла да, тәңре дә бер. Алла — бер, дөнья — бер. Җиһан — бер... Һәркем аңа үзенчә ышана, үзенчә аңлый, үзенчә килә, үзенчә күрә булып чыга. Ни өчен шулай?

— Иң олы алла — рух, олуг хан. Синең рухыңны олылаучылар бардыр, олылаучылар булгач, күрә алмаучылар да бардыр?

— Бар, философ.

— Олуг хан, син шуларның кайсын ярата төшәсең?

— Рухымны олылаучыларны һәм сүземне тыңлаучыларны, философ.

— Халкыңа сүз тыңлату өчен дәрәҗә кирәк, олуг хан.

— Мин сине аңладым, философ. Акыллы кеше китергәнсең, илче, рәхмәт сиңа,— хан Феофан ягына сизелер-сизелмәс кенә ияк какты.— Инде әйт миңа, философ: хәсрәт, кызгану, мәхәббәт, көнләшү, сагыш, курку, кайгы, ярсу ни?

— Олуг хан, хәсрәт — кеше башына килгән кайгыдыр, кызгану — кылган янсә кылынмый калган эшкә карата туган үкенечтер, мәхәббәт — гүзәллекне эзләүгә, гүзәллекне үз итүгә киткән сәләттер. Көнчелек — башка берәүләргә килгән мәхәббәттән синең күңелеңдә туган

эчке сагыштыр. Сагыш — куңелсезләнү, эч пошу, ачыргалану, гасабиланудыр. Курку — явызлык котүдән килгән билгесезлек борчуыдыр. Кайгы — дәвамлы сагыш, кеше башына төшкән яман чирдер. Ярсу — йөрәккә төшкән йөгәнсез ат кебек буйсынмас ачудыр.

Олуг хан җаваптан канәгать калып башын иде, беравык уйланып утырды. Беркем дә тынлыкны бозарга, сүз катырга кыймады, берәү дә кымшанмады, тамак кырмады. Тамак кыру Болгарларда сүз сорау билгесе иде. Төптәңре Ирсан утырган җирендә борсаланып алды. Уйланырлык, борчылырлык, шомланырлык иде төптәңрегә. Болгарга аңардан күп акыллырак кеше килгән, һәм аның ханны үз ягына аударуы бар. Ханның андый хәлләре булгалады.

Моннан шактый еллар элек, аварлар белән орышта, Кубрат хан яраланды. Төпимче белән төптәңре аны атна буе дәваладылар. Төпимче ярага төрле яфраклар каплады, төптәңре хан тирәсенә җыелган җенпәриләрне куды. Әмма яра төзәлмәде дә төзәлмәде. Шуннан Саклаб кавханы аңа грек табибын[1] китерде. Грек табибы яраны нindидер сыекча белән юды, шул сыекчага манып, чиста чүпрәк каплады, ханга шул сыекчаны ике сәгать саен эчәргә бирде. Шәмәхә төстәге сыекчадан эчемлек исе, тимер тәме килә иде. Өч көннән ханның ярасы җөйләнә башлады, ә инде тагын өч көннән яра яшь тире элпәсе белән капланды. Шул хәлдән соң Кубрат хан Болгардагы кайбер диннәргә рөхсәт бирде. Хан боерыгын илханнар йөргән барлык җәйләүләргә җиткерделәр. Рум табибы Гайсә сурәтенә табына иде, ярасы җөйләнеп, хәле арулангач, Кубрат хан табибның өенә барып, почмактагы Мәрьям ана белән Гайсә пәйгамбәр сурәтләренә карап торды. Шуннан соң уйга калды. Ни өчен Рум халкы бу сурәтләргә табына, нинди җиңеллек китерде икән бу халыкка изге Мәрьям ана белән изге Гайсә пәйгамбәр? Ни өчен Гайсә пәйгамбәрне җәзалап үтерәләр, житмәсә дар агачына кадаклап куялар? Бер дә гаепсезгә җәзаламаганнардыр, чөнки Кубрат хан үзе беркайчан да, беркемнең дә гаепсезгә башын кистермәде, ат койрыгына да тактырмады... Гайсә пәйгамбәр юк, аны җәзалап үтергәннәр, ә менә рухы, иманы һәр грекның күңеленә сеңеп калган, кырып та, җуеп та алмалы түгел, Кубрат хан да, төптәңре дә аңламаган ул нindидер көч-куәткә ия йола иде.

Төптәңре боларның барысын да белә, олуг хан христиан динен кабул итмәсен дип коты алынып утыра иде.

Олуг хан философ белән сөйләшә, беркемне күрми дә, белми дә, бөтенләй дөньясын онытты.

Төптәңренең хан алдында дәрәҗәсе көне-сәгате белән төшә бара иде, башкалар моны күрәме-юкмыдыр, әмма төптәңре моны җанытәне белән тоя иде. Төптәңре ярсынды, гасабиланды, әмма һични кыла алмады. Сүз катасы иде, олуг хан ошатмас, аннары нинди мәсьәлә генә күтәреп чыкмасын, аның авызын гректан килгән философ томалаячак. Рум дәүләте бик күп илләрне, бик күп халыкларны канат астына җыйды инде, христиан динен биреп, Болгарны да җыймакчы. Бер дә бүтән түгел, философны шул максат белән Болгарга җибәргән базилевс. Ул гынамы, христианнар кысрыклау сәбәпле (император Ираклий яһудләрне асып-кисеп йөри), Фанәгүрне соңгы елларда яһудләр басты, мона кадәр сирәк күренгән гарәп сәүдәгәрләре күренгәли башлады. Төрле илләрдән килгән сәүдәгәрләр ишәя башлагач, хан аларга махсус сарай салдырды.

Ниһаять, олуг хан башын күтәрде. Киң, куе кашлары астыннан тирәли утырган кунакларга сөзеп карап чыкты. Аннан карашын илчеләр китергән бүләкләргә төшерде. Бизәкләп эшләнгән йөгәннәргә, бил каешларына, путаларга, алтын йөгерткән бакыр шәмдәлләргә сокланмый-

[1] Табиб — врач.

ча карау мөмкин түгел иде. Бүләкләргә күзе төшүгә, ханның йөзендәге җыерчыклары языла башлады. Үтә канәгать иде Кубрат хан бүләкләрдән. Дусты Ираклий аңа һәрчак һәйбәт бүләкләр җибәреп торды. Көбә[1] күлмәкләр кирәкме, Димәшкъ корычыннан ясалган кылычлармы, грек ятаганнарымы[2], үткен очлы сөңгеләрме... Дөрес, Болгар да Румга бурычлы калмый, ай саен кеш, бүре, аю, болан тиреләре, бал-балавыз, агач сагызы, балык җилеме җибәрелеп тора. Ике арадагы сәүдә эшләре көйләнгән, җайланган иде, борчыласы юк, базилевс канәгать иде. Әмма Кубрат хан үзе бигүк канәгать түгел иде базилевстан. Моны ул ачыктан-ачык сиздермәде, әмма үзе генә белгән хикмәтле бер теләге бар иде. Рум дәүләте җиде гасыр буена үзендә грек уты җитештерә, әмма иң яхшы, хәтта христиан динен кабул иткән күршеләренә дә шул утны биргәне юк. Греклар менә җиде йөз ел инде ут ясауның серен үзләрендә саклыйлар. Ураган агасы Кубрат ханны сарайда тәрбиягә аманәт итеп калдырган вакытта ук, шул ут турында хыялланган иде Кубрат. Ул Патшакалада ут ясый торган алачыкларга керергә итте, әмма аңы алачыкларга кертмәделәр. Фанәгүрдә төпләнеп калырга ният иткәч тә, Кубрат хан ул ут турында онытмады. Патшакалага иң яхшы шымчыларын җибәрде, мәгәр тегеләр ничекләр генә тырышмасыннар, алачыкларга үтеп керә алмадылар, ут ясаучы бер генә останы да алып кайтмадылар. Император грек утын читләргә дә саткалый. Күптән түгел шымчылары җиткерде Кубрат ханга: базилевс Табгач[3] императорына бернича чүлмәк грек уты җибәргән. Мәгәр бу әле аның серен белү дигән сүз түгел. Грек уты ясауның серен Румнар күз карасыдай саклыйлар. Ут ясау сере кулга төшкән мәлдә Кубрат хан аны кемгә каршы кулланырга белер иде. Башта ташаткычларны корабларга куяр иде, аннары кораблар белән Әтил суы буйлап өскә күтәрелер, андагы барлык халыкларны буйсындырыр. Аннары түбән төшәр, Хәзәр диңгезе буенда яшәүче халыкларны яулар, аннан бәлкем Иберийгә... Әлегә Кубрат хан Әтил белән Чулман елгалары кушылган төбәкләрдә туктады, ары бара алмады. Дөрес, андагы халыклар белән сәүдә итү өчен шул җирдә кирмән салдырды. Ләкин барыбер теләгенә ирешә алмады. Төн илләрендә аю, болан тиреләреннән йөриләр икән, тауларында алтын-көмеш аунап ята икән. Барасы да кораблар белән шул якларга, Төн диңгезенәчә җитәсе иде. Грек уты кулына төшкән хәлдә...

Кубрат хан башын күтәрде, барысы да аңа игътибар итте.

— Хөрмәтле Ираклий дустым Фанәгүргә акыллы илчеләр җибәргән. Килеш, төптәңре,— диде хан.— Эт төлкене куып тоткач, төлке аңа әйткән ди: «Синең аякларың тотмады мине, сиңа тотылуым — минем көчсезлегем бәләсе, син әнә бүрене куып тотып кара»,— дип әйтеп әйткән, ди. Әгәр дә мәгәр син, Ирсан, илчеләр белән килешмисең икән, кем әйтмешли, бүрене тотып кара.

Барысы да көлештеләр. Төптәңре яшелле-зәңгәрле булып агарынып китте. Үе-шиге хак булган, Кубрат хан акрын гына христиан диненә авыша бара. Әйе, моннан күп еллар элек агасы Ураган бер дә тикмәгә генә оныгы Кубратны Патшакалада тәрбиягә калдырмаган икән. Төптәңре түзмәде, торып басты. Бу аның янә сүз соравы иде, хан аңа әйдә сөйлә дигән ишарә ясады.

— Тәңренең илаһи көче һәркемгә җитә, хан. Мәрьям ана белән Гайсә пәйгамбәргә дә. Эт кыр кәҗәсен куа китә. Шунда кыр кәҗәсе аңа әйтә: «Син беркайчан да мине куып җитә алмассың»,— ди. «Нигә?» — дип сорый эт. «Шуның өчен,— ди кыр кәҗәсе,— мин үз җанымны коткарыр өчен чабам, ә син хуҗаңа ярар өчен мине куасың»,— ди.

— Төптәңре, син дә хаклы,— диде олуг һәм беренче булып урынын-

---

[1] Көбә — тимер күлмәк.
[2] Ятаган — ике ягы да үткен кыска кылыч.
[3] Табгач — Кытай.

нан кузгалды.— Кунакларны ашчылар көтә, зарыктырмыйк табынны. Ач кешенең ачуы яман, дигәннәр бабаларыбыз.

Артык дәү гәүдәле, чәч-сакалы агара башлаган, алтын җепләр белән аралаштырып тегелгән рум чапаны кигән Кубрат хан торып баскач, барысы да үзләрен кечерәеп калгандай хис иттеләр. Аягүрә баскан Кубрат ханның күзләрендә, бөтен торыш-кыяфәтендә көч-гайрәт кенә түгел, нindидер тылсым да бардыр сыман иде. Хан инде бәхәстән туйган, аның бүген беркем белән дә бәхәсләшәсе килми иде. Кубрат хан бер адым алга атлады. Төн илләреннән китерелгән урман мәчесе тиресенә басты. Аннары борылды да, иелеп, бизәкле табактагы энҗеләр тезгән калфакны алды, килеп, ханшага кидерде. Шунда патрикий Симеон «Ах!» дип куйды. «Йа аллам, нәкъ изге Мәрьям ана!» — диде. Моны ишеткәннәре — ишетте, ишетмәгәннәре — юк. Хан аягүрә торып басканнарга күз йөртеп чыкты. Кунаклар янына Болгарның аксакаллары, илханнары, кавханнары, тарханнары чакырылган иде, алар барысы да, шул исәптән илчеләр дә хан тагын ни әйтер дип, аның авызына карап торалар. Хан иелеп табакны алды һәм төптәңрегә:

— Ышбу табактан ханшага ризык китерсеннәр!— дип, табакны төптәңре Ирсанга сузды. Төптәңренең алмый чарасы юк, бу хан боерыгы иде. Төптәңре нindидер мизгелдә үзенә терәк эзләп, үзе яраткан һәм үзе яклы дигән кавханнарга карады, әмма тегеләр күзләрен читкә алдылар, төптәңрене күрмәмешкә салыштылар. Төптәңренең йөзе болыттай каралып китте. Әмма хан аны күрми иде инде. Ул кулы белән барчасына да кузгалырга дип ишарә ясады, шуны гына көткәндәй, һәммәсе аш ягына кузгалдылар. Яңа аш бүлмәсен Рум осталары салган иде, бераз кечерәк булса да, базилевсныкына охшатканнар иде. Иоанн Фасиан моны эш бүлмәсенә килеп кергәч тә күрде. Аш ягына кергәч, кунаклар яңа төр шәкелләр-бизәкләр дә күрделәр, соклануларын яшермичә, тотып-тотып карадылар.

* * *

Үпкәсен эченә йотып, төптәңре Ирсан барысыннан да иртәрәк сарайдан чыгып китте. Хан сараеннан чыккач, төптәңре туп-туры ата-бабалар каберлегенә юнәлде. Җир астында дөнья көтүче ата-бабалар белән киңәшерлек уйлары бар иде төптәңренең. Бу кабергә бабалар күмелгән, һәрберсе янына хатыннары, атлары-коралары, коллары куелган. Биек көрбән[1] булып үсеп чыккан каберлеккә бүген дә китереп корбан чалалар, корбан ителгән малның канын кеше күтәрә алмастай кылыч утыртылган төбәккә коялар. Орышка чыгарга җыенган һәр алып, бирегә килеп, корбан чала, үз бармагын хәнҗәре белән төртеп кан чыгара, шул кылычка сөртеп китә. Ике-өч ел элек төптәңре Ирсан кылыч янына таш куйдыртты. Таш шул кадәр зур иде ки, аны көрбәнгә меңгерү өчен меңләгән кеше китерергә туры килде. Изге ташка руналар белән изге сүзләр язылган иде. Төптәңре бу ташны болгарларга күктән тәңре төшерде диде. Ышандылар.

Моннан йөз еллар элек, Төрек баба оныклары Ашин белән Дулу арасында каган тәхете өчен бәхәс купкач, төптәңренең этисе үзенә Дулу нәселен сайлый һәм аларны төркиләрнең каганы итүгә ирешә. Әмма ашинлылар атасының башына җитәләр. Кубрат ханның агасы Ураган каган ашинлылар белән көрәшеп йөргәндә башын сала, аның урынын Кубрат хан ала.

Төптәңре Ирсан үз атасы, Дулу ыруын сайлап һәм аларны төркиләр дөньясына баш итеп куярга маташып, зур хата ясаган дип бара иде. Башта ул шулай дип уйлап кына йөрде, ә инде Кубрат хан белән ки-

[1] Көрбән — курган.

лешә алмый башлагач, бигрәк тә ханның христиан диненә авышуын күргәч, Ашин ыруына ачыктан-ачык йөз тота башлады. Төптәңренең бәхетенә каршы, Истеми каган оныгы Йулыш исән калган икән. Ул ашинлыларга йөз тоткан хәзәрләргә килә һәм күп тә үтми аны ак киезгә салып күтәрәләр — каган итәләр. Йулыш каган биләү җире итеп Хәзәр диңгезе буйларын сайлый һәм шунда кала салдыра. Хәзәрләр таңрегә табыналар, кардәш халык, ә греклар кем? Греклар болгарларга телләре, гореф-гадәтләре белән дә ят кешеләр. Ә Кубрат хан шуңа да карамастан сараен греклар белән тутырды.

Ата-бабалар каберлегенә килгәч, төптәңренең зиһене ачылып киткәндәй булды. Әйе, әйе, хәзәрләргә йөз тотарга, кавханнарны, илханнарны шуңа котыртырга...

Төптәңре корбаннар көрбәненә менде, изге таш алдына тезләнде. Караңгы төште, тау артыннан ай калыкты. Төптәңре изге ташка баш ора-ора теләде.

«Атам-бабам, тыңла угланың, кыл бер-бер хәл олуг хан белән. Узына башлады, угланың санламый, сүзләремә колак салмый башлады, атам-бабам...»

Шул чакта җир кузгалып куйгандай итте, изге таш селкенеп бер якка авыша төште, һәм җир астыннан тонык кына аваз ишетелде. Ирсан коты алынып күккә карады. Таңре үзе шулай аңа дәшәме, җир астындагы бабаларымы?.. Ирсан йөзтүбән капланды, таңредән кичерүен теләде. «Йа таңрем, йа җир атасы, йа җир анасы, йа су атасы, йа су анасы, мин җир баласы, сезгә каласы, безгә барасы».

Шул мәлдә тагын җир селкенеп куйды, төптәңре Ирсанның аяк астындагы җир убылып киткәндәй булды. Төптәңре сикереп торды, йөгерә-йөгерә калага кайтып китте.

Өйдә аны коты алынып гарәп колы көтеп тора иде. Хуҗасы бусаганы атлап керүгә, ул: «Иям, җир тетрәде, өй уртасындагы сандал җир астына убылды»,— диде. Шунда белде Ирсан гарәп колының белекле булуын, шул көннән ул аңа кол дип түгел, аты белән дәште.

Ата-бабалар кабереннән кайтканнан соң төптәңре Ирсан үзендәге таңре тарафыннан бирелгән илаһи көчләргә ышанмый башлады. Төптәңре кисәк җиргә төште һәм иң әүвәл үзенә яклаучылар булдырырга, илханнарны Кубрат ханга каршы котыртырга дигән нәтиҗәгә килде.

## 2

Олуг ханда хезмәт итүче багатырларның күбесе болгарларга кардәш төркиләр иде. Аларның бер өлеше Болгарга Аппакка ияреп килде, бер ишесен Тугрыхан үзе җибәрде. Куәтләнеп, көч җыеп килгән киявне тагын да куәтлерәк итәсе килә иде, күрәсең, Тугрыханның. Әмма көтмәгәндә Тугрыхан үлеп китте. Хансыз калган көтригурларның аксакаллары Кубрат ханга Фанәгүргә киңәшкә килделәр. Алар үзләре белән яңа мыек чыгара башлаган Көбер илханны да алып килгәннәр иде. Кубрат хан тантаналы төстә Көбер илханны хан итеп ак киездә күтәрттерде. Болгардан хан титулы алып кайткан Көбер җизнәсе Кубрат ханга рәхмәт йөзеннән бер төмән алай җибәрде. Бу хәл җизнәсе Кубрат ханны хөрмәт итүне, ниндидер күләмдә аның канат астына керүне, буйсынуны аңлата иде. Кубрат хан, көтригур атка менгәч канатлана, дигән сүзнең дөреслегенә тагын бер тапкыр гына инанмаган иде инде. Фанәгүргә килеп төпләнеп киткән көтригурлар Кызкуыш туйларына[1] катнаша башладылар, болгар, хәтта грек кызларына өйләнделәр.

Соңгы елларда Фанәгүрдә халык ишәю сәбәпле кала күзгә күренеп

[1] Кызкуыш туе — болгарлардагы өйләндерү йоласы.

үсте. Рум төзүчеләре өйләр салсалар, тимерчеләре алачыкларда эшләде. Әмма болгар тимерчеләре дә корал һәм атлыга кирәк әйберләрне гаять дәрәҗәдә оста ясыйлар иде. Өзәңге, ияр, йөгән, ат башын каплагычларны болгардан да матур һәм нык итеп ясаучылар юк иде. Кубрат хан чит илдән килгән һөнәрчеләргә бөтен булган хокукларны бирде, аларның кайберләре хәтта болгарлардан өстенрәк хокукта яшәделәр. Хөкем иткәндә дә аларны бары тик хан үзе хөкем итте. Чит илләрдән килгән һөнәрчеләргә шундый ирек бирелү белән килешмәүчеләр дә булды, әмма Кубрат хан кылганында калды. Шул сәбәпле булса кирәк, Фанагүр каласының даны күрше-тирә илләргә бик тиз таралды. Фанагүргә төрле илләрдән һөнәрчеләр агылды. Читтән килгән кешеләрнең иң күп өлеше греклар иде.

Әйе, греклар иде Бөек Болгарның көчен-куәтен, дәрәҗәсен үстерүчеләр. Базилевс бу турыда белсә дә, күзен йомды, Патшакаладан Фанагүргә китәргә теләгән кешеләрне тоткарламады, җибәрде, әмма һәр икенче кешегә диярлек нинди дә булса бурыч йөкләде. Ахыр чиктә, нинди генә илдә яшәмәсен, кемгә генә хезмәт итмәсен, грек барыбер грек булып калачак, дип уйлады. Философ Иоанн Фасиан белән патриций Симеон Болгарга бик вакытлы киттеләр. Болгар куәтләнеп килә. Кыска гына вакыт эчендә көнчыгыштагы төрле кабиләләрне канат астына җыйган Кубрат хан тиз генә христиан динен кабул итмәс. Мәгәр базилевс фанатик Симеонга ышанып җитмәсә дә, философ Иоанн Фасианга зур өмет баглый иде. Болгар ханы философның акыллы сүзләрен тыңлар, тыңламый хәле юк, тыңлар-тыңлап да көннәрдән бер көнне, ханшасын ияртеп, чиркәүгә килеп керер. Иоанн Фасиан сиздерми генә кеше күңеленә керә белә, ул гүя сине әсир итә, күп тә үтми аныңча уйлый, аныңча фикерли башлыйсың. Нәкъ менә шул кешене логофет белән архиепископ яратып бетермәделәр, имеш, еретик, имеш, чиркәүгә каршы сүз әйтә. Үз вакытында базилевс та াларга каршы әйтә алмады, философны яклап чыкмады. Якларлык чак идеме, илче Феофан улы Константинның императрица Мартинага гыйшык тотуын беләләр. Ә көндәше Константиннан ничек котылу юлын әнә шул логофет өйрәтте. Кубрат ханга хат язарга һәм Константинны этисе белән Фанагүргә җибәрергә кушты. Базилевс нәкъ логофет әйткәнчә эшләде һәм уңды. Кубрат хан Константинны алып калган. Базилевсның Кубрат ханга рәхмәте зур иде. Дин мәсьәләсендә базилевс бернәрсәне бервакытта да исеннән чыгармады: нинди генә йолага табынмасын, кеше иң әүвәл үзе инанган динне тыюны яратмый. Бу — хакыйкать. Чөнки кеше дингә рухы белән керә, җанын бирә. Ә кешедә җан белән рух үлемсез. Византия империясенең беренче императоры Диоклетиан христиан динен кабул итми, тәңрегә табына, хәтта үзен тәңре илчесе итеп игълан итә. Мәгәр эллиннарда куәт алып, көчәеп, зур ташкын булып килгән христиан дине Диоклетианның да рухын сындыра, үзе император тәхетендә утырганда христиан динен кабул итмәсә дә, аннан соң тәхеткә килгән император Констанций Хлорның улы Константин элекке диннән баш тарта һәм христиан динен дәүләт дине итеп игълан итәргә мәҗбүр була. Диоклетиан чорында ук Рим өстенлеген югалта башлый. Император Диолектиан — Көнчыгыш Римне Византия итүче кеше. Аны мактарга кирәк иде дин әһелләренә, ә юк, аларны аны гүя белмиләр дә, алар бары тик бер изге Константинны беләләр, аны гына данлыйлар. Диоклетиан христиан динен кабул итми. Ни өчен?.. Ярлыларны яклаганга, изелгәннәрне. Христиан дине үзенә табынган кешеләргә дөньялыкта чакта ямьшы белән килешүне, буйсынуны таләп итә, якты дөньядан киткәч исә җәннәткә керүне, яисә кылган явызлыклары өчен тәмугта януны коткыларның да коткысы итеп ала. Европада христиан диненә каршы торырлык йола булмый. Шундый хәлдә дә император Диоклетиан беркемгә дә буйсынмый, үзе алла, үзе хода, үзе патша була. Ә монда базилевс дин

әһелләреннән башка бер адым да ясый алмый. Ике-өч гасыр эчендә Византиядә христиан дине ныгый, үсә, хәтта күрше-тирәдәге варварлар иленә үтеп керә, аларны берәм-берәм канат астына җыя башлый. Бөек Болгар империя өчен чираттагы ил иде. Ләкин соңгы елларда Мөхәммәт пәйгамбәр байрагы астында гарәпләр күтәрелде, сарациннар үз тирәләрендәге илләрне буйсындырып, Византия империясе чикләренә килеп җиттеләр, империя биләмәләренә кергән шәһәрләргә яу чаба башладылар. Кыска гына вакыт эчендә Византиянең берничә дәүләт-шәһәре сарациннар кулына күчте. Сарациннар ташкыны анда гына тукталып калмады, Хәзәр диңгезе янына килеп тәрәлде. Империя өчен менә шундый гаять җаваплы вакытта көнчыгыш тарафта форпост булып үсеп чыккан Болгарны кулдан ычкындыру ярамастай хәл булыр иде.

Күптән түгел базилевска Иоанн Фасианның «Белем чишмәсе» дигән китабын тапшырдылар. Китапны философ Иоанн Фасиан Болгарда язган иде. Иң гаҗәбе шул булды император Ираклий өчен, китапны философ аңа багышлый. Кулына үзенә багышланган китапны алуга, базилевс аны укып чыга, гаҗәп дәрәҗәдә ошата, шундук Фанәгүргә Иоанн Фасиан исеменә күп итеп бүләкләр җибәрә һәм аның илгә кайтуын сорый. Әмма Иоанн Фасиан тыйнак кына итеп тагын бер-ике елга Болгарда калырга рөхсәт сорап базилевска хат яза. Император рөхсәт бирә, мәгәр Иоанн Фасианны куарга мәҗбүр иткән архиепископ белән логофетны бик нык орыша, мин сезне үзегезне Болгарга сөрәм дип яный.

Бу вакытта Болгарның башкаласы Фанәгүрдә йөзләрчә сәүдәгәр яши, алар хан тарафыннан салдырган сарайда үз йолаларын мактап, көн-төн бәхәсләшәләр. Византиядән, Сүриянең Димәшкъ шәһәреннән, Хорезмнан, Табгачтан килгән халыклар, император Ираклий тарафыннан үз илләреннән куылган яһүдләр, базарларда сату-алу сәгатьләре беткәч, сарайга кайтып, гаделлек эзләп төкрекләрен чәчә-чәчә бәхәсләшәләр, сүз көрәштерәләр. Кайчак эшләр коралга кадәр барып җитә. Әмма хан сакчылары тегеләрне бик тиз сүрелдерәләр, коралларын алалар, анда да тынычлана алмаганнарын төрмәгә ябып, ике-өч көн суда тотып, сабырландырып чыгаралар.

Үзенең йомшак мөгамәләсе, сизгер күңеле белән тоеп ала Иоанн Фасиан Кубрат хан да сәүдәгәрләр арасындагы бәхәсләр белән кызыксына. Әмма ханны философның төп фикере күбрәк тарта: кеше ул — үзенә күрә бер дөнья, ә кешенең тәне, җаны акылга ияргән җисеме генә.

Иоанн Фасианның шактый катлаулы булган фәлсәфәсен Кубрат хан аңлап ук җиткермәсә дә, төптәңре Ирсан аңлый иде. Философ Иоанн Фасиан христиан дине көчеге патрикий Симеон белән Кубрат ханны үз йолаларына күчерергә килгәннәр. Симеонны төптәңре башта ук санга сукмады, бер сүз белән — фанатик, аны юлдан алып ташлавы авыр булмаячак. Ә менә философ Иоанн Фасиан төптәңре өчен шактый каты чикләвек иде. Шулай да төптәңре Кубрат ханны аның кулына тиз генә бирмәс, соңгы чиккә кадәр көрәшер. Болгар халкы мең еллар буена тәңре йоласына табына, ә аны яңа тапи йөреп киткән христиан йоласы йотарга тора. Булмас ул! Болгар халкы төптәңрегә ышана. Бөек Болгар ханы Кубрат та онытмасын иде: дәүләт төзүгә, җәйләүләрен киңәйтүгә ул иң әүвәл тәңре йоласына бурычлы.

Тәңре йоласын христиан диненнән йолып калу өчен иң әүвәл төптәңре илханнарга мөрәҗәгать итәр. Хан картаеп бара. Башта тәхеткә илханнарның берсен утыртырга. Әйе, әйе, аннары ул бөтен грекны Румга кудыртыр, салынып яткан чиркәүләрен җимертер, көлен күккә очырыр. Христиан диненә күчеп өлгергән болгарларны астырыр, кистерер, ат коерыгына тактырыр. Әйе, төптәңре моны гомерен корбан итеп булса

да эшләр. Ахыр чиктә ул Йулыш каганның алдына барып баш орыр, аны Болгарга алып килер, яулатыр, бөтен Дулу ыруын юк иттерер, әмма халкын христиан йоласыннан йолып алып калыр.

## 3

Төптәңре илханнарны, кайбер кавханнарны турыдан-туры грекларга каршы котырта башлагач, Кубрат хан алостаз Дәян белән киңәшергә булды. «Ни кылырга төптәңре Ирсан белән?»— дигән сорауны куйгач, алостаз Дәян зур мәҗлес җыярга һәм шунда төптәңрене чакыртырга кушты. Төптәңре болгар халкы алдында күрәзә итеп йөри, сүзе хак килгәндә: «Күктә — тәңре, җирдә — мин»,— дип әйтергә ярата иде. Кубрат хан алостаз Дәянның киңәшен тотып, мәҗлес җыйды һәм мәҗлескә килгән төптәңрегә мондый сорау куйды:

— Төптәңре Ирсан, син үзеңне күктә — тәңре, җирдә — мин, дип йөрисең. Әгәр чынлап та җирдә син тәңре икәнсең, әйт миңа, мәҗлес алдында әйт: тагын ничә ел миңа тәхеттә утырасы?

Төптәңренең җавап бирми хәле юк, чөнки төптәңре Болгарда иң абруйлы кеше, тәңре илчесе, аның сүзе — аткан ук. Ул ни әйтә — шулай була. Һәм аңа башка бер кеше сорау бирсә, нәкъ ул әйткәнчә дә булыр иде, монда бит хан үзе бирде сорауны, җитмәсә соравы нинди? Каян белсен ди Кубрат ханның тагын ничә ел тәхеттә утыруын төптәңре Ирсан? Әйтер ике ел дип, Кубрат хан өч ел утырыр, әйтер бер көн дип, Кубрат хан өч көн утырыр да төптәңренең күрәзәлеген юкка чыгарыр. Аннан инде ханнан мәрхәмәт көтмә, ат коерыгына тактырмаса да, кая булса да сөрер, я булмаса башын чаптырыр. Иң яхшысы — хан алдына килеп баш ору. Ирсанның атасы ханнарга баш бирмәүдән харап була. Иелгән башны кылыч кисми.

Төптәңре әкрен генә кузгалды да хан каршына килеп баш орды.

— Олуг хан, ханнар гомере белән төптәңре эш итми, ханнар гомере белән бары тик тәңре үзе эш итә. Мин исә бары тик синең колың гына, олуг хан,— диде.

Мәҗлестә шау-шу купты, әле генә күз алдында күрәзә һәм илаһи кодрәткә ия төптәңре гап-гади кеше булды да калды. Кара син аны, төптәңре бер дә күктән төшмәгән икән бит, ул да безнең кебек үк кеше икән ласа. Инде күрегез, кардәшләр, Болгарда Кубрат ханнан да акыллы кеше юк икән бит! Төптәңре түгел, олуг хан Кубрат үзе тәңре илчесе...

## 4

Византиядән килгән яучылар хөрмәтенә җыелган мәҗлескә буйтурлар [1], кавханнар, тарханнар да чакырылды. Илбарыс багатыр да табында утыра. Мәрхүм Саклаб кавхан угланы Илбарысның хан гаиләсендә тәрбия алуы турында чит илдән килгән кунаклар да беләләр иде. Сарайда җыелган мәҗлесләрдә Илбарыс багатыр һәрчак илханнар белән янәшә утырды. Бөек Болгар дәүләте башы Кубрат хан шат иде. Шатланмаслыкмы, моннан җиде ел элек ярәшкән кызына яучылар килде. Булачак кияү дә исән-сау икән, кызлары да исән-имин буй җиткерде. Әмма кызның әнисе ханша Аппак борчулы иде. Ул әле кызына карый, әле хан гаиләсендә тәрбия алган Илбарыс багатырга. Илбарыс багатыр Чәчкәдән күзен дә алмый, әйтерсең соңгы тапкыр күрә. Моны күреп-күзәтеп утырган ханша түзмәде, Илбарыс угланга тамак кырды: «Илбарыс углан, сиңа әйтәм, гел бер Чәчкәгә генә карап утырма, кунаклардан яхшы түгел»,— диде. Әмма Илбарыс багатыр ханшаны әллә ишетте, әллә

[1] Буйтур — унмең гаскәр башы.

юк, үзе белән һични кыла алмый, һаман хан кызы Чәчкәгә карап утыра. Ул өмет итә иде әле. Бәлкем, соңгы чиктә булса да олуг хан биргән вәгъдәсеннән ваз кичәр — кызы Чәчкәне базилевс угланы Юстинианга бирмәс. Белә бит олуг хан, аның кызын багатыр Илбарыс та ярата, белмәмешкә салышса да, белә. Теләсә олуг хан кызы Чәчкәне багатырга да бирә ала, төркиләрдә хан кызларын багатырларга бирү тузга язмаган гадәт түгел. Әмма моңа барырмы олуг хан? Юк, бармас. Ханның шатлыгы йөзенә бәреп чыккан, чөнки илханияләрне илханнарга кияүгә бирү ул — политика, бер гаилә кору гына түгел. Ул гынамы, Чәчкә белән Юстинианның кавышуы ике халыкны кызыл җеп белән бәйләр. Мәгәр нык булырмы ул җеп? Чак кына тартылуга да өзелеп китмәсме?.. Юк, өзелмәс, император Ираклий белән Кубрат ханның дуслыгын ныгытыр. Әйе, юкка өмет итә Илбарыс багатыр, юкка. Яучылар белән әнә рәссам да килгән, иртәгә ул Чәчкәнең рәсемен ясарга керешер, аны Румга алып китәрләр, булачак кияве Юстинианга күрсәтерләр. Күрер дә кияү хан кызын, таң калыр. Никадәр гүзәллек!

Күрә бит, белә бит Илбарыс багатыр, Чәчкә үзе дә Патшакалага китәргә теләми. Әмма аны барыбер Патшакалага алып китәрләр. Бүген түгел икән — иртәгә, иртәгә түгел икән... Заманында Тугрыхан кызы Аппак та үз җәйләвендәге бер багатырны яраткан булган, әмма Тугрыхан кызының теләге белән исәпләшеп тормаган, тоткан да Аппакны Кубрат ханга биреп җибәргән. Горур һәм тәкәббер көтригур кызы да атасы сүзеннән чыга алмагач, йомшак табигатьле, ата-ана сүзеннән беркайчан да чыкмаган Чәчкәгәме каршы торырга?! Бәлкем, Чәчкә дә тора-бара анасына охшар. Кирәк чакта Аппак Кубрат хан белән орышларга да чыккан, диләр. Хәзер дә Кубрат хан ханша белән киңәшмичә бер эш тә кылмый. Башта киңәшә, соңыннан үзенчә кылса да, киңәшә...

Иң әүвәл көмеш табакларда ризык-нигъмәтләр килде, аннары алан иленнән китерелгән озын муенлы җиз амфоралар белән грек эчемлеге куйдылар. Кайсын мөгезгә, кайсын җамаякка салып, кем ни тели шуны койдылар.

Олуг хан торып басты.

— Кунаклар, кардәшләр, аксакаллар, кавханнарым, тарханнарым,— дип, сүзыбрак башлады Кубрат хан, аннары истәлекчегә күз төшереп алды.— Истәлекче, яз. Эт елында мин, Бөек Болгар ханы Кубрат үземнең җәйләүләремне илханнарга бүлеп бирергә булдым. Мин картайдым, эт картайса, ятып өрер, дигән Әтнолан[1] бабабыз. Менә шушы мәҗлестә кунакларым алдында мин...,— табын өстендә «аһ» дигән аваз эленеп калды. Кемдер елап җибәрде, кайберәүләренең күзләре дымланды, бары тик төптәңре генә, дөрес ишетәме колагым, дип, тын алырга куркып, утырды. Төптәңренең йөзендә куаныч чалымнары күреп, Кубрат хан күзен-кашын җимерде. Юкка куанасың, мин беркая да: җир астына да, тәңре янына күккә ашарга да җыенмыйм, бары тик җәйләүләремне генә илханнарга бүлеп бирәм дигәндәй, кырыс кына карап алды. Хан торып басуга, табын тып-тын булды.— Аксакаллар, кавханнар, минем биш угланым, кызым Чәчкә бар. Чәчкә кызымның тәңре теләге белән язмышы хәл ителде. Инде хәзер мин җәйләүләремне угланнарыма бүлеп бирергә булдым. Истәлекче, бу юлларны алтын белән яз: өлкән угланым Батбайга — аланнар иле, миңа буйсынган тау ягы халыклары булыр; Кодрак илханга — Эске кирмән. Төн илләре җәйләүләрем; Аспарух илханга — Урта Әтил. Тын елга җәйләүләрем: Балкыр илханга — Түбән Әтил бүе көтүлекләрем, миңа буйсынган Даду даласында яшәүче халыклар булыр. Аслан төпчегем бире кайтыр. Мин әйттем, аксакаллар.

«Тәңрем, тәңрем, тәңрем»,— дип кабатлап торучылар булды.

---

[1] Әтнолан — Атилла.

— Кызым Чәчкә, кил әле бире. Сез дә, илханнар, яныма килегез. Чәчкә кызым, бир Батбай абаңа менә бу бер учма укны,— хан кызына бер учма ук бәйләме бирде.— Бир, кызым, Батбай абаңа учманы.

Батбай илхан горур тестә түргә узды, сеңелесе кулыннан бер учма укны алды.

— Инде сындыр, Батбай илхан, шул учма укны,— диде Кубрат хан.

Батбай учма укны тезенә салды, сындырырга теләде. Учма ук сыгылып килде, илханның муен тамырлары бүртеп чыкты, битенә кан саулы, маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты, әмма учма укны сындыра алмады.

— Булмый, атам — диде Батбай һәм, маңгаендагы тирне җиңе белән сөртеп, учманы кире Чәчкәгә бирде.

— Хәзер син ал, Кодрак илхан,— диде хан.

Киңчә җилкәле, калкандай күкрәкле, атасыдай төптән юан чыккан гәүдәле Кодрак илхан зур-зур атлап килде дә сеңелесе кулыннан учманы алды. Учманы тезенә куйды. Илханның муен тамырлары чыбыркы сабыдай бүртеп чыкты, учма ук җәя булып бөгелде, әмма сынмады. Чират Аспарухка җитте. Аспарух илханның беләк сеңерләре чытырдады, йөзенә гүя ут капты, буйтур бу тамаша көч салуга, учма менә-менә сынар кебек тоелды. Мәгәр илхан юкка көчәнде, юкка тырышты — учма сынмады. Балкыр илхан да учманы сындыра алмады, төпчеге Аслан Патшакалада иде. Ахырдан хан кызы Чәчкә учмадан укларны берәмберәм суырып чыгара һәм сындырып ташлый торды. Табын гөр килде. Уклар сындырылып беткәч, олуг хан кулын күтәрде, мәҗлескә тынычланырга кушты.

— Угланнар — илханнар! Бабаларыбыз, аерылганны — аю ашар, бүленгәнне — бүре ашар, дигәннәр. Бер учма уктай бердәм яшәгез, бердәм-тату яшәсәгез, сезне беркем дә җиңә алмас, җәйләүләрегезгә малларын кертмәс. Инде бер-берегездән аерылышып, һәркем үз ыруы, үз биләмәләре өчен генә кайгыртса,— җәйләүләрегезгә дошман керер, кәләшләрегезне, кардәшләрегезне, сеңелләрегезне, бөтен ыруыгызны турап ташларлар, сөңге белән кадап үтерерләр, ир-егет затларыгызны кол итеп сатарлар. Бердәм булган — береккән, ялгыз калган — кол иткән. Кәңәш иткән — уңар, кәңәшсез — туңар. Бердәм кәңәшеп яшәгез. Шул булыр, илханнар, минем сезгә әманәтем. Мин әйттем, кардәшләр, аксакаллар, кавханнар!

Сүзе беткәч, Кубрат хан илханнар янында утыручы үги оланы Илбарыс багатырга карады.

— Инде, Илбарыс багатыр, син бире кил.

Илбарыс багатыр хан ягына атлаганда табында чышын-пошын сөйләшү китте. Илбарыс багатыр хан янына килеп баскач, хан аңа билендәге путасын салып бирде.

— Багатыр, син бәйләмең белән Кодрак илханда булырсың.— Хан пута өстенә хәнҗәрен, кылычын салды.— Мин сиңа, багатыр, үз алаемнан бер төмән алай бирәм. Аксакаллар,— дип кавханнарга карады олуг хан.— Эске кирмәннән хәбәр килде. Угры Чалбай хан Эске кирмәнне алган, андагы кардәшләребез болгар-грекларны әсир иткән. Угрылыгын антлар эчеп тә ташламаган Чалбай ханны кирмәннән куып чыгаруны Саклаб кавхан угланы Илбарыс багатырга йөклим.— Кубрат, киңәш сорагандай ханшага карап алды, ханша ана сизелер-сизелмәс кенә ияк какты.— Кирмәнне Чалбай кулыннан ал, Этил, Чулман елгалары буенда яшәүче төрки-угор халыклары белән сәүдә эшен җайга сал. Үзең кирәк тапкан иң оста алыпларны, мәргәннәрне алаемнан сайлап ал. Кирмәнне алуга, Фанәгүргә хәбәр җибәр.— Хан хәзинә башы кавханга бармак изәде.— Кавхан багатырга хан казнасыннан Димәшкъ сәүдәгәрләреннән алган көмеш табак-савытлар, кирәк кадәр корал, көтүлегеннән ат бир. Багатыр, бүләкләрне Болгар белән сәүдә итәргә ки-

лешкән кабилә башлыкларына бирерсең. Кайтышлый кайнешем Көбер ханга керерсең, аңа Румнан килгән алтын табакны бүләк итәрсең.— Хан тамак кырды, ашап-эчәргә кыстап йөргән табынбашка күз төшереп алды.— Чалбай ханның башын кисеп Фанагургә җибәрерсең. Кодрак илхан яруы белән үз биләмәләренә Димәшкътан кайткач күчеп китәр. Болгарга асыл корычтан ясалган Димәшкъ кораллары кирәк. Кодрак илхан шунда чыгып китәр. Мин әйттем.

Илбарыс багатыр хан биргән әйберләрне артында басып торган ярдәмчесенә сузды, бирде дә хан алдында бил бөкте.

— Олуг хан, атам, йөкләгән ышанычың аклармын. Этил-Чулман буендагы халыклар белән сәүдә эшләрен җайга салырмын. Болгарның Эске кирмәнен кайтарып алу өчен гомеремне дә кызганмам.

— Сувар кавхан, орыш атларының башы, багатырга иң яхшы атларны бир,— диде хан,— орышларда даннары арткан алыпларым бир.— Хан карашы белән алостаз Дәянны эзләп тапты.— Алостаз Дәян, сине Илбарыс багатыр белән җибәрәм. Мин әйттем.

Алостаз Дәян озын, чандыр гәүдәсен урталай бөкләп, ханга ризалыгын белдерде.

— Инде ашагыз, эчегез,— диде хан.— Таган ата, кыста кунакларны, китер кымыз, китер эче бал.

Ашап-эчкәч, табындагылар шаулаша башладылар, Кубрат хан ханша Аппак белән киңәшеп утырды. Шуннан хан кинәт кутәрелле дә:

— Халаек [1], кунаклар килү хөрмәтенә, илхан Кодрак белән Илбарыс багатыр юлга чыгу хөрмәтенә иртәгә, диңгез буенда Кызкуыш уздырырга булдым. Сөрәнчеләр, халыкка бүген үк оран салыгыз. Мин әйттем.

Көтелмәгән бу хәбәрне күтәреп алдылар, өйләнмәгән багатырларның түбәләре күккә тиде, баш киемнәре чөелде, ул да түгел сөрән салучылар иртәгә Кызкуыш туе, орыш уеннары була дип оран сала-сала, калага чыгып киттеләр. Барысы да белә иде: бу төндә, бу төндә генә түгел, бу ике төндә бер генә кыз да керфеген йоммаячак, сөйгәне-сайлаганы турында уйлап чыгачак, таңредән сөйгәненең куып җитүен теләячәк.

Кодрак илхан да, Илбарыс багатыр да юлга Кызкуыш туеннан соң гына чыгып китәргә өстәмә боерык алдылар. Шул боерыкны алганнан соң Илбасыр багатыр урынына килеп утырды һәм Чәчкәдән күзен дә алмады. Ханша тагын багатырның бу карашын ошатып бетермәде. Мәҗлес тәмамланып бетәр-бетмәс Чәчкәне ияртеп чыгып китте.

Аш бүлмәсендә Кубрат хан һәм яучылар гына калды.

## 5

Башта төптәңре Ирсан Илбарыс багатырны эзләп табарга булды. Ул да кимсетелгән кеше, бүген-иртәгә Эске кирмәнгә китә, төптәңре аңа да күңеленә килгән шиген сөйләргә тиеш. Ятим бала аны ярата, хөрмәт итә, аңа ышана. Ятим угланны Кубрат хан кимсетте. Дөрес, углан юкка өмет итә, булмастай хәлне өмет итмәсен иде. Әйтергә кирәк, хан кызы Чәчкәгә өмет тотма, диярга кирәк. Багатыр аны аңлар, ул аны улыдай якын күрә. Ни өчен? Төптәңре белә дә, белеп тә бетерми кебек иде, әмма ниндидер бер аңлашылмаган хис аны шул балага тарта иде. Әллә инде анасын яратканга мы?.. Әллә инде мәхәббәт дигән нәрсә шулай аналарыннан балаларына күчәме?.. Тәңре үзе шулай яздымы икән әллә аңа?..

Иң әүвәл Илбарыс багатыр аңа ярдәм итәр. Кубрат хан картайды,

---

[1] Халаек — җәмәгать.

әнә үзе үк: эт картайса, ятып өрер, дип әйтә. Аның урынына илханнарның берсен хәзерләргә кирәк. Кемне, кайсы угланны?.. Менә монысы караңгырак иде әле төптәңре өчен, әүвәл илханнарны сынныйсы бар иде. Кайсы нинди уй белән яши?.. Бу эштә Илбарыс багатыр төптәңренең беренче ярдәмчесе булыр. Углан илханнар белән бергә уйнап үсте, бер табыннан ашады, бер төрле кием киде. Әйе, олуг хан булып бары тик төптәңре Ирсан теләгән илхан гына ак киездә күтәрелергә тиеш.

Ишегалдына төптәңре килеп керүгә, кораллар караштырып утырган Илбарыс багатыр аптырый калды.

— Углан, әйдә әле, йөреп керик,— диде төптәңре, күңел тынычсызлыгын сиздереп.

Багатыр, карусыз, төптәңрегә иярде. Урамга чыктылар, илханнар яшәгән урамга юнәлделәр. Сөйләшмәделәр, күңелләр сөйләште. Илбарыс багатыр бу кешегә гадәтләнеп килә иде инде.

— Углан,— диде төптәңре, үз урамнарына килеп чыккач.— Углан, ташлама мине. Мин синең кебек үк ягим кеше.— Төптәңре туктады да багатырның күкрәгенә кагылып алды. Илбарыс багатыр ни кыларга белмичә каушап калды:

— Төптәңре, төптәңре, мин сине ташламам, мин сине атамдай якын күрәм,— диде.

Тел очына рәтле сүз килмәде.

— Углан, мин синең анаңны ярата идем, өйләнмәвемнең сәбәбен беләсең... Олуг хан теләмәде... Сиңа ул кызы Чәчкәне бирмәс, кансыз ул, шәфкатьсез...

— Хан андый түгел, түгел, төптәңре. Әйтмә алай, минем сиңа рәнҗуем бар...

— Рәнҗе,— диде төптәңре кисәк кенә читкә тайпылып.— Рәнҗе, багатыр. Рәнҗи-рәнҗи кимсетел...

Һәм төптәңре борылды да китеп барды.

Багатыр кире өенә кайтты, әмма төптәңре белән очрашудан соң тиз генә йокыга китә алмады.

Иртән багатырны уң кулы Адай уятты:

— Багатыр, багатыр, кояш чыга, тәңредән матур көн телик.

— Матур көн телик, Адай, төптимерчегә барыйк, яхшы кораллар алыйк. Төптимерче ясый коралларның асылларын.

Яңа туган көнне каршы алгач, ашадылар-эчтеләр дә тимерчеләр урамына киттеләр. Тимерчеләр урамына килеп кергәндә, анда чаң да чоң тимер чүкиләр иде инде. Тимерчеләр Кубрат хан алаена калканнар, очлы сөңгеләр, кылыч, хәнҗәр, уклар, бик оста итеп, очлым [1], күкрәк, терсәк, тез башы каплагычлары ясыйлар иде. Көбә ясаучылар аерым, көбәне фарсыдан килгән осталар ясый. Әйбәт кылычларны, хәнҗәрләрне, ятаганнарны греклар җитештерәләр. Багатыр таныш грек алачыгына юнәлде. Төптимерче грек аларны күрүгә, җирән сакалын сыпырып, ике куллап күреште, түрдәге сәкегә әйдәде. Тимерченең биләндә үгез тиресеннән теккән алъяпкыч, чылгый мыекларының очлары көйгән, күзләрендә мут елмаю. Алачык түрендәге сәкегә утырышкач, төптимерче тамак кырды:

— Багатыр, хак булса, миңа җитте: сине олуг хан Эске кирмәнгә җибәрә икән?

— Җибәрә, төптимерче. Шул сәбәпле миңа корал кирәк.

— Болай булгач,— диде төптимерче һәм кузгалып ләгәндә кулын юып килде,— Тавир, күрек басуың туктатып тор әле.

— Сине түләү борчый кебек, төптимерче?

— Тимерче Агасике коралларын алтынга гына сата, багатыр. Белеп кердегезме икән?

[1] Очлым — шлем.

— Белеп кердем, төптимерче Агасике. Белеп кердем. Әүвәл кораларың күрсәт, оста.

— Корал булыр ул. Тавир, чыгар товарны, барысын да чыгар. Багатыр әнә Эске кирмәнгә яу белән китә, ә анда минем кардәшләр дә бар. Алып бармас микән төптимерче Агасикене дим, ә?

— Җаны теләгән — җылан иңе ашаган, төптимерче. Ниятең изге булса...

— Әй, Тавир, уклар да китер.

— Юк, төптимерче, укларны синнән алмыйбыз. Укны грек ясый белми, укны болгар оста ясый.

— Анысы хак,— диде Агасике килешеп, аннан соң батыр каршына өелгән коралларга ымлады.— Болар барысы да минем кулдан узды, багатыр. Юньгә бирәсем килми диюем...

Хикмәтле кеше иде төптимерче. Гомере буе диярлек Фанагүрдә яши, әмма үз диненә ышана, муеныннан тәресен салганы юк. Кайбер греклар исә болгарларга килеп төшүгә, далага чыгып китәләр, ә йолалары турында бөтенләй оныталар. Болгарларның иркен яшәүләре, гореф-гадәтләре ошый булса кирәк. Закон кешене кимсетә, буйсынырга мәҗбүр итә, ә болгарлар бернинди законга да буйсынмыйлар, аларның беркатлы, әмма кешене рәнҗетми торган гореф-гадәтләре бар. Закон астында тыелып, басылып яшәгән кеше, далага качып, күчмә халык арасына эләккәч, иркенләп сулыш алып куя. Менә кая икән ул җәннәт, ә аларга чиркәү әһелләре ул җәннәтне үлгәч кенә күрерсез диләр.

Багатыр кораллар өчен төптимерче Агасике учына уннан артык алтын дирһәм салды. Төптимерче алтыннарны алъяпкыч кесәсенә койды, уңлы-суллы чукынып алды. Шуннан соң гына тимерчеләренә кул изәде: янәсе, башлагыз.

Төптимерче алачыгында өч-дүрт кол тота иде. Кубрат хан тарафыннан болгарларга кол тоту тыелса да, Румнан күчеп килгән осталарга рөхсәт ителә иде. Бүген тимерчедә ике кол эшли. Берсе чүкеч белән эш итә, икенчесе күрек баса. Дәү чүкеч белән эш итүче кол аксыл чәчле, зәңгәр күзле, урта буйлы адәм иде. Багатыр аның юан беләкләренә карап торды-торды да:

— Агасике, сат миңа бу колың?— диде.

Грек хәйләкәр елмайды, кол ягына күз төшереп алды, аннары чылгыйланып килгән, очлары көйгән мыекларын сыпырып:

— Колым сатмыйм, мин аны үзем белән алам,— диде.

— Кил әле бире,— диде колга багатыр,— Әй, син, бире кил, дим!

Кол теләр-теләмәс кенә алар каршына килеп басты. Багатыр аны янә баштанаяк карап алды.

— Мин аны шул ике-өч ел эчендә менә дигән тимерче иттем, багатыр.

Илбарыс багатыр төптимерчегә ун бармагын тырпайтты.

— Сатмыйм дидем, багатыр. Мин аны үзем белән алам. Минем синең алаеңда буласым килә, багатыр.

Шул чак кол тимерче дәү чүкече белән идәнгә орды.

— Беләге юан берне егар, белеме бар меңне егар, дигәннәр, хак әйткәннәр өлкәннәр,— диде Агасике.

— Кабаланма.— диде багатыр колга.— Иректә жиргә баш орып алмыйлар, яу чабып алалар. Мин риза, Агасике, җыен. Китәсе көнне сиңа Адай хәбәр итәр.

Төптимерчедән чыккач, алар кием тегүчеләр, савыт-саба, чүлмәкчеләр урамнарыннан уздылар һәм төп сарай бөҗрасына килеп чыктылар. Әнә төптәңре өе. Төптәңре Ирсанны күргән бер кеше аңа бил бөгә, ак юл тели. Кыска муенлы, иңенә бигүк күзгә ташланмаган чапан салган, башына туладан баскан кәләпүш кигән, күкрәгенә уч төбеннән зуррак кояш сурәте төшерелгән алтын тәңкә таккан төптәңре юлында очрап,

күзеңә туры караса, бермәлгә каушап каласың. Бу кешедә тәңре үзе биргән илаһи көч бар сыман. Үзенә шикләнебрәк караган, каршы килгәндә бил бөкмәгән кешене төптәңре туктатыр да «Төптәңре көче чиксез, ул бер мизгелдә җир йөзендәге һәммәбезне юк та итә ала, шушы җирдә гөлбакча да булдыра ала. Җирдәге һәммә тереклек тәңре кодрәте белән яши. Барча нигъмәт тә, җир куеныннан чыккан май да тәңренеке. Тели — бирә, тели — тартып ала. Синең өстеңдәге чапан да аныкы. Ышанмасаң, кояшка бак, бераз карап тор».

Кеше күккә карый, кояшта күзе чагылудан ни кыларга белми, шуннан кеше төптәңренең сүзләренә ышана, аңа бил бөгә-бөгә китеп бара.

Төптәңре аларга каршы очрады. Багатыр да, уң кулы Адай да, күкрәкләренә кулларын куеп аңа бил бөктеләр.

Төптәңре алар белән исәнләшүгә, багатырны җитәкләп алды, туры Аспарух илхан өенә алып китте. Илхан өенә ул үз-үзенә ышанып, ишекне каерып ачып керде. Илхан аларны гаҗәпләнебрәк каршы алды.

— Рәхим итегез, кунаклар. Түрдән узыгыз,— диде илхан һәм чаршау артындагы хатынына нидер әйтергә өлгерде.— Утырышыгыз, кадерле кунаклар. Каравыш [1], кунакларга кымыз китер!

— Эчемлек тә биримме, илханым,— дип, чаршау артыннан каравыш кыз килеп чыкты. Ләкин кымызны каравыш кыз түгел, илханның хатыны алып керде, ул тыйнак кына кунакларга баш иде, чүлмәк белән кымызны түр яктагы таш өстәлгә куйды, чокырлар китерде. Шуннан ул багатырны чаршау артына дәшеп алды.

— Багатыр, каенсеңлем сине ярата. Атам-анам риза булсалар, мин Кызкуыш туенда аннан тоттырыр идем, ди.

— Нәрсә сез анда пышылдашасыз!— дип, алар янына илхан килеп керде. Шул чакта урамда сөрәнченең Кызкуыш туена чакырган ораны ишетелде.

— Мин багатырны Кызкуыш туенда катнашырга котыртам,— диде яшь хатын.

— Котыртма, башта Эске кирмәнне алып, угры Чалбай ханның башын кисеп Фанәгүргә җибәрсен,— диде илхан һәм багатырны түр якка алып чыгып китте.

Барысы да өстәл тирәли утырышкач, төптәңре сүз алды.

— Илхан Аспарух,— диде ул, кулындагы мөгезне кыса төшеп.— Буйтур Аспарух, әйтче миңа, олуг хан атаң нигә гел философы Иоанн белән көннәрен уздыра?

— Төптәңре, атам яуда яралангач, грек табибе терелтте. Алимче [2] белән син булдыра алмадың. Әйтмә сүз грекларга, алар Болгарны утрак тормышка күчермәкчеләр. Алар миңа да якын халык. Хак, минем гомерем җәйләүләремдә уза... Алай да, алай да, төптәңре...

— Хуш,— диде төптәңре һәм мөгездәге эчемлекне күтәреп эчеп җибәрде.— Хуш, илхан. Син дигәнчә булсын. Әмма ил өстенә яу килгәндә Кубрат хан ни кылыр?! Греклар сиңа кылыч тотмас, грек Фанәгүрне, Кубрат хан җәйләүләрен якламас. Ханга элек болгар белән көтригур кирәк иде, хәзер грек кирәк булдымы?!

— Мин олуг хан түгел, төптәңре. Мин бары тик илхан гына. Соңгы сүзне миңа әйтергә бирсәләр, мин дә грекларны яклар идем...

— Болгар грек түгел, аның дине дә, өне дә башка. Император илчесе Иоанн Фасиан Болгарга христиан динен таратырга килгән, империя Болгарны үз канаты астына җыймакчы.

Менә илханның хатыны килеп кереп ирләрнең сүзен бүлдерде:

— Ирләр, иртәгә Кызкуыш туе, багатырга эчемлек бирмәгез. Аның

---

[1] Каравыш — хезмәткә алынган кыз.
[2] Алимче — имчеләр башы.

кыз куасы бар,— диде ул, башындагы калпак һәм күкрәкчә тәңкәләрен чылтыратып.

— Житте, житте, хак сүз, житте, без киттек,— дип, төптәңре беренче булып урыныннан купты.

Аннан соң алар Батбай илханга килеп керделәр. Өлкән илхан аларны колач җәеп каршы алды, түр якка алып кереп китте һәм каравышларына:

— Эчемлек, ризык китерегез!— дип кычкырды.

Алга килгән эчемлекләрне татып карагач, төптәңре Батбай илханга да шул ук сорауны бирде.

Бу сорауны көтмәгән өлкән илхан чокырны өстәлгә куйды, бер тын шәмәхә эчемлеккә карап торды.

— Кеше чүлмәк түгел, төптәңре, аны чиртеп карап кына белеп булмый. Атамның философны сынап каравыдыр...

Җавап төптәңрене канәгатьләндермәде, әмма илханның кырт кисмәве аңа ошады.

— Илхан, атаң картайды, ә син өлкән углан. Атаң әнә үзе ук эт картайса, ятып өрер, ди. Ятып өрергә генә калды атаң, өлкән илхан. Яу чабарга кирәк. Кардәш хәзәрләргә түгел, Роська, мажарга, угорга. Ә олуг хан кул кушырып утыра. Эске кирмәнне Чалбай хан алды, Кирмәнне кайтарырга кимендә ун төмән алай җибәрергә иде, ә хан бер төмән йырмач[1] алай җибәрә. Чалбай ханның багатырны җиңеп куюы бар. Олуг хан булсаң, син ни кылыр идең, илхан?

— Минме,— диде Батбай һәм тураебрак утырды.— Мин иң әүвәл Фанагүрдән грекларны куар идем, тугандаш хәзәр каганына барып баш орыр идем.

Төптәңре як-ягына карап алды, түшендәге кояш сурәтен сыйпап куйды.

— Ышанычны ышаныч аша табалар, илхан. Мин сине олуг хан итү өчен сәләтем кызганмам, кирәк икән гомерем дә бирермен. Багатырга ышан, илхан. Багатыр да Кубрат хан яклы түгел, ул да хан корбаны. Хәбәр итүләренә караганда, Чалбай ханда ике төмән алай бар. Ә багатыр бер төмән алай белән кирмән алырга бара. Олуг хан греклардан болгарны богаулатмакчы. Патрикий Симеон чиркәүгә куяр өчен ханшаның сурәтен ясый. Иртәгә булмаса, берсекөнгә чиркәүгә чаң сугарга кыңгыраулар куячаклар. Ул чиркәүне төзетергә түгел, җимерергә кирәк, җимерергә, җир белән тигезләтергә!

— Булмастай эш бу, төптәңре. Рум белән Болгар солыхта, император белән олуг ханның балалары ярәшкән.

— Ярәшсен, ярәшсен, илхан, ярәшсен. Бетерергә! Кызкуыш туенда мин кан кардәшләребез хәзәрләрне күрергә телим, кара сакаллы, мәкерле грекларны түгел. Сер итеп кенә әйтим, Батбай илхан, Йулыш каганың уң кулы Җаек бәкнең кызы бар. Ай да ай, ул да ай. Керфекләрен кагып караса, күзләреннән гөлләр тама. Йулыш каган Кубрат хан белән туганлашмакчы, хан кызы Чәчкәгә яучылар җибәрмәкче икән. Син дә яучы җибәр Җаек бәккә, илхан. Юк, Биләмҗиргә үзең илче булып бар. Шунда әйтерсең сүзең... Җаек бәк сиңа үзенең җәйләүләрен бирер, Йулыш каган уң кулы итәр.

— Төптәңре, миңа атам биргән җәйләүләр дә бик житкән. Ыру-җаным ун төмән, алай-җаным сигездән узды. Чор каласы, Тимер Капка[2] минем кулда. Анда минем тарханым утыра, тау халыкларыннан ясак җыя. Атама каршы сүз катсам, кавханнары ишетер, атам мине ат коерыгына тактырыр, Кодрак илханга тәхетен бирер.

— Тәхетне олуг хан түгел, тәңре бирер сиңа, илхан. Сиңа язды тә-

[1] Йырмач — алдан разведка ясаучы гаскәр.
[2] Тимер Капка — Дербент шәһәре.

хетне тәңре, син утырасы Болгар тәхетенә. Бүген утырмасаң, иртәгә, иртәгә утырмасаң...

— Тәңрегә иманам, атама ышанам, төптәңре. Тыел, көчләмә мине. Багатыр, әйт, хак сөйлимме мин?— диде Батбай чарасызланып.

— Илхан хаклы, төптәңре. Ана таба, ата бага, тәңре юл сала адәмгә. Язмыштан — узмыш юк.

— Хак, багатыр, хак! Мин дә, төптәңре, язмышым тәңрегә тапшырырга булдым...

— Моңа дин дә, ил дә, тәхет дә кирәкми,— дип үзалдына сөйләнә-сөйләнә атлады төптәңре.— Син борчылма, багатыр, Батбай илхан барысын да мин дигәнчә эшләр. Күктә — тәңре, җирдә — мин. Мин илханнарны шулай сыныйм. Илгә булган игелекләрен сыныйм. Сыналган — бер откан, сынаган — ике откан. Батбай илханда өмет бар, ул уйланыр. Уйланыр-уйланыр да минем белән килешер. Аңа башка юл юк. Башка юллар ябык аңа.

Кодрак илхан белән Балкырга төптәңре кермәде. Алар белән боткасы пешмәсен ул сиземли иде. Өлкән илханга ышанычын җуймаса да, ышана иде. Җаек бәк кызы төркидә бер чибәр. Килерсең әле, илхан, төптәңрегә, килми чараң калмас...

Кәефе кырылгангамы, төптәңре сарай каравылчыларына рөхсәт таңкәсен дә күрсәтмәде. Әмма каравылбаш аны туктатты, айбалталар чалышынды.

Илбарыс алга чыкты.

— Каравылбаш, төптәңреңне танымыйсыңмы әллә?

— Таныйбыз, Илбарыс багатыр, таныйбыз. Хан боерыгы.

Төптәңре алтын таңкәсен чыгарды каравылбашка күрсәтте, аңа карап багатыр да таңкәсен чыгарды.

— Төптәңренеке алтын, синеке көмеш кенә, багатыр,— дип шаяртты каравылбаш. Каравыл алыплар мәргән багатырны сабан туйлары саен уздырылган ярышларда күрәләр, аның өчен горурланалар иде.

Төптәңре багатырны үз өенә алып китте. Ялгыз яшәгән төптәңренең ишегалды гөлбакча иде. Кем үстерә, кем карый бакчаны, һичкемнең күргәне юк. Өй ишегенә җитәр-җитмәс төптәңре кулларын күтәрде һәм, багатырны гаҗәпкә калдырып, ишекләр үзлегеннән ачылып киттеләр. Ул да түгел алар каршында чуендай кара гарәп пәйда булды. «Әллә җир астыннан чыкты инде бу җен-пәри?»— дип уйлады багатыр һәм гарәпкә карый-карый түргә узды. Кара гарәпкә төптәңре нидер әйтте, кол шундук ялтырап торган мәрмәр өстәлгә эчемлек, җиләк-җимеш китереп куйды. Һәм күз каршында торган гарәп кисәктән күздән югалды. Багатыр шомлана калды, куркынып төптәңрегә карады. Төптәңре гүя аны күрми иде, ул бик тәфсилләп алтын чокырларга эчемлек коя иде.

— Эч, багатыр. Минем сиңа сүзем озын булыр.

Эчеп куйдылар, янә өстәл янында кара гарәп пәйдә булды. Һәм кыяр-кыймас кына:

— Кымыз биримме, ширбәтме?— дип сорады.

— Икесен дә китер,— диде гарәпкә карамый гына төптәңре.— Кипкән балык та керт.

Гарәп күз ачып йомганчы көмеш табакка салып, сораган ризыкларны китереп тә җиткерде. Төптәңре алтын чокырларга тагын эчемлек койды.

— Эч, углан, эч. Хан сине барыбер Кызкуыш туенда йөртмәс. Аның өчен сиңа я аны юк итәргә, я тәхетен Батбай илханга биргәнен көтәргә туры киләчәк... Хак, хак әйтәсең, син аны хөрмәт итәргә тиешсең, сиңа ул бик күп изгелекләр эшләде. Иң яхшы сарай мәктәбендә укытты, грекча язарга, укырга өйрәтте. Укытучыларың грек булгангамы, син дә әнә аларны яклап утырасың.

— Мин сиңа, төптәңре, бу сүзләрне әйтмәдем. Каян белдең?

— Жиргә кояш төшми тормый, багатыр, илгә сүз чыкмый тормый. Чәчкәне сөюең илханнарга да, ханшага да билгеле. Олуг хан да беләдер. Чәчкәгә җыр чыгаргансың икән, тыңладым, колакка ятышлы, күңелгә җылы өсти җырың. Җырны ханша Аппак та яратып җырлый. Син җыр җанлы кеше, ә хан синең кулыңа кылыч тоттырды. Курайда, башка көй коралларында уйнарга иде сиңа. Фанәгүрдәге Рум халкы әнә атна саен диңгез буена төшә, җырлый, бии, күңел ача. Без дә чәчкә бәйрәмнәре уздырдык, килешле җырлар ишеттек, кыз оланнар ир теләп диңгезгә чәчәкләрдән тезгән таҗлар ташладылар. Болгар халкы да бәйрәм итә белә. Тик христиан дине генә канат астына җыймасын иде аны. Тиздән барысы да үзгәрер, багатыр. Нил буйларыннан сарациннар кузгалган икән, базилевс шәһәр арты шәһәр, дәүләт арты дәүләтен югалта. Минем дә Патшакалада шымчыларым бар, багатыр. Хәбәр итә торалар. Император Ираклий алай җыя икән, сарациннарга каршы чыкмакчы. Тиздән базилевсның да Болгардан кайгысы китәчәк. Император итәк астыннан ут уйната, ул хәзәрләрдән кораллар ала, аларга корал сата икән. Император ике куянны берьюлы тотмакчы: ике туган халыкны үзара сугыштырмакчы. Карап карыйк, башта сарациннар белән үзе алышып карасын әле. Улы Юстиниан тиздән Чәчкәне алырга килер. Ә ул арада...

— Бу дөрес түгел, төптәңре, дөрес түгел!

— Сарациннар империя җирләренә керә алмаганда, Тимер Капка аша Болгарга ташланырлар. Болгарны үзенеке итү өчен базилевска Кубрат хан белән кардәшләшү кирәк. Император моңа ирешер, ирешеп тә килә бугай инде. Мин өметем җуймыйм әле, багатыр. Батбай илхан акылга утырыр, Йулыш каганга барып башияр. Сиңа, батыр, әйтер сүзем шул: Эске кирмәндә Мангыш тарханның кызы бар. Йөзе — кояш, керфекләреннән нур тама, кашлары — җәя, авызы — уймак, буйсыны кипарис диярсең, гүзәлләрнең гүзәле. Чалбай хан күптән кодалап йөри диләр кызны. Угры ханга Мангыш тархан бирмәгәндер, шуннан Чалбай хан кирмәнне басып алгандыр. Кирмәнне алсаң, Кызкуыш туе булыр һәм туйда шул кызны ку. Шул булыр сиңа минем сүзем, багатыр...

Юата алмады багатырны төптәңре, егетнең йөрәген күптән хан кызы Чәчкә биләгән иде инде.

— Мин Чәчкәне сөям, төптәңре, мин аның өчен кирәк икән үләргә дә әзер.

— Ахмак, дивана. Кызлар өчен ирләр үләме. Ирне ир итүче сыйфат — батырлык. Батыр булып, җиңеп кайтсаң, илдә бер чибәргә өйләнерсең. Хан кызлары бары тик илханнарга гына язган, багатыр. Баш белән ташны орып булмый.

Эчендә давыл дуласа да, төптәңрегә кайтарып сүз әйтмәде багатыр. Тик төптәңре озата чыгып, капкага җиткәч кенә:

— Хан кызы Чәчкә дә мине сөя,— диде.

Бу юлы төптәңре дәшмәде, багатырның сүзен колак яныннан уздырды, әмма кунак китеп барганда:

— Егет кешегә сөю гаеп түгел, сөймәү гаеп, багатыр,— диде.

Күктә йолдызлар җемелди, Каф тавы артыннан иренеп кенә мөлдерәп тулган ай күтәрелеп килә. Күп тә үтмәде бөтен тирә-юнь ай нурына күмелде. Ярсулы, тәвәккәл иде бу мәлдә багатыр. Ни өчен? Ул моны үзе дә белмәде. Мәгәр күңеленә хәтәр котокы утырган һәм бертуктаусыз кытыклап, күңелне котыртып тора иде. Төптәңренең сүзләре багатырны тәмам ярсытты, бәгыренә ачуташ салды, йөрәгеннән кан тамардай итте. «Чәчкәне, аның сөйгәнен император оланы Юстинианга бирәләр һәм ул аны тиздән килеп алачак. Бәлкем, ул киткәч үк булыр...»

Илбарыс багатыр йөгерә-атлый, ярсынган йөрәген тыя алмаудан га-

җиз булып, хан сарае капкасына юнәлде. Каравылчылар дәшми генә багатырның юлын бүлделәр.

— Олуг хан ял итә, берәүне дә кертергә кушмады.

— Миңа хан кирәкми, миңа ханша кирәк, кызы Чәчкә!

— Чәчкә анасы белән диңгез буендагы Кызсарайга китте, багатыр.

Миңа хан кирәкми дисә дә багатыр, Кызсарайга таба кузгалгач, төптәңре сүзләрен Кубрат ханга җиткерә алмавына үкенү тойды. Әмма аны барыбер хан янына уздырмаслар иде. Ырып-ерып керә кала икән, каравыл алыплар аны ябып куячаклар. Кубрат хан каравылга иң батыр алыпларны куя. Ул боларны ханшага җиткерер. Кызсарайга ул ничек тә үтеп керер. Ә ханша аның сүзләрен иртәгә үк ханга әйтер.

Илбарыс багатыр диңгез буендагы Кызсарайга йөгерде, аның артыннан һау-һаулап каравыл этләре өреп калды. Диңгезгә җитәрәк багатырны ике каравылчы куып җитте, икесе ике яктан култыклап алдылар.

— Илбарыс багатыр бит бу,— диде берсе.— Кичер, багатыр. Без сине шымчы дип белдек.

Каравылчылар китеп барды, багатыр Кызсарай янына килде. Багатыр диңгез яклап, тез тиңентен судан Кызсарай диварына җитте. Сарайда, ханша бүлмәсендә ут яна. Чәчкә бүлмәсендә караңгы, ут юк. Димәк, әнисе белән кич утыралар. Кыз белән ана арасында нинди сүз булмас. Багатыр диңгез ярыннан килә-килә капкага җитте. Бу капкадан кереп булмаячак. Багатыр яр як капкага юнәлде. Капкага якынлашуы булды, эчтә каравыл дәште.

— Һәй, кем бар анда?

Багатыр дәшмәде, Кызсарай янында ят кеше күрсәләр, каравылчылар сөрән салачак, анда инде качып котылам димә. Багатыр дивар буйлап, көнбатыш якка күчте. Монда кечкенә яшерен ишек бар иде. Мәгәр монда да каравылчының аяк тавышлары ишетелде. Әйе, сарайга керим димә. Бердәнбер чара, ыргак ташлап, аркан белән мену. Моның өчен кимендә дүрт-биш кул буе аркан кирәк. Күп уйлап тормастан багатыр өенә йөгерде, ыргаклы аркан алып килде. Ыргакны ишектән шактый читкә китеп ташлады. Ләң-ләң этләр өрә иде, каравылчы ыргак тавышын ишетми калды. Багатыр өскә үрләде. Менә ул инде дивар өстендә. Багатыр ыргакны кире яктан эләктерде һәм сак кына йортка төшә башлады. Инде төшеп җиттем дигәндә урам яклап кече капканы дөбердәтә башладылар. Багатыр җиргә сикерде, караңгы почмакка посты.

— Кем анда капкада?— Каравыл барысы да ишетсен өчен тамак ерып кычкырды.

— Мин бу — төптәңре, ач, минем ханшага йомышым бар.

Кече капканың шудыргычы шылтырап куйды, келәләр ычкынды, чылбыр тавышлары чыңлап китте, шыгырдап, кече капка ачылды.

— Ханша биредәме, каравылбаш?

— Биредә, төптәңре, кызы белән кич утыра.

— Дәш ханшаны, каравылбаш. Хәер, тукта, үзем менәм.

Каравылбаш хәтта төптәңре «үзем менәм» дигәндә дә авыз ачып сүз әйтмәде. Төптәңредән барысы да куркалар иде.

Тегеләр сөйләшеп торган арада, багатыр диңгез ягындагы тәрәзәгә күчте. Ул ишетте, бүлмәдән ханша чыгып китте. Багатыр тиз генә тәрәзәгә таш ташлады. Бүлмәдә шундук ут сүнде, тәрәзәдән Чәчкә үрелеп карады.

— Чәчкә, мин бу.

— Багатырым,— диде Чәчкә каушап.— Багатырым, мин моннан төшә алмыйм.

— Мин сиңа ыргак ташлыйм, Чәчкә.

— Кирәкми, багатырым, мин синең яныңа үзем чыгам. Иә үзең кер, мин ишекне ачам.

— Үзең чык, Чәчкә.
Күп тә үтми Чәчкә ишегалдына чыкты, сак кына багатыр янына килде.
— Багатырым,— диде ул һәм килә-килешкә егеткә елышты.— Мин сине сагындым, минем сине күрәсем килде. Анама әйткән идем, ул орышты.
— Әйдә диңгез ярына чыгабыз, Чәчкә?
— Әйдә кече капкага?
— Анда каравыл, Чәчкә.
— Каравыл безне җибәрер, ул шундый әйбәт көтригур.
— Анаң кардәше?
— Әйе, багатырым.
Капка янына җиткәч, җир астыннан чыккандай, алар янында каравыл пәйда булды.
— Багатыр,— диде ул гаҗәпләнүен яшермичә,— айдан төштеңме әллә?
— Айдан төштем, кардәш. Мә сиңа ике алтын.
— Алтын,— дигән булды каравыл.— Илхания...
— Ал, ала күр,— диде Чәчкә.— Без диңгез буенда йөреп киләбез, Бавырбаш.
— Сез түгел, син, илхания. Анаңа шулай дип әйтермен.
— Сине хан багатыр итәр, каравыл. Илхания әйтте диярсең, багатыр итәр.
Алар кулга-кул тотынышып, диңгез буйлап йөгерделәр. Бала чакта да шулай кулга-кул тотынышып йөгерәләр иде. Ул чакта да, Чәчкәнең кулы уч төбенә керүгә, әллә нишләп китәр иде Илбарыс. Багатыр исенә килә алмый йөгерде, чынлап та аның белән янәшә сөйгәне Чәчкә йөгерәме? Төшендә генә түгелме?.. Юк, төшендә түгел, өнендә, күктә ай, һавада диңгез исе, йолдызлар сибелә. Ай яктысында Чәчкәнең чәчләре тоташ көмешкә буялган сыман, аның буй-сыны да тоташ көмеш кебек иде.
Йөгереп барган шәпкә багатыр кызны кулына күтәреп алды һәм диңгезгә кереп китте. Чәчкә аның муенына сарылды, ике куллап кочаклады.
— Диңгезгә ташларга исәбеңме, багатырым,— дип, назланып пышылдады кыз.
— Әйе, Чәчкә.
— Барыбер миңа буласы түгел, суга ташлап котылыйм дисеңме?
— Син барысын да беләсеңмени, Чәчкә?
— Беләм, багатырым.
Егет кызны судан алып чыкты, аягына бастырды.
— Чәчкә... Мин яратам сине, Чәчкә!..
— Син минем багатырым, син минем...
Илбарыс багатырның кыз сүзләреннән бөркет булып күккә күтәреләсе, аргамак булып далага чыгып очасы килеп китте. Саклаб кавханның олуг хан гаиләсендә тәрбияләнгән угланына гүя канат үсеп чыкты, гүя ул чынлап та күккә ашты. Чәчкә аны ярата, ярата! Ләкин моны белсәләр, ике дә уйламый багатырның башын кисәчәкләр. Кем ул? Колмы, багатырмы? Нигә аның хан кызына өйләнергә хакы юк?! Нигә?!
Диңгез өстеннән салмак җил йөгереп узды, дулкыннар ай нурыннан көмеш төс алып, узыша-узыша йөгерешеп киттеләр, юк, дулкыннар түгел, диңгез өсте көмеш тәңкәләр белән чуарланган. Йөгереп кереп җыеп аласы иде дә шул тәңкәләрне, көшел-көшел итеп хан алдына китереп өясе иде. Бу байлыкны күреп, ханның күңеле йомшар һәм ул аңа кызы Чәчкәне бирергә риза булыр иде. Бирми хәле юк, чөнки ханнар да, каганнар да алтын-көмешкә туймыйлар.
— Чәчкә, Чәчкә, син әйттеңме бу сүзне миңа, Чәчкә?!

— Мин, мин багатырым.

Җил йөгереп узуга, тынып калган диңгез өстенә ай нурыннан көмеш сукмак сызылды. Күтәреп аласы иде дә хан кызын, китәсе дә китәсе иде шул сукмактан, айга барып җитеп, тәңрегә әйтәсе иде: «Тәңрем, насыйп ит миңа хан кызы Чәчкәне, бәйлә чәчләребезне чәчкә...»

— Мин сине күтәрмен, багатырым. Ай, ел, гомерем буена күтәрмен.

— Гомерең буена... Анаң Аппак сарайда калдымы?

— Аны төптәңре дәшеп алып чыгып китте.

— Иртәгә Кызкуыш туе... Мин төптәңремә сине куам дигән идем.

— Кызкуыш туе,— дип моңсуланды Чәчкә, аннары башын күтәрде дә:— Ку мине бүген, багатырым. Ку Чәчкәңне. Ку-у!

Шулай диде дә Чәчкә диңгез буйлап йөгереп китте. Кызның чәчләре тузган, Рум ефәгеннән тегелгән күлмәге ай яктысында елтыр-елтыр килә, алтынга буялган башмакларыннан зөбәрҗәт очкыннары сибелә кебек иде.

Менә су өсте күренде, кыз суга җитсә, ул аны тота алмаган була. Егет соңгы мәлдә генә, диңгез читенә бик аз калгач кына кызны куып тотты. Кыз «Аһ» диде дә егетнең күкрәгенә капланды. Егет аның кулыннан алды һәм якындагы агачларга таба китте. Анда ай күләгәсе, анда әрсез айдан качып, йөрәк серләрең әйтеп була. Агачлар арасына җитү белән багатыр Чәчкәне кочагына алды. Кызның чәчләреннән исерткеч хуш исләр килә иде. Йөрәге дөп-дөп кагудан багатыр ни әйтергә, ни кыларга белми торды. Сүзләр артык иде сөйгәннәргә, йөрәкләре сөйләшә иде.

Биектә-биектә, күк йөзендә берсеннән-берсе көнләшеп җемелдәгән йолдызлар арасында адашып калган ай йөзә. Ай ике яшьнең йөрәк сөешүеннән агарынып көнләште, салкын нурларын чәчә-чәчә кайнарланган йөрәкләрне сүрелдерергә теләде, мәгәр ай яшьләрне күрмәде, ахыр ул йолдызлар атарга тотынды. Әмма йолдызлар әллә теләп, әллә теләмичә, әллә сөйгәннәрне яклап, җиргә җитәр-җитмәс янып, суынып, таралып беттеләр.

Ахырда ай түзмәде, оялып ашъяулык кадәр генә болыт астына кереп посты.

Алар Кызсарай янына килгәндә көнләшүеннән тәмам бүртенә башлаган ай Каф тау артына кереп бара иде инде. Капка янына җиткәч, Чәчкә багатырның күкрәгенә башын салды.

— Инде синсез мин нишләрмен, багатырым!.. Мин сине көтәрмен, көтәрмен, көтәрмен...

Илбарыс багатыр тынычлана төште. Чәчкә аны чынлап та ярата. Аны бирәү дә көчләп император оланы Юстинианга биреп җибәрә алмас.

Капка ачылды, яшьләр читкәрәк тайпылып, диварга сыендылар. Әмма капкадан берәү дә чыкмады. Илбарыс биредә көндезләрен булгалый торган хәлләрне күз алдына китерде. Әкәмәт була торган иде сәүдә кораблары килгәч Кызсарай янында. Сәүдәгәрләрнең кораблары килеп туктауга, тарханнар хан өлешен алырга өлгерер-өлгермәс, товарлар карарга ханша үзе килер, аңа ияреп кавхан, буйтур хатыннары, бер тапкыр Кызкуыш туенда куылып, яисә ирен яуда югалтканнан соң яңа ир таба алмаган бичәләр, матурдан-матур киенгән кала кәнтәйләре җыелыр иде. Кала кәнтәйләре, ханша теләгән әйберләрен алып киткәч сәүдәгәрләр белән чытлыкланырлар, хатыннарның котыртып йөрүләренә каннары уянган сәүдәгәрләр йомшак җирләренә кагылуга, рәвешен китереп, тегеләре чәрелдәп куярлар иде. Яңа кияүгә чыккан яшь хатыннар, ирләренә ярарга тырышып, матурдан-матур тукымалар сайларлар, алырга таңкәләре җитмәгәндә аһ-ух килерләр, сәүдәгәрләргә сырпаланырлар, парчалы тукымаларны буйларына куеп, юри әйләнгәләп, зифа сыннарын күрсәтерләр иде.

Чәчкә дә кияүгә чыккач, шундый булыр микән? Юк, булмас. Чәчкә андый түгел, Чәчкә аларның берсенә дә охшамаган.

Кызның йомшак, хуш исле чәчләрен тансыклап-тәмләп иснәгәндә кисәк кенә сарай эчендә моңлы бер җыр ишетелде. Чәчкә дә, Илбарыс та шым булдылар. Җыр шундый моңлы, сагышлы иде ки, йөрәк кысылып куя, ә сагышлы моң ачык тәрәзәдән тышка саркып чыга, иртәнге томан булып дингез өстенә ята иде.

Илбарыс багатыр да, Чәчкәдән аерылмас борын ук, күңелендә сагышлану хисе уянуын тоя. Чәчкәсе янында, ә ул аны сагына да башлады инде.

— Тыңла җырны, буйтурым. Тыңла да хәтереңә сеңдер. Кыз чагында анам бер егетне яраткан, ә бабам Тугрыхан анамны атам Кубрат ханга биреп җибәргән. Яшьлектә сөйгән егетен анам әле дә булса оныта алмый. Безне инде беркем дә аера алмас, багатырым. Эске кирмәнне алып кайткач, атам мине сиңа бирер. Мин сине атамнан үзем сорармын, Кызкуыш туенда кудырырмын. Мин йөгереп тә тормам, килермен дә кочагыңа иңәрмен. Атам мине аңлар, буйтурым, каршы төшмәс...

— Күрче, Чәчкә, бу төптәңре түгелме? Шул бит. Яңа чыгып килә. Ананны озатып куюымы?

Илбарыс белән Чәчкә диварга тагы да сыена төштеләр. Төптәңре Ирсан ашыга-кабалана кала ягына китеп барды. Шул чакта әле яңа гына алар басып торган агачлар арасыннан аңа каршы берәү чыкты. Менә алар очраштылар, бик аз гына сөйләшеп тордылар. Аннары шулай ук кабалана-ашыга агачлар арасына кереп киттеләр, ул да түгел әйләнеп тә чыктылар. Бу юлы теге кешенең иңбашында нидер бар иде. Менә ул диңгезгә таба китте, аңа төптәңре иярде. Текә яр янына життеләр һәм әйберне суга ташладылар.

«Кемнәр болар? Берсе төптәңре. Ни ташладылар? Шик юк, тәңре теләгән кабул итсен өчен төптәңре кемнедер корбан иткән. Кемне? Гарәп колынмы?» Шулай дип уйласа да, Илбарыс бу турыда Чәчкәгә әйтергә кыймады.

— Мин керим, багатырым,— диде кыз,— анам югалткандыр.

Шул чак, җир астыннан килеп чыккандай, алар янында төптәңре күренде. Шым гына капкага таба узды.

— Сабыр ит, Чәчкә. Төптәңре китсен.

— Багатырым, бәгъерем, анам күрер атама житкерерләр, газиз башың яман җәлладтан чаптырырлар, диңгезгә ташларлар.

— Олуг хан сине император угланына бирсә, мин аңа каршы чыгармын, Чәчкә.

— Каф таулары артына, далалардагы ерак җәйләүләргә күп илларга чыгып китсәң дә, мин сине көтәрмен. Чалбай ханны җиңеп кайт, атам ризалыгын бирер...

Якында гына кемдер тамак кырды, ул да түгел яшьләр каршына төптәңре килеп басты. Моны көтмәгән яшьләр калтыранып киттеләр, чарасыздан бер-берсенең кочагына сеңделәр. Коточкыч хәл иде. Әле генә төптәңре капкадан кереп китте кебек иде. Юк, төптәңре үзе түгелдер бу, аның өрәгедер. Тылсым, сихер белгән төптәңредән барысын да көтәргә була иде.

— Оланнар,— диде төптәңре.— Күктә — тәңре, җирдә — мин. Ялгыша күрмәгез. Чәчкә, анаң сине сарайга озатырга кушты. Ә син, багатыр, юлыңда бул. Синдәй кешеләргә баш җәллад кылычыннан киселер өчен бирелми.— Төптәңре кызны кулыннан эләктереп алды да, җилтерәтеп капка янына алып китте.— Әй, каравыл, ач капканы. Ач капканы, явыз, кылган языкларың тәңре алдында сөйләрсең.

Каравыл капканы ачты, төптәңре кызны эчкә кертеп җибәрде, каравылны тышкы якка сөйрәп чыгарды.

— Син чыгардыңмы, әйт! Син чыгардыңмы хан кызын?!

— Чәчкә, Чәчкә!— дип кычкырды ханша тәрәзәдән.

Эчтән ярсыса да, багатыр төптәңредән каравылны җуеп алырга кыймады. Килде дә төптәңре алдына тезләнде.

— Кичер аны, төптәңре, кичер. Изгелегең онытмам.

Төптәңре каравылчыны капкага таба этеп җибәрде, багатырны аягына бастырды.

— Углан, бар кайт. Иртәгә орыш уеннары була. Кыз кумасаң, үрнәгең күрсәтерсең. Батыр кеше — балда йөзми...

Багатыр кала каравыллары аша узгач кына бераз тынычлана төште. Җансакчысы йокы аралаш:

— Таң атып килә түгелме соң, багатыр?— диде.

— Юк әле, йокла, кузгалма,— диде багатыр һәм түр якка, үз бүлмәсенә узды.

Багатыр кояш чыгар-чыкмас кына уянып китте. Урамнарда сөрәнчеләр, уеннарга, Кызкуыш туена чакырып, сөрән салалар иде инде. Хан боерыгын карусыз үтәргә өйрәнгән халык, төркем-төркем булып, диңгез буена агылды. Күп тә үтми олы тугайлыкта мәйдан булдырылды, урта бер төбәккә колга кадалды. Болгарның зәңгәр төстәге әләме эленде. Мәйдан читенә хан һәм кунаклар өчен чатыр корылды. Шул тирәгә хан үзе, илханнар, кунак-кардәшләр, илчеләр, исемнәре өч-дүрт илдә билгеле булган сәүдәгәрләр җыелды. Колгалар белән бөтен кала буйлап, Кызкуыш туена йөгерәсе кызлардан җыелган бүләкләр китерелде. Бүләкләрне җыйган җайдаклар юырттырып мәйданга килеп керделәр. Җыенбаш бүләкләрне колгага бәйләде. Аннары күтәрелеп килгән кояшка карап:

— Туем-җыеным буласы көн, төкле аягың белән ту, туем-җыеным матур узсын, җыйган бүләкләр илдә тузсын...

Күтәрелеп килгән кояшка табынырга дип, чатырдагы олуг хан да чыкты. Бары тик илчеләр, чит илләрдән килгән сәүдәгәрләр генә утырган урыннарында калдылар. Шулай да соңгы мәлдә Кубрат хан аларга төксе генә күз төшереп алды. Илен хөрмәт итсәң, динен дә хөрмәт ит... Шулай дип аңладылар илчеләр Кубрат ханның карашын. Патрикий Симеон, аңа ияреп философ, аларга карап калган кунаклар да күтәрелеп килгән кояшка баш ордылар. Философ көлемсерәп патрикий Симеон ягына карап алды. Кайчандыр кояшка табынган грекларны мәҗүсилектә гаепләп, философиягә, медицинага, тарихка караган китапларын яндырып йөргән иде патрикий Симеон. Шуның өчен бу кеше император тарафыннан патрикий титулы алды. Ә монда үзе янә кояшка табына башлады. Әмма урынына килеп утыргач, патрикий Симеон чукынып, иреннәрен кыймылдатып, укынып карасын төзәтте. Моны ул ашык-пошык эшләде, хан күрмәгәе дип курка иде. Мәгәр хан кемнеңдер христиан диненә фанатикларча табынуын гаеп итми иде. Ул инде рәхәтләнеп, уен башлап җибәргән җыенбашка карап утыра иде.

Беренче булып мәйдан уртасына укчылар чыкты. Малай-шалай кәрзиннәргә тутырып чәүкәләр китергән. Бер чәүкә биш бакыр. Җыенбаш кәрзиннәрне янына тезеп куйды, бакыр акчалар көтеп торган малайларга үлән эченә бер уч бакыр ташлады. Малайлар өерелеп, акча чүпләргә керештеләр. Укчылар тезелеп мәйдан уртасына бастылар. Җыенбаш аларга нидер аңлатты. Аннары алар атларын юырттырып, мәйданнан чыгып киттеләр. Күп тә үтми әйләнеп тә килә башладылар. Беренче укчы мәйданга килеп керүгә, җыенбаш кәрзиннән бер чәүкәне алды да очыртып җибәрде.

Мәргән егет тезгенен җибәрде, очып киткән чәүкәгә җәядән атты. Әмма ук тимәде, кулдан ычкынган чәүкә кала ягына таба очып китте.

Гадәттә, мәргәннәргә бүләкне ханша бирә. Ханша алдында төрле иллардән китерелгән әйберләр. Бүләкләр төрле-төрле, көмеш белән бизәлгән ук савытларыннан алып, йөгәнле, иярле атка кадәр. Биредә көмеш тәңкәләр тезеп тегелгән йөгәннәр дисеңме, табгач ефәгеннән күлмәк дисеңме, сандал агачыннан эшләнгән тимердәй каты иярләр, калкannар, рум сәүдәгәрләре китергән бизәкле-чуклы ат япмалары дисеңме. Нечкә җептән тукылган йон күлмәкләр дисеңме. Күлмәк кан кызыл төстә булыр, сәдәфләре көмештер, яка өсте алтын җепләр белән чигелгәндер. Ханның иң оста мәргәнгә үз бүләге бар иде — иярле тулпар. Атны китереп үк куйганнар, бәйләнгән җирендә кешнәп, җир тырнап тора. Бүләк атның иярендә төрле төстәге тасмалар, җепләр тагылган. Тулпарның иясе булу өчен бик күп һөнәргә ия булырга кирәк. Әйтик, беренчедән, атта чаптырып килгән Җыенбаш очыртып җибәргән чәүкәгә ук тидерергә, ат корсагы аша чыгып, яңадан ияргә менеп утырырга. Элек бу уеннарга илханнар да катнаша торганнар иде, хәзер исә катнашмыйлар, карап кына торалар. Әллә аталары Кубрат кушмый, әллә үзләре үсеп җиттеләр. Кубрат хан Җыенбашка моны бик гади итеп аңлатты. «Тәңре кушуы белән дөньяга килгән илханнар уеннарга катнашмыйлар». Төптәңре ханга каршы сүз катырга теләгән иде, тыелып калды. Әйе, нигә ямьсезләнергә, аңа үз кайгысы бик җиткән. Ә менә тәрбиягә алынган Илбарыс углан һәр җыенда уеннарга катнашты һәм һәрчак бүләкләр алды.

Былтыр уздырылган уеннарда багатырга энҗеләр батырып бизәлгән саплы кылыч эләккән иде. Бүләкне аңа хан үзе тапшырды. Быел ни кылыр багатыр? Багатыр өчен иң әүвәл хан кызы Чәчкә кайгырып утыра иде. Кызның дулкынлануы йөзенә үк бәреп чыккан. Сөйгәне мәргәннәр арасына чыгып баскач, Чәчкә эченнән генә багатырга уңыш теләде, аты сөрлекмәсен, күзләре очлы булсын, угы Чәчкә теләгән җиргә тисен. Кызның борчылып, гел багатырга карап торуын сизеп алган әнкәсе:

— Гел аңа карап утырма, кунаклардан яхшы түгел,— диде.

Мәгәр яхшы белән яманны белми иде әле Чәчкә, ни тырышса да ул багатырдан күзен ала алмады.

Уктан атучылардан өч кеше мәргән чыкты. Алар арасында Илбарыс багатыр да бар иде. Куанычтан Чәчкә кул чабып куйды, ханша аңа янә усал итеп карап алды.

Ниһаять, Җыенбаш чаптырып килгән ат өстеннән чәүкәләрне атып төшерергә дип, мәргәннәрне мәйданнан ераккарак җибәрде. Мәйдан уртасына җиткән мәргән Җыенбаш очыртып җибәргән чәүкәгә ук тидерергә тиеш иде. Мәргәннәрнең берсе үтеп тә китте. Икенчесе мәйданга килеп керде. Чәүкә очыртылды һәм ук тишеп чыккан чәүкә таш булып җиргә төште.

Мәйдан гөр килеп, шаулап алды. Чәчкә янә куанычтан кул чапты, утырган урынында сикергәләп куйды. Ханша аңа карап ирен чите белән генә елмайды. Кубрат ханга күз сирпеде. Кубрат хан янәшәсендә утырган философ белән ни турындадыр сөйләшә иде.

Хан аларны күрмәсә дә, ханша кызы Чәчкә өчен тикмәгә генә борчылмый иде. Җиткән кыз булды, империя кадәр империя башында буласы кешегә кияүгә чыгарга җыена, ә үзе һаман сабый баладай кылана. Мәгәр тыштан хан белән килешсә дә, кайдадыр күңел төбендә баланы кызгануы кузгалгалап куйгалый иде. Соңгы сүзне ханшага әйтәсе булса, ул ике дә уйламыйча кызын Илбарыс багатырга бирер иде. Мәгәр ханнарда кызны чит илханнарга бирү политика белән бәйле нәрсә, монда хатын-кызларның кызгануы урынсыз. Ханга каршы чыкса, Кубрат аңа шулай дияр иде.

Ниһаять, атларны чабышка җибәрделәр. Бераздан алар күренделәр дә, атлылар мәйданга килеп керүгә, кәрзиннәрдә күпме чәүкә бар — барысы да һавага очырылачак. Көрәш өчен дә түгел, нәкъ менә шул уен өчен бәйләүдә хан бүләге — тулпар ат тора. Күп тә үтмәде, кемдер: «Киләләр, киләләр!»— дип кычкырды.

Чынлап та мәйданга җиде-сигез атлы якынлашып килә иде. Аларны күрер өчен хәтта хан да торып басты.

Илбарыс багатыр үткән ел шушы уенда бүләк итеп алган Кашка айгыр өстендә иде, хан аны ерактан ук таныды. Багатыр әлегә өченче булып килә.

Илбарыс багатыр мәйданга җитәрәк кенә атына камчы белән сугып алды. Кашка томырылып чаба башлады, менә бер атны узды, икенчесен. Менә мәйданга ике ук очар ара калды, бер... Тагын камчы төште Кашканың кабыргасына. «Һоп, һоп, Кашка! Алдыр!»— дип аваз салды Илбарыс. Ат, хуҗасының әйткән сүзләрен аңлагандай, сөлек кебек сузылып чаба башлады. Алар икәүләп, ике мәргән атлары тигез көйгә мәйданга килеп керделәр. Чәүкәләр очырылды. Буйтурның уң кулындагы мәргән чәүкәне шундук укка алды, багатыр төзәгән чәүкәне алды. Уклар төрле төскә буялган, җәяне киергән төштән багатыр аты үтеп киткәндә генә икенче чәүкәгә төзәде. Ләкин чәүкә ни сәбәпледер Җыенбаш аяк астына төшеп кунды, башка чара юк иде, багатыр җирдәге чәүкәне укка алды. Халык аһ! итте, мәйдан өстеннән: «Харап итте!» — дигән аваз узды. Чаптырып барган шәптән, багатыр ат астыннан чыгып, ияренә менеп утырды һәм борылып мәйданга әйләнеп килле.

Килгәч әйттеләр, бер карыш ялгышса, багатыр Җыенбашның аягына тидерәсе булган икән, әмма ук Җыенбашка тимәгән, чәүкәнең канатын тишеп чыккан, чәүкә очып китәргә тырышып, канатларын бәргәләп ята иде.

Бар мәргәннәр дә мәйданнан узгач , Җыенбаш мәйдан уртасына чыкты, кулын күтәрде.

— Халаек, беренче бүләк Кушкул кавхан угланы Илбәккә чыгадыр. Икенче бүләк Саклаб кавхан угланы багатыр Илбарыска булырдыр, өченче бүләк...

Ләкин халык инде Җыенбашны тыңламый иде, шаулый, гөжли башлады. Ур-ра кычкырдылар, баш киемнәре һавага очты.

Олуг хан урыныннан күтәрелде, халык әкрен генә тынычланды.

Ханга бүләккә дигән атны китереп тоттырдылар. Олуг хан атны җитәкләп, мәйдан уртасына чыкты, мәргән-чаптар егеткә атның тезгенен бирде. Янә ур-ра кычкырдылар. Аннары ханга Димәшкъ кылычы китерделәр, икенче бүләкне хан Илбарыс багатырга тапшырды.

Кулына ярсып торган атның тезгене эләккәч, чаптар-мәргән егет сикереп атка атланды, мәйдан икегә аерылды һәм ул очып диярлек мәйданнан чыгып китте. Мәргән егеткә бүген Кызкуыш туенда катнашасы кызлар кызыгып карап калдылар.

Менә Кызкуыш туена да вакыт җитте. Олуг хан кунаклар янына килеп утырды, мәйдан уртасына ханша чыкты, аның янына бирнәләр китереп куйдылар. Үз сөйгәнен тота алган һәр егеткә һәм кызга ханша бүләкләр бирәчәк иде.

Бар да беләләр, Кызкуыш туе алдыннан егетләр ике-өч көн буена йомырка эчәләр, ял итәләр. Әмма кызлар да житез йөгерергә тиешләр, югыйсә сине бөтенләй яратмаган егетең куып тотарга мөмкин.

Ниһаять, беренче кыз кызыл тасма сузган төбәккә килеп басты, аннан егерме адым кала егет басты. Ук очар арада егет кызны куып җитәргә һәм тотып ханша каршына китерергә тиеш. Еракта колга тора, колга башында кызыл яулык җилферди. Шуңа кадәр егет кызны куып



Т. Хажиәхмәтов рәсеме.

житә алмаса, яңадан кыз куарга хакы юк, киләсе елны көтә, ә кызлар исә өч-дүрт тапкыр куыша алалар.

Егетләрнең барысына да кыз тоту бәхете тимәс, әлбәттә. Әмма шайтан өметсез ди бит, ә кеше һәрчак өмет белән яши. Былтыр тота алмады күзе төшеп йөргән кызны, бәлкем быел тотар, бәлкем быел ул кыз да сабырлана төшкәндер. Әйтик, заманында төптәңре дә кыз куып караган иде, әмма арт ягы авыр булдымы, кыз бик җилле чаптымы — җитә алмады.

Түй башы Аппак кузгалу билгесе — ак яулык селкеп җибәрде. Кыз кош кебек очып китте. Тоттырмады егеттән, кире әйләнеп килде, тасмага басты. Кызны икенче егет куарга чыкты. Бу юлы кыз рәтләп йөгереп тә тормады, егеттән үзен тоттырды. Һәм алар кулга-кул тотынышып, ханша янына килделәр. Ханша аларга бүләкләр бирде, егет белән кызның чәчләрен чәчкә бәйләде. Чәчләрен чәчкә бәйләгән килеш мәйданнан чыгып китәргә тиешләр иде бер-берсен сайлаган яшьләр.

Тасмага тагы бер кыз килеп басты. Бераз көттереп егет чыкты. Аппак яулык болгады, яшьләр йөгерделәр. Егет кызны тотты һәм болар да ханша янына кулга-кул тотынышып килеп бастылар.

Өченче кыз егеттән тоттырмады, егет исә гарьлегеннән хәтта мәйданга да әйләнеп кайтмады, халык арасына кереп югалды.

— Ошамады кызга егет,— диде философка Кубрат хан.

— Ә мин, әтием, боларның барысыннан да мәхрүм,— диде Чәчкә. Кубрат хан кызына күз сирпеп тә карамады. Әмма атасына рәнҗемәде Чәчкә, кичәдән бирле аның күңеленә тымызык кына рәхәт коелып тора иде. Сөю һәм сөелүнең ни икәнен белә иде инде хан кызы.

Тасмага чыгып баскан кайбер кызлар рәтләп йөгереп тә тормадылар, шундук егеттән тоттырдылар, ә берсе үзе егеткә каршы йөгереп килде, йөгереп килде дә муенына сарылды. Чәчкә аларга көнләшеп карап утырды. Аны Илбарыс батыр куа чыкса, ул да колгага таба йөгереп тормас иде. Кызына игътибар иткән Кубрат хан, Чәчкә йөзенә чыккан куанычны күреп: «Яшьлек,— дип уйлады.— Йөгәнсез яшьлек. Аһ, үтә гомер, әле кайчан гына шушы бала аның тез өстенә менеп утырыр иде дә: «Әттә, әттә, мине пру-у ит»,— дип кинәнер иде.

Шулай Кызкуыш туе да үтеп китте. Кыз куучы егетләргә Илбарыс көнләшеп карады. Ул да кыз куса икән, тик ул куган кыз хан кызы Чәчкә генә булсын иде.

Кызкуыш туеннан соң мәйданга мәзәкчеләр, биючеләр, җыр-такмак әйтүчеләр чыкты. Ахырдан бөтен халык диңгез буенда хәзерләнгән мәҗлескә төштеләр. Биредә ике көн буена сугымчылар мал суйдылар, ашчылар аш пешерделәр, хәзерләнделәр. Шунда ук Рум сәүдәгәрләре китергән мичкә-мичкә эчемлек тора иде.

Кубрат хан мәҗлестә кунакларны үзе сыйлады. Янәшәсенә философ Иоанн Фасиан утырган иде, кәефләнеп киткәч, ханга «Киләсе елга, олуг хан, мин дә Кызкуыш туенда катнашам»,— дип сөйләнеп утырды.

Кич белән мәҗлестән кайткач, Кубрат хан философны шахмат уйнарга чакырды. Шунда сүзара сүз чыгып, Иоанн Фасиан аңа:

— Мине Болгарда ясак түләү тәртибе борчый, олуг хан,— диде.— Моны мин сине якын иткәнгә генә әйтәм. Аны тәртипкә салганда дәүләтең күзгә күренеп баер иде. Әлегә, олуг хан, синең тарханнарың гына баый. Ә эт симерсә, иясен тешли башлый, диләр. Ясак мәсьәләсендә сиңа яңа закон чыгару кирәк, олуг хан. Базилевс законнар чыгару белән көчле.

— Дәүләт көче законда түгел, кешегә биргән directive иректә, философ. Мин халкыма ирек бирдем, ясакны миңа тарханнарым күпме сорыйм шул хәтле түлиләр,— диде хан, ат шәкелен [1] кулына тоткан килеш уйлана-уйлана.

[1] Шәкел — фигура.

— Тарханнарың урлаша. Сәүдәгәрләрдән өчтән бер өлеш товар алалар, хан сараена аның бер өлеше дә кайтмый. Законнар кергкәндә тарханнар түгел, хан баер иде. Туры әйткән өчен кичерә күр, олуг хан.

Хан бик озак дәшми торды, ул ат шәкелен тоткан кулын кая куярга белми кебек иде. Ханның күзе-кашы җимерелгән, сул күз кабагы тартышып-тартышып китә иде. Философ бер мәлгә югалып калды, аның бер дә ханның ачуын китерәсе килмәгән иде. Ул аңа һәрчак изгелек теләде.

— Олуг дәүләткә олуг акыллы патша кирәк, ул дәүләт чәчәк атар, даны еракларга таралыр. Болгар халкы төрле кабиләләрдән тора, төрле телдә аңлаша — законның теле бер, закон телен барысы да аңлый. Үзең чыгарган законны тагын да көчлерәк, тәэсирлерәк итү өчен законнарны яклаучы яңа дин кирәк, олуг хан. Закон дәүләткә тәртип булдыру өчен чыгарылса, дин кешенең рухын әсир итә, җанын били.

Ниһаять, хан күтәрелеп философка карады һәм ат белән йөрде.

— Шах булыр сиңа, философ. Син фәлсәфә саткан арада мин сиңа шах бирдем. Озак фәлсәфә сатсак, империягә җиткән сарациннар Болгарга да килеп җитәрләр. Алар, әнә, кара болыт булып Румга ябырылдылар. Яңа законнар чыгарып, дин алыштыра башласам, халкым миннән йөз чөерер, җиңеллек ышандырган дошманга йөз тотар...

— Олуг хан, син җәйләүләреңне илханнарга бүлеп биреп ашыкмадыңмы икән?.. Алар хәзер һәрберсе үз җәйләүләре өчен кайгырта. Аларны бер йодрык итү өчен Болгарга бердәмлек кирәк.

— Илханнар барысы да миңа буйсына, философ.

— Буйсына, әмма бишесе биш төрле уйлый.

— Мин базилевс сараенда азмы-күпме тәрбия алган кеше, философ. Мин анда бик күп гыйбрәтле хәлләр күрдем. Муенга тавык тәпие тагып кына халыкны буйсындырып булмый, философ. Үз җәйләүләремә муеныма тавык тәпие тагып кайткан булсам, кем мине кабул итәр иде!? Кемгә кирәк булыр идем?! Төркиләр миннән йөз чөерер иде, халкым югалтыр идем. Мине бик кыстый башлагач, бу турыда базилевска да әйттем. Ул минем белән килеште, ә менә син, философ, мине аңларга теләмисең. Миңа халкымның карусыз буйсынуы кирәк. Халкым үз итсә, миңа беркем дә куркыныч түгел, кәкре кылычлы сарациннар да, Йулыш каган да.

— Ил белән идарә итү политика дип атала, олуг хан, ә гаилә, ыру белән идарә итү этика дип атала. Кечкенә ыру белән идарә итә алмаган патша, ил белән идарә итә алмый.

— Бу — синеңчә, философ, христианнарча. Адәм баласын тәңре кояш-күк яраткан.

Иоанн Фасиан Фанагурга килгәч үк Кубрат ханга гаҗәпләнгән иде. Әйе, ниндидер бер варвар дөнья турында фикер йөртә. Византиядә булса, чиркәү аны ретиклыкта гаепләп утта яндырган булыр иде. Ә монда хан адәм баласын яратучы күк-кояш дип бара.

— Минем сиңа бер үтенечем бар, олуг хан. Патриций Симеон чиркәү ачырга җыена, килегез беренче көнне чиркәүгә. Карар өчен, тамаша кылыр өчен?

— Ул чиркәүне мин базилевс хөрмәтенә генә салдырдым.

— Рәхмәт, мең рәхмәт, олуг хан. Акчасын да кызганмадыгыз. Фанагур греклары сине онытмаслар. Бу алар өчен зур изгелек булды. Синең тарафтан...

— Миңа,— диде хан,— миңа, Бөек Болгар ханы Кубратка — грек уты кирәк. Бик кирәк. Базилевс грек утының серен ачу белән Кубрат хан чат саен чиркәү салдырачак.

— Грек утының серен!— философ кадәр философ хан авызыннан

бу сүзләрне ишетүгә, як-ягына каранып, чукынып алды.— Моның өчен мине император...

— Башың кисәчәк, философ.

— Әйе, олуг хан.

— Миңа да менә үз башым үземә кадерле, философ. Ә баш кешегә бер генә бирелә. Болгар халкы гасырлар буена тәңрегә табынды, чиркәүләр салдыра башлау белән мин халкымны чукындырырга тиеш булачакмын. Күп кан коярга туры киләчәк миңа, философ, халкыма христиан динен тагу өчен. Болгар болай да грекларга күп игелек эшләде философ. Чиркәү салдырды, сәүдәгәрләр өчен сарай җиткерде. Исеңә төшерим, философ, иң башта ул сарайда Рум сәүдәгәрләре яши башлады. Сәүдәгәрләр сарае хәзер дини бәхәсләр оясына әверелеп бара. Мин сабыр итәргә булдым, философ. Кайсы дин өстен чыкса, шуңа йөз тотар Болгар. Анда да җиде кат уйлап. Уйлар-уйлар да янә бер уйлар. Дин-йола алыштыру — рух алыштыру дигән сүз. Рух исә тән белән туа — җан белән китә. Барысы да тәңре кулында, философ. Сабыр итик. Үтеп булмас тауны ике яктан тишәләр. Рум Болгарга, Болгар Румга игелек кылсын. Игелек итү халыкларны бер-берсенә бәйләр, дуслыкны ныгытыр, дуслык белән йола мәсьәләсе дә хәл ителер...

Уен житдиләнде, Кубрат хан сакалын бөтерә-бөтерә уйлады. Аның әле философка бер тапкыр да оттырганы юк иде. Ул белә иде, базилевс шахмат уенын тыя торган аерым закон чыгарган, шуңа греклар бу уенны бик үк яратып уйнамыйлар иде. Базилевс моны чиркәү кушуы буенча эшләгән. Болгарга христиан дине килсә, ул да бу уенны тыяр. Юк инде, ашыкмый торсын әле базилевс Фанәгүргә икенче чиркәү салырга, берсе дә җитеп торыр.

Бер шул хакта уйлады Кубрат хан, бер шахмат өстәлендәге шәкелләрне күзәтте. Шахмат уены дошманны җиңәргә өйрәтә, гомер буена варварлар белән орышып яшәгән империя архиепископы моны ничек аңламый икән, ул аңламаганда базилевс үзе?..

Шушы кичтә Кубрат хан философ Иоанн Фасианның галәмәт хәйләкәр кеше булуына янә бер инанды — ике йөрештән ханга шах куйды философ.

## 6

Әле дә булса күз алдында: мәҗлестән соң төптәңре Ирсан багатырны үзенә алып китте. Соң иде инде, барысы да калага кайта, багатырның атын уң кулы Адай җитәкләгән. Илбарыс багатырның төптәңре белән китәсе килмәгән иде, әмма ул аңардан сорап тормады. «Миңа кайтабыз, багатыр»,— дип кенә әйтте. Һәм шул сүздән соң, багатыр атка тагылган колын кебек, төптәңрегә иярде.

Дәү диварны үттеләр, өч-дүрт урам уздылар, түр якка җиткәч, сакчы алыплар сөңгеләрен чалыштырдылар. Икесе дә сүзсез генә рөхсәт тәңкәләрен күрсәттеләр. Түр яктагы урамның ике ягына да җимеш агачлары утыртылган, агачларны кара сакаллы грек карый. Шул җимешләрдән, греклардан күреп, Кубрат хан әчемлек коя. Хан сараена җиттеләр, сарайга үтү өчен асма күпер салынган, күпер күтәрелгән иде. Димәк, хан кайткан, философ белән дөнья хәлләре турында сөйләшеп утыра. Ханның һаман философ белән булуына төптәңре дә гадәтләнә башлады, кул селтәп, борылып китеп барды.

Төптәңре урамына килеп кергәч, аларны уң кулы Адай куып җитте, ул багатыр атына атланган иде.

— Багатыр, иртә таңнан юлга чыгабыз. Ничәнче этәчтә уятыйм?

— Һәр алып үзе белә, яу чапканда Кубрат хан кайчан кузгалды, без дә шул вакытта чыгарбыз дәү капканы,— диде багатыр.

Адай борылып китеп барды, төптәңре туктады, багатырның иңенә

кулын салды. Төптәңренең кулы җиңел, салкын иде, багатыр моны хәтта күлмәге аша тойды.

— Мангыш тархан башын салган булса, Эске кирмәнне алгач, Адайны анда тархан итеп калдырырсың... Сул кулыңа Кушкул кавхан оланы мәргән алып Илбәкне куярсың...

— Шулай итәрмен, төптәңре.

Төптәңренең ишегалдына керделәр, җимеш агачлары ябалдашларын күтәрә-күтәрә өйгә таба уздылар. Күптән түгел, Фанәгүрдә янгын чыкты. Тарханнар урамы тезелешеп янды, урамда бары тик бер өй — төптәңре йорты исән калды. Шул хәлдән соң төптәңрегә ышаныч арта төште. Янгыннан соң халык, төптәңре кебек, өйләрне я кирпечтән, я саманнан сала башлады.

Түр бүлмәгә уздылар. Илбарысның бу түр бүлмәдә бер тапкыр да булганы юк иде әле. Бүлмә уртасында таган, таганга казан асканнар, учак яна, казанда ит пешә, бөтен бүлмәгә тәмле ит исе таралган.

Илбарыс багатыр түргә узды, түмәргә утырды. Төптәңре өен таштан салдырган, түбәсен измә балчык белән яптырган иде, бәлкем шуңа бу өйгә янгын кунмагандыр. Кол гарәп күренмәде, эчемлекне төптәңре үзе китерде. Әмма чокырларга эчемлек коймады, багатырны түр диварга эленгән бозау тиресе янына чакырып алды. Ике яктан шәм яктырта. Бозау тиресенә карта төшерелгән иде. Картаны сызучы Рум юраучысына төптәңре уч тутырып көмеш бирде. Картада Көбән, Маныч, Әтил, Чулман, Ак әтил, Җаек елгалары төшерелгән. Төптәңре кулына янган чыра алды, шуның яктысында Эске кирмән салынган төбәкне күрсәтте.

— Багатыр, Эске кирмән менә бу төбәктәдер. Аңа Әтил елгасы буйлап менәрсең. Бу картаны мин сиңа биреп җибәрәм, багатыр. Төн илләрен төшереп кайт, сызылмаган елгаларны, күрсәтелмәгән халыкларны, нинди телдә сөйләшүләрен, нинди йолага табынуларын.

Төптәңре тирене төрде, багатырга бирде. Аннары табын янына чакырды. Чокырны кулына алгач, багатырның кисәк теле ачылды.

— Бу өйдә һәрчак тынычлык булсын, ыруг-кардәшләрнең эзләре суынмасын, татлы сүзләрдән гөлләр ел әйләнә чәчкәдә утырсын, ай нуры өй-бакчага ямь бирсен,— шулай диде дә багатыр эчемлекне эчеп куйды.

— Күр әле, күңелең тулы җыру, йөрәгең тулы гыйшык икән бит синең, углан. Әмма күңелеңне юкка алгысытма, хан барыбер сиңа кызын бирмәс...

— Ул мине сөя, ул мине көтәр, Румга китмәс, төптәңре.

— Багатыр, башта Эске кирмәнне алып кайт. Әтил елгасы аръягына көнчыгыштан кардәш төрекләр килеп утырганнар, ди. Алар белән орышма. Килеш. Янә бер киңәш сиңа, багатыр: үзең белән алты-җиде чанак [1] эчемлек ал. Аны ничек булса да кирмәндәге Чалбай хан алыпларына бирергә тырыш. Чалбай үзе генә түгел, аның бөтен ыруы эчемлек ярата. Шуннан соң аларны җиңүе авыр булмас. Мангыш тарханда алыплар аз, кирмәндә сәүдәгәрләр дә һөнәрчеләр. Чалбай хан аларга тимәс, аңа да корал кирәк. Хәбәр итүләре хак булса, мин Болгарда укыткан Илтотар Чалбай ханда шаман булып йөри икән. Менә шушы йөзекне күрсәтсәң, ул сиңа кулыннан килгәннең барысын да эшләр. Балдакны бармагыңа ки. Ярамаса, янчыгыңа сал. Күктә — тәңре, җирдә — мин. Ак юл сиңа, багатыр. Игелегең белән кузгал.

Төптәңре урыныннан күтәрелде, таган астындагы учакка утын ташлады, аннан багатырны кочагына алды.

— Төптәңре, мин сиңа бер сорау бирергә телим. Мин аны белмичә китә алмыйм, төптәңре.

[1] Чанак — күн капчык.

— Сора, углан.

— Төптәңре, теге көнне диңгезгә ни ташладыгыз?

— Корбан эте, багатыр. Хан миһербанлыгына сарай эттен корбан кылдык. Йөрәген уч төбенә куеп юрадык. Күрдек — Болгарга яңа хан килер. Шуны күрсәтте юрау.

— Кем булыр ул, төптәңре?

Төптәңре кулларын күтәрде.

— Барысы да тәңре кулында, багатыр. Тәңре кемне тели, шул булыр Болгарда олуг хан. Инде бар, багатыр, ак юл сиңа. Яшь хан сиңа Чәчкәне кайтарыр, хан кызын чит-ят империягә җибәрмәс...

Илбарыс ишегалдына чыкты, күләгә кебек, аның артыннан кара гарәп иярде. Капкадан чыгуга, багатыр күккә карады: күк йөзен йолдызлар чуарлаган, ялгыз калган ай моңсуланып кала өстенә салкын нурларын сибә. «Чәчкә, Чәчкә, ай да ялгыз, мин дә ялгыз...»

Багатырны аяклары Кызсарайга алып киттеләр. Багатыр үзе җырлады, үзе Кызсарайга ашыкты. Түр капка сакчысы аңардан рөхсәт тәңкәсен сорады. Багатыр аңа: «Чәчкә!»— диде. Сакчы аны әллә ишетте, әллә юк, әмма багатырны кертмәде. Багатырның тел очында Чәчкә сүзе исә асма күпер астына төшеп китте, чулт итеп суга чумды.

— Менә ул тәңкә, каравыл алып, менә...

— Ай-һай, багатыр, килешмәгәнне кыланасың. Әллә мәҗлестә артыграк сыйландыңмы? Юкмы? Әллә соң грек эчемлеге белән кымызны кушып эчтеңме?.. Э-э, шулайдыр, шул ике нәрсәне кушсаң, дөньяның асты өскә килә... Кушмадыңмы?.. Һы! Кем кирәк соң сиңа, багатыр?.. Хан кызы?! Әнә кая үрелә берәүләр... Беләмсең, багатыр, хан кызы кайда утыра да, син кайда басып торасың. Әнә, әнә, хан кызы кайда утыра — айда. Ә син минем янда — җирдә. Бакчы. Бакчы, багатыр, айга!

Илбарыс багатыр сакчы сүзләрендә кисәк хаклык күрде һәм борылды да өенә таба атлады.

— Адай,— диде багатыр, иртән торгач,— миңа Илбәк мәргәнне китер. Мин аны яуга алам. Хан боерыгы диген.

— Баш өсте, багатыр.

— Әйт әле, Адай, нигә син кичә Кызкуыш туенда катнашмадың?

— Багатыр, Фанәгүрдә мин яраткан кыз тумаган әле. Бәлкем, яуда табармын дим. Синең әниеңне дә әнә чит җирләрдән алып кайтканнар ди бит.

— Минем анамны яу чапкач алып кайтмаганнар, уң кул Адай, Рось князе Кубрат ханга бүләк итеп биргән. Шуннан кайткач, атам Саклаб кавхан аны Кызкуыш туенда куып тоткан. Мин туып биш яз узгач, атам яуда ятып кала, Кубрат хан анамны кавханына бирә, мине үзенә тәрбиягә ала...

## 7

Болгарлар киң болынга килеп керделәр. Албагар[1] алыплар елга буендагы таллар арасыннан поши куркытып чыгардылар. Алыплар өзәңгеләренә басып: «Һайт, поши!»— дип кычкырдылар. Көнозын аттан төшмичә, ияр өстендә килгән Илбарыс багатыр йокымсырап бара иде, алыплар кычкыруга, күзен ачты һәм елга яры буйлап элдерүче пошины күрде. Йокы качты, багатыр тезгенен җыйды, үкчәсе белән атның кабыргасына тибеп алды. Күк кашка колакларын торгызды, хуҗасының ни теләвен аңларга тырышкандай, кешнәп куйды һәм шундук елга буйлап китеп баручы пошины күрде. Күк кашка томырылып шул тараф-

---

[1] Албагар — гаскәр алдыннан баручы күзәтүче сугышчылар.

ка чапты. Илбарыс багатыр чабып барган җайдан алыпларга кычкырды:

— Урра-гыз!

Уң кулы Адай үз алыплары белән сулга ташланды, сул кулы Иштуган үз алыплары белән пошиның юлын бүлде. Елга буйлап юыртып китеп барган поши, ике яктан да һау-һаулап килгән җайдакларны күреп туктады, як-ягына каранды һәм уң яктагы таллыкка ташланды. Әмма барып житә алмады — поши каршында, җир астыннан калкып чыккандай, башына тимер очлым кигән багатыр пәйдә булды. Поши, кая барырга белмичә сул яктагы куаклыкларга сикерде. Мәгәр киекнең ни кыласын сизеп алган багатыр җәясен тартып өлгергән иде инде. Сызгырып ук очты. Поши артка чүгеп куйды һәм мәтәлеп китте. Ук-кылыч белән эш иткәндә хуҗасының аяк хәрәкәтеннән кая барырга кирәген чамаларга өйрәтелгән Күк кашка, поши мәтәлеп китүгә, юыртуга көчте һәм торырга маташып яткан киеккә житәрәк туктап калды. Багатыр сикереп атыннан төште, җәясен җилкә аша ташлап, кылычын суырып чыгарды.

Ике яктан да поши юлын бүлеп алган алыплар килеп житкәндә багатыр канлы кылычын үләнгә сөртә иде инде. Кылычын кынысына салды һәм киекнең корсак тиресе тартышып-тартышып куйган урыннан күзен ала алмый торды. Уң кулы Адай атыннан төшеп, багатыр янына килде.

— Багатыр, биредә гаҗәеп аулак урын, елга буе, кич житеп килә, төнлеккә туктап казан ассак,— диде.

— Эске кирмәнгә бер көнлек юл калды. Урын аулак. Әйт йөзбашларга: төнлеккә туктасыннар, ашчылар казан ассын, мул итеп ит пешерсеннәр,— дип боерды багатыр, тирә-юньгә күз ташлап.

Еракта-еракта, күз күреме житкән офык читеннән алып алар тукталган аланга кадәр тоташ кара урман сузылган иде. Шул урман эченнән зәңгәр тасмадай мул сулы Әтил елгасы агып чыга. Елганың сул ягында болын, болын бетүгә, калку-калку таулар башлана. Таулар өеме каядыр кояшчыгыш тарафка китеп югала. Шул тауларны узгач, Чулман елгасына килеп чыгасың. Анда, Чулман елгасы буенда, мажарлар[1] яшәгәннәр. Көннәрдән бер көнне, мажарларның ирләре яу киткәч, аларның җирләрен Чалбай хан басып алган һәм мажарлар әйләнеп кайткач, җәйләүләрен аларга бирмәгән. Шуннан соң мажарлар Азов диңгезе буйларына күчеп киткәннәр, әмма анда да тынгылык тапмагач, Тын елга буйларына күченгәннәр, ахыр Әтиолан җиренә юл алганнар. Мажарлар киткәч, Чалбай хан Чулман елга буендагы җәйләүләрне кул астына җыя. Кубрат хан Әтил буйларын буйсындырып йөргәндә Чалбай хан белән орыша, тегe җиңә, мал-туарын ала, ясак сала. Мәгәр Кубрат хан иленә кайтып китәргә өлгерми, Чалбай хан Кубрат хан килешеп киткән һәм аңа күпмедер күләмдә буйсынган угорларга яу чаба, тегеләрне җиңә, Кубрат ханга ясак салмагыз, миңа салыгыз, дип үз тамгасын куеп китә. Шушындый хәлләр кабатлана торгач, Кубрат хан янә Әтил буйлап күтәрелә, янә Чалбай хан белән орыша, җиңә, Чалбай ханнан ул биләгән җәйләүләргә чапмаска ант эчертә. Ул гына да аз тоела Кубрат ханга, Әтил буена кирмән салдыра. Кирмәндә үзе белән орышып, яңа җәйләүләр яулап йөргән кавханы Мангышны тарбхан итеп калдыра, бер төмән алай бирә. Ант эчеп калса да, Чалбай хан булган хәлләрне бик тиз оныта, тернәкләнеп, сәүдә эшләрен җайга салып җибәргән болгарларның Эске кирмән дип аталган җәйләүләренә яу белән килә. Кирмәнне ала, Мангыш тарханны әллә әсир итә, әллә — үтерә — бер тәңре үзе белә. Кубрат хан багатырга Эске кирмәнне Чалбай хан кулыннан тартып алырга, төрки кардәше булуына карамастан,

[1] Мажарлар — мадъярлар, хәзерге венгрлар.

башын кисеп, капчыкка салып, Фанәгүргә озатырга куша. Җиңел бурыч йөкләмәде Кубрат хан багатырга. Яу чаба-чаба остарып, орышларда үз алымын булдырган Чалбай ханны җиңәсе бар иде. Чалбай ханны җиңеп, аңардан Кубрат хан өчен аерата кадерле булган Эске кирмәнне тартып алган хәлдә ханның да, бәлкем, багатырга карата бераз күңеле йомшарыр иде. Белә бит, чамалый бит: сарайда тәрбия алган, үзенең угланнары белән бергә тәрбияләнгән Илбарыс багатыр Кубрат ханның бердәнбер кызын ярата. Хан үзе күрмәсә, игътибар итмәсә, ханша күрә, белә. Бу хәл турында ханша олуг ханга әйтми түзмәс. Әйткәндер дә, уйлашкан-уйлашканнардыр да, үзләре тәрбияләп үстергән багатырдан котылырга уйлаганнардыр — Чалбай ханга каршы җибәрде... Албагарлар җиткерде: Чалбай хан ике төмән алае белән кирмәнгә кереп бикләнгән, ә багатырда бары тик бер төмән алай. Дөрес, бер төмән булса да, болгарлар бик яхшы коралланган, чалбайныкылар белән тиңләрлек түгел. Шулай да, шулай да — ике төмән һәм бер төмән, җитмәсә Чалбай хан кирмәндә.

Ни өмет итә багатыр? Олуг хан кызы Чәчкә Рум императоры угланы Юстинианга ярәшкән. Кубрат хан вәгъдәсен боза буламы! Алай да Илбарыс багатыр өмет итә. Кем белә, бәлкем аны Кубрат бирегә сынамакка җибәргәндер?.. Чалбай ханны җиңеп, исән-имин Фанәгүргә кайтса, олуг хан императорга биргән вәгъдәсен бозып, кызын аңа бирер.

Хан кызы Чәчкәнең карашында сөю тоеп, башта Илбарыс бу турыда кемгәдер әйтү түгел, уйларга да куркып йөрде. Мәгәр йөрәк дигәнең акылга буйсынса икән ул — хан кызын очраткан саен күңел җилкенә. Бер табында ашап үскән кыз да, иртәнге кояшка тартылган чәчкә кебек, аңа тартыла иде. Шуның өчен бугай, алар һәрчак бергә уйнадылар, бергә үстеләр. Әмма көннәрдән бер көнне, ханшага ияреп диңгез буендагы сарайга төшкәч, алар икәүдән-икәү генә калдылар. Шул чакта Илбарыс кызны кочагына алды, сак кына иреннәре белән битләренә кагылды. Әмма шул якынлашу икесендә дә үзләре дә аңлап бетермәгән тетрәнү, дулкынлану хисен кузгатып җибәрде. Аларга кисәктән нидер булды. Бу бала чактагы яратышуларга бер дә охшамаган иде. Күзләр елмая, йөрәкләр бер дулкында тибә. Хан кызын Илбарыс тагын-тагын кочты, яратуның иге-чиге булмас кебек иде. Шунда алар янына ханша килеп керде. Ул диңгездә коенып менгән икән. Керде дә, кызын ятим бала кочагында күреп, тамак кырды. Яшь йөрәкләр икесе ике якка ташландылар. Кыз әнкәсе кочагына кереп чумды, егет ягына күз сирпеп, күңеле тулышкан шатлыктан сандугачтай сайрарга тотынды: әнисе матурланып киткән, диңгез суы җылымы, акчарлаклар күпме, Рум сәүдәгәрләренең корабы күренмиме...

Әнисе кызны кырт кисмәде, әмма шушы көннән соң үзеннән дә калдырмады, ә Илбарыска әйтте: «Углан, ул синең бертугандай сеңелең, ярәшелгән, котки салма күңеленә».

Шул булды сөйләшүләре һәм шул сөйләшү Илбарыска бик җитте. Чәчкәне аңардан аеру, бергәлектән тыю Илбарысның күңелендәге мәхәббәткә ялкын гына өстәде. Ул шуннан соң көн-төн Чәчкә турында уйлады. Ятса да — Чәчкә, торса да — Чәчкә. Аның өчен якты дөньяда берәү дә юк иде. Шул язда Илбарыска унҗиде яшь тулды. Кубрат хан яшь мәргәнне яуга алды. Беренче орышта ук Илбарыс хәзәр багатыры Кубашны кадап үтерде. Яудан кайткач, Кубрат хан аңа аксакаллар, кавханнары алдында багатыр исеме бирде һәм үз алаена алды.

...Әтил ярында утырганда әнә шундый уйлар узды багатырның башыннан. Әйе, кайчан гына әле Саклаб кавхан угланы Илбарыс хан сараенда Чәчкә белән бер гамьсез уйнап йөри иде, хәзер әнә бер күрергә

---

[1] угорлар — угор-фин кабиләләре.

зар — күз алдыннан елмаюлары китми. Елмаюлары гүя елга агышы: бер назлана, бер куркына, бер тынып кала.

Илбарысның атасы Саклаб кавхан аварлар белән орышта башын сала. Ул вакытта атасы Кубрат ханның агасы Ураган каган белән яу чаба. Аварларның калган ыруларын куып-таратып йөргәндә, илдә чуалышлар башлана. Алаен оныгы Кубрат ханга калдырып, Ураган каган иленә кайтып китә. Күп тә үтми, Кубрат ханга яман хәбәр китерәләр: Ашин белән Дулу ырулары арасында барган чуалышларда Ураган каган һәлак була. Кубрат хан илгә борыла, кайтышлый Ураган каган буйсындырган һәм аның кул астында яшәргә разый булган көтригурлар[1] ханы Тугрыхан ыстанына туктала, аның кызын сорый. Яше җитмешкә җиткән Тугрыхан аңа: «Башта илең-җирең булдыр, аннары килерсең кыз сорарга»,— ди. Агасы Ураган каган янәшәсендә булганда Тугрыхан авыз ачып сүз дә әйтергә кыймас иде, монда әнә шундый шартлар куя Кубрат ханга. Кубрат хан җан ачуы белән иленә кайта, хәзәрләрне җиңә. Әтил буйлап өскә күтәрелә, ахыр чиктә андагы халыкларны буйсындырып, Тын елга буенда яшәүче көтригурлар ханына килә. Тугрыхан аңа кызын, кызын сакларга өч төмән алай бирә, үзенең җәйләүләрендә хан итә. Моны ул кече угланы Көбер балигъ булганчы дип шулай итә. Көтригур аксакаллары Тугрыхан белән килешәләр.

Тугрыхан кызы Аппак Кубрат ханга бер-бер артлы алты бала табып бирә. Әнә шулай болгарлар белән көтригурлар туганлашып китәләр. Кубрат хан Илбарысны биш яшьлек чагында тәрбиягә ала. Хәзер багатырга егерменче яз китте. Менә ничә ел инде ул җәй көннәрен җәйләүгә китә, яу чаба. Аның кул астында бер төмән, илханнарда ун төмән, алар — буйтурлар. Була күрсеннәр, Илбарыс та аңа ирешер. Тик менә хан кызы Чәчкә генә аныкы була алмас. Илханнар аны беркайчан да читләмәделәр, үз иттеләр, туган да туган, ул да алар өчен туган иде. Алар аны әле дә яраталар. Әмма ни генә димә, ул барыбер илхан була алмас. Хәер, кем белә, Кубрат хан әнә хатын ягыннан килә. Кубрат ханның биш угланы бар: Батбай, Кодрак, Аспарух, Балкыр, Аслан. Аслан хан буласы кеше түгел. Аның кулында һәрчак китап, ул һәрчак грек укытучылары янында кайнаша. Хан башта аны да, башка угланнары кебек орыш уеннарына өйрәтергә кушкан иде, теге ялгыш грек акинагының кулын кискәч, кул селтәде. «Укысын, Болгарга да белекле кешеләр кирәк»,— диде. Аның каравы хәрби уеннарда Илбарыс бик тырышты, күп вакытта ул илханнардан да алдырды. Уктан аларга карый төзрәк атты, сөңге ыргытуда да калышмады. Көннәрдән бер көнне хан үзе уздырган чираттагы хәрби уенда уктан тоташ төз аткач, олуг хан аңа мәргән исемен бирде һәм үзенең алтын саплы хәнҗәрен бүләк итте.

Кырысрак холыклы, бер әйтеп ике сөйләргә яратмаган Кубрат хан аны угланнарыннан ким яратмады. Мәгәр илханнарны җәйләү йөртеп, үзе исә борынгы греклардан калган Фанәгүр каласын башкала итәргә керешкән Кубрат ханның игътибары бер аңарда гына түгел иде, күрәсең. Бөтенләй күрми йөргән чаклары да булды, әллә бар иде оланнары аның өчен, әллә юк. Илбарыс турында әйтеп тә торасы юк. Шул чакта аны бер кеше яратты — төптәңре Ирсан. Болгар халкы, бөтен төркиләр кебек, тәңрегә табына. Ирсан — Болгарда йола башлыгы. Сарай мәктәбендә ул аларны ата-бабадан килгән гореф-гадәтләргә, тәңре йоласының кагыйдәләренә өйрәтте. Шунда белде Илбарыс: дөньяда ни генә кылынмасын, барысы да тәңре эше икән. Берәүләр тәңре тарафыннан — каган, икенчеләре — хан, өченчеләре кавхан, дүртенчеләре буйтур, алып, оста, көтүче булып туалар икән. Әнә шул кеше Илбарысны да үз улыдай яратты. Олуг хан рөхсәте белән ул аны хәтта өенә дә алып китә иде. Тәрбиягә алса да, олуг хан Кубрат барыбер олуг хан булып кала иде.

[1] Көтригурлар — Дон елгасы буенда яшәгән кабиләләр.

калды, алар белән бик сирәк очрашты, ә менә Ирсан гел аның янында булды диярлек. Бала чакта ул моның сәбәбен белмәде, бала чакта аңа моның кирәге дә юк иде, ә менә үсеп-исәя төшкәч, төптәңренең шәхси тормышы белән танышкач, бу хәлнең сәбәбе әнисе Аниядә икәнен аңлады. Бу турыда аңа ханша сөйләде.

Төптәңре Ирсан заманында Кубрат хан белән яу чаба. Ураган каган белән йөргән җәйләү башы төптәңре үлгәч, Кубрат хан аның урынына төптәңре итеп Ирсанны куя. Ирсан атасы күтәргән йоланы бөтен таулаган халыкларга таратуга ирешә. Моның өчен ул Кубрат ханга буйсынган бар халыклардан дәрәҗәле кешеләрнең угланнарын Фанагүргә китерттерә, укыта, аннары кире җәйләүләренә җибәрә. Кубрат хан Ирсанның бу эшен хуплый һәм кулыннан килгән кадәр тегеңә ярдәм итә. Мәгәр бер нәрсәдә олуг хан төптәңре Ирсанга гел комачаулап килә — өйләнү мәсьәләсендә. Бу хәл чираттагы Кызкуыш туеннан соң була. Соңгы вакытта халык арасында төптәңре Ирсанның абруе шактый үсә, аңа җәйләүләрдән төркем-төркем халык килә, төптәңре аларның авырулары дәвалый, ырымлый, өшкерә, тылсымлы сүзләр өйрәтә. Шул елларда Кубрат хан Рось князенә солых төзергә бара. Князьгә ул бик күп бүләкләр ала, әлбәттә, ат-мал, корал да илтә. Рось князе дә үз чиратында Кубрат ханга бүләкләр биреп җибәрә, шуның янына кораб ясаучы останы һәм үзенең иң чибәр жариясе Анияне бирә. Болгарга кайткач, Кубрат хан Анияне Кызкуыш туенда катнаштыра. Моны, әлбәттә, ханша Аппак кушуы буенча эшли. Аппакның сарайда андый чибәр затларны тотасы килми, күрәсең.

Кызны беренче булып төптәңре Ирсан куарга тели. Кубрат ханга бу ошамый. Ул төптәңрегә тыелырга киңәш итә, әмма ханша аңа каршы төшә, төптәңре Ирсанга рось кызы Анияне куарга рөхсәт бирә. Ләкин рось кызы Ания ни сәбәпледер төптәңре Ирсаннан тоттырмаган, кызны Саклаб кавхан куып тоткан.

...Багатыр уйларын бүлдереп, алыплар җыр башлады.

Илбарыс багатыр авыз эченнән генә аларга кушылды.

Җирәнчәккәй атның юргасы,
Мәргән егет аткан ук кебек,
Уй-хәсрәтләрем дә юк кебек,
Йөрәкләрем яна ут кебек.

Ике дә генә җирән, ай, бер күрән,
Әйдәп алып булмый юл белән.
Маңгаена язган хак язмышын
Җуеп кына алып булмый кул белән...

Эскирмәнгә Чалбай килгән диләр,
Сөйгәнемне үзенә алган диләр,
Агыла ла болыт җилләр искәндәй,
Өзелә лә үзәк искә төшкәндәй.
Җыламалар дип үк ник әйтәсең,
Ник жыламый җаннар өзелгәчтәй,
Җырлар ла башлыйм кирмән күренгәчтәй...

Багатырга кисәк моңсу булып китте. Күңелдә һаман хан кызы Чәчкә. Ул еракта-еракта, диңгез буйларында калды. Алыплар җырлый башлагач, кисәк өзелеп киткән хәтер җебе янә ялганып китте.

Тирә-юньдәге халыкларны буйсындыргач, Кубрат хан, ниһаять, ныклап кала төзергә керешә. Иң әүвәл ул үзенә башкала сайлый. Күп эзләнә торгач, борынгы греклардан калган диңгез буендагы Фанагүргә туктала. Каланы салу, торгызу өчен хан Византия императоры Ираклийдан осталар, төзүчеләр, һөнәрчеләр сорый. Варварларга карата киң күңеллелек күрсәтеп, базилевс аңа хәтта кирәгеннән артык төзүчеләр, һөнәрчеләр җибәрә. Төзелеш эшләре киң колач алгач, Фанагүргә төрле илләрдән сәүдәгәрләр агыла башлады, аларга ияреп дин таратучылар

килде. Иң кыйммәтле, чит ил сәүдәгәрләренең күзләрен кыздыра торган товарлар Әтил-Чулман буйларыннан килде. Өрсәң җем-җем итеп торган кеш тиреләре дисеңме, аю, бүре, болан тиреләре дисеңме, балбалавыз, балык җилеме, төркиләр яратып үстергән тары дисеңме... Күрерләр иде дә хан базарларында җем-җем итеп торган тиреләрне, сәүдәгәрләрнең күзләре яна башлар иде. Нәкъ менә шуңа күрә Эске кирмән аерата кадерле иде Кубрат ханга. Тире, бал, балавыз, агач сагызы шуннан килә иде. Төн илләреннән. Кирмән елдан-ел киңәйтелде, үстерелде. «Көмеш» тире җыярга греклар агылды. Төн илләреннән угорлар күчеп утырды. Кирмәнне грек-болгар осталары салды. Диварларын агачтан утырттылар, дивар тирәли канау казып су җибәрделәр. Шул чаралардан соң сәүдә эше тагын да җанлана төште. Болгардан һөнәрчеләр күчеп китә башлады. Кыскасы, Кубрат ханның яшь дәүләте өчен бик тә «сөтле сыер» иде Эске кирмән. Әнә шул кирмәнне Чалбай хан алды дигән хәбәр килгәч, Кубрат хан тәмам йокыдан калды. Башта ул үзе чыгып китәргә итте, аннары кире уйлады, йырмач алай белән Илбарысны җибәрергә булды. Әйе, барып орышып кайтсын. Инде кирмәнне ала алмаса, ул чакта илханнарның берсен җибәрер.

Кояш баеды, алыплар да җырдан туктадылар, кайсы ияренә башын салып, кайсы ат япмасын җәеп, йокларга хәзерләнә башладылар. Илбарыс багатыр елга ярында утырды да утырды. Тын. Бары тик елга гына пышын-пышын сөйләшә-сөйләшә ага да ага. Кайчакта, ябалдашларын суга иеп утырган тал астында «шомбырт» итеп балык чумып куя: ә елга һаман ага, аның беркемдә гаме дә, кайгысы да юк.

Илбарыс алыплары янына барып ятты. Күктә йолдызлар җемелди, офык читендә алсу чаршау эленде; күктәге йолдызларны әйтерсең кемдер кабызып йөри. Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде... Җиде тәңре саны, җиде такмак саны. Җиде-җиде җидегән, җидегән йолдыз җидедән, җиде тапкыр такмак әйтсәң, бүләк бирәм җизнидән...

Әйләнеп кайтырмы Илбарыс? Күрерме янә хан кызы Чәчкәне? Чәчкәнең әнисе Аппак — көтригурлар ханы кызы — ай кебек ак йөзле, кылгандай ак чәчле, тирән елга суы кебек зәңгәр күзле. Кызлары Чәчкә дә зәңгәр күзле, тик чәчләре генә алтын җептән. Беренче улганы Батбай базык, киңчә гәүдәле, кызыл чырайлы, күк күзле; икенче улганы Кодрак исә бөтенләй берсенә дә охшамаган: коңгырт чәчле, яшел-күк күзле, шактый буйчан гәүдәле; өченче углан Аспарух кара сакаллы, тутсылрак йөзле, зәңгәр күзле; Балкыр углан кара чырайлы, зур борынлы, киң кашлы, төпчек Аслан чандыр гәүдәле, йомыкый, аз сүзле, бәлкем, ул багатырга гына шулай күренәдер. Бер тапкыр төпчек углан зур батырлык күрсәтә. Суга баткан Ишкул кавханының кызын коткара. Шуннан бу балаларны бер-берсенә тәңре язган дип, төптәңре аларның колакларын тешләштереп маташа. Имеш, үсеп-исәйгәч, Кызкуыш туенда илхан Аслан шул кызны куачак. Һәй бу төптәңрене! Ниләр генә уйлап тапмый...

Ияренә башын куйган килеш, багатыр байтак вакыт караңгылана барган күк йөзенә карап ятты. Әкрен генә күз кабаклары ябыла башлады, йокы басты, көн буена ат өстендә бару үзенекен итте, уйлар җәбе чәбәләнеп китте...

— Һай-һай-һай, алыплар! Көн туа, көн! Яңа көнне каршы алырга торыгыз, тәңредән игелекле көн теләгез! Һай-һай-һай...

Илбарыс багатыр каравыл алып тавышына күзләрен ачты. Шундук ятаганын капшап карады. Ятаган урынында иде, иргә таккан. Орыш өчен төрки кылычы уңайрак, әмма ятаганны да ташламыйлар иде алыплар. Орышта артык корал булмый.

Багатыр бөтенләй уянды, шундук сикереп торды, елгага таба китте. Кояш чыгып килә. Пөгереп яр астына төште, салкынча Әтил суы белән

юынып алды. Аннары йөгереп яр өстенә менде. Менде дә чыгып килгән кояш тарафына тезләнде. Тәңрем, матур көн бир, юлым уң ит. Тәңрем...

Көн-кояшны каршы алгач, алыплар ашап алдылар. Илбарыс багатыр ияр өстенә менеп утырды, табын-табын җыелып утырган алыпларына күз йөртеп чыкты. Каравыл алыплардан башкалары барысы да ашау белән мәшгуль иделәр. Һәр табында бер унбаш. Унбаш йөзбаш боерыгын үти, йөзбашлар багатырныкын, багатыр кавханнарныкын, кавханнар илханныкын, буйтур-илханнар олуг ханныкын. Илбарыс багатырны олуг хан Кодрак илханга бирде. Әмма Кодрак илхан биредә юк, ул Димәшкъка китте, корал алырга, димәк, алай белән ул җитәкчелек итә?.. Ә алостаз Дәян кем, ияреп чыккан төптимерче Агасике? Кызык та кеше бу Агасике, колын иявтеп ике дә уйламый юлга чыкты. Ә бит аның яу кырында ятып калуы бар. Бик бар...

Ашап-эчеп җыена башлаганнар гына иде каравыл алып сөрән салды:

— Багатыр, аръякта җайдаклар, ят кешеләр!

Барысы да, хәтта соңгарак калып ашарга утырган каравыл алыплар да сикереп тордылар, аръякка карадылар. Елганың аръягында чынлап та ике атлы күренде. Аның берсе ат муенына яткан, әллә яралы, әллә йоклый, икенчесе атын янәшәдән атлата, яткан кешене тотыбрак килә.

— Төрки кардәшләр, шуларга охшаганнар,— диде алостаз Дәян.— Сул як дала аларныкы... Ул-бу булдымы икән әллә?.. Сөрәнче, оран сал!— дип боерды алостаз Дәян.

Сөрәнче яр кырынарак килде, авызына кулларын куеп, оран салды.

— Һай-һай-һай, аръяктагылар, җайдаклар, бире чыгыгыз, болгар багатыры дәшә.

Аръяктагылар ишеттеләр, сөзәгрәк җирдән елга буена төштеләр.

— Без сезнең ниятегезне белмибез, кардәшләр!— дип кычкырды ярдан җайдакларның берсе. Аның аты суга тез тиңентен кереп эчә башлады, икенче алып, ялга яткан килеш, су читендә калды.

— Мин сиңа хәзер ниятем күрсәтермен,— диде мәргән албагыш Илбәк һәм җәясенә ук элде, әмма яръяктагы алып та җәясен тарткан иде инде.

— Тидермә, ат!— дип боерды багатыр.

Сызгырып ук очты, әмма шул мәлдә аръяктагы алып та керешен ычкындырды. Булган хәлдән бермәлгә аптырый калдылар. Нәкъ елга уртасында ук-укка орылды һәм алар суга төштеләр. Уклар төшкән тирәдә балыклар сикерешеп куйдылар. Илбәк мәргән янә җәясен тартты, әмма аръяктагы мәргән дә керешен тартып өлгерде, янә уклар чәкәште, янә елга уртасына чумдылар, янә балыклар сикерешеп алдылар.

Илбарыс багатыр су читенә йөгереп төште.

— Мәргән, кардәшләр, атмагыз. Болгарлар без.

Аръяктагы ике җайдак киңәшеп алдылар, ял өстенә ятканы чак кына башын күтәрде, елга читендәге багатырга карап алды. Кардәшләр дидеме, мәргән батыр атыннан төште, яралының атын елгага кертеп җибәрде. Аның артыннан үз атын төшерде, ат ялына ябышты. Бире якка чыгып җитүгә, болгарлар аларның атларын эләктереп алдылар, яр өстенә җитәкләп алып менделәр. Мәргән егет күзләре белән багатырны эзләп тапты.

— Багатыр, Чалбай хан угрылары атамны яраладылар, туганнарымны сөңге белән кадап үтерделәр, сеңлем белән анамны әсир иттеләр. Ике көтү сарыгыбыз, бер көтү атыбыз бар иде — куалап алып киттеләр. Җәйләүдән күчешебез иде. Өске җәйләвебез. Бозаулыкта, аскы җәйләвебез Җаек елгасы буенда иде. Атам яралы, арагызда имче бармы, багатыр?

— Имче,— дип кычкырды сөрәнче.— Имче Акчура, багатыр дәшә!

Яралы төркине иплэп кенә иярдән алдылар, үлән йолкып түшәделәр, үлән өстенә киез япма җәйделәр. Ул арада имче килеп җитте. Урынга салгач, төрек кулын күтәрде, әмма хәле китеп, башы бер якка авышты. Имче яралыга нидер эчерде, нидер иснәтте. Яралы күзләрен ачты, карашы белән угланын эзләп тапты.

Егет елый иде, аның битләре буйлап яшь бөртекләре тәгәрәшә.

— Угланым, алтыным, угры Чалбай ханнан үч ал. Мине тәңре үз янына чакыра... Сине, углан, багатырга бирәм,— яралы күзләре белән багатырны эзләп тапты.— Багатыр, дала мондый мәргәнне күрмәгәндер. Күзе бөркетнеке, йөрәге арысланныкы... Олан, о-л-л-ан, ан-нан тапсаң...

— Атам, атам...

Яралының авызыннан кан китте, менә ул күтәрелергә итте, әмма көче җитмәде, башы салынып төште, аякларын сузып җибәрде,— җан бирде.

— Атың ничек, мәргән?

— А-тым, Таш-булат, баг-гатыр,— диде мәргән яшь аралаш.— Ат-там Ак-тай...

Актайны калку урынга, яр башына күмделәр, янына җәя-укларын, коралларын куйдылар. Тәңре килеп алганчы дип, өч көнлек ризык, чүлмәк белән су куйдылар.

Алай кузгалып шактый юл үткәч кенә Ташбулат, ниһаять, тынычлана төште. Мәргән егет багатырның уң кулында бара. Аларны оластаз Дәян куып җитте, атын янәшәдән атлатып китте.

— Багатыр, Эске кирмәнгә ярты көнлек юл калды.

Әрәмәлекләрдән узалар иде, багатыр кошлар сайравына игътибар итте, ерак та түгел күке кычкыра. Алда шактый зур алан күренде.

— Аланда туктарбыз, алостаз. Олаучылар килеп җиткәнне көтик.

— Багатыр,— диде Ташбулат.— Чалбай хан кирмән капкаларын ачмас. Аның ике төмәннән артык алае бар. Синдә, күрәм, бер төмән чамасы гына. Ничек кирмәнне алырга уйлыйсың?

— Корал орыша, ир мактана, мәргән. Мин алыпларыма ышанам. Миндәге корал Чалбай ханда юктыр...

— Бер корал гына ярдәм итмәс, багатыр. Чалбай хан кирмәндә нык утыра. Аны алдап чыгарырга кирәк, ияртеп чыгарырга...

— Җыелыйк, киңәшик башта, мәргән.

Алай аланлыкка килеп тупланганчы шактый вакыт үтте, кояш аска таба — баешка күчте. Ашчылар казан астылар, багатыр йөзбашларын мәҗлескә җыйды.

— Я, киңәшләрегезне әйтегез, йөзбашларым.

— Киңәш бер,— диде алостаз Дәян.— Кирмәнне алырга.

— Багатыр, миңа әйтергә ярармы?— диде Агасике.

— Тыңлыйбыз, Агасике.

— Миңа калса, багатыр, бүген кичкә таба кирмәнгә кешеләр җибәрергә кирәктер. Сәүдәгәрләр булып. Үзләре белән эчемлек алсыннар. Сәүдәгәрләр булгач, каян килсәләр дә Чалбай хан кабул итәр.

— Я-я, төптимерче, шуннан?..

— Сәүдәгәрбаш булып үзем барам, багатыр. Үзем белән,— төптимерче грек табын тирәли күз йөртеп чыкты.— Алостаз Дәянны, олаучыларны...

— Алостаз Дәян, нишлибез? Килешәбезме?..

— Чалбай ханның сәүдәгәрләрне тануы бар.

— Танысын. Кичә мин алып идем, Кубрат ханга хезмәт итә идем, бүген Чалбай ханга сәүдәгәр булып килдем. Татлы грек ширбәте китердем.

— Хак әйтә төптимерче, далада очраган бер сәүдәгәрне талый-үтерә китсәң, кем килер Чалбай ханга?!— диде багатыр.

— Кылдык алай булгач,— дип килеште алостаз Дәян.

Шулай хәл иттеләр. Эчемлекләр төялгән олаучыларны чакырдылар да тиз арада юлга чыгарып җибәрделәр. Кояш баеганчы кирмәнгә барып житәргә тиешләр иде сәүдәгәрләр. Аерата дәртләнеп җыена башлаган Агасике олаучыларны ашыктырды.

— Җәтрәк, җәтрәк, өтек-әлән ятим бәрән. Кузгалдык!..

Сәүдәгәрләр китеп күздән югалырга өлгермәделәр, Этил буеннан дүрт җайдак килеп чыкты. Яр өстенә менүгә, аларны каравыл алыплар уратып алдылар. Каравылларның берсе, аерылып, багатыр туктаган түбәккә килә башлады. Атын чаптырып килеп җитте дә җиргә сикереп төште һәм сулышы каба-каба:

— Багатыр, җайдаклар арасында Эске кирмән тарханы Мангыш.— Сөенче!— диде.

Багатыр сөенчегә ике алтын бирде. Каравыл алыпның авызы колагына кадәр ерылды.

«Мангыш тархан исән!»— Багатыр тарханга каршы китте, килеп җитәрәк атыннан төште.

Алар кочаклаштылар. Мангыш тархан күз яшен яшерергә теләп читкә борылды.

— Өч алыбым белән көчкә качып котылдым, багатыр...

Сөйли-сөйли дә Мангыш тархан, күз яшьләрен кул аркасы белән сөртеп ала.

Еламаслык та түгел иде. Чалбай хан аның хатынын, кызын әсир иткән. Тарханның хатыны Этилгә ташланган, батып үлгән, кызы Чалбай хан кулында икән. Ике угланын Чалбай хан аналары алдында чабып үтергән.

Мангыш тархан яшенә буылып елап ук җибәрде. Багатыр аны иңнәреннән кочып алды, тынычланырга кушты.

— Болгар беркайчан да хатын-кызны рәнҗетмәде, багатыр. Ә болар...

— Тынычлан, тархан. Күз яше ярдәм итмәс инде аларга. Әйдә, уйлашыйк, ничек кирмәнне Чалбай ханнан алырга була. Кирмәндә ничә капка?

— Ике. Берсе яшерен, урман яклап.

Багатырның үз-үзенә ышанып сөйләве Мангыш тарханның да күңелен тынычландыра төште. Дине-өне булмаган, төшенә ни керсә шуңа табынып яшәгән Чалбай хан угрылыгын кайчан ташлар? Ташлармы? Заманында ул Кубрат ханны да шактый талкыган. Кубрат хан аны бер тапкыр гына тәүбә иттермәде иттерүен, әмма Чалбай хан һәрчак башы киселүдән котылып калды. Бер Болгар җәйләүләренә генә яу чапмый иде угры хан, бөтен төрки дөньясы аның угрылыгын белә иде.

Эске кирмән Төн илләре белән сәүдә итү өчен уңай су юлына салынган иде. Чалбай ханның кулы әнә шул кирмәнгә җиткән.

Йөзбашларны җыйгач, багатыр әйтте:

— Алыпларым, иртәгә көн тууга кирмәнгә кузгалырбыз. Кечкә кирмән безнең кулда булырга тиеш. Тәңре миңа шулай әйтте.

## 8

Иртәнге якта атларга атлангач, Илбарыс багатыр мәргән Ташбулатка күз төшереп алды. Ачуы йөзенә үк бәреп чыккан иде мәргәннең, күзләрендә нәфрәт чаткылары, карашы кирмән ягында. Ирек бирсәң, ике дә уйламый диварга ташланыр иде.

Кузгалдылар. Кирмәнгә тарлавык яклап барырга булдылар. Юлны Мангыш тархан күрсәтте. Багатырны бер нәрсә борчый иде: «сәүдәгәрләр» кирмәнгә керә алдылар микән? Кергән хәлдә Чалбай хан ничегрәк каршы алды икән үзләрен?..

Тарлавыкка җиткәч, туктадылар. Мангыш тархан багатыр янына килде. Атларыннан төштеләр. Моннан кирмәнгә чакрым чамасы гына иде.

— Багатыр, җиңелә калса, Чалбай хан яшерен капкага ташланыр. Яшерен капкага үзем барам. Угры ханны үз кулым белән үтерәсем килә. Без дә шул капка аша качып котылдык, атларыбыз шушы тарлавыкта иде.

— Яхшы, олуг тархан, шулай итәрбез. Тик безгә башта Чалбай хан алыпларын кирмәннән чыгарасы иде. Моны эшләве җиңел булмас кебек...

Багатыр йөзбашларны тагын җыйды, комлык җир табып, ком өстен тигезләде дә, кулына хан бүләк иткән алтын саплы хәнҗәрен алды.

— Кирмән нык, диварлары биек, бәреп алып булмас, багатыр,— диде Мангыш тархан.

— Кирмән нык, йөзбашлар, нык булса да алырбыз аны. Тәңре безнең якта. Менә бу кирмән. Менә почмак манаралар. Манараларда каравыл күренми, минем уемча, безнең «сәүдәгәрләр» изге эшләрен кылганнардыр. Хәзер безгә чалбайлыларны ничек тә кирмәннән алдап алып чыгарга кирәк. Миңа котыртучылар кирәк булыр, йөзбашлар, һәр йөздән ике котыртучы бирерсез. Иң оста мәргәннәрегезне сайлагыз. Мәгәр, йөзбашлар, башта без аз көч белән, әйтик, әнә шул ике йөз чамасы котыртучы алыплар белән дәү капкага якынайыйк. Чалбайлар безнең аз санлы булуыбызга ышанырга тиешләр. Шунсыз алар, капканы ачып, безне куа китмәсләр. Капканы ачкан хәлдә без алар белән орышырга тиеш булабыз. Кирмәннән күпме чалбайлы чыгар, анысы безнең өчен караңгы... Чынын гына әйткәндә, минем Чалбай хан белән бер дә орышасым килми. Ул төрки безгә кардәш халык. Әмма нишләмәк кирәк, язмыштан узмыш юктыр.

— Чалбай ханны мин үзем җәзалыйм,— диде Мангыш тархан.— Мин кирмәнем дивары буенда я ятып калам, багатыр, я Чалбай ханның башын кисәм. Хәсрәтсез — бер үләр, хәсрәтле — ике үләр, ди. Мин бер үлеп карадым инде, багатыр. Үлемнән куыкмыйм. Миңа, багатыр, ун алып бир. Мин яшерен капканы сакларга барам. Җиңгән хәлдә дә, җиңелгән хәлдә дә Чалбай яшерен капкага килми булдыра алмас. Чөнки шул капка кырында ат абзарлары, урманга ауга шуннан йөри идек.

— Ун алып алырсың, тархан. Башта киңәшик.— Багатыр Илбәк белән Ташбулат мәргәннәргә күз төшереп алды.— Сез, мәргәннәр, берегез уң кулымда, икенчегез сул кулымда булырсыз. Ташбулат, син уң кулыма басарсың. Адай, уң кулым Адай, син ун алыпны сайлап ал да Мангыш тархан белән яшерен капкага кит. Төп алай шушы тарлавыкта калыр. Атларны әнә теге аланлыкка яшерерсез. Тарлавыкның ике ягына ике йөз укчы басар. Ике якта да куаклыклар, яшеренеп утырырсыз. Безне Чалбай алыплары тарлавыкка куа киләләр, укчыларга җитү белән... Кыскасы, бер чалбайлы да кирмәнгә кире әйләнеп кайтмаска тиеш. Бу хәл аларның ачуларын китерер. Алар янә капканы ачарлар...

— Ачмасалар?— диде Илбәк мәргән.

— Ачарлар, ачмый хәлләре юк. Кирмәннән тарлавык күренми, без бик аз калдык, без янә әйләнеп капкага килербез, укка атыша башларбыз... Төп алай чыккач, орыш каты булыр, йөзбашлар. Укчылар үз урыннарында калырлар. Без янә чигенә башларбыз. Чалбай ханның алае зур, ике төмән, укка алып бетерү мөмкин түгел, алай безне куа-куа тарлавыкка керер. Чалбайлылар үтүгә, очлы ыргаклар ташлагыз. Ыргакларны ташлаганнан соң гына утка ала башлагыз. Инде без. Без төп көч белән болай итәрбез. Алдан укчыларны җибәрербез, алардан соң сөңгечеләр орышка керешер, сөңгечеләрдән соң ятаганчылар белән

кылычлы алыплар кузгалыр. Уң кулыма, сул кулыма мәргәннәрем басар, төп уртада үзем булырмын. Мин грек Агасике белән Дәян алостазга да зур өмет баглыйм. Алар исән-сау кирмәнгә керә алган булсалар, ничек тә капканы ачарга тырышырлар. Шулай да, алыпларым, мин иң элек сезгә зур өметем баглыйм. Ант эчик,— багатыр хәнҗәре белән бармак очына төртте, кан күренүгә, ашчы биргән алтын чокырга җиде тамчы кан тамызды. Һәр йөзбаш бармагын канатып ант канын чокырга тамызып чыкты, аннары һәммәсе иреннәренә тигезеп чыктылар.— Тәңре безнең якта, алыпларым. Кузгалдык!

Ике йөз алып иплэп кенә тарлавыктан чыктылар, кирмәнгә таба юнәлделәр. Ике йөз алып тарлавыкка кергән җирдә агачлар артына постылар, калганнары урыннарында калдылар.

Коралды җайдаклар күренү белән кирмәндә ыгы-зыгы купты, сөрәнче оран салды. Алыпның уң кулындагы Ташбулат җәясенә ук куйды. Кирмәнгә бер ара җир калгач, багатыр кулын күтәрде. Алыплар туктап калдылар. Болгар сөрәнчесе алгарак чыкты.

— Оран сал, сөрәнче,— диде багатыр.— Чалбай ханга сал. Капканы ачып, бирелсәң, сине болгарлар иреккә җибәрергә ышандыралар диген. Ачмасаң башың Әтилдән эзләрләр диген.

Сөрәнчеләр оран салды, кирмән диварына кабаланып менгән чалбайлылар сөрәнче сүзләрен Чалбай ханга җиткерделәр, күрәсең, кирмән ягында беравык тын тордылар.

Кирмән диварына кошлар кебек менеп кунган чалбайлылар ике йөз болгардан бер дә куркырга җыенмыйлар, өскә ук чыгып басканнар иде.

— Багатыр, алыйммы берсен укка?— диде Ташбулат.

— Ашыкма, мәргән, куян кумыйбыз. Монда Чалбай төлке үзе.

Чынлап та чалбайныкыларның барысы да диярлек очлымнарына төлке койрыгы таккан иде.

Чалбай хан һаман җавап бирми. Багатыр чалт аяз зәңгәр һавага күтәрелеп карады. Баш очында козгыннар очына, яман итеп каркылдап узалар. «Орыш буласы,— дип уйлады багатыр.— Чалбай хан кирмән капкасын ачмас, орышыр. Тәңрем, ярдәм кыл, Чәчкәм хакына, гаделлек хакына»... Багатыр көньякка әйләнеп карады. Көньяк тарафта кара болытлар җыела иде.

Ниһаять, чалбайлылар оран сала башладылар.

— Җиде елга, җиде дала кичеп килгән болгарларны козгыннар көтә. Моннан ары Чалбай хан ышбу җәйләүләрне биләп торачак. Үкчәгезне ялтыратыгыз...

— Әйе, кан коймыйча булмастыр, козгыннар тикмәгә генә баш өстендә уралмыйлар. Тәңрем, үзеңә тапшырдык.

— Укчы мәргәннәр, дивардагы төлкеләрне укка!

Ике йөз укчы дәррәү диварга таба кузгалды. Ике яктан да яңгыр булып уклар очты. Кайбер уклар болгарларга килеп җитмичә, елан кебек үлән арасыннан шуышып кереп туктап кала иде.

Беренче чалбайлыны Ташбулат мәргән атып төшерде. Аның икенче угы да бушка китмәде, күкрәгенә кадалган укка чалбайлы ике куллап ябышты, әмма суырып ала алмады, дивар өстенә капланды. Багатыр янәшәсендәге Ташбулат:

— Багатыр, алар исерекләр, якынырак килик!— диде.

Болгарлар диварга якын ук килеп укка ала башладылар. Дивар буенда болгарлар да ятып калгалады. Болгарлар дулкын-дулкын булып, әйләнеп килеп һөҗүм итәләр иде. Өченче әйләнгәндә якынрак килделәр, ахрысы, багатырның калканына ук кадалды. Болгарлар дүртенче тапкыр әйләнеп керә башлаганнар иде, дәү капка ачылды һәм өч йөзләп чалбайлы һай-һаулап килеп чыкты. Алар болгарларга каршы чаптылар. Болгарларны урап алмакчы иттеләр.

— Тарлавыкка чигенәбез!— дип кычкырды багатыр һәм атын кире борды. Аңа алыплары иярде.

— Һэ-лә-лә!— дип чалбайлылар алар артыннан ташландылар.

Болгарлар чаптырып тарлавыкка керделәр, укчылар яшеренгән жирне уздылар һәм, кисәк борылып, чалбайлыларга каршы килә башладылар.

— Ур-ра! Ур-ра, багатырлар!

Чалбайлылар тарлавыкка кереп бетүгә, аларга ике яктан да уклар болыты яуды. Һични аңламаган чалбайлылар каушап калдылар, кире чигенә башладылар, әмма укчылар агач араларыннан аларны чүпли тордылар. Ул арада алыплары белән багатыр килеп житте, ике арада орыш китте.

Чалбайлылар чынлап та исерекләр иде, күзләре тонган килеш өскә киләләр, сөңгеләрен аталар да кире борылалар.

Беренче тезмә ятып калгач, чалбайлылар чигенә башладылар. Ук тиеп ятып калган атлар ярсынып кешнәүдән, куркынып чинаудан, елга буендагы кошлар — һәммә тереклек тынып калды. Бары тик козгыннар, аларга ияреп ала карга, саесканнар гына кан исенә карылдыйлар, каркылдыйлар, шыркылдыйлар иде. Багатыр, өч-дүрт чалбайлыны укка алып, дошманга якынаюга, жәясен жилкә аша ташлады, кылычын суырып чыгарды.

— Ур-ра, болгарлар! Алыпларым, ур-ра!

Кайсының күкрәгенә үк кадалган, кайсының аркасын сөңге тишеп чыккан, кайсы яралы кулын тотып, тояк астында калмаска теләп, куаклар арасына йөгерә, әмма ерак китә алмый, агачлар арасында яшеренгән укчылар аларны укка тота тора иде. Чалбайлылар кача башлагач, болгарлар аларны куа киттеләр. Кыска гына вакыт эчендә тарлавыкта йөзләгән алып ятып калды. Тарлавыктан исән чыккан чалбайлылар капкага ташландылар. Алар бик аз калган, әмма жан газиз, тизрәк капкага житәргә тырышалар иде. Аларны куып баручы болгарлар чигенүче чалбайлыларны бертуктаусыз укка алалар, алай да егермеләп чалбайлы капкага якынлашты. Шунда бер хикмәт булып алды: кирмәндәгеләр тиз-тиз капкаларны яптылар һәм чигенүче үз алыпларын укка ала башладылар. Бу хәлдән каушап калган чалбайлылар дивар буйлап елгага таба борылдылар, әмма анда аларга болгарлар каршы төште. Көтмәгәндә чалбайлылар уртада калдылар. Аларның кайсын укка алдылар, кайсын сөңге белән кададылар. Арадан берсе кылычын бертуктаусыз селтәп, яман итеп кычкырып, багатырга ташланды. Кылыч кылычка орынды, корыч-корычка тиюдән очкыннар очты. Багатыр икенче тапкыр селтәнергә өлгерә алмый калды, Чалбай хан куштаны сөрлегеп киткәндәй артка чайкалып куйды, кулыннан кылычы төшеп китте. Багатыр шунда гына аның аркасына кадалган укны күрде. Укны Ташбулат мәргән аткан иде. Мәргән чаптырып багатыр янына килде.

— Багатыр, бу кеше Чалбай ханның уң кулы Күчтем батыр иде, Минем атамны ул яралады...

Багатыр күз карашы белән Ташбулат мәргәнгә рәхмәт әйтте, сөйләшергә вакыт тар иде. Багатыр өзәңгесенә басып, күтәрелә төште, тирә-юньне күздән кичерде. Бер генә чалбайлы да исән калмаган иде.

— Укларны, сөңгеләрне жыярга, мәетләрне тарлавыктан агачлар арасына күчерергә!

Һәм багатыр атын юырттырып, тарлавыкка таба китте. Аңа Ташбулат мәргән иярде. Шунда гына ул мәргәнгә:

— Мәргән, мин сине уң кулым итәм,— диде.

— Мин аңардан үч алдым, багатыр.

— Багатырың да үлемнән коткардың, мәргән. Тәңре сине бу иге-

легең өчен онытмас. Чалбай ханның батыры Күчтем Кубрат хан заманында ук орышып йөргән.

Тарлавыкка җитәрәк багатыр аркасына ук тигән бер болгар алыбын күрде. Алып тәңредән мәрхәмәт сорагандай, күзләрен зур ачып, күккә төбәлгән. Кулында керешен тарткан җәясе, бармак арасында кыскан угы. Төптәңре биргән кояш сурәте төшерелгән тәңкәсе берьякта ята, очлыгы тәгәрәп киткән. Таныды багатыр алыпны, Эске кирмәнгә китәр алдыннан Кызкуыш туенда канашкан иде егет. Кызны куып җиткәч, шатлыгын яшерә алмыйча, елмая-елмая ханша каршына килеп баскан иде, ханша ул тоткан кызга да, егеткә дә күлмәк биргән иде. Алып шул күлмәкне эчтән кигән.

Багатыр атыннан төште, алыпның күкрәгенә кадалган укны тартып алды, шул мәл мәетнең йөзе чытылып куйган кебек булды. «Әллә соң үлгәч тә авырту сизәме кеше?» — дип уйлады багатыр һәм карашын кирмән ягына ташлады. Кирмәндә янә нәрсәгәдер җыеналар иде. Ул арада капка ачылды. Бу юлы капкадан бик күп алай чыкты. Чалбай ханның исәбе бер төркем исән калган болгарларны бер орынуда капларга иде, күрәсең. Чалбайлылар ашыкмадылар, акрын гына, атларын атлатып кына болгарларга таба якыная башладылар.

— Болгарлар, тарлавыкка качарга! Укчылар, ыргак ташлаучылар, урыннарыгызга! Болгарлар, тарлавыкка чигенәбез. Ыргакчылар, болгарлар үтүгә, ыргаклар ташларсыз!

Багатыр сикереп атына атланды, тарлавыкка таба кузгалды. Багатыр кул астында йөз егермеләп кенә алып калган иде.

— Болары да исерекләр,— диде багатырның уң кулына баскан Ташбулат.

— Бик шәп,— диде багатыр.— Димәк, Дәян алостаз белән төптимерче Агасике исәннәр...

Ул арада чалбайлылар һай-һаулап аларны куа башладылар. Болгарлар ягына болыт булып ук яуды.

— Уклары җитми, аталар.

— Атсыннар. Чапмаска. Ашыкмаска! Тарлавыкка керсеннәр!..

Багатыр һәр боерыгын биргән саен артына әйләнеп карады. Болгарлардан ерак түгелләр иде инде чалбайлылар, уктан алырга була иде.

— Җәелергә, укчылар!

Болгарлар ике якка сибелделәр, бер тапкыр әйләнмә ясап, чалбайлыларны укка алдылар, аннары тарлавыкка чигенә башладылар. Чалбайлылар кача башлаган болгарларны тагын һай-һаулап куа киттеләр. Менә тарлавык бугазы. Агач артларында болгар укчылары. Чалбайлылар һични аңламый һаман куалар, арттан басып киләләр. Багатыр бертуктаусыз артка карап уктан атты. Багатыр чамалады, аны Чалбай ханның бие куа килә. Би кулында сөңге, багатырны ул киеменнән таныды булса кирәк, әллә батыр Күчтем белән алышканда күреп калдымы...

— Ташбулат, бине үзем алам,— диде багатыр һәм тезгенен җибәрде, ат үз иркенә чапсын, шулай артка карап укка алуы җайлырак.

— Юк, багатыр, бине мин алам. Апам өчен, анам өчен! Я мин аны, я ул мине, багатыр...

Тарлавыкка җиттеләр, болгарлар укчылар яшеренгән төбәктән үттеләр, ыргакчыларга җиттеләр. Чалбай хан алыплары, батырларның йөздән ким калган алаен тарлавыкка кысрыкларга уйлап, тагын да дәртләнебрәк куа башладылар.

Шул мәлдә ике яктан да чалбайлыларга уклар ябырылды. Сафлар бозылды. Кай тарафтан ук очканны абайламый калган чалбайлылар һаман алга омтылдылар. Бер төркем болгар алыбын сытып, изеп ташлау нияте белән алга чаптылар. Багатыр яшеренгән алаен чыгарды һәм болгарлар кәтмәгәндә чалбайлыларга каршы борылдылар. Багатыр башта укчыларын җибәрде, алар әйләнеп килүгә, сөңгечеләр куз-

галды, алар артыннан кылычлылар. Бертуктаусыз әйләнә-тулгана орыша, атыша, суеша башладылар. Чалбайлыларның иге-чиге юк кебек иде.

Йөзгә-йөз килеп орышырга вакыт житте. Багатырның кулына сөңге бирделәр. Чалбай ханның бие аны һаман күздән ычкындырмаган икән, янына ук килеп житте. Һәм сөңгесен ташлады, багатыр чак кына ат өстенә ятып өлгерде, аның колак төбеннән выжлап сөңге узды. Янәдән иярена менеп утырды багатыр. Бу юлы бинең кулында кылыч иде инде.

Ике арада кисеш, суеш башланды. Күкрәк тирәсендә үткен очлы сөңгеләр яшьнәде, кылычлар ялтырады, ярсынып атлар кешнәүдән, баш түбәсендә козгыннар каркылдаудан бөтен тарлавык ят тавышлар белән тулды.

Чалбай ханның бие акыра-бакыра Илбарыска ташланды. Би кылычын селти, багатырга тизрәк килеп житә алмаудан гажизләнә кебек иде.

— Кубрат хан угланы Илбарыс, котыл!

— Үзең котыл, би!

Кылычка кылыч бәрелде. Икенче тапкыр әйләнеп килделәр. Янә кылычлар чалышты. Өченчегә әйләнеп килгәндә багатыр кисәк ат корсагы астына төште, би бушка селтәнде. Ат астыннан чыгып өлгергән багатыр бинең битенә чапты. Әмма би дә аңа орынып өлгергән иде, багатырның калкан чите уелып очты.

Чалбай хан бие иярдән ычкынды, гөрселдәп жиргә төште, яман тавыш белән акырып жибәрде. Бу тавыш болгарларның алдыра башлаган вакытына туры килде. Чалбайлыларның күбесе тарлавык бугазында ятып калганнар иде. Калганнарын болгарлар кысрыклый башладылар. Анда да, монда да болгар алыплары алдыра торгач, «Ура!» тавышлары ешрак ишетелде.

Багатыр иярдә калды, әмма кулында кылычы юк иде, үрелеп, сул ягына — иярenә таккан ятаганын алды.

— Ур-ра, ур-ра, болгарлар!

Чалбайлылар кача башладылар, шунда аларның атлылары аяк астына очлы ыргаклар ташланды. Кача башлаган чалбайлыларның атлары баш аша мәтәлә, ә аты егылганда, сикереп төшеп, йөгереп китәргә өлгергән чалбайлыларны укчылар уктан ата тордылар. Шунда берсе:

— Аһ, атакай, алдадылар безне болгарлар!— дип кычкырды.

Исән калган чалбайлылар тарлавыктан качып китә башладылар. Тарлавыкта бүленеп калган егермеләп чалбайлы кире борылдылар. Моны күреп, багатырның уң кулы Ташбулат, сул кулы Илбәк жәяләрен алдылар. Ни тиз атсалар да, өч-дүрт чалбайлы болгарларга життеләр. Берсе багатырга сөңгесен атты. Сөңге калканны тиште, алай да көбә күлмәкне тишә алмады, багатыр атыннан егылды. Чалбайлылар үтерелде. Ташбулат жирдә яткан багатырга ташланды. Атыннан сикереп төшүгә, ул багатырның башын күтәрде.

— Чалбайлар кача, багатыр, жиңдек! Яраландыңмы?

— Зыян юк. Атка, атка атландыр мине. Мин исән. Ярам...

Ташбулат багатырны атына атландырды. Багатыр чалбайлыларны куып барган болгарлар артыннан чапты.

Чалбайлылар арасында:

— Кардәшләр, атакай, без бирeләбез!— дип кычкыручылар табылды. Икенчеләре: «Капкага! Капкага чабыгыз!»— дип аларга куәт бирергә теләде.

Чалбайлылар: «Бирeләбез!»— дип кычкырсалар да, ярсынган болгарлар тиз генә тыела алмадылар, калган чалбайлыларны чаптылар, кистеләр, арканга алып, сөйрәп киттеләр. Шул чакта капкалар ачылды, чигенгән чалбайлыларны уртага алып, коралланган Эске кирмәнле-

ләр килеп чыктылар. Чалбайлылар коралларын ташладылар. Багатыр янына алостаз Дәян килде.

— Багатыр, капканы төптимерче Агасике ачты,— диде.

Капкадан хатын-кыз, бала-чага — дала көтүчеләренең, Чалбай хан әсир иткән кабилә-ыруларның туганнары чыктылар. Иң алдан колгага ат коерыгы таккан шаман атлый. Шаман туры багатыр янына килде дә җиргә хәтле баш орды.

— Кубрат ханның батыр багатыры, бала-чага, кыз-хатыннарга тимә, иш табалганын ишле итәрсең, таба алмаганын каравыш итеп, Фанагүргә озатырсың.

— Алостаз Дәян, шаманга аңлат, бала-чагаларга да, кыз-хатыннарга да тимибез, кызларын каравыш итмибез. Шаманны күздән ычкындырма, миңа шаман исән кирәк!— диде. Шулай дип боерды да багатыр атын ачык капкага таба алып китте.

Соңыннан барысы да беленде: ахыр чиктә, котылу нияте белән Чалбай хан, җансакчыларын ияртеп яшерен капкага ташлана. Әмма аларның капканы ачып чыгулары була, Чалбай хан каршына Мангыш тархан килеп баса. Мангыш тархан җан ачудан Чалбай ханга сөңге белән кадый, шунда Чалбайның бер җансакчысы тарханга пычак атарга өлгерә.

Яшерен капканы эзләп килгән Илбарыс багатыр, сөңге кадалган Чалбай ханны күреп, йөзен чытты. Чалбай хан җан ачысы белән ике куллап сөңгегә ябышкан, гүя күкрәгеннән тишеп чыккан сөңгене суырып алырга тели иде. Көтмәгәндә аркасына кадалган пычакны аткан кешене дә күрмичә җан биргән Мангыш тархан чалкан килеп төшкән, колач җитмәстәй каен төбендә ята. Бирелә кыска гына вакыт эчендә чалбайлылар белән болгарлар арасында суеш-кисеш, кадаш булып алган. Болгарлардан бары тик ике алып белән Адай исән калган. Алыпларның берсе яраланган беләген тигәнәк яфрагы белән бәйләгән. Чалбай ханның берничә җансакчысы урманга качып өлгергән икән, Адай куа киткән.

— Яралыны имчегә илтегез. Мангыш тарханны, аның белән үлгән яралыларны, бер кабер казып, тәңре кушканча күмегез. Чалбайлыларның мәетләрен яндырыгыз,— дип боерды багатыр һәм кирмәнгә кереп китте.

Багатыр Мангыш тарханның өенә юнәлде. Юл өстендә аңа төптимерче очрады. Мәһабәт җиз сакаллы, киң күкрәкле тимерче юл уртасында аякларын җәеп баскан да сөңгесенә таянып тора. Багатыр аңа грекча дәште.

— Багатыр грекча беләʔ!— диде төптимерче, гаҗәпкә калуын яшермичә.

— Белә, Агасике, белә. Сине дә белә. Үлемнән курыкмыйча капка ачуыңны да белә.

— Капканы ачулары җиңел булмады, бер чалбайлы башыма җитә язды, чак абайлап өлгердем. Сиңа тәңрең ярдәм иткәндер, багатыр. Ике төмән алае булган ханны җиңдең. Җитмәсә Чалбай хан кирмәндә иде.

— Тәңре түгел, Кубрат хан җибәрде мине Эске кирмәнгә, төптимерче.

— Кубрат хан кодрәтле адәм. Озын гомер бирсен аңа хода.

— Аңа гомерне тәңре бирә, Агасике, синең аллаң түгел.

— Тәңре дә шул ук алла инде ул, багатыр. Философ Иоанн Фасиан шулай ди. Багатыр, тарханның кызы исән калды, мин аны йолып алып калдым...

— Рәхмәт сиңа, Агасике. Изгелегең онытмам...

— Онытма, багатыр,— диде.

Һәм багатырга юл биреп, читкә тайпылды.

Илбарыс багатыр Мангыш тархан өенә урнашты. Кич белән ул бозау тиресенең бер читенә: «Сәне алты йөз дә кырыгынчы елда тәнре илаһы белән Эске кирмәннән Чалбай хан алае куылды, башы киселеп Фанәгүргә озатылды»,— дип язып куйды. Кирмәнне алганда болгардан ике йөз дә кырык җиде алып үлде, йөзгә якын яраланды. Соңгысын язмады багатыр, уйлады гына. Тархан өенә багатыр уң кулы Ташбулат белән урнашты. Ташбулат гаять эшлекле кеше булып чыкты, кичке якта ул казан асты, төнлә салкын булыр дип, күрше бүлмәдән тиреләр кертте. Багатыр туктаган бүлмәдә Чалбай хан Мангыш тарханның ике угланын чабып үтергән. Әмма тархан үзе тәрәзә аша йортка сикергән һәм җансакчылары белән яшерен капкадан качып өлгергән. Башта Чалбай хан тарханның хатынын үзенә ала, әмма күз алдында ике угланын чабып үтергән ханга буйсынырга теләми хатын. Әүвәл «Мин риза, диварга чыгып, Әтил суын гына карап керим»,— ди. Чалбай хан риза була, хатынга ияртеп, ике җансакчысын җибәрә. Елга яклап дивар өстенә менгәч, елгага ташлана хатын. Бу турыда кайтып әйткән җансакчысын Чалбай хан уңлы-суллы яңаклый, аннары камчысы белән яра башлый. Шунда теге әйтә: «Хан, аның анасыннан да чибәр кызы бар»,— ди. Чалбай хан җансакчысын кыйнаудай туктый: «Кызны табып китермәсәң, башыңны югалтырсың»,— ди.

Җансакчысы Күчтем батырның кулыннан кызны тартып ала, җилтерәтеп, хан янына китерә. Күрә дә кызны Чалбай хан, җансакчысына бер уч алтын тәңкә ташлый. Чалбай хан кызны түр бүлмәгә яптыра, җансакчысына аны күз карасыдай сакларга куша.

Шул чакта аңа шаман килеп керә, кызны үзенә сорый.

— Анасы суга ташлангач, монысы да ерак китмәс, ирексезләмә баланы,— ди.— Хан, мин аны үзем сиңа, көйли-көйли үгетләрмен, шуннан ул үзе риза булыр, сиңа матур-матур балалар табар... Кызның аты ничек?..

— Кызның аты ничек, Артык?— дип, җансакчысыннан сорый үз чиратында Чалбай хан.

«Оял,— дип уйлый шаман.— Сиңа сылуларның сылуын китергәннәр, ә син, ахмак, аның атын да белмисең».

— Аты Айгөл, хан.

— Айгөлне шаманга биреп җибәр, Артык. Үгетләсен.

Багатыр бүлмә тәрәзәсе каршындагы түмәргә утырды. Кояш баеп килә, кирмәнгә кайтып кергән маллар кычкыра. Кичә Чалбай хан кулында иде кирмән, бүген кирмәнгә янә болгарлар хуҗа, ә көтүчеләргә, малларга барыбер... Барыбер микән?.. Түгелдер. Түгелме? Көтүчеләр — коллар, аларга кайда да көтү барыбер түгелмени соң?!. Алар — кеше кешесе. Син соң кем кешесе?.. Кубрат ханныкы... Кем җибәрде сине бирегә сөйгәнеңнән аерып? Кубрат хан... Юк, алай дип уйларга синең хакың юк. Кубрат хан синең... Нигә, нигә алды хан мине тәрбиягә?! Хан кызы Чәчкә белән бергә үсмәгән булыр иде...

— Ташбулат,— дип дәште багатыр уң кулына.— Сөрәнчегә әйт, иртән кояш чыкканда барысын да уятсын — Әтил буенда җыен була дип сөрән сал. Җыенда Фанәгүрдәгечә Кызкуыш туе уздырабыз. Чалбай хан үзе белән бер көтү хатын-кыз йөрткән, шуларны алыпларымнан кудырам.

— Баш өсте, багатыр.

Ташбулат чыгып китте, күңел һаман сагышта. Әле генә өйдә берүзе каласы килгән иде, хәзер янә кемнедер юксына башлады.

Багатыр өй эченә күз йөртеп чыкты. Юан бүрәнәләреннән нарат сагызы исе килә. Кем салып бирде икән бу өйне? Рось осталарымы, угорлармы? Алар сала агач өйләрне Төн илләрендә. Сәер, ни әйтергә телә-

де икән бая аңа Агасике? Мангыш тархан кызын ул коткарган?.. Кызны үзенә алырга исәбе бар микән әллә Агасикенең? Бик ихтимал ич! Әллә Айгөлне Адай мәргән эләктереп өлгергән микән. Мәргән аны беркемгә дә бирмәс... Агасике кызны аңардан сорап килсә?..

Ишектә берәү күренде. Нәкъ шул кеше турында уйлаганда, аның үз аягы белән килеп керүе ышанмастай хәл иде.

— Хәерле кич, багатыр!

— Кич хәерле, төптимерче, уз, утыр.

Төптимерче аның каршындагы түмәргә утырды, баш киемен салды, беравык очлым астыннан кия торган мескен бүреген бөтәрләп торды.

— Иртәгә Төн илләренә чыгып китәсең дип ишеттем, багатыр?

— Китәбез, әмма иртәгә үк түгел, Агасике, берсекөнгә.

— Мине дә ал, багатыр. Алыпларыңнан ким орышмам.

— Без анда орышырга дип бармыйбыз, Агасике. Маҗарлар, угорлар, Чалбай хан Эске кирмәнне алуга, сәүдәгәрләрен җибәрми башлаганнар. Кордаш субашлар арадашлык итүдән баш тартканнар. Кубрат хан миңа Төн халыклары белән сәүдә эшләрен җайга салып кайтырга кушты.

— Минем дә Төн халыкларын күрәсем килә, багатыр.

— Ярый, төптимерче, син дигәнчә булсын. Төн илләренә сине алырмын. Ә хәзер бар, син миңа шаманны китер. Эзлә, тап, китер.

— Мең рәхмәт сиңа, багатыр. Төн илләрен күрү күптәнге хыялым иде. Ә шаманны мин хәзер...

Агасике чыгып китүгә, уң кулы Ташбулат кайтты. Кичке ашны ашадылар. Ул арада шаманны ияртеп, Агасике килеп керде.

— Рәхмәт сиңа, Агасике. Сиңа кайтып китәргә мөмкин. Ә син, илтотар шаман, әйдә, түрдән уз.

Төптимерче чыгып китте, шаман кыяр-кыймас кына түргә узды, түмәрнең яртысына утырды.

— Иркенләп утыр, шаман.

— Игелек яусын, багатыр.

— Сиңа бер бүләк бирәсем бар, шаман.— Багатыр бил каешына бәйләнгән янчыгын чиште, төптәңре биргән йөзекне шаманга сузды.— Ал, шаман. Сиңа бу.

Илтотар шаман балдакны кулына алды да күзләрен акайтып, багатырга карап торды. Шаманның балдак тоткан кулы җиңелчә генә дерелди иде. Кисәк ул урыныннан купты, багатыр каршына килеп баш орды. Шаман багатырга баш орып ятканда тавыш-тынсыз гына ишектә алостаз Дәян пәйда булды. Ничә тапкыр сынаганы бар багатырның алостаз Дәянны, ул беркайчан да киңәше белән атылып чыкмады, башта кеше сүзен тыңлады, аннары гына киңәш бирде. Чандыр гәүдәле, буй-сынга барысыннан да бер башка озын алостаз Дәян сарайда да еш кына Кубрат ханның уң кулында утыргалый иде. Һәм ул һәрчак бар нәрсәдән дә хәбәрдар була. Кубрат хан Эске кирмәнгә дә аны тикмәгә җибәрмәгәндер. Кем кызыксындыра алостазны? Төптимерчеме, шаманмы?

— Булды, булды, шаман. Тор, мин сиңа олуг хан түгел,— диде багатыр, аннары әлегә кадәр ишек янында басып торучы алостазны күрмәмешкә салышып:— Ә-ә, алостаз, кер, түрдән уз. Менә Чалбай ханның шаманы килгән.

— Багатыр,— диде Дәян.— Мәетләрне җыеп бетереп булмады.

— Болгарларны?

— Болгарларны Мангыш тарханга казылган кабергә күмдек.

Алостаз Дәян түргә узды, шаман янәшәсендәге түмәргә утырды, өй эченә күз йөртеп чыкты. Мангыш тархан кунак өйне зур салдырган иде. Түр якта киң сәке, сәкегә ак аю тиресе җәелгән — Төн халыклары товары. Төн халыклары төркиләрнең арадаш кардәшләре булган субаш-

ларга күренмиләр, әйберләрен куялар да китәләр. Болгарга хезмәт итүче арадаш төркиләр аларның товарларына карап, тегеләргә кораллар куялар. Аннары бераз торгач, янә корал куйган төшкә әйләнеп киләләр. Әгәр дә Төн халыклары арадаш субаш кардәшләрнең коралларын алганнар икән, димәк, тиреләрне алып китәргә мөмкин, инде тиреләр бәясенә куелган коралларны азрак дип саныйлар икән, Төн халыклары болгарлар китергән коралларга кагылмыйлар, тиреләрен икенче җиргә күчереп, өяләр, янәсе, икенче алучыга күрсәтәләр. Шунысы гаҗәп: Төн илләрендә яшәүче халыклар кардәш субашлардан сапсыз ятаганнарны теләбрәк алалар. Шул сәбәпле субаш буйтуры Чакай Фанәгүргә килде, Кубрат ханнан сапсыз ятаганнар сорады. Кубрат хан бу эшне алостаз Дәянга йөкләде. Рум сәүдәгәрләренә сапсыз ятаганнар китерегез дигән теләк белдергәч, грек сәүдәгәрләре аптырый калганнар иде. Иллә сораган ятаганнарны күпләп китерә башладылар. Грекларның күзләрен Төн илләреннән кайткан затлы тиреләр кыздыра иде, күрәсең. Төптимерче Агасике бары тик шул сәбәпле монда. Алостаз Дәян моны белә, ә менә багатыр белми. Агасике багатыр янына бик еш керә башлагач, алостаз Дәян борчылып килгән иде, ни күрсен, багатыр каршында Чалбай хан шаманы баш ора. «Бусы кемгә хезмәт итә икән тагын?»— дип уйлады алостаз Дәян түргә үтеп утыруга. Дәян ишетеп белә иде, Илтотар шаман элек кардәш субаш буйтурында булган, хәзер әнә ниндидер юллар белән Чалбай ханга юлыккан. Шаман ни тели, нигә багатырга килгән?.. Субаш буйтуры Чакайны күрмичә, моны ачыклау мөмкин түгел иде. Мул яшәгән Мангыш тархан, түмәрләрдә бүретөлке тиреләре, идәндә болан-сыер тиреләре җәелгән.

Алостаз Дәянның карашы түр яктагы эт башына төште.

— Бу ни, багатыр. Түр башында эт башы?

— Чалбай хан эткә табына иде, алостаз Дәян,— диде алостазны гаҗәпләндереп, Илтотар шаман.

— Мине беләсең, шаман?

— Беләм, алостаз Дәян. Кубрат хан субаш буйтуры Алтыр белән бу төбәкләрне буйсындырып йөргәндә минем атам Алатыр буйтурда төптәңре булып кала. Төн илләре белән сәүдә итү өчен Кубрат хан буйтур Алатырны Әтил суының өске якларында калдыра. Атам аңарда күп еллар хезмәт итте. Алатыр картайды, карт кешенең акылы арттамине куды, урыныма угланымны алды. Фанәгүргә юл чыккан идем, Чалбай ханга тап булдым.

— Шаман, минем иманым тәңре, син үзең дә тәңредән иман алган кеше, ничек эт башына табынган Чалбай ханга хезмәт иттең?

— Алостаз Дәян, минем теләгем изге иде: Чалбай ханны тәңре юласына тарту. Өлгерә алмадым, башын салды.— диде шаман һәм, күтәрелеп ишеккә юнәлде, шунда кисәк туктап:— Багатыр, бер киңәшем бар сиңа. Ышанма Рум тимерчесенә. Ул кеше сурәтенә табына. Кеше сурәтенә табынган кеше — кеше үтерер.

— Алостаз Дәян, шаманны мин синең карамакка бирдем. Югалтма, ул миңа кирәк.

— Баш өсте, багатыр. Әйдә,— диде шаманга алостаз Дәян һәм, якасыннан тотып, алып чыгып китте.

Багатыр уң кулы Ташбулаттан төптимерчене чакыртты. Төптимерче, рөхсәт сорап, түргә узды.

— Илтотар шаман сиңа зарлана, Агасике.

— Яман кеше ул, багатыр. Хәйләкәр төлке. Төлке дә төлке, шаман да төлке. Кирмәндә йөздән артык грек яши, чиркәү кебек өйләре бар. Шунда кереп, изге йортка, Гайсә сурәтенә әтәч канын сипте, мине Чалбай ханнан астырмакчы итте. Һөнәрем генә коткарып калды: ханга моңа кадәр күзе күрмәгән матур хәнҗәр ясап бирдем. Шуннан соң гына ирек алдым.

— Шаманны нишләтергә киңәш итәсең?

— Ирек богаулаган — далада бозаулаган, багатыр. Яшәсен, грек туганнарым гына кимсетелмәсен.

— Мин аны тыярмын, төптимерче. Тынычланып кит...

— Рәхмәт, багатыр.

Өйдә берүзе калгач, багатыр ишекле-түрле йөри башлады. Мичтә күмер пыскый, шәмдәлләрдә май бетеп килә, ятарга вакыт. Багатыр Мангыш тархан сәкесенә менеп ятты, сәке башындагы кеш тиресеннән тегелгән юрганны өстенә япты. Ташбулат керде, идәнгә урын җәйде, ятты һәм шундук йокыга китте.

Багатырны йокы алмады. Урман ягында бүреләр улый, аюлар үкерешкәне ишетелә — чалбайлыларның мәетләрен ботарлыйлар.

Йөрәк кысылып куйды. Чалбайлыларны да күмдерәсе булган. Өлгерә алмадылар.

Багатыр әле бер ягына, әле икенче ягына әйләнеп ятты, йокы килми дә килми. Бер атнамы, дүрт-биш көнме кайтыр ат-чабыш, Кубрат хан хәбәр алыр — Эске кирмән болгарлар кулында. Хан грек сәүдәгәрләрен янә Эске кирмәнгә җибәрер, Төн илләреннән алган товарлары белән субашлардан кахван Алатыр угланы буйтур Чакай килер. Эске кирмәндә яңадан сәүдә эшләре җанланып китәр.

Йокыга талыр алдыннан багатырның күз алдына хан кызы Чәчкә килде. Чәчкәнең зур күзләрендә тиңе булмаган матурлык, илаһи дөнья, бер Илбарыс кына аңлаган сер тулып ята иде. Чәчкәнең әнә шул серле карашын үзендә тою белән әллә нишләп китәр иде багатыр.

Илбарыс багатыр йокы аралаш каравыл торган алыпларның тукмак тавышларын ишетә һәм бу тавышлар ерагайганнан-ерагая бара иде.

— Багатыр, багатыр, уян, көн туа!— дип уятты багатырны уң кулы Ташбулат. Багатыр күзләрен ачты, яктырып беткән иде инде. Сикереп торды, тиз-тиз киенде дә су буена йөгерде. Каравыл алыплар елга як капканы ачканнар, юынырга төшүче алыпларны куәтләп торалар. Багатырны күргәч, шым булдылар.

Елга буенда халык күп иде инде. Барысы да юына, су чәчрәтеп уйныйлар, шаяралар. Багатыр өстенә кыска күн сырмасын салды һәм тез тиңентен суга керде, ахылдый-ухылдый билгә кадәр юынды, аннары сөртенде, итек-сырмасын киде дә кирмәнгә юнәлде.

— Хәерле иртә, багатыр!

— Хәерле иртә, Агасике.

— Багатыр әйбәт йокладымы?

— Бик әйбәт, Агасике.

— Адәмнәрне үтерә белгәч, җирләргә дә кирәк иде, багатыр. Аллаһы тәгаләнең каргышы төшүе бар. Алла хакына боер мәетләрне җыярга...

— Син хаклы, төптимерче. Болгарларны без кичә үк күмдек, ә менә... Иртәнге аштан соң керешербез...

— Күмү кирәк, багатыр, мәет җир өстендә ятса, фәрештәләр җанын алырга төшми торырлар, ди.

— Һы, христиан йоласы шулай диме, Агасике?

— Тәңре дә, багатыр.

Ул арада кояш чыкты. Багатыр кояшка таба карап тезләнде дә тәңредән игелекле, матур көн сорады. Багатырның чыгып килгән кояшка карап тезләнүен күргәч, төптимерче грек та, кояшка карап, уңлы-суллы чукынып алды.

*Дәвамы бар*

## Ренат Харис

# ГҮЗӘЛ ГӨМБӘЗ

*

Кайчан гына әле тын суга да
таш атмыйча түзми идем мин,—
әйдә, бер сискәнсен балык халкы,
күмелмәсен ләмгә күңеле,
утырмасын оеп төнбоеклар,
онытмасын җилне камышлар...
Дулкынланган күлдәвекне хәтта
тын күлләргә күңел алышмас.

Тынычлыкка шундый сусадым мин
давыллардан хасил заманда —
керфек каккан тавышны да кайчак
кабул итә күңел яманга.
Дулкын күрсәм әле кайчан гына
шатлыгымнан шаша идем мин...
Хәзер балык сикерсә дә куркам —
чайпалдырыр кебек Иделне.

*

Яшь йөрәкләр җил-давыллар яклы..
Тәҗрибәле күңел ашыкмый.
Болыт-өметләрдән кыйммәтлерәк
учка тамган тамчы яхшылык.

Шул тамчыны канга кушабыз без —
ашкынмаса, әйдә, ашкынмас —
туктамасын гына, ачы тозга
әйләнмәсен, кибеп, яшь сыман;

беләкне дә, хыял, йөрәкне дә
өмет белән генә сугарсын...
шулар үлсә, илне туар таңга
нәрсә генә алып чыгар соң?

Заман шундый... Безне сәрлектергән
реаль кыенлыклар, киртәләр
җилдән ауса, ава безнең өскә...
Ә җилкәдә безнең — Иртәләр.

Көннән көек исе килә.
Нидер яна... Сумы? Ташмы?..
Мин диңгезгә куркып карыйм,
аның дымлы ташын капшыйм...

Ташлар салкын...
Диңгез янмый —
акчарлаклар, әнә, оча...
Тик кайдадыр бик якында
көн итәген өткән учак...

Йөрәк яна. Йөрәк яна
Көнгә очкын ата-ата...
Ялта оҗмахында Ливан
тәмугларын карап ятам.

## Соңгы сулыш

Ватан өчен һәлак булганнарның
соңгы сулышлары
сугыш кырлары өстеннән күтәрелеп,
болытлар хасил иткәннәр дә
очып киткәннәр иксез-чиксез киңлекләргә...

Шул болытлар ничә еллар ничә илдә ничә кырга
яңгыр я кар булып яуганнар —
сугарганнар бодай, маис, банан, ананас тамырларын.

Шуның өчен дә булса кирәк
яуда һәлак булганнарны
искә ала Җир шарының барлык табыннары...

Минем баш очымда бүген моңсу болыт
явам-явам дип эленеп тора.
Күз алдымда сугыш кырлары:
Сталинград... Вьетнам... Иран-Гыйрак...

## Сугыша ике күбәләк

Ике күбәләк сугыша
Җир белән Ай арасында...
Алар бит җил җаннар гына —
өйдә, бераз шаярсыннар...
Җил дә куптара алмаслар,
ачкан-япкан керфек сыман...
Чү!
Бу нәрсә!?

Иманнарнең
ботаклары шартлап сына,
Ай-Петридән ташлар кубып,
мәрмәр сарайларны вата,
кипарислар чалкан ята,
Аю-Даг диңгезгә бата...
Канатларының оныннан
Купты болыт — кызыл-кәрән...
очкан кошлар бәрелешеп
җиргә егыла... Этләр өрә...
Җир белән Ай арасында
олы шау-шу, каргыш, нәләт...

Чәчәк түтәле өстендә
сугыша ике күбәләк...

## Төен

Айның нурын төйним һәр кич —
онытмаска саубуллашу барын:
минсез калачак кышның кары,
диңгез яры...

Йолдыз нурын төйним һәр төн —
онытмаска хушлашулар барын:
минсез калачак кышның кары,
диңгез яры,
сөйгән ярым
һәм Җир шары...

Кояш нурын төйним һәр көн —
онытмаска күкрәп яшәү барын:
тәгәрәтеп барам әле Җир шарын,
күрәм әле язлар гөлен,
кышның карын,
офыгымда диңгез яры,
кочагымда сөйгән ярым!..

Яулык читендә төен...
Нәрсә онытылмасын дип
аны төйнәгән идем?..

## Сизиф

Меңенче тапкыр тәгәрәтеп менгергәннән соң,
тау астына меңенче тапкыр тәгәрәп төшкән
ташы янына соңгы тапкыр төшкән дә Сизиф,
тәүбә иткән башка болай интекмәскә.
Йомрыланган таш өстенә менеп утырып,
аллаларның күзенә туры карап сөйләячәк
үзен яклау сүзен уйлый башлаган Сизиф.
... һәм әверелгән Роденның «Фикер иясе»нә!

...Төн барыбер гүзәл гөмбәз...
Аның терәкләре — җирнең тирәкләре,
Эверестлары, завод морҗалары, телевышкалары һәм мин.
Таулардан да, агачлардан да җиргә ныграк береккән килеш,
циркач сыман, күз нурыма терәп әйләндерәм төн гөмбәзен:
йолдызлары, Ае, космик кораблары белән,
трансконтиненталь лайнерлары, хәрби самолетлары,
ясалма иярчен ише кирәк-яраклары белән,
илләр серен урлый торган электрон караклары белән...
Әйләндерәм —
буталалар күкнең барлык маршрутлары,
чуалалар яман ниятлеләрнең кара ниятләре...
Үземнең дә баш әйләнә...
Мин шатланам Иблисне алдаган Алла сыман...
Ә карасам —
калкансыз калган икән ич чалу сөякләрем.
...Ә төн барыбер гүзәл гөмбәз!..

## Үтенеч

Гадирәк, гадирәк сөйләш минем белән —
җил белән ут,
ут белән су,
су белән җир сөйләшкәндәй:
кабызсаң — кабыз,
сүндерсәң — сүндер,
я дым сеңдер тамырыма!

## Тылмач

Әрекмән яфракларының
сырларын укый-укый,
күңелемә сеңдердем мин
бер китапта да юкны.

Хыялны күкләргә чөйде
яфраклардагы рәсем.
Яшел сызымнарда күрдем
яшәеш фәлсәфәсен.

Үләннең сүзсез телендә
җыр чыгарырлык булгач,
үсемлекне кеше белән
аңлаштыручы тылмач

итеп сиздем мин үземне.
Бу — иң олы белемем.
Дөнья миңа аңлы-аңсыз
тарафларга бүленми.

## Кушамат

Мин туган авылда да
яңа туган балага
авырлык белән исем табалар...

Һәм шул бала, тәпи баскач,
иң беренче тапкыр урамга чыга да
үзенә кушамат тагып керә...
Урам тәгәл — җисемгә исемне тиз табып бирә.

Кешенең үз кушаматы юк —
ул я урамга чыкмый калган,
ә чыккан булса,
ни бер хата, ни бер кызык,
ни батырлык эшләмәгән!..

## Тукталышларда

Бер генә яхшы шигырьне дә
тукталмыйча укып чыга алганым юк...
Һәм шул тукталышларда мине
иң гакыллы әңгәмәдәш көтеп тора:
астын өскә Җирнең айкыйбыз,
гөнаһларны савапларда чайкыйбыз,
сөенечләрдә чәчәк атабыз,
көенечләргә кереп янабыз,
акыл алабыз үкенечләрдән...

Кем соң син, әй, әңгәмәдәш:
шигырьләрнең серле иясеме,
әллә... юк, юк, булмас... үземме?

## Калкавыч

Яшәеш океанында
бер калкавыч кына булсаң — ах, аянычІ..
Бата... калка... бата... калка...
Зуррак элгә... катырак каба...
катырак каба — зуррак элгә!
Һәм бер заман
зыңлап тартыла арыган аркан,
күккә оча буш калкавыч...
Ах, аяныч — белми-күрми:
яр башында нәрсә ялтырый...

Ярый әле без — балыкчы...
Я — балык!

*

Салкын сүздән сүзсез калып туңганым бар...
Янар таудай ялкын атып сынганым бар...

Утлы караш йөрәгемне өткәне бар...
Күзләремнән үзем агу түккәнем бар...

Кайтып булмый торган җиргә озаткан бар...
Ябылып килгән ярага тоз аткан бар...

Бәхәстә отылганым бар, отканым бар...
Йотылганым һәм көчсезне йотканым бар...

Инде беттем дигәндә дә котылган бар...
Инде котылдым дигәндә тотылган бар...

Килмисен белә торып та көткәнем бар...
Каберне дә, сабыйны да үпкәнем бар...

Кыскасы шул — ярты капчык үткәнем бар..
Ә яртысын җыясы бар
бергә-бергә...

## Үзем дә күрәмен

Үз илем яманын үзем дә күрәмен —
яхшылык кылам дип кыланма!
Син аны табасың электрон күз белән,
Мин — күңел нурымны яктыртып.

Үземнең яманым — үземнең ярам ул.
Аңа тоз үзем дә күп сибәм.
Син сипкән ачы тоз — агулы ачу ул,
мин аңа күз яшем тамызам.

Үземнең яманны мин үзем яманлыйм —
иң утлы сүз белән яндырам.
Ә синең сүзләрең напалм утыннан,
мин — янган йөрәктән кабызам!

*

Нигә купты әле давыл —
бөрәр хокук даулапмы?
Кыш җиңелде. Язмышына
күптән риза... Шаулашмый,

эреп, бетеп, агып ята —
баш калкыту кая ул!
Күз күрә — күңел ышанмый...
Ышана алмый давыл!

Яз бердәнбер хаким хәзер,
кодрәте иксез-чиксез...

Ә шулай да яши алмый
«Ә бәлки...» дигән шиксез.

## Үпкәләгән алмагач

Өзделәр...
Өлгергәнен дә, өлгермәгәнен дә
сындыра-сындыра өзделәр...

Койдылар,
саргайганын да, саргаймаганын да
койды җилләр кыйный-кыйный...

Хәзер мин азат бар нәрсәдән —
ботакларны канат итеп,
очып китәм бу суынган туфрактан...

Хәзер мине бер пәрәвез җебе генә
җиргә бәйләп җибәрмичә тотып тора,
менә-менә өзеләм дип...

Һәм өзелми,
бәхеткә каршы...

*

Мәхәббәтемнең чәчәген
каерып ачмак булдым.
Таң кояштан иртә атмый...
Көтмәгәндә ябылды...

Йөрәкнең матур өлешен
ябылган чәчәк йотты.
Мин хәзер — тешләнгән алма,
мин хәзер — сагыш йорты,

мин хәзер — ачылган яра,
кузгатылган янартау...
Зинһар, назлы сүз әйтмәгез —
давылымны яңарта.



# Зөфәр Фәтхетдинов

*Зөфәр Фәтхетдинов 1940 елда Кострома шәһәрендә туа. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының юридик факультетында белем ала.*

*Хәзерге вакытта Зөфәр Фәтхетдинов — профессор, юридик фәннәр докторы, ил күләмендә билгеле галим, алтмышлап фәнни китап һәм мәкаләләр авторы. Аларның кайсылары чит телләргә дә тәрҗемә ителгән.*

*Иҗат эше белән җитмешенче еллар а°агында шөгыльләнә башлый. Аның «Ачылган серләр» исемле маҗаралы повесте 1983 елда «Казан утлары» журналында (7-8 саннар) дөнья күрде.*

## АК «ЖИГУЛИ» ЭЗ ЮГАЛТА

МАҖАРАЛЫ ПОВЕСТЬ



Кичкә таба җил күтәрелде. Ләкин бөркүлек кимемәде. Көннең сүрелер нияте күренми кебек иде. Офыкка авышкан кояш һаман да күкләрне тутырып, кайнар чуен булып агып ятуында булды. Юк... хәзер инде озакка бармас. Утлы-кызган шәфәкъның, иң биек калкулыклар түбәсендә көйрәп, иңкүлекләргә, тузанлы юлларга кисәүле-көлсу күләгә булып елышыр сәгате якынлашып килә.

Олы юл кинәт уңга — баеп баручы кояшка каршы борылып, сыртын кабарткан эткә охшап торучы текә калкулыкка үрмәли башлады. Ул шул уңайдан иске агач күпергә әверелеп, тар гына ерганак өстеннән шуышып чыга да, сырт буйлап ахыргача күтәрелгәч, сытыла-җәелә төшкән кызыл кояш табына терәлеп, туктап кала. Күрәсең, аннары тагын аска — сыртның теге ягындагы иңкүлеккә төшеп китәдер...

Калкулыклары артында яткан серлелеге белән кызыктыра да, күзкарашка киңлек бирмичә аптырата да торган яклар икән бу!

Милиция лейтенанты Нәҗип Данишев өчен болар — әлегә күнегелмәгән, ят манзара. Ул әле каршындагы бу калкулыкның бүгенгә иң соңгысы булуын, аңа күтәрелеп җиту белән, түбәндә — инде күз күреме җирдә — рәшә кебек тирбәлеп, бәләкәй генә шәһәрчек сурәте көтеп торасын белми.

Анын бүгенге сәфәре бераз уңышсызрак килеп чыкты. Әйбәт фалмы, түгелме,— Казан белән район үзәге арасында йөрүче «ПАЗ»икка әллә нәрсә булды. Пассажирлар, инде ерак калмады, тиздән кайтып житәбез, дип сөйләнә башлаганнар иде. Нәжип, төшеп, әкрен генә атлый торырга карар кылды. Инде менә жиде-сигез чакрымнар үткәндер, автобус һаман күренми. Теләсәң, узгынчы машиналарны туктатып, милиция бүлегенә кадәр илттерергә булыр иде булуын, әмма яшь следовательнең үзе эшкә билгеләнгән төбәкне алдан ук бераз караштырып барасы, күз күнектерәсе килде. Тик... юлның очы күренмәде, көн сүрелмәде, әмма әлеге теләк тиз сүрелде. «Эт сырты»на менеп житә алса, аркага ябышкан гимнастерканы салып атасы да, юл читендәге чирәмлеккә авасы иде...

Түземлекне учка кысып яулаган калкулык, дөресрәге, шунда менеп житү белән күз алдына баскан күренеш юл газапларын бер мәлгә оныттыргандай булды. Куенга бер көлтә жиләс жил килеп керде.

Күбәләк канатларыдай төрле төстәге түбәләре белән ачылып киткән шәһәрчекнең инде якында гына булуын тою рәхәт иде... Кулындагы чемоданын куеп, шул күренешне исендә калдырырга теләгәндәй, бераз басып торды Данишев. Күз карашы: «Бу шәһәрчектә мин яшисе почмак кай тирәдә булыр?»— дип чамаларга тырышты. Уйлары: «Монда мине ниләр көтә икән?..»— дип алга йөгерде.

## 1. Капитан Минаев

Район милиция бүлегенең таш баскычына тузан сарган чемоданын бастырып куйганда Данишев сәгатенә карап алды: уһу, уңынчы ярты икән инде! Ике катлы кирпеч йортның яшел ишеге шар ачык, үтеп-сүтеп йөрүче кешеләр озын буйлы яшь лейтенантка күз сирпеп алалар да, дәшми генә узып китәләр. Шулай да, кайсыдыр кире борылырга булдымы соң, кинәт арттан килеп эндәштеләр:

— Безгә эшкә түгелдер бит?!

Лейтенант тавыш килгән якка борылды. Аңа сүз каткан кеше яшь кенә, таза гына капитан икән.

— Ният бар иде.

— Ният булгач, бик хуп. Алайса, әйдә, танышып жибәрик.— Капитан кулын сузды.— Минаев Георгий Давыдович. Милиция бүлеге начальнигы.

Лейтенант үзе белән таныштырды:

— Данишев. Казан университетын тәмамлагач эшкә жибәрелгән юрист булам.— Һәм шунда ук:— Әлмәт милиция бүлегенең элеккеге сержанты,— дип өстәп куйды.

— Алай булгач, милициядә үз кеше икәнсез?— Капитан инде турыдан-туры эш тонына күчәргә өлгергән иде. Сөйләшү дә бераздан икенче катка, начальник кабинетына күчте.

— Әлмәттә — өч ел. Ике ел армиядә итек туздырдым.

— Коры жирдә, димәк!— дип сүзне ялгап китте капитан.

— Тын океан ярында, Курилда. Анда диңгезчеләр безне, коры жирдә хезмәт итүчеләрне, «итек» дип йөртәләр иде.

Милиция начальнигы үз итеп, зур коңгырт күзләрен балкытып елмайды:

— Ул сүз бездә дә бар иде. Мин үзем диңгездә хезмәт иттем. Әйтерең бармы! Безнең аякта ботинка, өстә ыспай кием, горурлык-масаю эчтән кайнар пар булып бәреп чыга. Хәзер генә кызык тоела ул чактагы балалыклар...

Бер мәлгә тынып калдылар. Үзләре сак кына бер-берсенә күз салгалап алалар. Нәкъ менә кунак кызы белән кунак егете танышкандагы

кебек — яшертен, хәтта оялчанрак сынаулы караш иде бу. Капитан үзенең тартмаларын актарган була. Нәҗип исә начальнигының кабинетын күздән кичерә. Бүлмәнең төп бизәге ике зур рәсем икән: өстәл яктагы стенада Дзержинский портреты тора, уң якта — Шишкинның урман картинасы. Картинадан дымлы урман җиле исеп куя кебек. Рәсем астына ук вәкарь белән килеп баскан мәһабәт корыч сейф, уртадарак зур ялангач өстәл, әнә шулар кәҗүнниләтеп торган бу кечкенә кабинетны, чыннан да, «урман һавасы» булу гына бераз иркенәйтә төшә икән.

Минаев, яшь лейтенантның күзе төшүен сизеп, үзе дә картинага таба борылды:

— Шуңа караган саен, үзебезнең Себер урманнарына кайткан шикелле булам,— диде. Тавышында ниндидер сагыш, тирән яшерелгән моңсулык сизелеп китте...

Капитан көрсенеп куйды һәм, үзе бөтенләй башка нәрсә турында уйлагандай, сүзен таркау гына дәвам итте:

— Гаҗәп бит: талант иясеннән калган талантлы иҗат, талантлы мирас һәр буын өчен кичә генә дөньяга килгән кебек яңа, аңлаешлы, кызыклы була. Кешеләр үзгәрә, заманнар үзгәрә, зәвыклар үзгәрә, акча алышына, ә ул кыйммәтен җуймый. Ул — адәм баласына гомерлек җан азыгы, ул ипи кебек: беркайчан да күңелне кайтармый, һәрвакыт кирәк булып кала.

Минаевны тыңлап утырганда Нәҗип үзалдына: «Тормыш агышын аңлый торган, нык сүзле кешегә охшый. Мондый начальник белән, мөгаен, ботка пешереп булыр»,— дип уйлый иде.

Капитан исә яшь лейтенантның уйчанланып китүен үзенчәрәк аңлап, фәлсәфәгә бирелә төшүеннән уңайсызланган сыман елмайды, гади генә итеп сүзне түгәрәкләргә ашыкты:

— Бу картина нәкъ хатыным кебек, кайда гына эшләсәм дә минем арттан калмый инде,— дип куйды.— Әлегә кадәр комсомол райкомында эленеп торган иде. Анда секретарь булып эшләдем. Инде менә... яңа прописка.— Беркавым тын торгач, бөтенләй тыныч, корырак тавышка күчте.— Ярар. Болар барысы да хисләнеп алу, тормышның шигырь сөйләтә торган ягы. Аның үз кубызына биетә торган яклары да күп шул әле. Кем әйтмешли, тормыш прозасына күчик.— Минаев баядан бирле актарган тартмаларның берсеннән ярты бит кәгазь тартып чыгарды.— Менә шушы язу буенча урнашырсыз. Анда бүлмә хан сарае булмас булуын, ну... эт оясы да түгел...

— Икесенең уртасымыни?— дигән булды Нәҗип.

— Баргач күрерсез. Бер сүз белән әйткәндә, дүрт ягыгызга дүрт күрше. Мин сезнең әлегә өйләнмәгән булуыгызны беләм. Үз вакыты җиткәч, башлы-күзле булып алсагыз, квартира җаен карарбыз. Тагын шунысы да бар: сез яшисе йорт — ни җитте генә түгел: шактый кызыклы культура истәлеге! Бер ягыннан соңгы готика стиле карап торса, икенче ягы — классик барокко...

Бер бите ай, бер бите кояш икән алайса... Бу нәрсә — коммуналь йортның бәясен күтәрергә тырышумы, әллә эрудицияне капшап каравымы икән?

— Гафу, иптәш капитан, миңа ул йортның кайсы ягы тиячәк соң — унҗиденче гасыр һавасын сулау насыйп булырмы, әллә... немец бароны кебек, унбишенче гасыр замогында хозурланырга туры киләчәкме?

Минаевның йөзе яктырып китте, үзе уенны дәвам иткәндәй, һаман табышмак ясады:

— Очлаеп торган тәрәзәләрдән карап яшәрсез,— диде.

— Димәк, барон тормышы булачак икән...

Капитан сизелер-сизелмәс кенә ияк какты, урыныннан торды, шәкертенә фатиха бирүче остаз кебек, җитди-тантаналы төс алды:

— Баштан ук зур, мәшәкатьле эшкә тотынырга әзер булыгыз, Данишев. Бездә үзеңнең чын бәяңне шулай гына яуларга була. Ә мин сезгә һәрчак ярдәм итәргә әзер.

Шоферына яңа хезмәткәрне өенә илтеп куярга кушып, начальник үзе җәяү кайтып китте.



## 2. Ату

Төн — караңгы серләр патшалыгы. Үткен ай урагына эләгеп корсагын ерттырган галәмәт зур болыт шәүләсе аша саркылып торган сүрән яктылыкта гади генә агач йорт та әллә ниткән шом чоңгылы булып тоела.

Артык зур булмаган менә бу йортны заманында тыгыз коймалар урамнан, кеше-кара күзеннән нык яшергәндер, мөгаен. Хәзер исә андасанда череп сынган, яисә кубарып ташлаган такта-рәшәткәләр шулкадәр күп — көндезен урамнан узып китүче һәркем ишегалдында ниләр барын рәхәтләнеп күзәтә ала.

Тик хәзер төн. Караңгы. Кул сузымы кадәр җирдән гайре берни күренми... Коймага сыланып баскан нindидер Шәүлә дә моны яхшы белә, шунлыктан ул үзен кем дә булса күрер дип борчылмый, ишегалдында җан иясе юклыгына ышангач, җил капканы ачып, кыю гына эчкә үтә, агачлар арасына кереп поса, иңеннән мылтыгын алып, тәтесен төшереп куя. Ул кемнедер көтә шикелле...

...Төн уртасы авышканда, шайтан таяклары баскан ишегалды буйлап тагын бер күләгә шуышкандай булды. Нәкъ шул мизгелдә, караңгылыкны телеп, мылтык тавышы яңгырады. Кайдадыр якында гына эт чинап җибәрде. Аңа ачыргаланып кычкырган хатын-кыз тавышы кушылды. Аннары әйләнә-тирә тагын тынып калды. Тонык кайтаваз булып ерактан килгән этләр өргәне генә ишетелде.

Мылтыклы кеше койма аша җитез генә сикереп, өрәк сыман, төн карасында эреп юкка чыкты.

Сәгать бер тулып килгәндә Данишевны милиция бүлеге дежурные чакырып алды һәм бүген төн уртасында өенә кайтып килүче ялгыз хатынга һөҗүм ясалуы турында хәбәр итте. Данишев килеп җиткәндә хатынны ашыгыч рәвештә больницага озатканнар иде инде. Бөтен кешедән алда килеп өлгергән прокурор-криминалист кына авыр яраланган ханымны рәсемгә алырга өлгергән булып чыкты.

Минаев кушуы буенча лейтенант Данишев җинаять эшләнгән урынны карауда катнашты. Беркетмә язу эше прокуратура тикшерүчесенә — пеләш башлы, әзрәк бөкресе чыга башлаган агайга тапшырылган иде. Ул үзенең кесә фонаре белән әледән-әле тротуарны яктыртып, урамның теге ягын да кармалап ала, аяк астындагы җирне капшый, дәфтәренә нәрсәдер язып куя.

Нәҗип фонарь яктысында койма тактасындагы пуля тишеген абайлап алды.

— Менә бусы ярый!— дип мактап куйды аны пеләш агай.— Урамнан түгел, ә ишегалдыннан атканнар, күрәсең.

Шунда гына барысы да ташландык йортка игътибар иттеләр.

— Бу бит... үткән ел асылынып үлгән Цветова йорты,— диде кайсыдыр.

— Ышансаң ышан, ышанмасаң юк. Бәхетсез йорт, җен ияләшкән йорт дип, халык юкка гына сөйләмидер инде,— дип аңа тагын кемдер кушылды. Моңысы шушы тирәләрнең хуҗасы — участок инспекторы икән.

Таң әтәчләре кычкыра башлагач кына таралыштылар. Ачыкланган нәрсәләр аз да түгел, күп тә түгел иде. Җинаятьче алтмыш биш метр-

дан, ишегалдының теге почмагында ук үсеп утырган алмагач артыннан торып аткан. Монысын трассологик экспертиза да раслады. Алабута баскан иске түтәл өстендә беленер-беленмәс кенә эзләр калган иде. Бу эз аяк киеменең үлчәмен ачыкларга ярдәм итте: 45 нче размер. Димәк, атучы кеше — шактый гәүдәле ир-ат! Шуннан кала берни дә билгеле түгел иде. Ни өчен атканнар (яраланган хатын анык кына берни дә әйтә алмаган); җинаятьче шушы район кешесеме, әллә читтән килүчеме; мылтык каян алган — кешедәнме, әллә үзенекеме... Менә шундый бик күп сорауларга җавап юк, һичнинди фаразга нигез бирерлек дәлил дә күренми. Әлегә кулда булган бөтен табыш — яртылаш көйгән кәгазь кисәкләре: ихтимал, җинаятьченең мылтык көпшәсеннән атылып чыккан пыж калдыклары шушыдыр. Алар төрлесе төрле кисәктән җыелган булып чыкты: укучы бала дәфтәреннән, канцелярия кәгазеннән, хәтта киногамы, театргамы дигән бер билет кыйпылчыгы да эләккән. Дәшмитынмый гына шушы кәгазьләрне караштырдылар. Бөтенесенең дә чырае караңгы иде. Баягы пеләш агай гына борынын төшермәскә тырышып:

— Чү! Җинаятьченең визит карточкасы булмагае әле бу!— дигән булды.— Кеше аңларлык мәгънә юк-югын әлегә, тик җинаять исе аңкып тора үзләреннән. Шул искә ябышып була бит, ә, егетләр?!

Милиция бүлеге начальнигы Минаев төксе генә әйтеп куйды:

— Ябышырга була анысы, үзең уйлап чыгарган әкияткә ышанып та әллә ниләр майтарырга була. Тик җинаятьче өненә алып керә торган бердәнбер ишекне таба алырсыңмы?! Ә, бәлки, бу бик шомарган адәм актыгыдыр, шушы кәгазь кисәкләрен кеше ишегалдындагы чүп савытыннан җыеп алгандыр? Безне юри ялгыш юлдан җибәрү өчен.

— Я инде, Георгий Давыдович,— диде пеләш,— сез шунда ук кирегә юрап куясыз... Яканы каерып, бозлы су салган кебек, билләһи!

— Минем юравым ялгыш булса бик шәп булыр иде дә ул...— Капитан Минаев бер мәл тынып торды да, ачык бер карарга килеп:— Яраланган хатынның кем икәнен ачыкларга кирәк. Һәм бик тиз!— диде.

Аушева Зәйнәп сугыш вакытында партизан отрядында йөргән, хөкүмәт бүләкләре алган. Сугыштан соң хәзерге көнгә кадәр тегү фабрикасында мастер булып эшли икән. Аның турында, аның белән бәйләнешле кешеләр хакында мәгълүмат шактый тиз җыелды. Ләкин җеп очы күренми иде әле.

«Бәлки кем өчендер куркыныч шаһит булгандыр, шуңа юк итәргә теләгәннәрдер аны?— дип уйланды Нәҗип.— Әйтик, партизан отрядында йөргән заманнардан ук. Андый хәлләр дә очрап куйгалый бит...» Район прокуроры җыйган киңәшмәдә бу версия, башка фикерләр белән беррәттән, алга таба өйрәнү һәм ачыклау өчен калдырылды.

## 3. Күршеләр

Лейтенант Данишев урнашкан биш катлы йортны заманында шактый калын кесәле патша түрәсе төзеткән, диләр. Аның иң соңгы хуҗасы бу тирәләрнең канын имеп яткан эшкуар булган. Революциядән соң ул качкан, йортта шәһәр кешеләре яши.

Иң өске каттагы бүлмәләрнең берсе менә хәзер Нәҗипнеке. Аның бөтен байлыгы биек түшәм белән тәрәзәдән гыйбарәт. Тәрәзәләр иске кирпеч койма белән уратып алынган ташландык бакча ягына карый икән. Күренеп тора: бүлмәгә баштанаяк ремонт кирәк.

Нәҗип җыелма караватын кайсы тешкәрәк куярга да уйлап өлгермәде, ишек шакыдылар. Шунда ук ярым ачылып киткән ишектән чалярган чәчле, борын өстенә күзлек атландырып куелган бер баш сузылды.

— Мөмкин булыр микән?— дип тыңкышланып мөгрәде әлеге баш-

ның хуҗасы. Аның инде кыска аяклары гына бусаганың теге ягында калган иде.

— Әйдүк, керегез!

— Кояшлы көннәр белән, хөрмәтлем!— Әкияттәге Хоттабыч кебек кечкенә, җиңел гәүдәле бер карт иде бу.— Безгә инде танышырга да вакыт.

— Мин бит әле...

— Беләм, беләм, хөрмәтлем. Мин, җәмәгать тәртибендә дигәндәй, бу квартирда хәлләр белән кызыксынам, бөтенесен кайгыртам, шуңа күрә һәммәсен дә белеп торуым кирәк. Мине Анатолий Григорьевич Винокуров дип йөртәләр.

— Нәҗип Гатауллович Данишев.

— Бик һәйбәт, хөрмәтлем, бик һәйбәт. Сез, кем, кадерле Нәҗип Гатауллович, безгә вакытлычага килдегезме, әллә соң ни... даими прописка беләнме?

— Бергә-бергә яшәргә исәп бар әле.

Карт, күзләрен челт-челт йомып, чукрак кеше кебек, лейтенантның авызына карап катты, борынын сызгыртып алды һәм, кинәт нәрсәдер аңлагандай, иреннәрен бөрештереп әйтә куйды:

— Әһә. Исәплисез, димәк. Ә кайчан исәпләүдән тукта... дөресрәге, кайчан тулысынча хәл итеп бетерерсез дип белик?

Коридорда тышкы ишекне шапылдатып яптылар. Тәрәзәләр зыңгылдап куйды. Кемдер, агач аяк белән йөргәндәй дөп-дөп басып килде дә, Нәҗипнең ишегенә ышкылып үтте. Шунда ук коридорның икенче башыннан исерек тавыш блән үкси-үкси җырлап җибәрде.

...Я институтка,
Я дочь камергера.
Я черная моль,
Я фея из бара...

«Хоттабыч» имән бармагын өскә күтәрде:

— Ләх булган, сизәсезме!.. Бу, хөрмәтлем, безнең уртак йортта яшәүче — Моратов Самат. Бөтенләй йөгәннән ычкынды. Үкенәм хәзер: юкка гына беренче каттан монда күчкәнмен...

Ишек бу юлы кайдадыр икенче якта шапылдады, анда Самат яңа җыр суза иде:

...Сыер тырма тырмалай!
Яз җиткәнен шундин беләм,
Кызлар артын боргалай!..

— Беләсезме, беренче катта идән боз кебек салкын, дымсу иде. Ә миндә ырматиз, хөрмәтлем. Миңа хәтле ул бүлмәдә яшәүчеләр артык интилигентчия булганнар. Мин үзем дә интилигинтчия анысы, торак конторында җаваплы эштә идем. Бер сүз белән әйткәндә — булгахтер. Канализатчияне бездә күптән түгел генә ясадылар. Әлеге шул интилигинтчияләр юынтык суларын, урамга чыгарырга оялып, идән астына гына түгә барганнар. Өй астында бака батып үләрлек сазламак барлыкка килгән... Дөрес, ул сазлыкның бер файдасы тиде — подвалда иснәнеп йөрүче ниндидер өрәкләрдән котылдык.

— Албастылар сазлыкка кызыкмадылар, дисез инде алайса...— дип көлеп җибәрде Нәҗип.— Әле, шәт, аларга ияреп, үзегезнең йорт ияләре дә качып беткәндер.

— Сез юкка гына болай авыз ерасыз, хөрмәтле кем...

— Нәҗип Гатауллович.

— Әйе, әһем. Мин сезгә хак дөресен сөйлим. Беләсезме,— тынкыш карт инде пыш-пыш килеп, Нәҗипнең колагына ук үрелде,— өрәк кебек шикле бәндәләр төннәрен безнең подвалда ломнар, көрәкләр белән актарынып йөрделәр...

Данишев тагын шаркылдап көлде. Ул әле шактый вакыт үткәч кенә аңлар: подвалдагы өрәкләр турындагы хәбәр һич көлке түгел икәнлеген дә, лейтенантка тапшырылачак эшнең нәкъ шушы хәлләр белән бәйле булып чыгасын да... Шуннан соң ул үз-үзенә: «Теләсә кемне башта игътибар белән тыңларга кирәк икән»,— дип сүз бирер. Ә тыңлаганны соңыннан аралап алырга, бәяләргә беркайчан да соң түгел...

Хәзергә исә, Нәҗип уйлавынча, бу сөйләшү, ким дигәндә, юкны бушка авыштырып утыру иде. Картны рәнҗетмәс өчен генә ул:

— Ник тотмадылар соң аларны?— дип сораган булды.

— Беләсезме, хөрмәтлем, алар безнең идән астына канализациягә дип казылган траншея аша кергәннәр. Ике ел бушка ятты ул траншея. Жуликлар шуның буйлап эргә астына үрмәләгәннәр дә инде. Халык баштарак аларны төнге сменага чыккан траншеячылар йөри дип уйлаган. Аннары кемдер, төнлә йокларга бирмиләр дип, жалу язган. Шуннан соң гына беленде. Милиция дә чакырып карадылар. Иләк белән су сөзгән кебек булды ла аларны тотарга тырышу.— Карт кулын селтәп куйды.— Әй, болары узган эш. Монда хәзерге хәлләр шәптән түгел әле. Саматны, уртак күршебезне әйтәм, һич игә китерә алмыйбыз шуны. Боламык! Тәртипкә чакыра башласаң — анаңны да фәләнне... Ә аракы сасысы!— Винокуров йөзен кулы белән каплагандай итте.— Валлаһи, авызыннан ут чәчә торган аждаһа инде: йөзеңә өрсә — аяктан егылырлык итә. Бөтен өмет сездә инде хәзер, хөрмәтлем.

Карт түргә узып, тәрәзә төбенә таянды, озын борынында җайсыз гына утырган иске күзлекне рәтләп куйды һәм авыр сулап сүзен дәвам вам итте:

— Тагын әле Розка дигән күгәрченкәебез бар, анысы менә бу як күршегез,— Винокуров зур шадралар белән бизәлгән котсыз стенага ишарәләде.— Нервынный нәрсәкәй үзе, хәзер кабынып китәргә тора — артистларың бер якта торсын. Үз чираты җиткән саен: «Идәнне юмыйм!— дип тавыш чыгара.— Кем пычраткан, шул юсын!» — ди. Бәла инде аның белән. Бәла! Иреннән аерылган, кулында унике яшьлек малай. Ә үзе — пешкән кура җиләге! Кура җиләген яратасызмы?! Эх, авызга сулар китерә ул!— «Хоттабыч» тешсез авызын чәпелдәтеп куйды.— Мәгәр безнең квартирда гайрәтле ир-ат күренсә, күзгә күренеп яхшыра Розочкабыз. Анда да фәлсәфәсе бик сәер.— Карт колак артын кашыгандай итте.— Минем күзәтүемчә, аның бөтен белгәне шул: әгәр ир-ат аны күргән минуттан итәк астына үрмәләсә,— баш-аягы белән гашыйк булган, дип уйлый. Сез, хөрмәтлем, тәртип саклаучы кеше, монысын да белеп торырга тиеш. Югыйсә, чибәр шайтан сезне дә юлдан яздырырга мөмкин...

Анатолий Григорьевич хәйләкәр генә елмаеп куйды, лейтенантка якынрак килеп, хрусталь вазага кагылгандай, сак кына аның терсәгеннән тотты:

— Хөрмәтлем, сезне бу квартирның режимы белән якыннанрак таныштырырга рөхсәт итегез.

— Соңрак мөмкин булмасмы икән?...

— Юк-юк, хөрмәтлем. Сез инде беренче көннән башлап бу монастырьның кагыйдәләрен өйрәнергә тиешсез.— Карт аны ирексезләп диярлек коридорга алып чыкты.— Сез бит тәртип сагында торучы кеше...

Анатолий Григорьевич ярым караңгы коридор буйлап Нәҗипне эчкәре алып кереп китте. Стенадагы ниндидер майлы кәгазьгә кыска бармаклары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә аңлата башлады:

— Бу дукументта барысы да төгәл билгеләнгән. Сез инде эш кешесе,— ваннада коену көнен, иртән туалетка бару вакытын үзегез сайлагыз. Безлә, телефон будкасындагы кебек, бик озакка кереп утырырга ярамый. Күп дигәндә — ун минут.

Винокуров тәртип һәм чисталык саклау турында бик тәмләп, озак-

лап сөйләде, төрле графикларга Нәҗипнең дә исемен язып куйды. Алар гәпләшеп торган арада каршы бүлмәдән зифа буйлы, кара чәчле мөлаем гына бер кыз килеп чыкты, матур кашларын сикертеп «Хоттабыч»ка карады: янәсе, нишләп йөри монда милиционер белән?

— Ә-ә, Асия хөрмәтлем. Бик вакытлы килеп чыктыгыз әле. Бу иптәш безнең яңа күрше була бит. Таныш булыгыз...

Кыз әлеге ыспай яшь лейтенантның үзләренә күрше буласын көтмәгән иде. Ул йомшак кына исәнләште дә, матур аяклары белән йөзеп баргандай җиңел атлап, кухняга үтеп китте.

— Менә бу туташ,— Винокуров кухня ягына ымлады,— беркайчан да графикны бозмый. Бик әдәпле, инсафлы бала. Гаҗәп, әмма факт.— Картның тавышында кызны үрнәк итеп кую төсмерләре сизелә иде. Ул үзе төзегән графикларга тагын бер кат күз йөртеп чыкты да, лейтенантның вакытын алуына уңайсызлангандай, тыз-быз килә башлады:

— Вәт, шул, хөрмәтлем, бу тәртипкә буйсынырга туры килер,— диде.

Кухня ягыннан чәйнек күтәргән кыз күренде.

— Бәлки, бу мөнәсәбәтләрне җайга салу эшен сез үз кулыгызга алырсыз...— диде карт.

Асия, тәкате корудан бер урында таптанып торучы милиционерны күргәч, пырхылдап җибәрде.

— Сезнең кулыгыздан килә бу эш,— дип дәвам итте карт.— Сез бит...

— Юк-юк, Анатолий Григорьевич!— дип бүлдерде аны Нәҗип, күзен әле генә үтеп киткән сылу күршесеннән ала алмыйча.— Минем вакыт ягы таррак шул.— Данишев бер мизгелгә күз алдына китерде: гөнаһлы мәчене танавы белән суга чумырган кебек, шушы майлы графиклар янына хөрмәтле күршеләренңе алып киләсең...— Юк, Анатолий Григорьевич, сез бу бик мөһим постта, зинһар, үзегез калыгыз инде. Сез, бары тик сез генә! Сездән башка беркем дә булдыра алмый бу эшне.

— Мөгаен, сез хаклыдыр,— дип сөенде карт.— Мин инде монда күптән...

— Әйе, сез тотынсагыз, әйбәтрәк килеп чыга ул!— Данишев, өстеннән зур йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйды.

Ул арада Асия инде үз бүлмәсенә барып җиткән иде, аның артыннан җиңел җил булып ишек ябылды.

## 4. Үз-үзенә кул салган...

Нәҗип милиция бүлегенә килгәндә, начальник күптән аяк өстендә иде инде.

— Күрдегезме,— диде капитан,— беренче төнне үк мамык түшәктә йоклау насыйп булмады үзегезгә. Шулай да бу сезнең файдага — эшкә керешү белән үк мондый җитди вакыйгада катнашу бөтен кешегә дә эләкми ул. Аушевага һөҗүм — әлегә бик буталчык, катлаулы эш. Аны прокуратура үз кулына ала. Ләкин сезгә дә өлеш чыгуы мөмкин.

Шуннан соң капитан, гадәттәгечә үгезне мөгезеннән алып, шәһәрдәге тәртипнең торышын аңлатты.

— Кыскасы, безгә эш юк түгел,— дип йомгаклап куйды ул.— Сез әле яңа кеше. Шуңа күрә хәзергә ике генә материал бирәм.— Минаев сейф янына килде. Иконага баккан кебек, бик игътибар белән Шишкин картинасына карап торды. Тирән сулыш алып, сейфны ачарга кереште.

«Гаҗәп аның бу үзгәрешләре,— дип үзалдына нәтиҗә ясады Нәҗип,— нәкъ оста артист кебек. Берииндн бутафория буяулар да кирәкми. Артист алдан ук билгеләп куелган рольгә керә, шуңа күрә ул ахыргача табигый булып бетә алмый. Ә капитан үзенең уй-фикеренә ярашлы

рәвештә үзгәрә, тормышка, тирә-юньгә карап хәрәкәт итә,— шуңа күрә аның кыланышлары, үз-үзен тотышы чын, табигый килеп чыга». Данишев һәрвакыт игътибар итә килә, дөньяга нечкә иләктән үткәреп карауч сизгер кешеләрдә бик сирәк һәм кыйммәтле сыйфат — үз-үзенә анализ ясау күнекмәсе була. Бу исә үз-үзеңә тәнкыйть күзе белән карый алу, димәк ки, кешелеклелек сыйфаты дигән сүз. Каты күңелле һәм тупас бәндәләр үз-үзенә тәнкыйть күзе белән карый белми...

Капитан Нажипнең алдына ике соры папка китереп салды.

— Өстәгесендә — район больницасыннан хәбәр: Гавашев дигән гражданинның билгесез кешеләр тарафыннан кыйналуы турында. Кыйналган кеше әлегә аңсыз ята.— Минаев тәрәзә янына китте, урамга карап торды һәм, артына борылмыйча гына:— Эшне тикшерү планын тезүдән башлагыз,— диде. Аннары, плацта маршка басып йөргән кебек, кискен борылып өстәл янына килде, астагы папканы үзе чиште һәм төрле төстәге таушалган кәгазь битләрен тартып чыгарды. Баш бармагы белән ияген ышкып, бераз тын торгач:

— Бусы — гражданка Цветованың үз-үзен үтерүе турындагы материал,—диде.— Үткән елның июлендә булган хәл. Бер уңайдан әйтим, ул карчык сез урнашкан йорт белән янәшәдә генә яши иде. Шушы материал нишләптер тынгы бирми миңа: бөтенесен тикшергәннәр дә кебек, үзе асылынып үлгәнлеген суд-медицина экспертизасы да раслаган... Әә, әйтергә онытып торам икән: бу эшне мин ике атна элек архивтан күтәреп алдым. Ул миңа хәтле эшләгән начальниктан калган. Мине менә нәрсә шикләндерә: карчык бик диндар булган, ә дин үз-үзеңә кул салуны хупламый, алай гынамы әле, мордар китү — бик зур гөнаһ дип аңлата. Моннан тыш тагын бер мөһим деталь: карчыкның фатирында һәр нәрсә үз урынында сакланган. Вакчыл педант булганмы ул, әллә ныклы тәртипкә буйсынган кешеме — икесенең берсе. Бөтен шкаф-тартмаларында да искиткеч тәртип. Бары бер генә тартманың эче мунчалага әйләнгән. Күрәсең, нәрсәдер эзләгәннәр. Мин бу карчык асылынырга бау эзләгәндер дип уйламыйм. Пөхтә кеше үзе куйган әйберенең кайда ятканын бик яхшы белә. Аңа эзләп азапланасы, тартманың астын-өскә китерәсе юк. Ә педантлык, гадәттә, кешенең үзе белән бергә генә үлә..

Капитан бүлмә буйлап йөренде һәм, корабль палубасында торгандай аякларын киң аерып, Данишев каршысына килеп басты.

— Шулай итеп, иптәш лейтенант, сезгә ике юлның берсен сайларга кала: я мине корт кебек кимереп яткан шикне таратырга, я... карчыкны үтерүләрен расларга! Ни эшләргә уйлыйсыз! Ике көннән фикерегезне көтәм.

Аларның бүгенге күрешүе шуның белән тәгалләнде.

Ике папка арасыннан астагысы, саллырагы — Цветованың асылынуы хакындагысы аеруча катлаулы икәнлеген аңлый иде яшь тикшерүче һәм эшне нәкъ шуннан башларга булды.

Ул баштан ук экспертизалар раслаган хакыйкатькә каршы фикер йөртергә тырышты. Дөрес, карчыкның үз-үзен үтерүе турындагы фикерне тагын бер кат дәлилләргә керешсәң дә була. Ике юлның берсен сайла, диде бит капитан. Берсен расласаң — икенчесе үзеннән-үзе кире кагыла. Тик һәрвакыт шулай буламы соң?! Тулысынча бер версиягә генә таяну Нәҗипкә бокс ярышларын карауны хәтерләтә иде: андый чакта үзең яраткан боксерның ударларын гына күреп утырасың, ә аңа төшкән йодрыкларга әллә ни игътибар ителми. Һәм уенның нәтиҗәсе дә синең өчен еш кына көтелмәгәнчә була: ни өчен яраткан боксчың җиңелде — һич аңлый алмыйсың. Сәбәпне бөтенләй башка төштән эзлисең...

Нәҗипкә, бер күз йөртеп чыгу белән, Цветованың үлеме турындагы материал инде яттан билгеле иде. Әмма кайдан башларга? Ул әле һич кенә дә тотынып китәрлек нәрсә таба алмады. Аның уйлаган версиясе

судагы кәгазь көймә кебек кыска гомерле булып чыкты: экспертиза нәтиҗәләреннән ул чыланды һәм тарала башлады, ә фактлар «көймә»не бөтенләй төпкә батырды: Цветова ишеге бикле бүлмәдә асылынган икән, ә ачкычны карчыкның үз кесәсеннән тапканнар. Бүлмәгә җинаятьченең алдан кереп калуы да мөмкин түгел: Цветова беркая да чыкмыйча диярлек бикләнеп яшәгән, кешеләр белән бөтенләй аралашмаган, беркемне дә өенә кертмәгән.

«Әйе, сумалалап куйган мичкә белән бер бу: һич саркып керерлек түгел,— дип уйланды Данишев.— Әлеге материал белән шөгыльләнгән кешеләрне дә җүләр дип булмый. Тәҗрибәле юристлар. Юкка гына эшне япмас иделәр. Барысы да бер нәтиҗәгә алып килә, димәк, килешергә туры киләчәк. Шулай да, соңгы тапкыр талпынып, үз сүзеңне әйтергә тырышып карарга кирәк».

Шундый уйлар белән ул район поликлиникасына таба юл тотты. Цветованың авыру тарихын эзләтеп алды. Карчыкның уң кулына төшкән буын ревматизмы белән интеккән икән. Экспертиза нәтиҗәсе буенча, ике кулның да терсәгендә шеш булуы билгеләп үтелгән. «Авыру тарихында ни өчен соң сул кул турында бер сүз дә юк? Ә бәлки ул врачка бик сирәк баргандыр, шул арада икенче кулы да авырта башлаган булуы мөмкин...» — дип фикер йөртте лейтенант, карчыкның иң соңгы тапкыр поликлиникага килгән көнен карады. Цветова үләренә ике көн кала врачка барган! Һәм сул кулы турында бер сүз дә әйтмәгән. Сәер. Бик сәер! Уң кулын дәвалатып кайткан да асылынган, имеш...

Көтмәгәндә Нәҗипкә шундый фикер килде: «Әгәр карчыкның сул кулын терсәктән тотып каерган булсалар, авыртудан ул аңын җуйса һәм, шуннан файдаланып, аны асып куйсалар?..» Цветованы дәвалаган врач белән сөйләшүдән соң да тикшерүченең шиге таралмады.

Берничә сәгатьтән тагын бер деталь ачыкланды: экспертиза вакытында карчыкның терсәк буыннары тикшерелмәгән, андагы шешләрне ревматизмнан гына дип уйлаганнар.

## 5. Көтелмәгән борылыш

Данишев, бөтен якларын уйлап, исәпкә алып бетергәч, катгый карарга килде. Шул ук төнне зиратта, мотоцикл утлары яктысында Цветованың каберен ачтылар. Экспертиза Нәҗипнең шикләнүен раслады: карчыкның сул кулы тайган, ә терсәктәге сеңерләре тәмам өзелгән иде.

Шулай итеп, гражданка Цветованың үтерелүе турында җинаять эше яңадан кузгатылды. Капитан Минаев бу уңайдан: «Үтерү эшләре, әлбәттә, безнең таләпчән түтиебез — прокуратура карамагында. Әмма мондый очракларда милициянең дә читтә калуы мөмкин түгел»,— диде.

Таныш, иске сораулар өр-яңадан алга килеп басты: үтерүнең сәбәбе нәрсәдә? Талау нияте беләнме? Пенсия акчасына яшәүче ялгыз карчыкта таларлык нинди байлык булырга мөмкин? Аның өендә һичбер әйбергә дә кагылмаганнар бит. Кемнеңдер бер тартмада гына казынып алуы батып барганда саламга тотыну кебек үк ышанычсыз дәлил.

Данишев, бу эшкә ныклап ябышу өчен, карчык яшәгән йортны карап чыгу кирәк, дигән фикергә килде.

Артык зур булмаган бу йорт моннан йөз илле еллар чамасы элек салынган, диләр. Аның кызыл кирпеч диварлары биек койма артында, хәзер ташландык хәлгә килгән бакча яшеллегенә чумып утыра. Бу өйне бай үзенең хезмәтчеләре өчен салдырган. Цветова инде биредә илле елга якын яшәгән икән. Ул үлгәч, варислары да күренмәгәч, йорт үзеннән-үзе башкарма комитет карамагына күчкән. Әмма әлегә кеше кертергә ашыкмаганнар — башта капиталь ремонт ясарга кирәк, ди.

Әнә ул — Цветова өе. Нәҗип, бәләкәй җил капканы ачып, ишегалдына үтте. Йорт, минага эләгеп трюмы тишелгән иске пароход сыман, бер якка янтаеп, шул авыш ягы белән бакчаның яшел күбегенә чума төшебрәк утыра. Җил капкадан болдырга кадәр көрәнсу күгәрек белән капланган юан тимерчыбык сузылган. Эт юлы. Шул юл читендә ышкылмаган такталардан сугып куелган зур эт оясы карап тора. Нәҗип өйне әйләнеп чыкты: аңа бары бер генә юлдан — болдыр ишегеннән генә керергә мөмкин икән. Бөтен тәрәзәләрне баш бармак юанлыгындагы тимер рәшәткә «пәрәвезе» сарып алган. «Өй түгел, чын-чынлап гауптвахта бу»,— дип, аны нигезеннән алып түбәсенә кадәр күздән кичерде лейтенант. Кирпеч морҗа очында, зәңгәр күк киңлегендә, сикерергә әзерләнгән кебек кукыраеп калай әтәч басып тора. Әтәч-флюгер әкрен генә шыгырдап әйләнә — бу иске бәхетсез йортның хуҗаларын сагынган кебек итеп моңсу, елак аваз чыгара.

Өйне эчке яктан карау да әллә ни бирмәде. Һәрхәлдә, тузан сарган бу «төрмә»дә соңгы чишелешкә алып чыгардай сукмак табылмады.

Лейтенант ишегалдын караштырып йөрде. Түтәлләрнең күбесен яңгыр юып бетергән, яшелчә утырта торган җирләрне тыгыз келәм булып яшел ут сарган иде. Койма буйларын котырынып кычыткан баскан.

Данишев кырынаеп торучы өйгә кабат борылып карады. Ниндидер көч аны һаман шунда таба тарта иде. Бусы, мөгаен, хезмәт вазифасын үтәүгә кермидер. Бусы аның гади кызыксыну, күңелне кымырҗытып торган үткәннәр белән, тарих белән очрашу теләге бугай. Унсигезенче йөздә патша түрәләре үз сарайлары янына шул сарайның баласы кебек бәләкәй генә матур-матур өйчекләр салып куйганнар.

Өй нигезендәге тишектән, мескен генә мияулап, йоны коелган бер арык мәче башын сузды. Цветованың мәчесе микән инде бу? Мәче юлы итеп калдырылганмы икән ул тишек, идән астына килеп чыгамы, әллә турыдан-туры өйгә керәме?..

— Ә бит мин идән асларын карамадым әле!— Янында кемдер бар кебек, кычкырып ук әйтеп куйды Нәҗип. Цветова үлгәч, тикшерү үткәргән вакытта да идән астына игътибар итүче булмаган.

Нәҗип кире өйгә керде. Озаклап эзләгәннән соң гына баз авызын тапты. Аңа төшү юлы өйалдында булып чыкты. Ул чит кеше эзләп таба алмаслык итеп, шактый оста яшерелгән иде. Нәҗип текә, авыш баскыч буйлап тирән подвалга төште. Соңгы баскычны атлауга, яңа гына сөрелгән басуга килеп кердемени — бер аягы күпереп торган салкын туфракка батып китте. Кемдер җир идәнне яртылаш казып-ерып бетергән иде. Фонарь яктысында багача утырту өчен казылган кебек тар авызлы тирән-тирән чокырлар карап күренде. Монда, әйтерсең лә, җирне актарып нидер эзләгәннәр!

Шулчак лейтенант күрше «Хоттабыч»ның хикәятен исенә төшерде. Үз подвалларында кемнәрнеңдер казынып йөрүләрен сөйләгән иде бит карт. «Бу ике подвал арасында ниндидер бәйләнеш юкмы икән? Бер үк вакытта булмаганмы бу хәлләр? Җир астыннан нәрсә эзләгән бу кешеләр? Цветованың үлеме дә аларга бәйле түгелме?»

Тикшерүче шушы сорауларга җавап табарга, казу эшләренең вакытын чамаларга тырышып, туфракны аралап маташканда, өстә ниндидер аяк тавышлары ишетелде. Өйалдындагы идән шыгырдап куйды. Нәҗип сагайды. Кем йөри бу ташландык өйдә, нишләп йөри?!

Өстә, колак тондыргыч тавыш чыгарып, подвал капкачы ябылды.

Данишев күз ачып йомганчы баскыч буйлап өскә сикерде, ләкин аркылы чыгып торган өрлеккә башы белән килеп бәрелде. Нык авыртудан күз аллары караңгыланып китте, хәлсезләнеп баскычка чүкте. Ул арада өстә, подвал ишегенә дөбердәп ниндидер авыр әйбер килеп төшкәне ишетелде. Авыртуга тешен кысып, Нәҗип яңадан өскә үрмәләде.

— Ачыгыз хәзер үк!— дип үзенә үк ят бер тавыш белән кычкырып җибәрде ул.

Өстә тынлык урнашты.

— Атам!

Тагын нәрсәдер гөрселдәп төште. Терелэй күмәргә уйлыйлар! Лейтенант берничә тапкыр атып җибәрде. Өстә яңадан тынып калдылар. Нәҗип баскычка җайлырак урнашып, подвал капкачын штанга күтәргән кебек ике куллап этәргә, баш очына күтәрергә азапланды. Авыр иде. Шулай да бераздан сызык рәвешендәге яктылык саркылды, аннары капкач өстеннән нәрсәдер дөбердәп ишелде. Ниһаять, ул үзе сыярлык юл ача алды. Сикереп чыгу белән, лейтенант өй эченә ташланды — анда беркем дә юк иде. Ишегалдында да, урамда да җан иясе күренмәде. Подвал авызын бастырып куючы бәндә, өрәк кебек, тавыш-тынсыз эреп юкка чыккан.

Тикшерүче бик сак кына, искәрмәстән һөҗүм итә калса дип әзер торган хәлдә, өйалдына яңадан әйләнеп керде. Подвал авызына аркылы яткан тимер тышлы зур авыр сандыкның капкачын ачып карады. Бераздан сандык артындагы идәндә беленер-беленмәс кенә төсмерләнгән эзне абайлап алды. Кемдер акшарлы эз калдырган иде.

«Кем булыр бу? Димәк, күзәтеп торганнар? Әллә бәлки, очраклы туры килүдер?!»

Лейтенант җилкапкага чыкты, тәнендәге киеренкелек әле сүрелмәгән иде, тагын бер тапкыр ишегалдын әйләнеп кайтты, койма тирәләрен яхшылап карады. Бер урында яңа гына тапталган кычыткаңнарга игътибар итте. Нәкъ шул турыда, койма артында, соры кыя булып, ул үзе яши торган биш катлы йорт күтәрелеп тора иде. Данишев эз буйлап коймага якынрак килде, вакыт яңгырыннан черек-соры төскә кергән такталарны капшап карады. Ике такта бары өске кадакларында гына эләгеп тора икән. Лейтенант «ишек»нең астын шудырып урам ягына килеп чыкты. Каерылган такталарның берсендә акшар тиеп киткән иде. Чак-чак беленеп торган сукмак Нәҗипне иске кирпеч коймага таба әйдәде. Ләкин эз тиздән тәмам югалды. Лейтенант туктап башын күтәрде, үз бүлмәсенең тәрәзәләренә карап алды, аннары подъездга таба юнәлде.

Подъезд баскычы янына ук төзелеш материаллары китереп бушатканнар иде. Ремонт башларга уйлыйлар, ахры. Баскычка якын ук бер мичкә тора. Тишектер, күрәсең: аннан акшар суы саркылып, сөт кебек ак күлдәвек хасил иткән. Шул күлдәвекнең бер читенә кемдер ялгыш китереп баскан. Аксыл эз аермачык булып Цветова йортына таба юнәлгән иде!

Дулкынланудан Данишевның аркасына тир бәреп чыкты. Инде Цветованың өйалдына кире барасы, теге аяк эзен үлчисе һәм төшереп аласы гына калды.

«Ни өчен билгесез кеше капкадан кермичә, безнең ишегалдыннан узды икән? Димәк, ул мине биредән торып күзәткән!»

Лейтенант үзе торган йортның подвалын да тикшерде. Андагы казу эшләре таныш булып чыкты: нәкъ шундый ук тар авызлы тирән чокырлар! Димәк... Цветованың үлеме биредәге казу эшләре белән турыдантуры бәйле булырга тиеш. Ләкин бу кадәресе әлегә зур нәтиҗә түгел, җепнең очы күренеп кенә килә иде...

Нәҗип малайларча, кем беләндер узышкан төсле, тыны кабып бишенче катка йөгереп менде. Коридор ишеге төбендә, ачкыч эзләп, ашыкпошык кесәләрен актара башлады. Ләкин ишек кинәт үзе ачылып китте — аның алдында зур гәүдәле, кене-төне эчүдән шешенгән йөзле бер бәндә чыгып басты. Бу әлеге дә баягы сәрхүш Самат иде. Ул ялт кына карап алды да, телен көчкә әйләндереп:

— Ә... Күрше... Кая таба очуың?— дип куйды.

— Өйгә.

Моратов әкрен генә юл бирде, үзе Нәҗиптән күзен алалмый басып калды.

«Күз карашы ук ниндидер бәйләнчек моның»,— дип уйлап алды Нәҗип, үзе Винокуров картның ишеген шакырга үрелде.

## 6. Җепнең очы күренә

Анатолий Григорьевичка көндезге йокысыннан айнып житү авыр булып чыкты. Ул минут саен авызын ачып исни, яңа күршесенең вакытлы-вакытсыз килеп керүенә төшенә алмый аптырый иде.

— Соң, кемнәр йөрде, дисезме безнең идән астында? Шайтан белсен аларны. Йөзләрен танытмас өчен башларына нәзек оек кигәннәр дип тә ишеттем...— Винокуров тагын бераз мышнады, ухылдады, борынын сызгыртты, ниһаять, торып, кровать кырыена аякларын салындырды.— Ни өчен безнең подвалны казыдылар, дип сорыйсызмы? Беләсезме, хөрмәтлем, бу йортның хуҗасы бөтен тирә-юньгә бер бай булган. Революциядән соң бер кат эчке ыштан белән генә качып өлгергән, диләр. Киткән дә югалган. Ә малы күп булган, банкыда сакламаган. Мин монысын сезгә финансист буларак әйтәм...

Данишев түзмәде, картны бүлдерде:

— Сез ул кадәресен кайдан беләсез соң?

Йокылы авызын учы белән томалап, карт сүзен дәвам итте:

— Миңа аны укытучым, авыр туфрагы җиңел булсын, сер итеп кенә әйтеп калдырган иде. Ул байга озак хезмәт иткән... барысын да белгән...

— Шулай итеп, бай абзый акчасын банкка салмаган, үзендә саклаган булып чыга?

— Шулаен-шулай. Ә бит ул аны үзе белән дә алып китә алмаган.

— Бусы каян билгеле?..

— Кеше сөйли, хөрмәтлем, кеше сөйли...

Икесе дә тынып калдылар.

— Ыштансыз чыгып йөгергәнен, имештер, кучеры сөйләгән, диләр. Ә бит халыкның башы түгәрәк, хөрмәтлем, кулы җитез. Күктән төшкән мал дигәндә — бигрәк тә...

— Сез соң үзегез, Анатолий Григорьевич, бу хакта ничек уйлыйсыз?

— Минем кара исәп буенча, яшереп калдырган ул малын. Җиргә күмгән. Менә шуңа һәртөрле авантюристлар, ач шакал кебек, йорт тирәсендә иснәнеп йөриләр.— Винокуров йокыдан тәмам айнып җитте бугай. Аның күзләре салкын гына ялтырап китте.— Ә теге... кем... кучер дигәннәре, беренче катта, соңрак нәкъ мин яшәгән квартирда торган, диләр. Менә шулай, хөрмәтлем.

— Фамилиясе ничек булды икән соң ул кучерның?

— Анысын ук белмим инде, хөрмәтлем. Үзем белмәгәнне әйтер хәлем юк. Ә бит бу йортта егерменче еллардан бирле дөнья көтүчеләр бар... Алардан сорашыгыз булмаса...

Данишев торак конторасына кереп, кайсы квартираларда «аксакаллар» яшәвен ачыклады, ут алынганчы шулар белән сөйләшеп чыкты. «Элегрәк билгеле нәрсәләр һәм бүген бөртекләп җыелган мәгълүмат инде ачык бер фикергә килергә нигез бирә»,— дип уйлады лейтенант.

Йокы алдыннан, арыган гәүдәне караватка ипләбрәк салып, көнозын тупланган информацияне баш мие иләгеннән үткәрергә кирәк иде.

— Шулай итеп,— дип үзалдына сөйләнә-сөйләнә йомгакны сүтә башлады Данишев,— мәрхүмә Цветова йорт хуҗасы Аршев әфәнденең

асравы — хезмәтчесе һәм, бер уңайдан сөяркәсе дә булган. Ул чакта әле кызга егерме яшь, үзе янып торган чибәр, мут...

Ишек шакыдылар.

— Керегез, бикле түгел,— дип кычкырды Нәҗип.

Ишектә күрше Асия күренде. Үзе бала кебек сулкылдый, кулъяулык чите белән күзләрен сөрткәли.

— Ачуланмагыз инде, Нәҗип абый, сезне борчыйм...

Данишев урыныннан сикереп торды:

— Нәрсә булды, Асия?!

— Алар миңа гына түгел, үткән-сүткән һәр кешегә бәйләнәләр.

— Ничек? Кемнәр инде — алар?

— Әнә шул... алкашлар. Подъездан үтәр хәл юк. Башта кертмичә интектерделәр, аннары... берсе муенсамны йолкып алды... Әни бүләге иде... чәчелеп китте... үзем көчкә ычкындым... Безнең подъездны дуңгыз абзарына әйләндереп бетерделәр инде...

Нәҗип тиз генә аска төшеп китте. Вакытны әрәм итмәс өчен, формасын да киеп тормады. Баскыч төбендә торган өч салмыш егет кычкырып-кычкырып нидер сөйләшәләр, быргычылар кебек башларын артка ташлап, шешә авызыннан гына аракы чөмерәләр иде.

— Сез нишләп әле монда аракы эчәсез?— дип кырыс кына эндәште Данишев.

Шешә имеп торучы егет мәлҗерәгән күзләрен акайтып Нәҗипкә текәлде.

— Әү, нәрсә дисең?..— дип, икенчесе кулын колагына куйган булды. Аннары йөзен ыржайтып, Нәҗипнең өстенә килә башлады.— Син, сасы көзән, кем булдың әле, ә?!

— Мин милициядән. Менә таныклыгым.

Тәрәзә төбенә менеп кунаклаган өченче «борын» иптәшләренә:

— Ха! Саташа ул!— дип кычкырды.— Мин бу яктагы бөтен мельтонны беләм. Ә бу — мәче ялаган нәрсә... Кәгазь күрсәтә, имеш — энекәченең герой-ана таныклыгын!— Тәрәз төбендәге этәч рухландыргыч нотыгын дәвам итте.— Тамыз берне үзенә, ычкынсын моннан. Рәхмәт әйтсен әле, җиңел котылдым дип. Ха!.

Ул соңгы сүзен әйтеп өлгерә алмады, Нәҗипкә тибәргә азапланган ахирне, мәтәлеп килеп, «этәч»нең аягына сыланды. Икенче егет — кыска буйлы кара тутлысы — Данишевка шешә белән кизәнде. Лейтенант аның өстенә сикерде, шешә баш очыннан гына узып, кирпеч стенада челпәрәмә килде. Кара тут күз ачып йомганчы һавада тыпырчынып алды, таш идәнгә очып төште һәм идән чүпрәге кебек җәелеп ятты.

Эшнең мондый борылыш алуын күреп, тәрәз төбендәге «этәч» идәнгә сикерде, иелә төшкән ахирен Нәҗипкә таба бәреп җибәрде дә, үзе урамга атылды. Башындагы кепкасы гына тәгәрәп калды.

Өстән аяк тавышлары ишетелде.

— Әйтәсем калмаган икән... Алар бит... Нәҗип абый!..— дип такмаклый башлаган иде Асия, шулчак идәндә аунап яткан хулиганнарны күреп, тынып калды.— У-у, сез хәтәр кеше икән! Йодрык белән дә ничек сөйләшә беләсез... Кичерегез инде, борчыдым, ялыгызны бүлдем, Нәҗип абый...

Нәҗип тынычланырга һәм тыштан булса да тыныч күренергә тырышып, кулын гына селтәде:

— Юк, исегез китмәсен, бу бит минем өчен гадәти хәл. Нишлисең бит...— дип куйды.— Аннары һәркем үз телендә сөйләшкәнне ярата! Ә болар әнә бүтән телне аңламый... Сезнең муенсаны чәчкәннәр бит әле болар. Әйдәгез әле...— Лейтенант идәнгә чүкте.— Эзләп карыйк әле... Әһә, мин инде икесен таптым,— дип сөенде,— кара, топаз [1] ич бу!

[1] Топаз — асылташ.

Кыз аңа гаҗәпләнебрәк куйды:

— Чынлап танудыгызмы? Күп кеше нишләптер топазны хрустальдан аера алмый бит. Бу муенсага, шәт, йөз илле еллап бардыр инде, әбинең әбисеннән калган...

Нәҗип телефонга чыгып керде. Тиздән милиция машинасы килеп, хулиганнарны җыеп алдылар. Кыз белән егет әле бик озак мәрҗән җыйдылар: муенса бөртекләре плинтус асларында, төрле почмакларда посып ята иде.

Нәҗипнең күңеленә таныш җыр килде:

Сары-сары гәрәбә,
Икесе әрәмәдә.
Сөйләшкән-серләшкәннәр,
Муенсаны чәчкәннәр...

— Мин ташның асылын гына түгел, кешенең асылын да яхшы аерам бугай,— дигән булды егет.

— Чынмы?— диде Асия, тагын бер мәрҗәнне алъяпкыч кесәсенә салып.— Кеше тану белән асыл таш тану бер түгел бит... Сезне эштә шулай өйрәтәләрдер инде, әйеме?

— Милиция эше — турысын әйткәндә, бик усал укытучы. Колакны борып өйрәтә. Үсемлеккә, әнә, тиз үсәр өчен җылы, дым, көләч кояш кирәк. Ә адәм баласы, минемчә, кырыс шартларда тизрәк өлгерә...

— Мин сезне, Нәҗип абый, хәтәр кеше икәнсез, дигән идем инде...— Кыз оялчан гына елмаеп куйды.— Безнең бу йортта белмичә дә каласың, үзеңне хәзер «тискәре геройлар» исәбенә кертеп куялар... Мин, әдәбият укытучысы, тискәре геройга бер ябышкан мөһернең тиз генә купмавын беләм... Шуңа күрә...

— Ю-ук, сезгә ул яктан борчыласы юк,— дип шаярта-көлә бүлдерде аны Нәҗип.— Сез — идеаль герой...

— Сезнеңчә, кем була инде ул? Идеаль герой дигәнне әйтәм...

— Беләсезме,— егет әле дә шаярта иде,— бер бик зур язучы нәрсә дигән: «Хатыннар ирләрен бөек эшләргә рухландыралар. Тик моның өчен вакыт кына калдырмыйлар»,— дигән. Идеаль хатын-кыз, димәк ки, бөек эшләргә рухландыра һәм шуңа әзме-күпме шартлар да тудыра дигән сүз.

— Мин инде кемгә шундый «идеаль шартлар тудырам» икән?

— Ну, мәсәлән, миңа...

— Сезгә?!— кызның гаҗәпләнүе йөзенә чыкты.— Ничек инде...

Нәҗип аяк очындагы шешә ватыгын бер читкә тибәреп куйды, уңайсызлана төшеп, кызның күзләренә карады.

— Ничек дип...— авыз эченнән ботка пешереп алды,— ну... сезне күргәч, күңел күтәрелеп китә... Эш әйбәтрәк бара... Аннары ярдәм итәсез, әнә бит, минем өчен идәнне юып чыгаргансыз. Миңа бик уңайсыз инде... Сезнең алда бурычлы булып калам...

— Я инде. Тагын әллә ниләр уйлап чыгармагыз. Сез юкка гына...

— Ничек, юкка гына?— дип сагаеп калды Нәҗип. «Юкка тасма телләнәсең, егет!» дип кисәтү түгелме соң бу?

— Идән юу — минем өчен рәхәт кенә, Нәҗип абый!..

Кыз тагын нидер әйтмәкче иде, ләкин, Нәҗипнең җитдиләнеп киткән күзләрен, тагын нәрсәдер әйтергә җыенган кебек таптанып торуын күреп, борылды да баскычтан менеп китте. Өске басмада туктап, әкрен генә: «Сау булыгыз»,— диде.

Нәҗипнең әле тагын сөйләшеп торасы килә иде, тик кызны юлыннан туктатырга базмады.

Берничә минуттан Данишев, утын кабызмыйча гына, «барон» тәрәзәләреннән урамга карап тора, караңгылыкка төренгән күрше йортны ачыграк күрергә тырыша иде. Кем үтерергә мөмкин карчыкны? Подвал

авызын кайсы мөртәте томалады икән? Хулиган шаяртуымы, әллә шул үтерү белән бәйлеме? Алай дисәң, җинаятьче күптән эзен югалткан, болай «шаярып», үзен куркыныч астына куеп йөрүдән аңа ни мәгънә? Сизелеп тора: анда хәйлә һәм тәҗрибә җитәрлек. Бөтен кешене ышандыра алган бит Цветованың үзе асылынып үлүенә.

Подвалдагы хәлләр белән Аушевага ату арасында даниндидер бәйләнеш юкмы икән? Ә бәлки... Цветованы үтерү, милиционерны тереләй күмәргә азаплану, Аушевага һөҗүм — бөтенесе бер чылбырга тоташкан буыннардыр?

Данишевка кинәт кенә шундый фантастик фикер дә килде. Ләкин ул шунда ук бу фикерне читкә куды: әлеге вакыйгалар арасында һичнинди эчке бәйләнеш күренми. Гомумән, җинаятьченең нәрсә теләве аңлашылмый.

Лейтенант куен дәфтәрен кулына алды. Ләкин әле дә булса куллар сизелер-сизелмәс кенә дерелди, хулиганнар белән чәкәләшү истән чыкмый, күз алдында аларның оятсыз-кызыл чырайлары биешә иде. Әйе, аларның теле бер, дип уйлап куйды Данишев. Хам, теләсә нинди хайван кебек, башына сукканны гына аңлый.

Урамнан сузып-сузып улаган тавыш ишетелде. Чү, ни бу? Кышкы төннәрдә авыл башына килгән ач бүреләр генә шулай улый иде. Бераздан улау кабатланды һәм якыная да төште шикелле:

— У-у-у...

Данишев утны сүндереп, тәрәзәсен ачты. Аста, тәрәзә каршында диярлек бер эт улый иде. Йорт янындагы фонарь янмый икән, Нәҗип астагы хәлләрне әллә ни ачык күрә алмады. «Кайдан килгән бу елак эт?» Бала чагында Нәҗипкә әнисе әйтә торган иде: «Эт уласа яхшыга түгел, улым. Эт ул бәла-каза киләсен сизеп улый...» Нәҗипкә нәкъ унбер яшь тулган көннәр иде. Малайның җан дусты Сарбай сузып-сузып көн-төн улады. Әтисе этне бәйдән ычкындырып, ачудан таяк бәреп куды. Бер айдан әниләре үлеп китте. Шул чактан ук, этнең улавы улау түгел икән ул, елау икән дип, күңеленә беркеткән иде Нәҗип.

Лейтенант бүген бик арыган иде. Тәрәзәне ябып, урынына килеп ауды. Беравык әле ераклашып, әле якынаеп ишетелгән эт улавына колак салып ятты. «Хуҗасы Цветова үлеменә елавы түгел микән бу этнең?»— дигән уй башына килде. Ләкин ничек алай булсын икән — карчык инде бер елдан артык җир астында ята.

...Нәҗип таң беленә башлаганда гына уянып китте. Тән ял итәргә өлгергән иде. Сафланып киткән башта алдан ук әзерләп куелган кебек бер фикер уянды! Күрәсең, Цветованың идән астында зур хәзинә яшеренеп яткандыр. Аны эзләп табарга һәм казып алырга комачаулаганлыктан, карчыкны үтерергә мәҗбүр булганнар. Хәзинәне таба алганнармы-юкмы — бусы әлегә билгесез. Ләкин казу эшләре тукталган икән, тапкан булулары да ихтимал. Подвалларда ике кеше казынган булса кирәк. «Төнге эшчеләр»не күреп калган кешеләр, озын буйлы ике ир ат иде, берсе шактый яшь, аксыл чәчле, аксыл йөзле, икенчесе — сумала кебек кара, диделәр. Ләкин ул «кара җен» дигәннәре (бер карт хатын аны шулай дип атады) башына кара капрон оек киеп йөргән,— чынлыкта аның үз чыраен күрүче булмаган.

Йөзен яшергәне, мөгаен, шушы тирәдәге кешедер, дип уйлады Данишев. Таныйлар дип шүрләгән! Ә иптәше? Ул ничек курыкмады икән? Шәһәр бит әллә ни зур түгел. Читтән килгән булуы хак микәнни?

## 7. Алар өчәү булган

Өйнең иртәнге күләгәсе урам аша күрше ишегалдына сузылганда, Нәҗип участок инспекторы янында утыра иде инде.

Өлкән лейтенант Шамов агай — офицер дәрәҗәсенә махсус белем алмастан, хезмәте белән генә ирешкән кеше. Чал чәче пөхтә генә итеп артка таралган, җетелеген югалтмаган күзләрендә дәрт, гайрәт, акыл һәм тәҗрибә сизелеп тора. Данишевның йомышын ул ярты сүздән аңлап алды.

— Булды андый хәл. Унтугызынчы йорттан, төнлә идән астында дөбер-шатыр киләләр, йокларга бирмиләр дип, гариза язып кертканнәр иде. Тикшердек без аны.

Шамов ниндидер папканы ачып, анда бераз казынгач, саргайган кәгазь бите алып лейтенантка сузды:

— Менә ул гариза. Үткән елгы хәл. Дружинниклардан дежурлык оештырдым, үзем дә сагалап карадым. Тота алмадык. Әйтерсең, нәкъ шул чакта гына аларны кемдер кисәтеп куя иде. Без генә китәбез — алар тагын пәйда булалар. Шунда яшәүчеләр телефонга чыгып хәбәр итеп карыйлар, барабыз — тегеләрнең эзе суынган булып чыга. Кемдер, тәгаен, кисәтеп өлгерә иде аларны. Йорт янында сыңар автомат-телефон. Күрәсең, арадан берсе, шул тирәдә булып, күзәтеп тыңлап торгандыр.

Данишев гаризаның соңгы юлларына игътибар итте:

— 16 июльдә язылган икән. Димәк, вакыйга шул көннәрдә барган...

— Әйе. Шуның алдыннан гына бер-ике көн элек телефоннан шалтыратканнар иде. Бардым. Чак кына өлгермәдем. Подъезд аша чыгып качканнар. Аңа кадәр нигез астындагы траншея буйлап сызалар иде. Ә ул вакытка траншеяны күмеп өлгердек.

Димәк, бүтән чара калмаган. Подвалдан коридор аша чыгарга туры килгән. Коридорда кешеләр очрыйсы билгеле. Шуңа күрә бу икәүнең берсе йөзен яшерергә мәҗбүр булган. Июль урталарында алар әнә ничек ачыктан-ачык йөргәннәр. Ә карчыкка июльнең 25 ендә чират житкән. Аңлашыла. Байның үз подвалында хәзинә юклыгын белгәч, хезмәтчесе йортына таба тәпиләгәннәр. Димәк, аларга бу йортларның заманында бер үк хуҗаныкы булганлыгы да мәгълүм. «Димәк...— дип уйлады лейтенант.— Җинаятьчеләр кулына шактый ышанычлы информация эләккән». Югыйсә, карчыкны үтерүгә кадәр үк барып житмәсләр иде. Моның өчен нәрсә буласын алар бик яхшы белә. Әле борынгы заманнарда ук Талион законы буенча шулай хөкем иткәннәр: күз өчен күз, теш өчен теш белән түләткәннәр. Кеше үтергән өчен хәзер дә шул принцип буенча җәза бирелә. Гадел җәза.

Бу җинаятьче кем — йорт хуҗасының якыннарыннан берсеме соң әллә?..

Данишев участок инспекторына гариза кәгазен кире кайтарды:

— Ә сез ул йорттагы Моратов дигән тип белән дусларча яшисезме?

— Чү, таныш фамилия... Тик кисәк кенә искә төшереп булмый...— Шамов маңгаен җыерып торды.— Әйе, шул үзе. Эчүдән дәваланырга җибәргәннәр иде. Качып та кайткалады. Бер ара ару гына йөрде. Тик ул дәвалану аның өчен җилгә чаршау корган кебек кенә булды. Хәдер яңадан мавыга.

Данишев шунда гына инспекторның сөйләшүенә игътибар итте. «Хәзер» димәде бит «хәдер» диде. Минзәлә, Актаныш якларыннан, күрәсең.

— Кылган эшләре уголовный кодекска сыямы соң?

— Елгыр бәндә. Тик әлегә андый гөнаһлары юк,— диде участковый.— Үзе ул Казанда туган ахырысы. Атасы зур галим, профессор, диләр. Бу нәмәкәй менә бөтенләй бүтән буразнадан бара.

«Аттан ала да туа, кола да туа шул»,— дип уйлады Нәҗип.

— Ә Цветованың туган-тумачасы тәки табылмадымы?

— Юк. Ул карчык бит, урманда яшәгән кебек, кеше күзенә чалынмады.

— Беркем белән дә аралашмады инде алайса?
— Атнага бер кибеткә барып кайткандыр да, айга бер почтага — пенсия алырга...
— Пенсияне һәркемнең өенә китереп бирәләр ләбаса.
— Бәй, чынлап та шулай шул.— Инспектор җилкәсен җыерып куйды.
— Цветова үлгәннән соң аның йортына керүче-чыгучы булмадымы?
— Өйне пичәтләп куйдылар. Мин гел караштыра йөрдем. Аяк басуы сизелмәде. Тирә-күршеләре дә зират янынннан үткән кебек әллә кайдан урап узарга тырышалар иде. Буш йортка җен ияләшә, диган сүз хак анысы. Карамыйча торсаң, төрле шикле кешеләр хәзер оялап өлгерә.
«Димәк,— дип фикер йөртте Данишев,— җинаятьчеләр соңыннан бу тирәдә күренмәгәннәр. Алар шунда ук, Цветованы үтергән минутта ук эшкә керешкәннәр. Казылган җир буенча чамалаганда, ким дигәндә, ике көн маташканнар. Ике көн буе аларның баш өстендә карчыкның үле гәүдәсе асылынып торган...»
Нәҗип участковый яныннан чыгып, почтага юл тотты.
Почта начальнигы — аксыл чырайлы, елмайганда яңагында бәхет чокыры уймакланып китә торган мөлаем генә ханым — сорауларга ашыкмыйча гына, бик тәфсилләп җавап бирде. Пенсиясен почтада калдырып торуларын Цветова үзе сораган булган икән. Аңа хат килмәгән, газета алдырмаган.
Тирә-күршеләре дә Цветованың беркем белән сөйләшмәвен-йөрешмәвен расладылар. Аның йортын һәм ялгыз тынычлыгын бүре аулый торган усал эт саклаган. Карчыкның үлеменнән соң ул эт каядыр китеп югалган.
Төштән соң Нәҗип милиция бүлегенә кире кайтты, начальникка Цветова подвалында булган хәлләрне кыскача гына сөйләп бирде.
Капитан баш авыртудан каты чәй эчеп утыра иде. Стаканын бер читкә этеп, кисәк кенә урыныннан кузгалды.
— Нишләп йөриләр кабахәтләр һаман ул йорт тирәсендә?— Минаев өстәлен урап чыкты.— Чыннан да бер үк кешеләр микәнни соң?
Ул бер йотым чәй эчеп куйды, чигәсен уып алды һәм яңадан урындыгына килеп утырды. Бер тын торгач, Данишев әзерләгән кәгазьләрне кулына алды, андагы тикшерү планын карап чыкты.
— Өеткысы бар,— диде.— Шулай да үз фикерегездә нииндидер каршылык күрмисезме. Сез менә, хәзинә инде табылган һәм таланган, дип барасыз. Ә ни өчендер үзегезне шул ук подвалга тереләй күмәргә маташалар. Сезнең арттан өйалдына кереп, җинаятьче үзен куркыныч астына куйган. Болай ук тәвәккәлләргә нәрсә мәҗбүр иткән аны?
— Мин бу хакта уйландым, иптәш капитан. Җинаятьченең, шул рәвешле, безне юлдан яздырырга маташуы да бар...
— Ә сез ничек уйлыйсыз, Нәҗип Гатауллович, Цветованы үтерү белән Аушевага һөҗүм арасында бер-бер бәйләнеш бармы?
Лейтенант җилкәсен сикертеп алды:
— Хәзергә андый бәйләнешне күрмим.
— Кызганычка каршы, әлегә моны раслау кыен шул. Аушевага атуны тикшерү өчен махсус эксперимент кирәк: миңа җинаятьченең үзүзен тотышы бик сәер тоела. Бу турыда прокуратура тикшерүчесенә дә әйттем әле. Эксперимент нәтиҗәләрен көтеп карыйк.
Капитан чәен тагын бер йотып куйды һәм шактый озак уйга чумып утырды.
— Я, хәзер, әйдәгез, сезнең план турында конкретрак сөйләшик.— Капитан телеграф тасмасыннан укыган кебек төгәл, ачык итеп тезеп китте.— Беренче. Җинаятьчеләр икәү түгел, ә өчәү булган. Өченчесе каравылда торган. Шуңа күрә алар качып өлгергәннәр. Икенче. Хәзи-

нәне урлаганнар. Моңа дәлил — Цветова подвалының яртылаш кына казылган булуы. Аларга бөтен идәнне казып бетерергә һичкем комачауламаган бит. Өченче. Җинаятьчеләр безнең кузгалуны сизеп, саклык чаралары күрәләр. Алар я Цветова каберенең кабат казылуын абайлаганнар, яисә өй тирәсендә йөри башлаудан чамалаганнар. Дүртенче. Җинаятьчеләрнең берсе монда яши. Дәлил: бай йорты тирәсендәге юлларны, хәлләрне яхшы белеп эш иткән һәм казу эшләрендә йөзен яшергән. Җинаятьче — Цветованың якын кешеләреннән булырга тиеш: югыйсә ул өйгә шома гына үтеп керә алмас иде.

Данишев капитан сөйләгәннәрне сүзгә-сүз отып калырга тырышты. Тик, үч иткәндәй, игътибарын читкә тартып, фикерен чуалтырга азапланып, бер сорау миен бораулады: «Кемгә охшаган соң бу капитан? Кайдадыр күргәнем бар бит минем бу йөзне...» Капитан сүзен төгәлләп, имән бармагы белән өстәл читенә шакып куюга, кылт итеп исенә төште Нәҗипнең. Аның начальнигы гаҗәп бер тәңгәллек белән Бетховенның скульптурадагы мәшһүр сурәтенә охшаган иде. Әйтерсең лә, мәшһүр композитор портретын ясаганда сынчы нәкъ менә милиция капитаны Минаев йөзенә карап эшләгән!

Маңгаенда — тибеп чыккан кан тамырлары кебек кабарынкы сырлар, тирән фикер һәм нык ихтыяр сизелеп торган күз карашы, кысылган иреннәр, озынча йөз... Кызык... Капитан үзенең Бетховенга охшаган булуын белмидер әле, мөгаен...

— Ничек, каршы төшәсегез килмиме шул пунктларга?

— Юк, шикелле.

Минаев башын иеп куйды:

— Яхшы, алай булгач. Инде хәзер беренче эш итеп нәрсәгә тотынырга уйлыйсыз?

— Аксыл йөзле җинаятьченең җыелма сурәтен төзергә кирәк. Кунак йортына да барып киләсе бар. Җинаятьче бәлки шунда яшәп яткандыр? Әгәр читтән килгән кеше булса, ул кайдадыр кунарга тиеш бит.— Лейтенант куен дәфтәрен ачып карады.— Аннары белешәсе иде: үткән елның август аеннан бирле алтын-көмеш әйбер белән сату итеп тотылган кеше юк микән?

Минаев яшь тикшерүченең фикерләре белән килеште һәм:

— Үткән елның июль ахырыннан алып август урталарына кадәр эшеннән чыккан яисә ялга киткән кешеләрне дә тикшерергә кирәк,— дип өстәде.

— Иптәш капитан, Цветова йортын күзәтеп тору эшен дә кемгәдер йөкләсәгез иде.

Начальник өстәл артыннан кузгалып, тәрәзә янына килде:

— Сез, Нәҗип Гатауллович, бер мөһим детальне ычкындыргансыз бит. Зур хата булмагае әле ул.

Данишев тураебрак басты.

— Сез теге акшарга баскан эзне үлчәгәнсез дә, рәсемен дә ясап алгансыз. Ник соң шул вакытта ярты юлда бүленеп калдыгыз, үзегезнең йортта кемнәр барлыгын тикшермәдегез?! Цветова хуҗалыгын күзәтү өчен сезнең йорттан да шәп урын табып булмый. Сезне, мөгаен, нәкъ менә үзегезнең подъезддан карап торганнардыр да. Кырык өченче үлчәм, билгеле, хатын-кыз аягы түгел. Көпә-көндез йортта ничә генә ир-ат булгандыр. Шик астына алырдай кешеләр шундук ачыкланыр иде, бәлки.

Минаев урынына барып утырды, лейтенантка дикъкать белән озаклап карап торды, теге көнне үк тапшырылган икенче эшнең ничек баруы белән кызыксынды. Данишев әле аңа тотынырга өлгермәвен әйткәч, капитан кашын җыерды:

— Дус итеп кенә әйтүем, берьюлы ике көймәнең койрыгын тотарга өйрәнегез. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар. Кеше хәтере бик тиз үзгәрүчән,

көн үткән саен, безнең өчен кирәкле детальләр, нечкәлекләр җуела бара. Безнең дустыбыз да — вакыт, дошманыбыз да — вакыт. Онытмагыз һәм өйрәтә дип үпкәләмәгез, Нәҗип Гатауллович.

Саубуллашканда начальник күңелле генә итеп күз кысып куйды:

— Башлавын әйбәт башлагансыз. «Шөрепләрегез» эшли. Ә тәҗрибә, чәчтәге чал кебек ул, үзеннән-үзе килә.

## 8. Эзләр

Кунакханә администраторы, кечкенә буйлы ябык хатын, Данишевның таныклыгына кырын күз ташлап, шактый коры каршылады:

— Былтыр июль-август аенда яшәгән кешеләрнең карточкаларын әзерләп куйдым. Башка вакытта, зинһар, бер генә көн булса да алдан әйтегез.

Өстәлгә бер тотам яшел кәгазь салып, администратор үз бүлмәсеннән чыгып ук китте.

Лейтенант җиң сызганып эшкә чумды. Иң беренче итеп кырык яшькә кадәрге ир-атларның карточкаларын бер якка аралап куйды.

Җинаятьченең җыелма портретын төзегәндә ниндидер «уртак ваклаучы»га килергә мөмкин иде әле, ә менә аның яшен билгеләү бик мәшәкатьле булып чыкты. Аны төрле яшьтәге кешеләр күргән. Ә төрле яшьтәге кешеләр өчен «яшь» һәм «карт» төшенчәләре бертөрле генә була алмый. Мәсәлән, унҗидедәге кызларга утыз биш яшьлек ир-егет тә карт күренсә, җитмештәгеләр өчен иллене ваклый башлаган агайэне дә әле шактый яшь булып тоела.

Район үзәгендә учреждение-оешмалар аз һәм командировкага килүчеләр дә күп түгел иде. Аларга Данишев тукталып та тормады диярлек. Командировкага килүченең вакыты чикләнгән, аның тормышы күбрәк кеше күз алдында бара. Җинаятьче гадәттә мондый шартларда эшли алмый.

Лейтенант кунак йортында бер ай чамасы яшәгән ике генә кешегә игътибар итте. Администратор белән сөйләшкәч аларның да берсеннән шикләнергә нигез калмады. Шул ук көнне Бөгелмәгә телефонограмма тапшырылды:

«Бөгелмә шәһәр милиция бүлеге начальнигына

Бик ашыгыч.

Аерым йомыш тәртибендә, тикшерү өчен, 1951 елда туган Гуцаев Петр Владимирович турында мәгълүматларны (шулай ук аның телдән ясалган портретын да) хәбәр итүегезне үтенәм.

Район милиция бүлеге начальнигы
капитан Минаев».

Данишев юл уңаенда шәһәрдәге иң зур оешмаларның берсенә — тегү фабрикасына сугылып чыгарга уйлады. Ләкин кадрлар бүлеге начальнигы әллә кая югалган булып чыкты. Берәр сәгатьтән кайтыр, үз йомышы белән йөри, диделәр. Кыскасы, хатын кибеткә киткән иде. Ачуы килеп, Нәҗип директорга шалтыратты. Начальникны бик тиз табып, утлы табага бастырдылар. Ул сиам мәчесе кебек йоннарын тырпайтып килеп керде.

Тышта җил күтәрелгән иде. Кечкенә генә бүлмәнең бердәнбер тәрәзәсе шапылдап ябылды. «Кадровичка» сискәнеп китте, тозлап-борычлап берәр сүз әйтергә дип авызын ачкан иде, кунактан яхшысынмады, ахры, борын астыннан гына мыгырдап куйды. Лейтенант эшкә алу һәм эштән азат итү турындагы приказларны карап утыра иде.

Кабинет хуҗасы җитез генә торып, тәрәзәне кире ачып җибәрде:

— Көне буе утыра-утыра, бу эт оясында буылып үләргә мөмкин.

Бүлмә ишеген әледән-әле ачып карыйлар, әмма милиция кешесен күргәч, шунда ук кире ябып куялар иде. Ачык тәрәзәдән ир-ат сөйләшүе килеп керде: чыелдык-нечкә тавышлы берәү кемнедер машинасын сатарга кыстый иде. Тегесе, каты кавказ акценты белән сабыр гына җавап бирә: «Нәрсә син мине яшь кызларны юмалаган кебек, кымтырыклыйсың. Сатмыйм мин «Волга»мны. «Соң бит син инде берне Мәхмүтовка саткансың, ә миңа — иң якын дустыңа — сатасың килми. Озакламый туй үткәрәсем бар. Кәләш алырга нәрсә белән барырмын? Сыерга атланып барырга кушмыйсыңдыр бит?» Кавказ кешесенең үз исәбе үзендә, күрәсең, тыныч кына җавап бирүен белә: «Кара сыртлы «Волга»лар сатып уйнаган кешегә сары билле «УАЗ»икка күчеп утырасы гына кала. Дарагой, кацо, төрмәдә беренче булганчы, иректә соңгы кеше булуың шәбрәк бит».

— Кара син бу диваналарны!— Кадрлар бүлеге начальнигы тәрәзәгә очып кунды.— Тапканнар сайрашыр урын. Көш моннан! Эшләргә ирек бирмисез. Милициядән килгән иптәшкә дә мишәйт итәсез.

Тәрәзә артында тынлык урнашты, ә аннары:

— Вай-вай-вай! Милициядән килгән иптәшкә дә мишәйт итәбезмени?

— Ә сез нәрсә дип белдегез?— дип кычкырып җибәрде хатын.

— Менә күрдеңме, дарагой! Әйттем бит мин сиңа, сары билле машинага күчеп утыру озак түгел дип. Тапкансың син дә сатулашыр урын!

Тәрәзәдән бүтән берни дә ишетелмәде.

Данишев үткән елның августында эштән киткән кешеләрнең исемлеген төзеп өлгерде. Алар арасында Гуцаев юк иде. Лейтенант, исемлекне начальникка сузып, шул кешеләрнең шәхси эшен карап чыгасы килүен әйтте.

Инде шәхси эшләр өеме дә сүтелеп бетте диярлек. Эш көне күптән төгәлләнде. Нәҗип, хатынны тынычландыру өчен, сәгатенә карап алгалый башлады. Шул чак ул үзе эзләгән кешене күреп алды. Чираттагы «дело» битеннән карап торган блондин бөтен кыяфәте-чырае белән сөйләүләр буенча күз алдына килгән җинаятьчегә тартым иде. Лейтенант зәңгәр картон папкага ябыштырылган язуга кабат күз салды: «Шпыру Михаил Давыдович, 1949 елгы, слесарь».

Следователь, дулкынланып, битләрен сак кына ача-ача, папканы актара башлады. Әйтерсең, аның кулында менә-менә таралып китәргә торган кульязма иде.

— Бу нинди кеше? Фабрикадан ник китте?

— Кеше төсле кеше инде. Озак эшләмәде. Ел да тулмады бугай. Семьясы белән нидер булган. Үзе шулай диде. Эштән киткәндә язуларын бик ашыктырды. Аннары үзе нишләптер хезмәт кенәгәсен дә алырга килмәде. Почта белән җибәрергә туры килде.

— Шулаймыни?— Лейтенант уйга калды.— Ә нинди адреска салдыгыз? Ул бит Одессадан килгән.

— Мин мондагы адресына яздым.— Хатын папканы алып карады.— Менә шушы адрес буенча, генерал Сафиуллин урамына.

— Кайчан булды инде бу хәл?

— Эштән киткәч тә бер ун көннән. Мин үзе килер дип уйлаган идем. Шуңа күрә бераз көтеп тордым.

— Приказ 2 нче августта бирелгән. Димәк...— Данишев кәгазьләрне тиз генә җыйды да китәргә ашыкты.— Иртәгә мин, мөгаен, тагын керермен әле... Бүген сезне тоткарладым инде, гаеп итмәгез.

Ярты сәгатьтән ул генерал Сафиуллин урамындагы 17 нче йорт каршында басып тора иде инде. Бәләкәй генә кирпеч йорт икән. Ишекне көянтә кебек сыгылып килгән ярымсукыр ачты. Тимер кроватьта кәгазь төсле ак-чырайлы авыру карт ята иде. Тикшерүченең сорауларына алар шактый ачык җавап бирделәр. Үзләрендә квартирада торган кешенең

соңгы тапкыр кайчан чыгып китүен дә хәтерлиләр икән: үткән елның 2 нче августында. Ул көнне бабай нәкъ сиксән яшен тутырган.

— Без Мишенька765 табынга дәштек,— диде карчык,— ул эшем бар әле дип чыгып китте, шул китүдән әйләнеп кайтмады. Безгә болай да озакламый китәм дип әйтә иде анысы...

— Хезмәт кенәгәсен алдыгызмы соң?

— Алдык, алдык,— дип пышылдады карчык.— Аннары арыш көлтәсе кебек сузан буйлы — синнән дә озын — бер юан мужик килде. Бөтен әйберләрен җыеп алып китте. Мишенька авырый, бүлнистә ята, диде. Без бөтен әйберен биреп җибәрдек. Безгә кешенеке кирәк түгел...

Лейтенант теге ирнең кыяфәте, кием-салымы турында сораштырды. Карчык сөйләргә иренми иде, тәфсилләп бирде.

Икенче көнне, фотосы буенча, Михаил Шпыруны Нәҗип яшәгән йорт кешеләре дә таныды. Хәзер инде аны табарга кирәк иде. Шул ук сәгатьтә больницадан белештеләр: Шпыру анда беркайчан да ятмаган булып чыкты. Элек яшәгән шәһәренә телеграмма суктылар.

«Одесса шәһәр башкарма комитетының эчке эшләр идарәсе начальнигына.

Бик ашыгыч.

1949 елны Одессада туган Шпыру Михаил Давыдовичны эзләү һәм кулга алу буенча чаралар күрүгезне сорыйбыз. Ул үткән елның июлендә гражданка А. Ф. Цветованы үтерүдә катнашуы өчен гаепләнә.

Район милиция бүлеге начальнигы капитан Минаев».

Берничә көннән Одессадан хәбәр килде: Шпыру моннан тугыз ел элек шәһәрдән күчеп киткән, туганнары аның кайдалыгын бөтенләй белмиләр икән. Бу хәбәрдә тагын бер деталь бар иде: «Мишенька» бер тапкыр кеше малын урлап тотылган һәм биш елга хөкем ителгән булып чыкты.

Инде бер генә юл калган иде — җинаятьчене бөтенсоюз кинлегендә эзләү игълан итәргә кирәк.

## 9. Көтелмәгән хәлләр

Минаев белән Данишев, икәү киңәшеп алгач, Шпыруның җинаять эшен карап чыгарга кирәк дигән фикергә килделәр. Аның үзе белән бергә утырган «ахири»ләреннән берәрсен бу эшкә дә тарткан булуы ихтимал иде.

Аннары Минаев Бөгелмәдән кергән җавапны күрсәтте. Кунакханәдә озак яшәгән Гуцаев Петр дигән кешенең Цветовага һичнинди кагылышы юк икән.

— Ә менә Аушева Зәйнәпкә һөҗүм буенча азмы-күпме ачыклык керә башлады.

Данишев урыныннан талпынып куйды:

— Минем эш белән бәйлеме?..

— Ашыкмагыз, Нәҗип Гатауллович. Чикләвек юкәдә булып чыкмагае. Эксперимент нәтиҗәләренә ышансаң, җинаятьче үзе баскан төштән Аушеваны күрмичә аткан булып чыга.

— Ә бит ул койманың әллә ничә җирдән тактасы купкан...

— Хикмәт тә шунда шул. Аушева автовокзал ягыннан кайтып килгән. Койманың нәкъ менә бөтен такталары да исән турысыннан үтеп барганда атканнар аңа. Хәтерлисезме, тактада пуля эзе калган урыннан карасаң, ишегалды бөтенләй күренми иде.

Данишев эшнең асылын хәзер генә төшенә башлады.

— Чынлап та, җинаятьче басып торган алмагач төбеннән күренү өчен, хатынга тагын аз дигәндә өч-дүрт адым атларга кирәк булгандыр.

— Шул-шул. Аушева каты яралангач та, кызу бару җаена, ике-өч адым атларга өлгергән. Ул чакта безне менә шул хәл саташтырды да. Аннары, җинаятьче аткан ераклыктан, өстәвенә төн уртасында, урамдагы хәлләрне күрү өчен ким дигәндә мәче бәбәкләре кирәк. Һәм иң соңгысы: Аушеваны атарга уйлаган җинаятьчегә ник шул хәтле ерак яшеренергә, ул бит койма артында гына да посып тора алыр иде. Шулай түгелме?

Данишевның баш кагудан кала чарасы юк иде.

— Инде шулай булгач, нинди нәтиҗәгә киләбез?

— Аушева — очраклы корбан...

— Дөрес, иптәш лейтенант. Ул җинаятьчегә очраклы гына тап булган.

— Шулай да мылтыклы кеше кемнедер сагалап торган бит?

— Әлбәттә. Тик сагалап торган кешесе килмәгән булырга мөмкин. Янсә килеп тә, атучының кулы калтыраган, пуля бөтенләй бүтән кешене аяктан еккан.

— Димәк, җинаятьче үз корбаны белән очрашуны нәкъ шушы ишегалдына билгеләгән?

— Күрәсең, шулайрак килеп чыга...— Минаев сүзен түгәрәкләргә ашыкты.— Хәзер менә, Нәҗип Гатауллович, үзегез куйган сорауга үзегез җавап бирегез инде: Цветованы үтерүче белән әлеге мылтыклы кеше арасында бәйләнеш бар дип уйлыйсызмы, әллә соңгысы бөтенләй башка җинаятьчеме?

Данишев дәшмәде.

Шул вакыт ишекне шакып, участок инспекторы Шамов килеп керде.

— Иптәш капитан, бер сәер вакыйга турында рапорт тапшырырга рөхсәт итегез.

— Тыңлыйм сезне, иптәш Шамов.

— Кичә, Рәхмәтуллин урамындагы 19 нчы йорт янында бозау хәтле эт һич көтмәгәндә бер ир-атка ташланган. Аны аяктан егып, шактый каты тешләп алган. Дружинниклар аралап алмаса, мөгаен, чәйнәп бетергән булыр иде. Тик иң мөһиме бусы түгел әле,— участковый маңгаендагы тир бөртекләрен сыпырып төшерде.— Берничә минуттан мин дә шунда килеп җиттем. Бәлага тарган гражданин кырык-кырык биш яшьләрендә булыр. Аны больницага озатыштым. Анда ул үзен Җамалетдин Силагаев дип яздырган. Палатага салганнар. Ә бүген миңа больницадан шалтыраттылар: шул адәм эзсез югалган! Әле тикшереп караган идем: безнең шәһәрдә андый кеше бөтенләй дә юк икән.

Инспектор рапортын өстәлгә куйды:

— Бер гаепсез кеше шулай алдап маташыр идеме? Нинди зур яра алган хәлдә дә больницадан качып кара син...

Капитан Минаев кашларын җыерды, арыганлыгын аз гына булса да киметү өчен, гасабиланып чигәсен уды.

— Да... Янә бер табышмак.— Начальник рапортка күз салып алды.— Ул бәндәнең килеш-килбәтен җентекләбрәк языгыз. Кайдан булса да бер калкып чыгар әле ул Силагаев.

— Иптәш капитан, мин үзем этне күрмәдем. Мәгәр шундый ук бер овчарканы безнең участокта кыш көне тотарга азапланганнар иде. Анда ул юлына аркылы төшкән берәүне бәреп еккан да... койрык очын гына күреп калганнар. Тешләвен тешләмәгән.

— Үз участогыгыздагы этләрне барлап чыгыгыз, иптәш Шамов. Андый башбаштаклыкка юл куймаска кирәк.

— Юл куймабыз, иптәш капитан.

...Төштән соң Данишев больницага китте. Аңа тапшырылган эшнең корбаны — Гавашев Миңнәхмәт әле һаман да авыр хәлдә иде. Авыру сыкранып кына урыныннан кузгалды, стена буена мендәр бастырып шуңа аркасын терәде һәм үз башыннан кичкән хәлләрне сөйли башлады.

Ул көнне Гавашев, кайдадыр тоткарланып, өенә кайтырга соңга калган. Куак төпләренә, йорт ышыкларына посып яткан кичке эңгернең тагын да куера төшеп, тын урамнарга тарала башлаган чагы икән. Өенә кайтып җитәрәк, күзгә күренмичә генә кемдер үзен эзәрлекләп бара кебек тоела башлаган аңа. Ул борылып караган, ләкин артында бер җан иясе дә күренмәгән.

Пушкин урамы аша чыкканда, Гавашевның юлын кисеп, озын буйлы, симез гәүдәле бер ир-ат узган һәм якындагы караңгы ишегалдына кереп киткән. Шул ишегалды турысын узып, ике катлы кирпеч йорт янына җитәм дигәндә генә, көтмәгәндә почмактан янә теге адәм сикереп чыккан һәм ниндидер авыр әйбер белән башына суккан. Гавашев егылган, әмма аңын җуймаган. Һөҗүм иткән кеше аны зәһәрләнеп типкәләргә тотынган... Аннары бандит кулында озын ак йөзле хәнҗәр ялтырап киткән. Өнсез-тынсыз Гавашев соңгы көчен җыеп, җан ачысы белән кычкырып җибәргән:

— А-а-а! Кот-ка-ры-гыз!!

— Тинтәк! Болай бугаз ертып кешене качырасың гына бит.— Юлбасар үзен шундый иркен тоткан, тавык суярга чыгып баскан диярсең.— Өйдә утыручылар ишекләрен хәзер соңгы келәгә бикләп куйдылар инде,— дип сөйләнүен дәвам иткән ул.— Ярый, Хаммат дус, мин синнән тәмам гарык, бәхил бул, дигән.

— Мин Хаммат түгел! Хаммат түгел мин!— дип гырылдаган үпкәсе авызына килгән Гавашев. Ул бүтән сүз әйтергә өлгермәгән, авызыннан кайнар чишмә булып кан бәреп чыккан.

Әлеге адәм актыгы Гавашевның йөзенә иелебрәк караган, кесәләрен капшаган. Ләкин шулчак урам чатыннан машина килеп чыккан. Машинаны күрү белән җинаятьче яңадан караңгы ишегалдына ташланган.

«Район милиция бүлеге
начальнигы капитан Г. Д. Минаевка

РАПОРТ

Кичә, 7 августта 23-05 сәгатьтә, машина белән патрульдә йөргәндә, безне бер гражданка туктатты һәм әле генә күрше урамнан кемнеңдер ярдәмгә чакырып кычкыруын әйтте. Без машинаны шул якка таба бордык һәм Пушкин урамындагы 7 нче йорт ишегалдына йөгереп кереп киткән ир-атны күреп калдык.

Машинадан төшеп мин аны куа киттем. Озын буйлы, таза бәдәнле бу ир кеше машина үтә алмый торган ишегаллары буйлап чаба иде. Аннары ул биш катлы йортның бер подъездына кереп качты. Мин аның артыннан калмадым. Баскыч буйлап өскә йөгереп мендем. Ләкин анда беркем дә юк иде. Шуннан соң кире төшеп, подвалга ташландым һәм подвал буйлап күрше подъездга барып чыктым. Мин урамга чыкканда йортның икенче башыннан ак төстәге «Жигули» кузгалып китте. Аңа утырган ике кешене абайлап калдым. Аларны куа чыгу мөмкин булмады, ул урам бик тыныч, бүтән бер машина да юк иде. Качып баручының кем икәнлеген анык белмәгәнлектән, корал кулланмадым.

Өлкән сержант Жбанов Н. П.»

Бу рапорт турында Данишев бер атнадан соң, менә бүген — 14 августта гына белде. Хәер, начальник кулына да ул әле бүген килеп кергән иде. Капитан Минаев өлкән сержантның командирын яхшы гына кыздырып алды. Тегесе шулай да акланырга азапланды: Жбановны нәкъ шул төнне сукыр эчәге борып алган, ашыгыч операция ясаганнар... Кыскасы, егетнең башыннан рапорт кайгысы очкан.

...Данишев бу рапортны больницада тагын бер тапкыр укып чыкты да, Гавашев сөйләгәннәр белән күңелдән генә чагыштырып карагач, портфеленә яңадан салып куйды.

— Миңнәхмәт абый, сез җинаятьченең үзегезгә Хаммат дип дәшүен дөрес ишеткәнсездер бит?

— Так точно, иптәш следователь, мин хәзер сезнең сүзләрне ишеткән кебек ишеттем. Дөрес, анда хәлләр мөшкелрәк иде...

Чынлап та, Гавашевны кем беләндер бутаган гынамы бандит? «Ахмат» димәдеме икән ул? Әллә корбанының кем икәнлеге аның өчен барыбер булганмы? Дөньяда шундый канәчкеч маньяклар да очраштыра бит әле.

Үз сүзләренә караганда, дошманнары да, көндәшләре дә юк иде Гавашевның. «Кайдан килсен алар миңа? Акча күп алмыйм, кеше белән әчелешле булганым юк»,— диде ул.

Һич гаепсезгә рәнҗетелгән бу кешене юатасы килеп китте. Шуңа күрә, палата ишегеннән чыгып барганда лейтенант саубуллашу өчен кул изәргә дип артына борылды. Марля белән уралып беткән Гавашев стенага сөяп куелган ак гипс статуяны хәтерләтә иде. Читтән караганда аның тупас формалы җилкәләре белән зур пумала башын тотып торучы кыска калын муены гына күзгә ташлана. «Мондый фигураны тагын кайда күргәнем бар соң минем?— дип уйланды Данишев, палата ишеген сак кына ябып.— Күрдем бит кайдадыр! Караңгыда җинаятьче аны шул фигурасы өчен генә тотып дөмбәсләмәде микән әле?»— дигән уй килде лейтенантның башына.

Охшашлыкны тою, әмма аңлата алмау лейтенантка тынгы бирмәде. Бу сорау бәләкәй чүкеч белән, кайдандыр эчтән баш капкачына бәреп тора кебек иде: «Кемгә шулкадәр охшаган соң ул? Кемгә?»

Данишев табышмакның беренче өлешен логик фикер йөртү юлы белән чишәргә азапланды. Әйтик, җинаятьче билгеле бер урында үзенең корбанын сагалап торган, ди. Димәк, ул аның нәкъ шул тирәдән узасын алдан белгән! Шуннан... Бу, әлбәттә, кешенең өенә кайту юлы булырга тиеш. Ләкин кайдан кайта ул — кунактанмы? Әллә эштәнме? Эштән булса, бу вариантны әле тикшереп карарга мөмкин, әгәр кунактан булса, «Хоттабыч» карт әйтмешли, иләк белән су ташу килеп чыга. Бәлки, чыннан да, әлеге кешенең эштән кайту вакыты шул чамага туры киләдер? Безнең кайсы предприятиеләрдә кичке смена бар икән?

Нәҗип, күп уйлап тормастан, теге көнне Гавашев өенә кайткан маршрут буйлап китте. Юл тегү фабрикасы белән кичке мәктәпкә таба алып бара иде. Һаман шул тегү фабрикасы тирәсендә әйләнергә туры килә! «Хаммат сирәк исем. Хамматлар фабрикада күп булмас, әлбәттә. Тикшереп чыгарга кирәк»,— дигән карарга килде Данишев.

Бу юлы хезмәт кенәгәләрен актару бәйрәм открыткаларын караштырып утыру кебек күңелле шөгыль булып тоелды. Бу — механик эш. Башны ял иттерү өчен бармакларның җитезрәк кыймылдавы кирәк. Менә ул, кулына эләккән кенәгәне ачып: «Моратов Самат» дип укыды да, чираттагысына үрелде. Бармаклардан шулай үтеп тә китәр иде, бәлки... Ләкин, йокымсырап утырган баш миенең кайсыдыр ноктасында бер фидакарь, уяу сакчы калган иде. Ул бөтен күзәнәкләрне дәррәү сискәнеп куярга мәҗбүр итте. «Моратов Самат»,— диде кабат, бу юлы хәтта иреннәрен кыймылдатып укыды Данишев. Күзалдына оятсыз чырайлы, аюдай гәүдәсе белән исерек күршесе килеп басты. Менә кайда эшли икән ул. Чү! Самат Моратов белән больницадагы Гавашевның сыннары, еректан караганда, шахмат тактасындагы ике ладья кебек охшаш түгелме соң!

Нәҗип, дулкынлануын басарга тырышып, Моратовның теге бәхетсез көнне кайсы сменада эшләгәнлеген белеште. Графикта акка кара белән язылган иде: икенче сменада!

Тикшерүче көтелмәгән нәтиҗәдән аптырап калды. Аның фикере, тирән тау мәгарәсендә адашып калган геолог сыман, шушы хәлдән чыгу юлын эзләп бәргәләнә иде. Әлбәттә, Гавашевның, куркудан, Самат дигән исемне Хаммат дип ишеткән булуы бик ихтимал. Ләкин бу ничек килеп чыга соң әле? Моратовны үтерергә теләгәннәрме? Кемгә ярый алмаган ул һәм ни өчен?

Самат, әлбәттә, эчү аркасында, юкка чыгып баручы бәндә. Әгәр

шулай дәвам итсә — аракыга сусавын басар өчен ул теләсә нинди җинаятькә дә барырга мөмкин. Әйтик, шул ук Цветованы асканда элмәкнең бер башына Моратов ябышмас дисеңме? Бәлки, хәзер ул, капсюлы шартлаган патрон кебек, кирәксез бер нәрсә булып калгандыр. «Ахири»ларының артык шаһиттан котыласылары килгәндер!

Менә бит әле Шпыру да суга төшкән таш кебек юкка чыкты. Аны инде теге дөнья капкасыннан кертеп җибәрергә өлгермәделәрме икән? Хәрәм малның кадерен белүчеләр аны теләсә кем белән бүлешергә яратмыйлар.

Нәҗип сүтелгән версия җепләрен тиз генә бер йомгакка җыйды. «Әгәр болар барысы да хыял җимеше генә булса?» Шул уй, салкын су сипкән кебек, аны яңадан үз халенә кайтарды. Ул тикшерүне азаккача дәвам итәргә булды. Ләкин Хаммат яисә Самат исемле бүтән кеше фабрикада да, кичке мәктәптә дә юк иде.

Капитан Минаев яшь лейтенантның яңа табышмакларыннан бик канәгать булды.

— Монда инде нәрсәдер бар!— дип начальник учын-учка ышкып куйды.— Эләктерим дигән кешегә җеп очы күренә. Әлегә кадәр, «сукыр тәкә» уйнагандагы кебек, бәйләгән күз белән нәрсәдер тотарга азапланып йөрдек бит.

Минаев шунда ук уголовный розыск начальнигын чакыртып алды.

— Шәүкәт Идрисович, һич кичекмәстән гражданин Моратов артыннан күзәтү оештырырга кирәк. Ул Цветованы үтерү эшенә катнашкан булырга тиеш. Ни дәрәҗәдә? Кемнәр белән берлектә? Бусын әле ачыклыйсы бар. Ләкин бер нәрсә төгәл билгеле: хәзер аңардан котылырга чамалыйлар.

## 10. Асия

Нәҗип һәркөнне эштән кайтышлый, юл уңаендагы азык-төлек кибетенә сугылып чыга иде. Бүген: «Соңгарак калынды, ябылып өлгермәгәе»,— дип ашыгып барганда, урам чатында үзенең талчыбыктай зифа күршесе белән бәрелешә язды.

Бер мәлгә алар икесе дә аптырап калдылар. Без кайдадыр бер күрешкән идек түгелме соң дип, искә төшерергә азаплангандай, бер-берсенә гаҗәпләнеп карап тордылар. Иң әүвәл кыз телгә килде:

— Сезме соң бу?!— дигән булды.

— Хәерле кич, Асия. Мин дә сезне күрермен дип уйламаган идем...

— Каядыр ашыга идегез бугай, Нәҗип абый... Юлыгызны бүлмәдемме?— Кыз уңайсызланып, башын иде.

— Нинди сүз ул!..

Алар бүтән берни дә сорашмастан, парк ягына таба юл алдылар. Әйтерсең лә, шунда барырга дип алдан килешеп куйганнар иде.

Кичке сәгатьләрдә шәһәр паркында зур җанлылык сизелә. Мондагы бөтен хәрәкәт танцы мәйданчыгыннан ишетелгән джаз ритмнарына буйсына кебек. Мәйданчык үзе исә, еракган караганда, төрле төсләре белән җемелдәп, берөзлексез әйләнеп торучы карусельны хәтерләтә.

— Да-а...— тимер рәшәткә белән уратылган мәйдандагы мәхшәргә карап, Нәҗип уйга калган иде.— Вакыт — безнең дустыбыз, вакыт — безнең дошманыбыз, ди минем начальник... Хәзер болай кәҗә тәкәсе кебек сикерәсе килми инде. Сөякләр авыр...

Асия аңа бер генә күз салып, елмаеп куйды: егетнең сакалын сәлперәйткән карт кебек сөйләнеп торуы мәзәк иде.

Парктагы үзәк аллея шактый тар. Аны җәелеп китүдән як-яктагы карт агачлар тотып тора кебек. Куе ябалдашларның юл өстендәге зәңгәр ачыклыкны томалап, бер-берсенә тоташуыннан гаҗәеп тоннель ха-

сил булган. Аяклар үзеннән-үзе шул яшел тоннель буйлап үтәргә кызыга иде. Паркның икенче башындагы тәбәнәк агач рәшәткәгә кадәр сүзсез генә атладылар. Рәшәткәнең теге ягыннан текә ерым башланып китә. Аста, шушы иңкүлек төбендә тыгыз, тәртипсез урнашкан умарта ояларыдай, кечкенә йортлар — бакчалар сибелеп ята икән. Иңкүлек буйлап арырак китсәң, корыч хәнҗәр йөзедәй тар тасма булып елга ялтырый.

— Кечкенә шәһәрнең шул ягы уңай, бер башыннан икенче башына тәпи-тәпи дә барып җитәргә була. Мин җәяү йөрергә яратам. Аннары монда яшеллек күп...

— Әйе. Миңа да бу шәһәрчек ошый.

Бераз дәшми тордылар.

— Асия, сез элек кайда яши идегез?

— Бөгелмәдә. Мине бирегә эшкә җибәрделәр... Өч елга...— Кыз рәшәткәгә таянып, аны бармак очлары белән капшап дигәндәй итте.— Әнине алып киләсем килә. Ул анда ялгызы...

Рәшәткә буендагы бер эскәмия тирәсендә чеби төсле генә кызлар, малайлар килеп оялаган. Чыелдыйлар, чыркылдашалар, ә эскәмия өстендә Вахтанг Кикабидзе тавышы белән җырлап утырган магнитофон, чеби әнкәсе кебек, аларны үз янына чакыра иде:

Мои года — мое богатство...

Яңарак кына танышкан ике кеше үзара сөйләшеп китсә, аларның сүзе бик тиз үзгәреп торучан була. Моның сәбәбе төрле темалар буенча бер-береңне сынап-тикшереп карауда түгел. Шундый чакта тегене-моны сөйләшеп тору, уртак сүз эзләү — гәптәшеңне нәрсә кызыксындыруын белергә тырышу гына. Асия дә, мөгаен, шуңа күрәдер, Кикабидзе җырына игътибар иткән булды:

— Бик мәгънәле сүзләр...— дип уйчан йөз белән әйтеп куйды ул.— «Үткән еллар — минем байлыгым».

— Анысы дөрес,— дип хәйләкәр генә күз кысты Нәҗип. Аның сүзне шаяртуга борасы килә иде.— Ләкин... һәркемнең шул байлыктан котылып... банкрот булып каласы киләдер.

— Афоризм! Үзегез уйлап тапканмы?

Нәҗип дәшмәде.

— Дәшмәү — ризалык билгесе. Рим судьялары шулай дип хөкем иткәннәрме әле?

— Ә сез моны каян беләсез?

Кыз гәүдәсен турайта төште, башын югары күтәрде:

— Юристларны бераз чамалыйм мин... Алар үзләрен генә дөнья тоткасы дип уйлыйлар. Күп белүләре хак анысы. Тик кайчакта, бүтән кешеләр хокук фәнен укымый, аңламый дип кенә ялгышалар.

— Сез дә укыйсызмы?

— Мин, мәсәлән, үзем өчен кызыклы бер нәрсәгә игътибар иттем. Наполеон Бонопартның сугыш чукмары икәнен белмәгән кеше юктыр. Полководец буларак аның бәясе хәзер бер тиенгә дә тормый. Ә Наполеон төзегән гражданлык кодексы бүген дә гамәлдә икән: Франциядә, тагын кайсыдыр илләрдә. Шушы мавыгу — юристлык аның төп шөгыленнән — полководецлыгыннан көчлерәк булып чыккан. Тыныч эшләр, күрәсең, дөньяны яулап алу данынnan да озынрак гомерле була!

— Шулай...— дип килеште егет, соклануын яшермичә.

Асия сүзнең артык җитдиләнеп китүен абайлап алды.

— Менә бит. Юристлар турында сөйләшә башлауга, дөньякүләм мәсьәләләргә барып төртелгәнбез. Юристлар шулай инде алар, акыллы темаларны яраталар, әйеме?

Нәҗип тагын башын җилкәләргә салды:

— Әллә тагын... Сез укыган китапларда шулай язылса гына инде...

— Аһ! Минем җыр!— дип канатланып куйды Асия.

Парк шау-шуы өстеннән татарча җыр күтәрелеп килә иде:

Минем белән бергә бәхетем туган —
Өлешемә тигән көмешем.
Шул бәхетемне эзләп юлга чыктым,
Шул бәхетемне эзләп килешем...

Җыр тынганчы сүз ялганмады. Һәр икесе үз уйларына чумган иде. Агач яфракларын кыштырдатып җил кузгалды. Асия башын артка чөеп күккә караган иде — аһ итте.

— Яңгыр килә, Нәҗип абый! Әйдәгез, тизрәк өйгә йөгерик.

Нәҗипнең әле кайтасы килми иде, тик эшләрнең күплеге исенә төшеп, әкрен генә кыз артыннан атлады. Шунда ук аның йөзенә болыт күләгәсе төшкәндәй булды.

Баягы пластинканы тагын куйдылар:

Юлларымда бәхет күп очрады,
Тик берсе дә түгел минеке...

— Вафирә Гыйззәтуллина...— дип, үзалдына гына сөйләнгәндәй әйтеп куйды Асия.— Ә сез нигәдер күңелсезләнеп киттегез әле, Нәҗип абый.

Егет елмаеп куйды.

— Әйдә, юл уңаенда мин сезгә бераз чәчәкләр турында сөйләп кайтам. Букетлар төзү турында. Сез чәчәк яратасызмы?

— Сөйләгез, Асия, миңа сезне тыңлау кызык...

— Беләсезме, борынгы Римда...— Асия яңадан укытучы кыяфәтенә керде,— ...греклар венок ясарга яратканнар. Ә Көнчыгыш илләрендә чәчәкне гирлянда итеп үргәннәр. Хәзерге букетлар Яңарыш чорында...

Нәҗип кызга беренче тапкыр туп-туры карады: аның зур тере күзләре, матур борыны, алсуланып киткән яңагы... ап-ак муенындагы сыңар миңе...— барысы да үзенә тартып тора иде. Бу вакытта кызның сүзләрен егет бөтенләй диярлек ишетми, ул аңа сокланып-яратып караудан дөньясын онытқан иде.

Асия моны сизеп, алсу алма кебек янып китте.

— Мин сезгә чәчәкләр турында сөйлим, ә сезнең, минемчә, башыгызда бүтән җилләр уйный...— диде ул йомшак тавыш белән, әз генә үпкә белдереп.

— Чәчәк турында, фәкать чәчәк турында гына уйлыйм!— диде егет ант иткән сыман, кулларын алга кушырып.— Шул хәтле кызык нәрсәләр сөйләгәндә, башка бүтән уй керәмени!

Кыз ышанмыйча гына аңа карап алды, шулай да сүзен дәвам итте:

— Яңарыш чорында — әле кечкенә букетлар заманы. Тора-бара XVIII гасырда бугай, колач җитмәслек зур чәчәк бәйләмнәре модага кергән. Ә аннары...— Асия егеткә сынаулы караш ташлады, ләкин бер гаеп эш тә күрмәде.— Аннары чәчәктән көлтә бәйләү гадәте беткән, өч чәчәктән генә торган нәфис букетлар төзи башлаганнар...

Егетнең янә ымсынулы карашын тоеп, Асия тынып калды.

Алар инде, үзләре дә сизмәстән, өй янына ук кайтып җиткәннәр икән. Урамдагы тузаннарны тузгытып җил күтәрде.

Ишегалдында аларга Моратов каршы очрады. Ул, суга төшкән тавык кебек, бик өтекләнеп киткән әле. Үзе нинди дер зур киндер сумка өстерәп чыгып бара. Сумкадан муеннарын сузып буш шешәләр карап тора иде.

— Ох. Менә безнең пирсанальный начәлник тә кайтып килә.— Моратов авызын ерып, сары тешләрен ыржайтты, алагаем зур кепкасын күтәреп куйгандай итте һәм, туктап тормастан, үз юлында булды.

Алар бишенче катка күтәрелделәр. Коридорда саубуллаштылар. Асия беренче тапкыр кулын бирде; читтән карап торучы булса, болар икесе ике урамда яшәүче кешеләр икән, дип уилар иде.

## 11. Шомлы төн

Яшенле яңгыр төн карасы куера башлагач килеп җитте. Килеп тә җитте, коя да башлады. Кисәк җил искәндә яңгыр агынтысы беләк юанлыгы аркан булып тәрәзәне кыйнады, ачык форточкадан чәчрәп кергән тамчылар күптән буявы уңган тәрәзә төбен чылатты. Әледән-әле бүлмәне яктыртып зәңгәр балкыш чатыр-чотыр килде.

Нәҗип ут алып тормады. Җиңел караватын тәрәзә яныннан стена буенарак өстерәп килде дә, Асия белән әле генә булган очрашуны күз алдыннан кичереп, ләззәткә чумды.

Күк күкрәү тынып торган арада, урамнан сузып-сузып эт улаган тавыш ишетелде. Тавыш бу юлы тоныграк шикелле иде. «Тагын шул эт килгәнме!? Әллә бусы — теге, больницадан чыгып сызган Силагаевка ташланган овчаркамы? Ә бәлки... Икесе дә бер үк эт булырга мөмкин бит. Ә нишләп әле ул һаман безнең йорт тирәсендә әйләнә?..»

Данишевның ишеткәне бар: затлы нәселдән килүче этләр кайчакта үзләренең элеккеге хуҗаларын чит кешеләргә караганда да ныграк күралмыйлар икән. Бала чакта ул үзе дә Мохтар дигән эт турында бер кино караган иде. Кинодагы Мохтар үзенең хуҗасын өзгәләп ташлардай булып ябышкан иде... «Монда да шундый ук хәл түгел микән?» — дип баш ватты Данишев.

Кемдер, аның уйларын бүлеп, каты итеп ишек шакыды.

— Керегез!

Бүлмәгә ун-унике яшьләрдәге бер малай килеп керде.

— Абый, мин сезнең күршедә яшим. Бүген без әни белән авылдан кайттык. Ул әле өйдә юк...

Нәҗип утны кабызды.

— Исемең ничек соң синең?

— Әхәт.

— Кил, утыр, Әхәт, менә монда.

— Абый! Анда Настя әбинең эте улый. Мин куркам. Ул бик зур. Настя әби үлде, эте бәйдән ычкынып качты. Былтыр да шулай улаган иде. Аннары бик озак күренмәде... Бик усал эт ул. Абый, әйдә безнең бүлмәгә. Мин сезгә ул этне күрсәтәм. Яшен яшьнәгәндә күренә. Абый, әйдә инде безгә. Минем йокым да килә...

— Ярар, әйдә алайса...

Ләкин этне күрә алмадылар. Ул инде китеп барган иде, ахрысы. Озакламый бүлмәгә утыз яшьләрендәге, мәһабәт сынлы, чибәр ханым килеп керде. Ул Нәҗипкә сәерсенүле караш ташлады.

— Әнкәй, бу безнең күрше абый. Мин курыктым да, аны чакырдым.

— Роза,— диде ханым һәм күрешергә дип кулын сузды.— Рәхмәт инде сезгә...

Шул ук мәлдә кинәт ишек ачылып, бусагада Моратов күренде. Күзләрен маңгаена тәгәрәтеп бер Нәҗипкә, бер Розага карады:

— Куллар кысышасыз, ә! Бик тиз, мин сиңайтим!.. Хуть... урын җәяр вакыт җиткән икән шул инде. Мин соңгарак калганмын.

— Нәрсә иснәнеп йөрисең, сөрхәнтәй!— дип чыжылдап аның сүзен бүлде хатын.

Моратовның балак очларыннан идәнгә су тамып тора иде.

— Пардон... пардон, Розочка.

Ул ботинкасын салып тормыйча гына түргә узды һәм пөхтәләп җыештырылган урын-җир өстенә килеп утырды.

— Мин, Розочка, сиңа дип кергән идем. Бу станок бик сагындырды, етить!— Самат кыдрачланып, кровать башын шапылдатты.— Ә монау начәнник,— ул кулы белән Данишевка төртеп күрсәтте,— йорттагы өвтен хатыннарны аздырып бетерә инде... Ахры, тушы станга да... борының суза башлаган.

Данишев Саматның сүзеннән бигрәк, ботинкасына игътибар итте: аңа ябышып кергән быкырдык-балчык чип-чиста идән буйлап бик ачык эз калдырып үткән иде. Хәзер лейтенантның колагына өер сүз дә керми, әлеге эзне ничек төшереп алырга дип кенә исәп кора башлады.

Ул арада ханым йөрәксенеп ишеккә килде, аны бәреп ачты һәм Моратовка коридор юлын күрсәтте:

— Ычкын моннан, хәшәрәт!

Бусагага килеп җиткәч, Самат әкрен генә артына борылды:

— Нәчәнник, син үзеңне Розочканың...— ул житез ишарә белән үз гәүдәсенә калкулыклар ясап күрсәтте,— җимешен татыган соңгы кеше булырмын дип уйлама!

Моратов ишекне шапылдатып япты һәм коридорга бик әшәке итеп кычкыра башлады.

Нәҗип, кибеп өлгергәнче, аяк эзен төшереп алырга ашыга иде. Ул тиз генә бүлмәсенә чыгып, үтә күренмәле зур кәгазь алып керде. Пычрак эз өстенә шуны җәеп, карандаш белән ачык контур ясады. Аннары Розадан линейка сорап алды да, нәрсәдер үлчәде, исәпләде. Хатын Нәҗипнең кыланышларын бөтенләй аңышмый калды. Лейтенант аңа бу хакта беркемгә дә сөйләмәскә кушты.

Егет, ишекне ачып коридорга чыгуга, Асия белән йөзгә-йөз килде.

— Сез... Аңа...— Кыз каушап-тетрәнеп калган, йөзеннән нур качкан иде. Ул йөзен каплап, үзенең бүлмәсенә йөгерде.

Нәҗип эшнең асылын төшенеп алганда соң иде инде. Шулай да тиз генә барып, кызның ишеген ачты:

— Мине аның малае чакырды.... Бу бер аңлашылмаучылык кына, Асия. Мин бит эш белән...

Кыз, әле дә булса йөзен учлары белән каплап, диванда утыра иде. Ул үзе дә шулай ярсуына аптырады, оялып куйды. Болай өзгәләнгәне юк иде бит әле. Күрәсең, шушы көнгә кадәр беркемне дә көнләшергә якын ала алмагандыр... Шуңа күрә бөтен дөньясына битараф булып йөргәндер? Ә бүген иртән Асия үзенә урын таба алмый торуын сизде... Аның Нәҗипне күрәсе килә иде, аңа егетнең янәшәдә генә булуы җитми иде бугай... Ә менә хәзер... Хәзер ни булып чыкты инде?

Данишев артыннан ярым ачык калган ишектән кинәт Винокуров картның карлыккан тавышы ишетелде:

— Пожар! Янабыз! Йорт яна...

Нәҗип үзенең бүлмәсенә ташланды. Түшәмне кара-кызыл төскә манып ике тәрәзәдән дә ялкын шәүләсе ургылды. Егет йөгереп килеп аска карады: мәрхүмә Цветова йорты канлы-кызыл учак булып күккә үрли иде.

— Менә ни өчен улаган икән теге эт!— дип кычкырып җибәрде лейтенант.— Әлбәттә, аның эте ул!

Урамда янгын сүндерүче машиналар тавышы ишетелде.

Данишев атылып коридорга чыккан иде дә, шунда ук кире борылып керде. Янгын сүндерүчеләр аның ярдәменә мохтаҗ түгелләрдер. Ташландык өйгә кем ут салырга мөмкин? Аның өчен иң мөһиме хәзер менә шуны ачыклау.

«Һәрхәлдә, ут төртүченең Цветова үлеменә дә бәйле булуы ачык»,— дип фикер йөртте Нәҗип. Карчыкның өйалдында абайланган эз белән бүген Моратовтан калган тапны чагыштырып карады. Алар икесе дә бер үк иде. «Өйне дә шул мөртәт яндырды микәнни?»— дип уйлады Данишев һәм Моратовны хәзер үк табарга теләп, коридорга чыкты.

Саматның бүлмәсе бикле, әмма ачкычы ишектә үк калган иде. Кухня-ванна тирәсендә дә Моратов күренмәде.

Лейтенант баскыч буйлап урамга йөгерде.

Җәйге төн яңгырдан соңгы салкынча саф һавасы белән бөтен күзәнәкләргә тереклек суы өрде. Әле һаман вак яңгыр сибәләсә дә, күк күкрәү авазы инде бик ерактан тонык кайтаваз гына булып ишетелде.

Нәҗип дөрләп янган йорт янына китте. Янгын карарга бер көтү ачыгавыз җыелган иде.

Йорт, коры чаган утыны кебек, дөрләп яна. Ут коточкыч дуамаллана, тирә-юньгә зур-зур чаткылар көлтәсе очыра. Дранча түбәне, агач болдырны, тәрәзә уемнарын кабып йотарга өлгергән. Хәтта зур эт оясыннан да кисәүләр генә калып бара иде. Янгын машиналарыннан сиптергән су бу кызыл аждаһага көмеш сөнге булып кадала, шунлыктан ул инде ак пар бөрки-бөрки, сүрелә башлаган. Күренеп тора: озакламый аны авызлыклап алырга тиешләр.

Янгын тирәсендә Моратов күренмәде. «Кая олакты соң ул?»— дип борчыла башлады Данишев.— Әллә койрыгына басканны сизендеме? Әллә бу янгын, ниндидер хәтәррәк, җитдирәк эшләрдән игътибарны читкә тарту өчен, юри оештырылгандыр?» Һәм ул тирә-юньдәге тар урамнарга күз салып чыгарга булды.

Соңыннан, бәлки, лейтенант үзенең ничек итеп нәкъ менә Семафор тыкрыгына барып эләгүен аңлата да алмас. Ә хәзергә ул, җыелып яткан күлдәвекләргә бата-бата, тыкрык уртасындагы өч катлы кирпеч йортка якынлашып килә иде. Ике йөз адымнар чамасы алда, урам фонаре яктысында ак тап булып торган бер машина күзгә ташланды. Нәҗип адымнарын ешайтты.

Ни өчендер, теге сержант рапортында телгә алынган ак «Жигули» исенә төште. Әгәр монда да ак «Жигули» булса? Ләкин шул ук «Жигули»мы?

Ул арада машинадан зур гына гәүдәле ике кеше чыкты. Алар үзара сугыша да башладылар кебек! Лейтенант, бөтен көчен җыеп, алга ташланды.

## 12. Ак «Жигули» эзеннән

...Моратов подъездан чыкканда урамда көндезге кебек яп-якты иде. Чик-чаманы онытып дулаган ут өермәсе, бәйдән ычкынып, төнге күккә ашар төсле! Тыгыз соры боҗра булып баскан халык, оясына ут төшкән кырмыска күче сыман, мыж килә. Самат, болар ни сөйлиләр икән дип, ут тирәсенәрәк якынлашты.

Шулвакыт аңа артыннан кемдер эндәшкән кебек булды. Яктыдан сукырая төшкән күзләрен чекерәйтеп, Моратов як-ягына каранды. Караңгылык эченнән якасын муен эченә яшергән бер озын шәүлә шуып чыкты.

— Нихәл, Самат...— дип әкрен генә сәлам бирде шәүлә.— Читкәрәк китеп сөйләшик әле.

— Нәрсә бар?

Кепкасын маңгаена төшереп кигән кара тутлы ир-ат кесәсеннән бер төргәк биш тәңкәлекләр чыгарып Моратовка сузды.

— Миша Шпырудан сәлам. Сиңа бурычлы булган икән... Шуны җибәрде.

— Аның миңа бирәчәге болай гына түгел.

— Әйтәм бит, анысы турында читкә китеп сөйләшергә кирәк.

Алар йорт ышыгына керделәр.

— Калган бурычын да онытмады Мишка, әйберләтә җибәрде... Товар хәзер минем машинада,— дип пышылдады «Шәүлә».— Син тагын бераз тамаша караган булып тор. Аннары, беләсеңме, кая... Семафор тыкрыгына тарттыр. Анда өч катлы йорт артында, сулга борылгач, фонарь түбәндәрәк көт. Кара аны, койрык ияртмә!

— Нинди койрык тагын?! Минем чабуыма тизәк ябышмаган. Мин пешка гына. Каравылда торган өчен криминал юк!

— Я, я, артыгын сөйләнмә, әйтелгән бит сиңа: Гафиятуллин урамы ягыннан урап кил! Аңладыңмы!

«Шәүлә» үзе дә, Гафиятуллин урамы ягына таба китеп, күздән югалды.

Самат, дөрләп янган йорт тирәсендә бераз таптанып торгач, «Шәүлә» кушкан төшкә барырга тәвәккәлләде. Ул арада теге бәндәне кайда күргән булуы да исенә төште. Әлбәттә, шул үзе! Миша белән бергә подвалда казынып йөргән сукыр тычкан. Дөрес, бусы гел читкәрәк тайпыла, һәрвакыт кара күзлек элгән булыр, кепкасын да борынына хәтле авыштырып кия — кыскасы, йөзен яшерергә маташа иде. Моратов аңа әллә ни илтифат итеп тормады. Төкерә ул аңа! Башта ук чамалап куйды: Миша инә, тегесе җеп булырга тиеш. Саматны бу шухыр-мухырга тартучы да, мәгъриче турында килешүче дә Шпыру иде.

Ләкин сүзендә тормады Мишка. Исәп-хисапны өзмәс борын күздән югалды, дуңгыз. Кәкре каен терәтеп калганын сизенгәч, Самат аны эзләргә керешә. Бервакытны хәтта менә бу кара күзлек киеп йөрүчесен базарда очраткан кебек тә булган иде. Тик ул, фәлән дә төгән, сез мине кем беләндер бутыйсыз ахры дип, бик тиз ычкыну ягын карады. Быел язын Моратов ул адәмне тагын күрде. «Жигули» рулендә утырадыр иде. Ул да Саматка игътибар иткән кебек булды, тик күрмәмешкә салышты.

Менә шул сурәбәт хәзер үзе Моратовны эзләп килгән. Димәк, аны онытмаганнар әле! Кесәсендәге бишлек кыштырдавыннан рухланып киткән Самат ун-унбиш минут дигәндә билгеләнгән урынга — Семафор тыкрыгына барып та җитте.

...Рәхмәтуллин урамындагы 17 нче йорт янында бүген уголовный розыск инспекторы Чаев дежурлык итә иде. Төнге уникe тулып 20 минутларда Цветова өенең чардагыннан урләгән ялкын телләрен күреп, ул шунда ук автомат-телефонга ташланды. Шалтыраткач, Чаев үз урынына кире кайтты. Аңа Моратовны күздән ычкындырырга ярамый иде. Бәхеткә каршы, янгын сүндерүчеләр озакламады.

Моратовны ул подъезддан килеп чыгуына «мушкага» алды. Каршы яктан торып, янып ятучы йорт ягысында караганда, Саматның янына озын буйлы бер ир-ат килүе, аларның ашыгыч кына нәрсәдер сөйләшеп алуы аермачык күренә иде. Ләкин Чаев бу ят кешене никадәр генә танып-хәтерләп калырга тырышмасын, ул, шуны сизенгән кебек, гел күләгәгә, караңгыга табарак елышты.

Ут тирәсендә бераз чуалгач, Моратов караңгы урамга таба юл тотты. Инспектор аны күздән югалтмаска тырышты. Ләкин моны эшләү җиңел түгел иде. Тар, караңгы урам аркылы пәрдәсе ачык бер тәрәзәдән төшкән күз камаштыргыч турыпочмаклык кына яктырып тора...

Шушы яктылыкны кисеп сикерәм дигәндә генә, Чаевның алдында, җир астыннан үсеп чыккандай, бер ир-ат пәйда булды. Инспектор аның әзмәвердәй гәүдәсен, баш очына кискен күтәрелгән саллы йодрыгын гына күреп алды. Каты авырту аның сул кулын каерып аткандай булды. Әзмәвер бер селтәнүдә җилкә башын сугып сындырган иде. Икенче селтәнүендә... Чаев читкә тайпылып өлгерде, башы белән бәреп тегенең йөзен җимерде, шул ук мизгелдә уң кулы белән касыгына берне төртеп алды. Озын гәүдә урталай сынып төште. Инспектор инде аны тибеп аудармакчы иде, ләкин кинәт аягыннан эләктереп алып бандит аның үзен җиргә сузып салды.

— Самат!— дип кычкырды әзмәвер.— Кайда син!— Аның кулында пычак ялтырады. Инспектор яткан җирдән кушаяклап кизәнде. Бандит каршы яктагы стена буена мәтәлеп китте.

Чаев пистолетын суырып алганда пәйда булган Моратов бар көчкә аның башына типте...

Бу хәлләрне тәрәзәдән күреп, кемдер милициягә шалтыратып өлгергән иде.

Берничә минуттан Гафиятуллин урамына участок инспекторы Шамов йөгереп килде. Чаевның тынсыз калган гәүдәсен яктыга алып чыга башлады. Шул вакыт егет аңына килде, Шамовны таныды:

— Алар... Моратов белән икәү...— дип ыңгырашты. Уң кулы белән күкрәк кесәсен капшады.— Алганнар...

Кинәт ул үз хәлен бөтенләй оныткандай, кискен генә талпынып куйды:

— Йөгер. Тизрәк! Алар әле монда гына. Семафор тыкрыгына таба... Ишетәсеңме! Йөгер! Аларда пистолет...

Бандитларны ычкындырмаска кирәк иде. Тыкрыкка килеп чыгу белән, тәртипсез ату тавышлары яңгырады. Шамов, гадәт буенча, юлдан читкә сикерде һәм коймага ышыкланды. Кемнең кемгә атуы әле һич аңлашылмый иде. Ул арада караңгы урамга ак төстәге «Жигули» килеп чыкты. Шамов аны җибәрмәс өчен юл уртасына ташланды. Кобурасыннан пистолетын тартып чыгарды. Аны һавада селкеп:

— Тукта! Атам!— дип кычкырды.

«Жигули» әкренәйде.

Машина артыннан тагын кемдер йөгереп килә иде. Бу бер генә мизгелгә Шамовның игътибарын читкә тартты. Һәм шул мизгелдә автомобиль аның өстенә ыргылды. Участковый инде читкә чыгып өлгерә алмый иде. Ул исән калыр өчен бердәнбер дөрес юлны сайлады — өстенә килеп җиткән машинаның капотына сикерде. Алгы тәрәзә чәлпәрәмә килде һәм бәрелүнең көчен бераз киметте бугай. Шамов капот өстеннән юл читендәге канауга очып төште.

Борылышта машина тигезлеген югалтып, уң канаты белән бер койманы сөзеп үтте. Шатырдап сынган такталар гына коелып калды. Машина артыннан тагын берничә тапкыр ату тавышы ишетелде.

«Район милиция бүлеге
начальнигы Г. Д. Минаевка

РАПОРТ

Цветованы үтерү эшенә Самат Моратовның да катнашы бар дигән нәтиҗәгә килдем. Шул сәбәпле аңардан сорау алмакчы идем. Ләкин 18 августта 0 сәгать 30 минутта Моратов өйдә юк булып чыкты. Качу ихтималын истә тотып, аны табарга һәм тоткарларга тырыштым.

0 сәгать 55 минутта Семафор тыкрыгында аксыл төстәге «Жигули» күреп алдым. Аннан ике ир-ат чыкты да үзара якалаша башлады. Шуны күреп, аларга таба йөгердем. Мин килеп җитәргә 70—80 адым кала, ирләрнең берсе икенчесенә ике тапкыр атты. Коралльы ир машинага утырып кача башлады. Мин машина тәгәрмәчләренә өч тапкыр атып карадым, әмма тидерә алмадым, ахрысы.

Шуннан соң җинаятьчене участок инспекторы өлкән лейтенант Т. В. Шамов та тоткарламакчы булган. Машина аны бәреп узды.

Чатка кереп югалырга өлгергәнче, мин «Жигули»ның артыннан тагын ике тапкыр аттым.

Машина туктап торган урында ике пуля ярасы алган Моратов ята иде. Ул аңсыз хәлендә больницага озатылды. Барыбер эзенә төшкәннәрдер дип уйлап, Моратовны, минемчә, Цветова эше буенча иптәше аткан булырга тиеш. Алар икәү сугышкан урынга гел биш сумлыклардан торган акча чәчелеп калган иде.

Шуларны искә алып, больницадагы С. Моратов янына чит кешеләр кереп-чыгып йөрүен чикләргә кирәк дип саныйм.

Лейтенант Н. Данишев».

Җинаятьче машинага утырып качканнан соң унбиш минут эчендә республика Эчке эшләр министрлыгының дәүләт автоинспекция идарәсеннән махсус күрсәтмә тапшырылды.

«Барлык ГАИ постларына.

Алгы тәрәзәсе ватык, алгы уң канаты сыдырылган, ак төстәге «Жигули» автомашинасын тоткарлау өчен бөтен чараларны күрергә. Җинаятьче пистолет белән коралланган».

Шәһәр читендәге ГАИ постларының берсендә дежур торучы старшина шушы хәбәрне алып кына өлгергән иде әле. Тәрәзә турысыннан, малайлар аткан кар йомарламы сыман сызгырып, ак төстәге «Жигули» узып китте.

«Кара син аны, туксан белән куа,— дип куйды старшина.— Шикле нәрсәкәй. Моны тикшереп карасаң да ярый».

Берничә минуттан ул теге лихачны «Волга» белән куа чыккан иде. Спидометр угы «130» турысында дерелдәп тора...

«Әгәр шул үзе була калса, ерак китә алмас,— дип уйлады егет.— Алгы тәрәзәсез сәгатенә йөзне озак тотарсың, пычагым: кабинада коточкыч җил уйный, ә йөзеңә һава агымы шундый итеп бәрә — авызыңа эшләп торучы компрессор эчәгесе тыгып куйган кебек».

Ун минутлап вакыт үткәч, алда аксыл тап булып әлеге машина күренде. Ул, тизлеген киметмичә, кискен генә борылды һәм басу юлы буйлап сибә башлады. Борылганда машинаның бер ягы бөтенләй күтәрелеп, ике тәгәрмәчтә генә хәйран җир барды. Зур ярымшардагы кебек хәтәр итеп борылуы белән, шикне көчәйтә төште ул. Качып баручы булмаса, ай-һай, болай ук җүләрләнер микән?!

Хәзер «Волга» үзенең фара яктысы белән алдагы машинаның койрыгына басып бара башлады: аның инде «Жигули» булуы да, ак төстә икәнлеге дә беленә иде.

Басу юлы тиздән поселокка барып керәчәк. Старшина бу тирәләрне яхшы белә, шуңа күрә ул ышанычлы рәвештә алдагы машинага якыная барды.

Поселокка килеп җитәрәк, тар гына агач күпер аша үтәсең. Качкын шул күпергә килеп кергәч тизлеген аз гына кимета төште һәм көтмәгәндә тормозга басты. Машина кисәк борылып, юлга аркылы басты. Кабинадан атылып чыккан ир-ат, бераз йөгергәч, артына борылып пистолеттан атып җибәрде. «Жигули»ның бензин багына тиде бугай — машинаны шундук ялкын чорнап алды.

Җинаятьче хәзер бөтен көченә поселокка таба элдертә иде. Старшина, куртка белән йөзен каплап, дөрләп янган «Жигули» белән күпер култыксасы арасыннан сикереп чыкты. Көчле яктылык күзләргә бәреп, тирә-юньне күрә алмас хәлгә китергән иде. Мондый халәт, мөгаен, бер минут чамасы дәвам иткәндер. Әмма шул кыска вакыт та җинаятьченең төн куенына качып өлгерүе өчен бик җиткән иде. Аны шул тирәдән эзләп карау бернинди нәтиҗә бирмәде.

...Нәкъ шул көнне күрше районнан бер кибетченең машинасы урланган дип хәбәр иттеләр. Ак «Жигули» әнә шул кешенеке булып чыкты.

## 13. Уңышсызлык

Берничә көн үтте. Цветованың үтерелүе турындагы уголовный эшне, закон кушканча, прокуратура карамагына тапшырдылар. Җинаятьчене эзләү бурычы, әлбәттә, милиция өстендә дә калды. Шуңа күрә лейтенант Данишевка тынычланырга иртәрәк иде әле. Хәер, ул үзе моңа

сөенде генә: аңарда бер башлаган эшне ахыргача җиткерү гадәте яши иде.

Михаил Шпыруның җинаятьчелек биографиясе белән танышу искитәрлек берни дә бирмәде. Аңа квартира басарга булышкан адәм үткәннәр белән араны өзгән, шуның өстенә Мишаның ни сәбәпле Одессадан Татарстанга күчеп китүен дә белми иде.

Данишев яңадан больницага юл тотты. Авыр яраланган Моратов шушы хәлләрдән айнып җитә алмаган булып чыкты. Аннан сорау алу турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде.

Капитан Минаев мәрхүмә Цветованың нәсел-нәсәбен ачыкларга һәм, архивларда казынып, йорт хуҗасы Аршев турында мәгълүмат җыярга киңәш итте. Бераз уйланып торгач:

— Кайчандыр хуҗалары тирәсендә чуалган бәндәләр хакында хәбәрдар булу да зарар итмәс иде,— дип куйды.— Бу бик күп көч сорый торган, мәшәкатьле, четерекле эш. Сезгә ярдәм итәр өчен тагын ике кешене билгеләрбез.

Иң беренче ачыкланган нәрсә — Казан кызы Анастасия Цветованың бирегә, өяз шәһәрчегенә 1917 елны күчеп килүе булды. «Димәк, ул чакта әле аңа унсигез яшь кенә...— дип уйланды тикшерүче.— Кияүгә чыкты микән? Фамилиясен алыштырмады микән?»

Казанга барып кайту бу сорауларга беркадәр ачыклык кертте: Цветова беркайчан да фамилиясен үзгәртмәгән, документларда аның кияүгә чыгуы турында шулай ук бер сүз дә юк иде. Чиркәү кенәгәсендә аның Анна исемле апасы булуы күренә. Данишев моны мыегына урап куйды. Ләкин Аннаның алга таба язмышын берничек тә ачыклап булмады.

Элеккеге йорт хуҗасы да, камыр малае Камырбатыр кебек, нәселнәсәпсез булып чыкты. Дөрес, карчыклар аны Казаннан килеп урнашкан һәм япа-ялгыз яшәгән дип хәтерлиләр икән. Ләкин бу хатирәләрне расларлык кәгазь табылмады. Байга хезмәт иткән кучердан исә «Микола» дигән исеме генә калган иде. Болар өстенә, бөтен ил буенча Михаил Шпыруны эзләү дә әлегә һичнинди нәтиҗә бирмәде.

Кеше язмышын иске кәгазьләр арасында казынып, яисә комы коела башлаган кешеләрдән сорашып кына торгызу мөмкин түгел икән. Бу эзләүләр бары бер хакыйкатькә алып килде: җинаятьчеләрне башка юл белән, тагын да уйлабрак һәм җентекләбрәк эзләргә кирәк. Данишев университетта үзен укыткан бер профессорның сүзләрен исенә төшерде: «Фәнни эзләнүнең тискәре нәтиҗә белән тәгәлләнүе дә — билгеле бер нәтиҗәгә ирешү ул,— ди иде профессор.— Әлеге эзләнүләрне яңабаштан, бөтенләй икенче юл белән дәвам итәргә кирәклеген раслый!» Ә бит катлаулы җинаять эшенең чуалып беткән йомгагын сүтү белән гыйльми тикшеренү арасында уртаклык бик зур.

«Шулхәтле күп вакыт үтте,— дип пошынды Нәҗип,— инде җеп очлары да күренмәгән кебек иде. Ә тотынган бере өзелеп бара! Башкисәрне «Жигули» белән качырдык. Аның «ахирие» Моратов акылга җиңеләйде... Саматның шөрепләре бушау, гомумән, бөтен исәпне бутады».

Бу шундый халәт, үзенчә бер «үле нокта» иде: үз көчең белән генә алга таба кузгалып китәрлек түгел, ә инерция көче ахыргача сарыф ителгән...

Данишевның, ай буе эшләп, бу кадәр күңел төшенкелегенә бирелгәне юк иде әле. Бу көннәрдә ул балтасы суга төшкән агай кебек йөрде. Шаяру-көлүне онытты. Асияне искә алганда гына йөзенә моңсу елмаю куна иде. Анысы Роза бүлмәсенә кергән өчен үпкәсен оныта алмый бугай. Көнләшә башлаганмы әллә?! Янгын чыккан төннән бирле күзгә-башка чалынганы юк. Беркөнне коридорда очрагач та бик салкын гына исәнләште. Егетнең дә бу арада бик матавыкланган чагы. Өйгә арыпталып кайта, кайту белән урын өстенә ава.

Менә бүген дә иртә таңнан больницага шалтыратты. Моратовның хәлен сорашты. Сәгать сигез тирәсендә үзе дә барып житте. Бинтка уралып беткән, сары йөзле, сүнгән күзле Самат тере мәет төсле ята иде. Аның күз карашында мәгънә һәм зиһен чаткысы сизелми. Бары Данишевны күргәч кенә ул сискәнеп, сагаеп киткән кебек булды. Карлыккан тавыш белән әкрен генә әйтеп куйды:

— Ә-ә... Күрше. Нәчәлник...— Моратов башын күтәреп Нәжипнең йөзенә текәлде. Аннары, кинәт, хәле җиңеләеп киткәндәй, талпынып куйды, теленә килгән бөтен сүзен бер тын белән яудыра башлады:

— Шикләнгән идем мин. Баштан ук шикләндем. Син — шпиун. Сине юри безгә керттеләр. Ник алай димме? Беләсең киләме? Беләсең килсә шул... Син мине коммуналкадан кудырмакчысың. Юк-юк! Кирәкми, нәчәлник. Кирәкми, дим. Коммуналкасыз мин ачка үләм. Ачка!..— Самат ике куллап башын тотты.— Бер күршенең бәрәңгесен — һам! Икенчесенең коймагын — һам! Кухняга салган кәстрүлдән итне — һам! Итен кимерәм-кимерәм дә, сөяген чулт — кәстрүлгә. Шулай яшим. Яши-и-им! Тимә син миңа. Тимә. И куркытма да мине, нәчәлник. Синнән курка торган күлмәгем тузган.

> Әй, зимагур, кайт иленә,
> Илдә иген игәрсең.
> Стаканыңны ат итеп,
> Бутыйлкаңны җигәрсең!..

Әйт шуны!

Моратов тагын бераз җырлап алды, аннары яңадан, инде бөтенләй аңлаешсыз сүз боткасы башлады.

Тикшерүченең сорауларына җавап итеп, ул попугай кебек гел бер нәрсәне тукыды: коммуналь квартира белән кәстрүлдәге сөяк турында сөйләде.

Данишев больницадан кәефе кырылып кайтты.

Күрәсең, тәртәне борып, яңабаштан эзләнүләр юлына чыгарга кирәк. Ә йөк бик авыр. Әле аның да иң ипсез ягыннан тикшерүчегә тартып барырга туры килә... Юл уңаенда вакыт һәм вакыйгалар агышы синең өстеңә яңа мәшәкатьләр өя бара: көтелмәгән табышмаклар, җинаятьченең мәкер-хәйләләре, яңа фактлар... Кайчакны тикшерүче чүлдә адашып калган ат хәленә килә: үзенә салынган йөкне соңгы көче белән тартып бара; аны авырлык һәм сусау гына түгел, бердәнбер хакыйкатькә илтүче юлның чиксезлеге һәм билгесезлеге дә җәфалый. Хакыйкать андый вакытларда, чагым-мираж кебек, әле бик якын тоела, әле бөтенләй күздән югала...

Данишев күптән бер нәрсәне аңлады: һәркемнең тормышында (һәм бер мәртәбә генә дә түгел) шундый уңышсыз вакытлар була. Аларны уздырып җибәрә белергә — түзәргә һәм юлыңнан туктап калмаска кирәк. Бу түземлелек, ныклык, кайчакта айлар, еллар дәвамында, әкренләп, шушы «хәерсез» сәгатьтән алып чыга, күптән билгеләнгән максатка таба илтә.

«Бәлки, мин артык төшенкелеккә биреләмдер?— дип уйланды лейтенант.— Озак түзәргә туры килер дип, юкка гына үз-үземне тынычландырамдыр?.. Бәлки, чишелеш инде ерак та түгелдер?..»

## 14. Барс исемле эт

Данишев үзләренең подъезд төбенә чыгу белән икеләнеп калган иде: милиция бүлегенә юл тотаргамы, әллә башта Цветова йортын карап чыгаргамы?.. Янгыннан соң карчыкның йорты ни хәлдә калды икән?

— Исәнмесез, Нәҗип абый.

Янында гына Асиянең ягымлы тавышын ишеткәч, егетнең зиһеннәре таралып китте.

— Асия... Сез ничек монда килеп чыктыгыз?..— диде ул ничектер каушап.

Кыз күңелле генә көлеп куйды:

— Ә мин кайда булырга тиеш соң? Мин дә шушы йортта яшим, ләбаса. Ә сез шул тиклем кыска хәтерле икәнсез, минем кайда яшәвемне дә онытканысыз.— Асиянең шатлыгы кайнар чишмә булып тибә иде.— Оныттыгыз да мыни, Нәҗип абый?!.

— Нигә алай дисез, Асия? Мин сезне гел искә төшерә идем... Хәерни сөйләп торам тагын! Искә төшерү өчен бер минутка булса да онытып торырга кирәк. Ә минем сезне онытканым юк, Асия.

Кыз дәшмәде, башын кыңгыррак салып, тик елмаеп торды.

Кичә кичен, әнисе тагын биләмгә чыгып киткәч, Асиянең бүлмәсенә Әхәт килеп кергән иде. Сүз иярә сүз чыкты. Малайның ничә көннәр эчен тырнап йөргән бер соравы бар икән. Әнисеннән җавап ала алмаган. Ә Асия апасы — укытучы. Ул барысын да белергә тиеш. «Теге янгын булган төндә Самат абый кереп, пычрак аяклары белән безнең идәнне буяп чыккан иде,— дип башлады Әхәт.— Нәҗип абый нишләп шул аяк эзләрен рәсемгә төшереп алды икән?..»

Ул төнне булган мажараларның сере дә, шуннан соң Моратовның ни өчен күздән югалуы да кызга берьюлы аңлашылды.

Асия, әлбәттә, егеткә бу хакта әйтеп тормады. Оялып, кызарды:

— Кичерегез мине, Нәҗип абый... җүләрлегем өчен...— диде.

Нәҗип ургылып килгән шатлыктан йөрәгенең күкрәк читлегенә бәрә башлавын тойды, бер талпыну белән Асияне кочагына алды. Иреннәре сусыл иде кызның, алардан җиләк тәме килә иде.

Беркайчан да егетләр куенын тоймаган Асия куркып яисә уңайсызланып калырга да өлгермәде. Күңелендә, тәнендә курку-оялу тойгысына урын юк. Аны тулысы белән олы, матур, рәхәт, кайнар бер хис биләп алган иде. Ул үзендә оялчан һәм кыю мәхәббәт дәртенең ничек кабынуын сизми дә калды. Көтмәгәндә, дәррәү генә булдымы бу, әллә язгы кар сулары кебек, әкренләп, җыела-җыела килдеме?

— Кһем, кһем. Кояшлы көннәр белән! — Аларны тыңкыш карт тавышы сискәндереп җибәрде. Икесе дә, ярамаган эш өстендә тотылган кебек, җәһәт кенә борылып карадылар.

Йорт җанлы Винокуров карт, патронташ кебек тезеп, туалет кәгазе кәтүкләренә уралган иде. Ул тагын нәрсәдер әйтмәкче булды, ләкин, бераз таптанып торгач, подъездга таба теркелдәде.

Асия әкрен генә: «Сау булыгыз»,— диде һәм, карттан аерылып калмаска теләгәндәй, ашыгып кереп китте.

Данишев янган йорт урынына ничек килеп керүен дә абайламый калды. Ул үзен яңадан гайрәтле, акыллы, теләсә нинди бурычны хәл итәргә сәләтле итеп тойды.

Лейтенант әкрен генә бөтен йортны әйләнеп чыкты, ут ялап алган агачларга, ауган коймага карап торды. Әле һаман да бөтен җирдән дымсу көек исе килә иде. Өйдән, кара мунча мичен хәтерләтеп, ыслангач кирпеч стеналар гына утырып калган иде.

Экспертиза өйнең «тиз кабынып китә торган матдәләр кулланып, ут төртү нәтиҗәсендә» януын билгеләде. Ут салучының гына кем булуын хәзергәчә белә алмадылар: Моратов үземе, әллә аның иптәшләреме?

Янгынның эз югалту максаты белән оештырылуы ап-ачык иде. Ләкин... Җинаятьчеләр шул рәвешле хәзинәнең талануын яшереп калырга уйлыйлармы? Әллә бу — игътибарны Моратовтан читкә тартуга азапланугынамы? Алай дисәң, бу хәлнең Моратовны аклыйсы урында, кире-

сенчә, аны батыруы да бик ихтимал. Хәзер утны нәкъ менә шул үзе салган дип уйларга, аңа тагын да шикләнебрәк карарга бөтен нигез бар. Ниһаять, Моратовны дөмектерү өчен генә дә Цветова өеннән утлы учак ясап тормаслар иде. Юк! Монда бөтенләй бүтән сәбәп булырга тиеш. Хәзер бандит муенына тагылган, үзен төпкә өстерәп төшүче ниндидер йөктән котылырга тырыша. Ул шул йөктән курка.

«Янгын нинди эзләрне юк итте икән?— дип исәпли башлады Данишев.— Түбә... түшәм... тәрәзәләр... идән... болдыр... эт оясы... Чү!»

Лейтенант кирпеч нигез янына йөгереп килде. Шул төштән алып эт оясы торган урынга кадәр араны үлчәде: биш метр! Эт оясыннан бер-ике кечкенә кисәү һәм көл генә чәчелеп калган иде.

Нәҗип кинәт исенә төшерде: ялкын өй чормасында улап утырган чакта ук эт оясы урынында инде кисәү башлары гына елтырый иде түгелме соң?! Ул арада гына ояга ут сикерергә өлгерде микән? Билгеле, факел кебек дөрләп янган чормадан берәр утлы такта очып төшәргә дә мөмкин... Ләкин Данишев өчен бусы бик шикле тоелды. Утны бер очтан эт оясына да төрткән булырга тиешләр. Тик нинди максат белән?.. Бәлки, дөньяда әле шушы этнең дә барлыгын искә төшереп тормасын өчендер?!

Лейтенант яшен суккан кебек калтырап китте. Башына кеше ышанмаслык бер фикер килде: өйгә утны нәкъ менә шул эт оясы аркасында гына төрткәннәр! Әйе, әйе. Беркемнең дә башына килмәс әле дип уйлаганнар. Хәерчеләр кебек, хәзинә эзләп өй кисәүләре арасында казынырлар, дип өметләнгәннәр.

Данишев кайчандыр бу эт турында бер уйлаган иде бит. Ниндидер кызыклы чишелеш юлы да күренгән кебек иде! Ул чакта аның уйларын бүлдерделәр. Күрше малае килеп керде. Яшенле яңгыр башланды. Нәрсәгә тотынып киткән иде соң ул фикер? Кайда туктап калган иде?

Лейтенант бер читтә аунап яткан тимерчыбыкны табып алды. Аны сузып карады. Күренеп тора: эт уздырмаса, өйгә үтеп керергә һичничек мөмкин түгел. Ә бит кергәннәр! Эт үз постында калса да, тавыш-тын чыкмаган. Алар хуҗа карчыкның якын танышлары булганмы? Ә бәлки, эт аларны үзе танып өрмәгәндер?..

Шулчак теге яңгырлы төндә очкынланып киткән фикер яңадан тернәкләнә башлагандай булды. Цветова йортына ул эт кайдан килеп эләккән? Кемдер саткан лабаса аны. Димәк... Бөтен дөньядан йөз чөергән карчык янына үтеп керүнең бер генә юлы бар: газраил шушы этнең хуҗасы булган!

Данишев теге чакта мәсьәләнең икенче ягын да күздә тоткан иде: эт халкы еш кына очракта үзенең элекке хуҗасын танымаска, ягъни үзен саткан кешегә рәнҗешен онытмаска ихтимал. Тугрылыкка хыянәт итү, күрәсең, эт законнары буенча хөкем йөрткәндә дә — гайре табигый эш, аңлатып булмый торган этлек булып санала. Ләкин... Әгәр дә эт үзенең хуҗасын гафу итсә?

Этнең Цветова йортында кайчаннан бирле хуҗа булуын тирә-күршеләрдән сорашырга мөмкин. Шуның өстенә кушаматын, яшен, нәсел-нәсәбен белешергә һәм, әлбәттә, үзен табарга кирәк! Һич кичегергә ярамый!

Озакламый лейтенант әлеге этнең Барс исемле овчарка булуын, Цветова йортына биш-алты ел элек килеп эләгүен ачыклый алды.

Этнең үзен табу бер дә көтелмәгәнчә мәшәкатьле булып чыкты. Данишев аны эзләп, энәгә күзләнгән җеп шикелле йөрде. Күршеләр аны ак түшле, җирән-соры төстәге бозау хәтле овчарка дип сурәтләгәннәр иде. Соңгы арада гына андый этне күрүчеләр табылмады.

Тикшерүче Барсның ата-аналарын, дөресрәге, аларның хуҗасын эзләргә кереште. Башта тирә-күрше районнардагы нигездә терлек асрау белән генә шөгыльләнә торган хуҗалыкларны ачыклады. (Алар шак-

тый икән.) Аннары үз районыннан башлап, күрше район авылларына кадәр барып җитте. Һәм... «Беренче Май» колхозында әлеге этне белүче кеше табылды!

Гомере буе мал көтеп көн иткән Мәхмүт исемле ул абзый бик ачык күңелле кеше булып чыкты. Кунакны өенә чакырып, чәй-мәй белән сыйлап утырганда, бик тәмен белеп кенә сөйли башлады:

— Ызначитсы, мине бала чактан ук эт кияве дип йөртәләр иде. Бүрегә каршы торыр өчен, үзең беләсең, тәтием, овчарканың да әле нинди кирәк! Эт өрер, бүре йөрер, дигәндәй, сарыкларың белән бергә этеңне дә чәйнәп өзәргә күп сорамый ул сабакылар... Ә син сораган этнең әле ата-анасы да исән. И бөтен балаларын хәтерлим. Кайсын кемгә биргәнлегем генә истә юк.— Лейтенант дулкынланудан сикереп торуын да сизми калды. Карт аның бу кыланышына бер дә исе китмичә генә сүзен дәвам итте:— Ызначитсы, шуңа аерым бер дәфтәр тотам. Барысын да тезеп-тезеп яза барырга.

Данишевның йөрәге кысылды:

— Ул дәфтәр исәнме, сакланамы?

— Сакланмый ни, саклана, кәнишне.

Нәҗип, җепнең очын ычкындырудан курыккан төсле, бик җайлап кына сорарга тырышты:

— Барсны кемгә саткан идегез соң?

— Этләрнең нәселе буталмасын өчен,— Мәхмүт абзый, тикшерүченең түземлеген сынагандай, сүзне уратыбрак башлады,— гадәттә, яңа хуҗаларының исемен язып куялар...— Карт шикәрне вак кына тешләп, кайнар чәй йотып куйган булды, диванга җайлабрак утырды:— Эш болайрак тора бит, тәтием... Минем бөтен кәгазьләр кечкенә агач тартмада иде. Ә өйләр юган вакытында ул тартманы кызым әллә кая куйган. Мин инде бер эзләп карадым, таба гына алмадым.

Нәҗипкә менә-менә йөрәге туктап калыр кебек тоела башлады; ул бөтенләй карлыккан, ят тавыш белән:

— Югалмаганмы ул тартма? Табылырмы?— дип кенә сорый алды.

— Табылыр. Кая китсен ул, тәтием! Иртәгә кызым ялдан кайта. Табып бирер. Безнең өйдә әле бернәрсәнең дә югалганы юк иде.

— Ә кызыгыз, Мәхмүт абзый, иртәгә чынлап та кайтамы?

— Кайтыр. Нишләп кайтмасын ди. Иртәгә инде эшкә чыгарга тиеш.

— Ә Барсны сатып алучының төсен-битен дигәндәй... бер дә хәтерләмисезме, Мәхмүт абзый?

— Хәтерләмим, тәтием... Картлык... Ул кеше кайдандыр ерактан килгән иде. Машина белән...

— Машинаның төсен яисә исемен дә искә төшерә алмассыз инде?

Карт бусын да хәтерләми иде. Аның бар белгәне этләр генә иде, ахрысы.

— Эт үзенең элеккеге хуҗаларына ташланырга мөмкинме?— дип, сүзне яңадан шул эзгә төшерергә мәҗбүр булды Нәҗип.

Мәхмүт абзый зәңгәр шакмаклы кулъяулыгын борын тирәсендә йөртеп алды, бераз уйга чумып утырды, аннары:

— Бик хәтерен калдырсалар — мөмкин,— диде.

Нәҗип район үзәгенә, үзе урнашкан кунакханәгә китәргә җыена башлады.

— Тукта, улым, төнгә каршы кая чыгып китәсең? Бездә генә куп. Миңа да иптәш булырсың. Карчык вафат булганнан бирле, кызым белән икәү генә яшибез.

Кыз иртүк кайтып җитәсе икән. Аны күрәсе, этнең кемгә сатылган булуын тизрәк беләсе иде. Ул чакта үтерүчене табу да бермә-бер җиңеләячәк, әлбәттә!

Шуның өстенә Нәҗип авыл өен сагынган иде. Ул үзенә урынны кече якта, инде күптән беркем дә ятмаган сәндерәдә җәяргә рөхсәт сорады.

## 15. Көтелмәгән очрашу



Нәҗип, күзен йому белән, тирән йокыга талды. Хуҗа картның өйалдына тәмәке тартырга чыгуын һәм, иртән казан астына ут тергезеп җибәрү өчен бер кочак чыбык-чабык күтәреп керүен дә тоймады.

Төн уртасында тәрәзә шакыдылар.

Алгы өйдә йоклаган Мәхмүт абзый, фронтта алган контузиясе аркасында, колакка катырак иде. Ул, әлбәттә, болай шакуга гына уянмады, бөтен өйне дер китереп гырылдавын дәвам итте. Тәрәзә рамына тагы — бу юлы катырак һәм түземсезләнебрәк шакыдылар.

Данишев төш күрде: имеш, аның студент чагы, алар җыйнаулашып походка чыкканнар; дежурда калган зур корсаклы Ленька Сергеев иртән аларны уятырга азаплана икән. Бензиннан бушаган канистрага таяк белән шакылдатыпмы шакылдата...

Нәҗип күзләрен ачты, бермәл үзенең кайда ятуын искә төшерә алмый торды. Башмакларның лыштык-лыштык сөйрәлүе, ишеккә таба баручы хуҗа абзыйның йөткергәләп алуы гына аны айнытып җибәрде.

«Алай булгач, нишләп бензин исе килә икән?— дип аптырады Данишев.— Әллә төштә күргәнгә генә шулай тоеламы...»— Ул иснәп алгандай итте. Чынлап та, кайдандыр бензин исе килә иде. Әллә түшәмнән, әллә инде өйалдыннан...

Өйалдында шап итеп ишек ябылды. Мәхмүт абзыйның кем беләндер сөйләшкән тавышы ишетелде. Идәннәр шыгырдап куйды. Кайдандыр ләгән дөбердәп төште.

«Кызы кайтып җитте микәнни?»— дип шатланып куйды Данишев. Ул ишектән кем килеп кергәнне күрмәде. Әмма ят ир-ат тавышы ишетелгәч, өмет чаткысы шунда ук сүнде. Нәҗип яңадан йоклап китәргә тырышып, күзләрен йомды. Колагына тоныкына булып өзек-өзек сүзләр керде.

— Сез үзегезне милициядән дидегезме әле?.. Соң бит ни...

— Утыңны кабыз!— дип бүлдерде аны теге кеше тупас кына итеп.

Түшәмдә тәлинкәсез генә асылынып торган кырыклы лампочка кабынды.

Данишев, терсәгенә таянып, ятагыннан сак кына үрелеп карады.

Башы түшәмгә тиярлек озын буйлы, типсә тимер өзәрлек бер ир-ат иде бу. Зур кепка астыннан күзләре бөтенләй күренми, диярлек. Козыректан төшкән күләгә аны озынча йөзле, караңгы чырайлы итеп күрсәтә. Әйтерсең лә, бу адәм йөзенә кара битлек киеп килгән иде. Сәндерәдән үзен күзәтүче барлыгын сизенгән кебек, ул арты белән борылды:

— Бала-чагаң өйдәме?

— Юк югын...— дип, ашыкмыйча гына җавап бирде карт.— Ә сезгә алар нигә кирәк булды, бала-чаганы әйтәм...

Таныш түгел кеше, бу сүзләрне бөтенләй ишетмәгән кебек, түр якка сузылып карады һәм, хуҗага аркасы белән торган хәлдә, теш арасыннан гына әйтеп куйды:

— Бер эш чыгып тора, картлач. Давай теге якка керик әле. Шунда сөйләшербез.

— Кызыма берәр нәрсә булдымы әллә?..— дип пошаманга төште Мәхмүт абзый, үзе караңгыда капшанган төсле итеп, утырырга урындык эзләде.

Төнге кунак, әледән-әле сәгатенә карап, үзенең ашыгуын сиздерергә тырышты:

— Кызыңа әлегә берни дә булмады. Анысы башка мәсьәлә. Миңа синең кәгазьләрең кирәк. Синнән эт алган кешеләрнең исеме язылган бөтен кәгазьне китер монда.

Данишев каушап калды, сикереп тормакчы булды, сәндерәдә ятуын да онытып җибәрә язган ул. Ике бүлмә арасындагы ишек ачык; сәндерәдән төшкән арада бандитның күреп алуы һәм бөтен эшне бозуы мөмкин иде.

Мәхмүт абзый акыллы карт булып чыкты. Җилнең кайдан исүен сизеп алды, ахрысы. Үзе ишекле-түрле йөри, үзе көр тавыш белән сөйләнә:

— Кара әле, тәтием! Мин бит күптән этләр белән эш йөртмим... Мәшәкате күп. Туйдым. Картайдым инде. Кәгазьләре дә хәзер миңа чуртыма кирәкмени. Булганнары да югалып бетте.

Мәхмүт абзый, бу хәерсез кунакны сәндерәгә аркасы белән бору өчен, түр тәрәзә ягына басты. Данишевка хәзер бик сак кына идәнгә төшәргә кирәк иде.

— Син нәрсә, карт тәре, телеңә салынып торасың!— дип сыртын кабартты теге адәм һәм кесәсендәге коралын капшап куйды. Картны якасыннан эләктереп алды да усал итеп сүгенде:

— Алдыйсың, үләмәт. Син ул эшне әле дә ташламагансың. Бөтен авыл белә, әйтеп торалар.

Каты итеп бәреп җибәрүдән карт идәнгә ауды.

— Әгәр кәгазьләрне бирмәсәң — үзеңне тончыктырам, өеңне көл итәм. Давай яхшы чакта кушканны эшлә! Юкса кызыңны да дөмек...

Кинәт нәрсәдер сизенеп, бандит ялт итеп артына борылды.

— Кулыңны күтәр!— дип кычкырды аңа таба якынлашып килүче лейтенант.

Ярсыган бандит көтелмәгән хәлдән катып калды, аннары әкренләп кулын күтәрә башлады.

— Аз гына кымшансаң да атам! Ташла коралыңны!

Шулчак көтелмәгән хәл килеп чыкты. Җинаятьченең күтәрелгән кулы ялгыш түшәмдәге лампочкага тиеп китте. Ул, күз ачып йомганчы, лампочканы бәреп, караңгы почмакка сикерде.

Лампочка ватыклары идәнгә коелганчы ук бандит качкан яктан пистолет уты чәчрәде. Данишев аның теләсә нинди очракта да атып котылырга азапланасын белә иде. Шуңа күрә ул баштан ук мич яклап басты, ут сүнү белән мичкә ышыкланырга өлгерде.

— Өй камап алынган! Каршылык күрсәтү мәгънәсез!— дип кычкырды лейтенант.

Яңадан ату тавышы яңгырады. Пуля мичкә тиде ахрысы, боз яуган кебек шыбырдап кирпеч ватыклары коелды.

Данишев атмады. Хуҗага тидерүдән курка иде ул.

Теге почмактан хырылдаган тавыш ишетелде.

— Ах... нишлисең, мөртәт?!— дип карт ыңгыраша иде.

Җинаятьче, хуҗага ышыкланып, тәрәзә аша чыгып качарга чамалый, димәк. Лейтенант, караңгылыктан файдаланып, шул ук якка ташланырга торганда, баш өстендә күк күкрәгән кебек булды.

Беренче мәлдә «яңгыр башлана...» дигән уй сызылып үтте. Ләкин зәңгәр яктылык ялтырап сүнмәде, йортта нииндидер кара шәүләләр биешә башлады.

Өй түбәсендә кинәт дөрләп киткән ут көч алырга талпына, аның төтене кара канаты белән җиргә бәргәләнә иде.

Өй хуҗасы да, Данишев та сизми калган хәл килеп чыкты!

Чакырылмаган кунак, ишек шакудан әүвәл, чормага үтеп кергән, анда бензин сипкән, шуның өстенә бензинлы чүпрәккә кечкенә генә ике стеарин шәме утырткан, әлеге чүпрәкнең очын бензинлы канистра авызына тоташтырган иде. Ул, әлбәттә, биш-ун минут эчендә үзенә кирәкле кәгазьне алып өлгерергә һәм картны юк итеп ычкынырга исәп тоткан. Шушы вакыт эчендә чормадагы шәм янып бетәргә, ут бөтен өйгә сикерергә һәм янгын яңа җинаять эзен ялап алырга тиеш булган. Соңгы

чиктә, бандитка әлеге язуларның өйдә саклануын белү дә бик житәр иде. Йорт хужасы белән бергә аларның шушында көлгә әйләнеп каласы ачык.

Кыскасы, теләсә нинди очракта да өйгә ут салып китү максаты белән килгән бу бәндә. Шуңа күрә, ышанычлырак булсын өчен, чормада берьюлы ике шәм кабызып калдырган...

Бензинлы канистраның шартлавы ике якның да хәлен мөшкелләндерде. Өй эче яктырып, андагы әйберләр уч төбендәге кебек күренә башлады. Эшләрнең һич көтелмәгәнчә катлауланып китүен бандит та аңлады. Тәрәзәдән сикерә калса, ул хәзер мишень кебек ап-ачык күренәчәк. Исән калуга өмет аз хәзер.

Картка ышыкланып, теләсә кайсы секундта атарга әзер торган жинаятьче бизгәк тоткан шикелле калтыранды. Әгәр өй чынлап та чолгап алынган булса — беттем, дип уйлады ул. Әгәр инде мильтон шаярткан гына булса... димәк, ул монда ялгызы гына килгән һәм эзләгәнен әлегә таба алмаган. Югыйсә, нишләп әле кунып-төнеп ятар иде... Эт эзеннән жинаятьче дә килеп чыкмасмы дип көтеп-сагалап торучы дисәң... Аның нәкъ менә бүген киләсен кайдан белергә мөмкин? Төшкә дә керми торган хәлләр чыгып тора бит бүген бу йортта!

Әгәр картны йомдырып, үзем ычкына алсам — артымнан куып та тормаслар, дип фикер йөртте бандит. Утны сүндереп, өйнең астын-өскә китерерләр. Аның исем-фамилиясе, төгәл адресы язылган кәгазьне тапмый калмаслар. Ул чакта — харакири... Шулай булгач, бер генә юл кала... Өйне бөтенләй ут чолгап алганчы, моннан китәргә ярамый. Һәрхәлдә, кызуга һәм төтенгә түзә алганчы! Ә бит ул чакта аңа бу тамугтан котылу юлы да ачылырга тора... Ай төтен, вай төтен!.. Синең куеныңа сыенып, жир читенә качып булачак! Түзә алганчы түзәргә генә, түзәргә генә!..

Ике як та, тәжрибәле шахматчылар кебек, бер-берсен сыный, берберсенең ялгыш адым ясавын көтә иде. Өйдә авыр тынлык урнашты. Түбәдә бәпкәләрнең шытырдап януы һәм Мәхмүт абзыйның ара-тирә ыңгырашып куюы гына ишетелә...

Өй эченә башта көек исе таралды, аннары түшәм ярыкларыннан яр комы кебек аксыл-сары төтен саркып керә башлады. Төтен күзләрне әчеттереп, тынны буып, әкрен генә түбән төшә, идәнгә җәелә иде. Өй эче бик тиз эсселәнде: әйтерсең лә, мунчада кызган ташка салкын су бөркеделәр!

Урамда кычкырган-чырыйлаган тавышлар ишетелде. Ләкин берәү дә өйгә якын килмәде. Лейтенант моның сәбәбен шунда ук аңлады: авылда янгын сүндерү машинасы юк, кешеләр искәрмәстән дөрләп киткән бу йортны коткарып калырга инде соң икәнлеген күргәннәрдер. Мөгаен, кем дә булса колхозның ат абзарындагы сулы мичкәләрне алып килер. Ул су шушы өй урынында каласы кисәүләрне сүндерергә кирәк булачак!

Нәжип сак кына үрелеп карады. Куе төтен рәшәсе аша жинаятьченең шәүләсе ике булып күренә иде. «Кеше жилкәсенә ышыкланырга, тәрәзәдән сикереп качарга чамалый! Барып чыкмас!»— дип, тешләрен кысты лейтенант һәм икегә аерылып торган фигураның сулдагысына тәзәбрәк ике-өч тапкыр атып жибәрде. «Нервыларың өзелсен, кабахәт!»

Ике башлы шәүлә шундук уңга тайпылды һәм ату белән җавап кайтарды. Бер пуля янә мичкә килеп тиде. Кирпеч кыйпылчыгы чәчрәп, Данишевның күзенә бәрде.

Шул ук мәлдә чылтырап тәрәзә ватылганы ишетелде. Вакытлыча сукыраеп калган Нәжип, ике дә уйлап тормыйча, тавыш килгән якка томрылды.

Тәрәзә төбенә менеп тезләнгән бандит өстенә килгән лейтенантны күреп алды. Каушавыннан картны ычкындырып жибәрде. Төтенгә бу-

лыккан Мәхмүт абзый, котылу юлын эзләп, шунда ук тәрәзәгә капланды һәм, үзе дә сизмәстән, башы белән, тегене мәтәлдереп төшерде. Бандит пулясы Данишевның җилкәсен генә тырнап үтте.

Лейтенант та тәрәзәдән тышка сикерде. Ләкин ул җинаятьчене күрми иде. Бөтен тирә-як кызыл-кара тап булып җәелгән, аңа таба ниндидер тавышлар гына якынлашып килә. Хәзер тавыш килгән якка атарга ярамый — һич гөнаһсыз кешене харап итүең бар.

Нәҗип Мәхмүт абзыйны тәрәзәдән суырып алырга гына өлгергән иде, өй эчендә инде түшәм такталары янып ишелә башлады. Карт, тәрәзә төбендә үк егылып, һушсыз калды. Лейтенант аны бик авырлык белән генә күтәреп алды. Ул арада кемдер ярдәмгә килеп җитте...

## 16. Барысы да яңабаштан

Университет профессоры хаклы булган шул, дип уйланды Нәҗип. Чыннан да, тикшерүче-следователь белән фән кешесенең буразналары бер-берсенә бик якын уза. Бу охшашлык нәрсәдә: уй-мәшәкатьләреңне, «бәйләнчек идея»ләреңне, эш сәгате беткәч тә, өстәл тартмасына бикләп калдыра алмауда — аларның кунакта һәм мунчада, сыра эчеп торганда һәм кызлар кочканда да баштан чыкмыйча, эзәрлекләп йөрүендә генә микән?! Ә бәлки, безнең язмышлардагы иң зур уртаклык — айлар, еллар буе эшләгән эшнең кайчак бер селтәнү белән юкка чыгуында, еш кына юл уңмауда һәм бөтенесен яңадан башларга туры килүендәдер? Бөтен корган планнарың, ниятләрең комнан ишкән бау кебек тарала да төшә! Шуңа күрә галимнәр һәм тикшерүчеләр өчен мондый хәлләр табигый, алар уңышсызлыкка психологик яктан һәрвакыт әзер, «алдан планлаштырып куелган» бәла-казаларны җиңелрәк кичерергә тиешләрдер кебек... «Кебек»!

Башланып кына килүче зур, катлаулы эш хәтта кыю, нык ихтыярлы кешенең дә күңеленә шик-шөбһә сала. Әгәр ул эшнең коточкыч көч сорыйсын алдан белеп тә, аның ни белән төгәлләнәсен күз алдына китерә алмасаң, бу шик-икеләнү икеләтә зуррак, икеләтә авыррак була.

Мәхмүт абзый яныннан буш кул белән кайтып кергәч, Нәҗип Данишевка да шундый авырлыкны кичерергә туры килде. Үзенең яшьлеге, тәҗрибәсезлеге, ә дошманының шактый шомарган булуы аркасында бандитны кулдан ычкындырса да, ул артык төшенкелеккә бирелмәде. Шушы мәшәләнү аның бер зур сәләтен — җеп очын ерак яшергән җинаятьче өненә дә илтеп җиткерерлек саллы версияләр төзи алуын раслады.

Ул киеренке төннән соң Нәҗипнең бер күз кабагы тарта башлады. Күрүен әйбәт күрә иде. Врач, күз тартышуы нервыдан гына, ул әкренләп бетәр, диде.

Үзенең соңгы маҗаралары турында начальнигына сөйләп биргәч, лейтенант шул ук көнне прокуратурага, теге пеләш башлы агай янына китте.

Дөресен әйткәндә, «агай» дигәне — Кәрим Нуркаев — чынлыкта аннан өч-дүрт яшькә генә олырак иде. Пеләшләнә башлаган, җәелебрәк киткән кыяфәте генә аңа өлкәнлек төсе бирел тора. Нәҗипнең фикер-фаразларын бик игътибар белән тыңлады Кәрим. Аннары алар тагын бер тапкыр Цветова йортын барып карадылар.

Йорт уртасындагы кечкенә генә калкулык баштан ук тикшерүчеләрнең игътибарын җәлеп иткән иде. Экспертиза пуляның әлеге калкулык турысыннан ярты метр гына биеклектән очып үтүен ачыклады. Һәм нәкъ менә шул калку җир өстендә зур эт эзләре ярылып ята иде.

Эт белән булган хәлләр хәзер артык кызыксыну уятмый, ул инде җинаятьне ачу юлында шактый эшкәртелгән катлам; ләкин эткә бәйлә-

нешле вакыйгалар мөһим бер моментны ачыкларга ярдәм итте: Цветованы үтергән һәм Аушевага аткан җинаятьче бер үк кеше булырга тиеш. Эзләнүләрне хәзер шул юнәлештә дәвам итәргә кирәк. Гавашевка да шул үк бандитның һөҗүм итүендә инде шик юк.

Тикшерү, исәп-хисап эшләрен тәгәлләгәч, Кәрим Нуркаев тәмләп кенә тәмәке суыра башлады. Аның кәефе шәп, тавышы көр иде:

— Менә шулай, брат,— дип куйды ул.— Хәзер эшнең вак-төяге генә калды: шул хәшәрәтне йонлач муеныннан эләктереп алырга да хурлык баганасына бәйләп куярга!..

Данишев әллә елмайды, әллә чыраен сытып алды:

— Ул «вак-төякләр» безне утлы күмер өстеннән яланаяк йөгерергә мәҗбүр итмәгәе әле. Ә җәзасын бирү — безнең эш түгел...

— Мин ул кандаланы үзем сытып үтерер идем. Җирәнгеч...

— Картлар әйтмешли, ризыгы калган әле юлбасарның. Авылда аның башын бетерергә форсат чыккан иде... Ярый инде ичмасам, үз күзләрем белән күреп калдым. Хәзер башы белән мичкә керсә дә, артыннан таныйм. Теге чакта Шамов агай больницага озаткан кеше дә нәкъ шул үзе булган бит.

— Димәк, эт үзенең хуҗасына ташланган булып чыга?

— Әйе, эт тешләгәч, эз яшерү өчен үзен Силагаев дип яздырган ул...

— Кызык... Әмма болар барысы да үткән тарих кына, брат. Беләсең бит, янгыннан соң батыр кирәкми.

— Син нишләргә киңәш итәсең?

— Бүген иртән, эшкә килгәндә, миңа буш чиләк тоткан бер бик чибәр кыз очрады. Ә минем исәп — җинаятьчедән калган пыж белән эш итә башлау иде. Менә шуннан үзең исәпләп кара инде, брат. Әгәр мин тотынсам — пыждан пшик килеп чыгачак. Ә син алынсаң... Сиңа бүген буш чиләк белән каршы чыкмаганнардыр бит?

— Һм... Буш чиләк, имеш.— Данишев борынын җыерып куйды.— Син, ичмасам, эш тупикка килеп терәлде, Нәҗип абыем-җаным, инде ни эшләргә дә белгән юк, диген.

— Бик әйттерәсең килсә, анысын да әйтеп була. Пыж мәсьәләсендә шактый тир түгелде. Ике кисәгенең очына чыктык шикелле. Берсе канцелярия кәгазе, икенчесе укучы бала дәфтәреннән. Минаев дөрес әйткән: исеме дә буш булып чыкты. Хәтерлисеңдер, анда бит барысы өч кисәк иде. Өченчесе — билет кыйпылчыгы. Менә шунысына теш үтмәде. Эчендә теше бардырмы-юктырмы, әмма факт — каты чикләвек булып чыкты ул билет.

Бу чикләвекне дә ватарга тырышып караганнар. Экспертиза аның театр билеты икәнлеген билгеләгән. Кечкенә генә кыйпылчыкка «Ка» дип башлана торган сүз өзеге, «8» саны һәм аның белән янәшә «и» хәрефе сыйган.

— Билет Казандагы ике театрның берсенә булырга ихтимал,— диде Кәрим.— Галиәсгар Камал исемендәге Татар академия театрына яисә Качалов исемендәге Рус драма театрына. Һәрхәлдә, ике театрга да бирелгән исемнәр «Ка» иҗеге белән башлана. Чагыштырып карагач, төгәлрәк ачыкланды: билет татар театрына булган! «8 и» дигәне дә язылышыннан ук күренеп тора: спектакль көнен аңлатырга тиеш. «И» димәктән, июль аенда театр гастрольгә киткән. Шуна күрә сүз июнь аендагы спектакльләр турында гына барырга мөмкин. Ә 8 дигәне, бәлки, 18 е, яки 28 е булгандыр?..

Нуркаев урыныннан торды, пиджагын салып урындык аркасына элде. Бүлмә, чыннан да, эсселәнеп киткән төсле иде. Икесе дә тынып калды. Икесе дә нидер уйлана иде.

— Син ничек уйлыйсың, Кәрим, театр билеты да буш чикләвек булып чыкмасмы? Җинаятьчене, театрдан чыгып, эт атарга килгәндер, дип фараз итәбезме?

— Эш шунда, баштагы ике кәгазь кисәгенең хуҗалары кайда яшәгәнлеге безгә мәгълүм. Һади Такташ урамындагы ике катлы йортны беләсеңме? Ике кәгазь дә шул йорт янындагы чүплектән алынган. Димәк, үткән елның июнь аенда әлеге йорттан кемдер Казанга барган һәм театрга кергән булып чыга. Ләкин тикшереп карадык: бу йортның үзеннән генә түгел, аның тирә-юнендәге йортлардан да андый кеше табылмады... Җинаятьче шушы, бармак бите хәтле билет кыйпылчыгын бүтән чүплектән эзләп алган булырга да мөмкин, әлбәттә. Ләкин моңа ышану кыен. Баштагы ике кәгазь кисәге пыж ясау өчен дә, тикшерү эшен ялгыш юлга кертеп җибәрү өчен дә бик җиткән. Минем уемча, билет кыйпылчыгы мылтык көпшәсенә очраклы гына килеп эләккән. Җинаятьче аңа бөтенләй игътибар итмәгән. Пыж ясый торган кәгазь арасына ул костюмга ябышкан чәч бөртеге кебек кенә кушылып киткән.

— Җинаятьче хаклы,— дип сүзен дәвам итте Нуркаев.— Шушы кечкенә кыйпылчыктан җеп очын табарга маташу мөмкин түгел эш. Аңа ябышу — суга сәнәк белән язганны укырга азаплану. Һәрхәлдә, мин шулай уйлыйм. Бу билетның безгә әйтергә теләгәне бер бәләкәй генә факт: июнь аенда, бәлки җинаятьченең театрга барып чыгуы да ихтимал. Я, шуннан нәрсә?

Кәрим кулларын бутый-бутый селтәде дә кинәт тынып калды.

Алар сүзсез генә урамга чыктылар. Саубуллашканда Нуркаев, алыштырып куйгандай, яңадан балкый иде:

— Син шулай да кулдан килгәнне эшлә инде. Борынны салындырмыйк әле, брат. Килеп капмый карасын ул безнең кулга. Иң мөһиме — хәзер без аның эзенә бастык.

## 17. Санаторийдагы роман

Самолет 45 минут дигәндә Казанның иске аэропортына килеп төште. Күптән түгел шәһәрдә яңгыр явып үткән: юеш асфальт яңа гына юылган тәрәзә кебек күңелгә рәхәтлек биреп тора. Һавада яшел яфрак исе. Сулышка иркен. Зур-зур тимгелле аксыл болыт астыннан кояш ялтырап чыкты. Еракта, Казанка турысынарак, аллы-гөлле салават күпере эленде.

Нәҗипнең күңелендә шатлык та, кайгы да юк. Ул хәзер артык дулкынланудан, кичерешләр муллыгыннан арынган бер кеше кебек салкын иде. Ләкин «Пионерлар сарае» тукталышында троллейбустан чыккач кинәт сул аягы хәлсезләнеп китте, күкрәк туры авырттырып чәнчешеп куйды.

Бер талпынуда лейтенант театрның пыяла ишекләре төбенә килеп җиткән иде. Аның киеренке халәтен баса барып, рәхәт бер дулкынлану хисе җәелде. Казанда укыган елларында ул бирегә шактый еш килеп чыга, һәр килүе студент тормышының көтелмәгән бер бәйрәме була иде.

Галиәсгар Камал театры Нәҗипнең хыялында һәрвакыт зур океан корабы булып җанлана. Бу бәхетле кораблъгә эләгүе җиңел түгел — теләүчеләр саны урыннар саныннан һәрвакыт артыграк.

Менә өченче звонок яңгырый. Авыр пәрдә калын дулкын кебек ике якка аерылып китә. Һәм синең алда яңа дөньялар ачыла. Шул сәяхәттә үз телеңне һәм культура хәзинәңне тирәнрәк аңлый төшәсең, башка илләр, халыклар, аеруча бөек рус халкының олы язмышына тоташасың; күңелеңдә мәхәббәт һәм мәрхәмәт хисе арта, кешеләрне һәм тормышны аңлау сәләте үсә. Бу корабның тагын бер гаҗәеп ягы бар: вакытлар үтү белән, үзенең команда составы һәм капитаннары тулысынча алышынып бетсә дә, ул дөрес юлыннан тайпылмый, яңа буыннарны үзенә җәлеп итә, алар өчен якын һәм тансык булып кала...

Данишевның уйлануларын бүлеп, театрга артистлар кереп-чыгып йөри торган «служебный» ишек шапылдап ябылды. Бусагада озын буйлы, чандыр гәүдәле бер егет күренде. Нәҗип аны шунда ук танып алды: кайчандыр сәхнәдә уйнаганын да күргәне бар, үзе пьесалар яза икән дип тә ишеткән иде. Егет мондагы хәлләрдән хәбәрдар булып чыкты: театр әле гастрольдән кайтмаган, хезмәт күрсәтүчеләр ялда икән. Ә июнь аенда... Июнь аенда билет тикшерүчеләрнең берсе больницада яткан, ишек төбендә Нәгыймә Бәдретдинова дигән хатын үзе генә торган.

Егет театрның әдәби бүлек мөдире булып эшли иде. Аның кәгазьләре арасыннан тикшерүче 8 нче һәм 28 нче июньнәрдә нинди спектакльләр булуын язып алды. Ә 18 е көнне театр ял иткән.

Билет тикшерүче хатын театрдан ерак түгел, шул ук Горький урамында яши икән. Ләкин ул әле өйдә юк иде. Күршеләренә кичке сәгать унберләрдә генә кайтам, дигән.

Данишев урам буйлап җәяүләп кенә Кольцога таба китте. Юл уңаенда туры килгән афишаларга күз салды. Бүген опера һәм балет театрында «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы бара икән. Үткән ел ул аны караган иде.

Юл уңаенда Данишев тагын Камал театрына сугылып чыгарга уйлады. Теге егеттән кайбер детальләрне сораштырасы килде. Ләкин вахтердан ары уза алмады: әдәби бүлек мөдире кайтып киткән иде. Ә вахтер шактый кире карт булып чыкты — бөтен сорауга тырт-пырт кына җавап бирде.

Нәҗип, кәефе кырылып, урамдагы витрина янында бераз туктап торды. Фотолардан елмаешкан театр йолдызлары да бу юлы әллә ничек житдиләнеп калгандай тоелды аңа. Сәхнәдә күренүе белән генә дә бөтен залны шырык-шырык көлдерә торган Равил Шәрәфиевкә кадәр, аның хәленә кереп, кайгыртып тора кебек иде. Нәҗип, авыр уйларга бирелеп, опера театры ягына таба атлады.

«Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы аны яңадан таң калдырды. Спектакльдән соң төнге урамнар буйлап атлаганда, Нәҗип соклануларның җиденче катында йөри, дөньяның бөтен мәшәкатьләре исә вак булып калган иде...

Сәгать унбер тулганда ул билет тикшерүче хатын яшәгән квартираның ишеген шакыды. Нәгыймә апа чәй эчеп утыра икән. Кунакны да өстәл янына чакырды. Театр буфетыннан алган бер тартма конфет ярап куйды. Данишев чәй янында ук килүенең сәбәбен, гозерен сөйләп өлгерде.

Ул үзе белән җинаятьченең җыелма фотосын (фотороботны) да алып килгән иде. Хуҗа хатын рәсемгә, ниндидер танышын күргәндәй, бик игътибар белән карап торды.

— Күргәнем бар да кебек, юк та кебек. Һай алла, минем күз алдыннан көн саен күпме халык үтә! Бөтенесен хәтерләп бетерсәң...

Лейтенант аңа ярдәм итәргә тырышты.

— Аның буе ике метрлап булыр, сабантуй батыры кебек таза, күзләре кысык, кашлары кара, маңгае алга чыгыбрак тора, борыны зур, итләч...

— Тукта, тукта, наный,— дип элеп алды Нәгыймә апа,— бер нәрсә исемә төшәргә тора. Шулмы-түгелме, анысын белмим, тик...— ул маңгаен җыерды, сүзне кайдан башларга дигәндәй, аптырап торды, аннары кулын селтәп куйды:

— Кып-кыскасы, мин бервакыт күрдем андый пәһлеванны. Буе дисәң, ике метрдан да озынрак булыр әле. Ялгызы гына түгел, беләгенә ниндидер бер чәчби дә тагылган иде.— Хатын тәрәзәгә таба борылды.— Шул үзе булды микәнни?

— Ничек, Нәгыймә апа, әллә белеш кешегез идеме ул?

— Юк ла-а... Истә калуының сәбәбе бүтән... Күрсәтергә билетын алганда бер тәңкә акчасы идәнгә төшеп китте. Шуны иелеп алмады. Башта алмакчы иде дә, аннары... Ишек төбендә пычрак, әллә ни арада таптап өлгергәннәр. Көндезен яңгырлап торган иде...

— Кәгазь берлеге пычракка төште инде алайса?

— Әйе шул, идән пычрак иде... Бөтәрләнеп-укмашып беткән берлек иде. Мин алай да иелергә иренмәдем,— акча бит... Пәһлеванның артыннан кычкырып калдым. Борылып та карамады. Кызы туктамакчы иде дә, теге ир аңа нәрсәдер әйтте. Исемен генә ишетеп калдым.

— Исемен хәтерләмисезме?

— Хәтерләмичә! «Найла!» дип дәште ул аңа.

— Наилә яисә Нелядыр инде?

— Юк, юк. Үз колагым белән ишеттем. Найла, диде. Мин аны онытыр идем, безнең күршеләрнең этен шулай атыйлар. Бик мәзәк кешеләр яши минем күршедә. Әнчекләре Найла исемле, песиләренә Мартын дип кушканнар. Ул эт белән мәченең кызыкларын күрсәң! Агылый белән тагылый кебек, бер-берсеннән аерылмыйлар, гел икәү, гел бергә... Әле икәүләшеп пес итәргә барганнарын күрсәң, хи-хи-хи... көлеп үләрсең...

Данишев аны бүлдерергә уйлаган иде, үпкәләтермен дип курыкты. Аннары рәтләп сөйләшмәс тә, сорауларга юньле җавап та бирмәс... Күрәсең, хуҗа хатын эт-мәче халкын бик ярата, җае чыккан саен алар турында сөйли һәм шул сөйләвеннән зур ләззәт ала иде.

— ...Менә шул Мартын, йомышы төшеп, туалетка кермәкче булса, ишеген ача алмый, тик мияулап тора. Эт шуны ишетеп, йөгереп килә дә, аягы белән төртеп туалетны ачып җибәрә. Мартын ишекне үзе яба, унитаз читенә баса, аннары суны үзе җибәрә имеш... Ишектән янә чыга алмый, янә мияулый, «ачыгыз» дип дәшүе инде мескеннең. Найла аның тавышына йөгереп килеп, ишекне ача...

— Нәгыймә апа, ул кешеләрне сез соңыннан бүтән күрмәдегезме?

— Юк шул. Күрмәдем. Ә күрәсем килгән иде.

— Берәр сәбәбе бар идемени?

Хатын, гадәтенчә, бусын да тәфсилләп сөйләде. Теге пычрак берлекне кесәсенә тыккан да, оныткан булган ул. Икенче көнне алып караса, йомарланган акча эченнән бер автобус талоны килеп чыккан икән. Иске, тишелгән талон.

— Ул талонга әдрис кебек нәрсә язылган иде. Мин инде акчасына исе китмәсә дә, шул әдрисне кирәксенер дип уйладым... Егерме ел эшлим бит инде. Театр ишеге төбендә һәр көнне мәхшәр була. Кешеләр кесәләреннән билет актарганда, кирәкле язуларын үз куллары белән ташлап китәләр. Егерме ел эчендә күпме кеше килгәндер инде: фәлән төрле документ тапмадыгызмы, дип.

— Бусы аңлашылды, Нәгыймә апа. Аннары ул талонны нишләттегез инде?

— Килмәсме дип көттем. Өстәл тартмасына салып куйган идем, театрда. Хәзер ташлангандыр инде. Күпме вакыт үтте бит!

— Кайчан булды соң ул хәл?

— Июнь аенда бугай.

— Ул көнне нинди спектакль куелган иде?

Контролер хатын уйга калды. Лейтенант үзенең язуларына карап алды.

— Алай-болай, «Әлдермештән Әлмәндәр» түгеллер бит?

— Театр гастрольгә җыенган көннәр иде. Әйе! Исемә төште! «Әлдермештән Әлмәндәр» иде. Шул театрны халык бигрәк яратты инде. Кайчаннан бирле бара, һич карап туймыйлар. Таш яуса да килəләр.

Соныннан Данишев тагын бер детальнең дөреслеген тикшерер: чыннан да, 28 июнь көнне Казанда көчле яңгыр явып узган икән!

Билет тикшерүче апа белән сөйләшкәндә, әлбәттә, сүз нәкъ менә ул эзләгән җинаятьче турында барадыр дип ышанырга һичнинди нигезе юк иде Нәҗипнең. Бер тәңкә акчасын төшереп калдырган «пәһлеван»ның бөтенләй гаепсез кеше булуы да бар. Ләкин тикшерүченең эше шундый: шик төшкән бөтен нәрсәне ахыргача ачыкларга, җинаятьченең эзенә алып чыкмасмы дип, бик күп сукмаклардан үтәргә туры килә.

Данишев «Татарстан» гостиницасына тукталган иде. Иртән буфетта гына капкалап, тизрәк театрга ашкынды.

Бәдретдинова озак көттермәде. Тикшерүчене үзенең бәләкәй генә эш бүлмәсенә алып керде, аның күз алдында ук кичә телгә алынган өстәл тартмасын ачып җибәрде.

Тартмада автобус талоны юк иде.

Хатын аптырап кулларын җәйде:

— Шулайдыр дип уйлаган идем... Ташлаганмын инде.

— Кая ташладыгыз?— дип сорады Нәҗип. Аның дулкынланудан иреннәре кипкән иде.

— Кәрзингә инде, кая ташлыйм тагын.

— Нәрсә язылган иде икән соң, Нәгыймә апа?

Бәдретдинова уйга калды. Аның бик тә ярдәм итәсе килә иде. Ләкин хәтер сандыгың никадәр зур булса да, мөмкинме соң анда шул хәтле вак-төякне саклап тору?!

— Талонда ниндидер бер кирәкле сүз бар иде. Мин шул сүзне укыгач, нәрсәдер уйлап та тордым бугай әле. Нәрсә турында уйладым икән... Ә-ә! Ял турында. Минем абый да яз көне анда ял иткән иде...

— Талонда... ял йортының адресы идемени?

— Әйе, әйе. Хәзер менә исемә төште. Санаторий исеме иде. «Морквашн» кебегрәк. Түлке «Морквашн» түгел. Ничек кенә соң әле...— Нәгыймә апа бармагындагы алтын балдакны әйләндергәләргә керешге.— Тфү, тел очымда гына тора бит...

Хатын бүлмәсеннән үк чыгып китте. Ахрысы, кемнәндер сорашкандыр, бераздан кире әйләнеп керде.

— «Крутушка»! «Крутушка» икән. Минем абый аны бик ошатып кайтты.

...Ике сәгатьтән Данишев санаторий регистратурасында утыра һәм июнь аенда «Крутушка»га килгән кешеләрнең анкеталарын караштыра иде.

Ял итүчеләр арасында, чыннан да, Найла исемле бер хатын булган икән. Июньнең 6 сыннан 30 ына кадәр ике кешелек бүлмәдә яшәгән.

Лейтенант Найла Мурлыкинаның паспорт мәгълүматларын язып алды. Аның белән бүлмәдә торган хатын-кызның да анкетасына күз салды. Алар икесе дә Казаннан килгән булып чыктылар.

Автобус кузгалырга ярты сәгатьләп вакыт бар иде әле. Данишев вакыт үтсенгә генә санаторий тирәсен әйләнеп килергә уйлады. Шунда гына «Крутушка»ның гаҗәп матур урынга салынган булуына игътибар итте. Ике катлы иске йорт янына, текә яр буена килеп баскач, ул бөтен дөньясын онытты. Күз күреме җирдә табигать искиткеч гүзәллеге белән балкып ята иде: купшы ябалдашлар арасыннан офыкка кадәр җәелеп киткән басулар күренә; сулда — чуар төсләргә уралган әрәмәлек башланып китә; ә яр астында кояшлы тәңкәләре белән Казанка суы уйнаклый.

Нәҗип елга буена төште. Көн бик бөркү, суга бер генә чумып чыксаң да бөтен ару-талчыгуларны юып алыр кебек... Юк шул, озакламый автобус китә. Мурлыкина белән тизрәк очрашасы килү теләге лейтенантны Казанга, профессор Камай урамына ашыктыра иде.

...Ишекне Найла үзе ачты. Төскә-биткә яшь, үтә чибәр нәрсә икән.

Данишевның таныклыгына керфек сирпеп кенә карап алды да, кыска халат итәкләрен җилфердәтеп, алдан кереп китте.

Тәбәнәк журнал өстәле янындагы йомшак кәнәфиләргә утырыштылар.

— Мин сезнең ихтыярыгызда,— диде Мурлыкина.

— Найла Владимировна, минем сезгә кечкенә генә ике соравым бар иде...

Яшь ханым сигарет кабызды, тирән итеп бер суырды, күзләрен тутырып лейтенантка карады.

— Сез быел июнь аенда татар театрына баргансыз икән...— дип сүзен ялгап китте Данишев.

Найла сигарет очындагы көлне чиртеп төшерде. Төн кебек кара, ишелеп төшкән чәчләрен төзәтеп куйды. Иреннәрен назлы гына күпертеп җавап бирде:

— Булган идем ахрысы. Тыелган спектакль түгелдер ич ул?

Данишевның йөзе яктырып китте.

— Юк, Найла Владимировна, сүз һич тә ул турыда бармый! Мин үзем дә ул спектакльне ошаттым.

Сөйләшүнең рәсмилеген аз гына булса да оныттырасы, бу назлыбикәнең телен чиштерәсе иде. Нәҗип аның ялангач шома тезләренә күз төшереп алды. Матур иде кызның аяклары.

— Мин килеп, сезне эштән аермадыммы соң?

Мурлыкина мутланып елмайды:

— Сезнең икенче соравыгыз шул идеме?

— Шул тирәдә...

— Кызы-ык... — Найла кәнәфигә киерелебрәк утырды, аның мул түше, тулы ак ботлары тагын да ачыла төште; кыска халатының уртадагы бер төймәгә генә эләгеп торуы күренде. Ул егетнең игътибарын сизә, шул игътибарны тоюдан төнбоек кебек ачыла бара һәм, әлбәттә, ситуацияне үзенчә бәяли иде. — Ә сез, между прочим, минем зәвыкка туры киләсез...

— Сездән... күзне аерып алып булмый диярлек.— Нәҗипкә хәзер аның телендә сөйләшү бик мөһим иде.

— «Диярлек» кенә мени? — дип чытлыкланды кыз. — Сезнең өчен алай гына түгел икәнен күреп торам, — дип бармак янады.

Данишев елмаеп куйды.

Найла сәгатенә карады:

— Озакламый ир кисәгем кайта...

— Бу бик куркынычмы?

— Белмим. Ул әле минем ирем булып өченче генә көнен йөри. Ир булгач, ничегрәк көнләшә торгандыр бит...

— Кияү егет чагында көнләшә идеме соң?

— Фәнгә кереп чумган бер уҗым бозавы шунда. Китапларын кочаклап ятса, күбрәк ләззәт ала. Бу дөньяда гаме юк...

— Әйбәт кеше икән. Сезгә яшәве җиңелдер.

Мурлыкина борынын җыерып куйды, күңелсез тавыш белән тезеп китте:

— Иң мөһиме: алкаш түгел. Өстемнән йөрми. Әдәпле... Хатларына оятсыз сүзләр язмый иде.

Лейтенант сизеп алды: кияү турында сөйләшү Мурлыкинага бер дә ошамый.

— Алай булгач, Найла Владимировна, мин сезне ширбәтле аегыз белән котлыйм. Хәзер туй сәяхәтенә җыенасыздыр инде?

— Кызганычка каршы, мин отпускыны туздырып өлгердем шул.

— Шәп ял иттегезме соң?— Сөйләшү кирәкле темага якынлашып килә иде.

— Ярыйсы-ы...— дип сузды Мурлыкина, йомры иңнәрен назлы гына

уйнатып. — «Крутушка» миңа ошады. Тагын барырга да була.

— Киявегез дә канәгать калгандыр, ә?

Яшь хатын тәкәллефсез генә елмайды:

— Ирен ялга алып барган — чирен янга салып барган. Ирләр беркая да китми алар.

— Анысы дөрес. Тик чибәр кызга ялгызына ничек түзәргә: ир-егетләр аның артыннан эт көтүе кебек тагылып йөриләр бит. Араларында хатын-кызга тәмам котырган күк ябыша торганнары да була...

— Һи... Хатын-кызны кысып, кочып кына куркытырсың...

— Сезне кыскалап йөргәне, ай-һай, батыр кеше булгандыр. Зур гәүдәле, аю кебек таза, буе ике метр...

Тикшерүче, кылларын тарткалап карау белән, бу хатынның кемлеген аңлаган иде: ир-атлар белән шаярырга яратучы ыштыр битле бер җилбәзәк. Ләкин мондыйларга да сорауны турыдан-туры биреп булмый, аларның да үз ачкычы булуын онытмаска кирәк.

Найла Владимировна дәртенә чыдаша алмыйча хихылдап куйды.

Данишевның сүзләре аның кытыгына тиде: димәк, теге «пәһлеван» белән аларның бик ярсу роман булган. Тик кем ул? Үтерүчеме, әллә бөтенләй очраклы кешеме?

— Сез мине юри көнләштерәсез. Шундый чибәрне үзенеке итә алган кавалер кем соң ул? Ә?

Яшь хатын тирән итеп сигаретын суырды, лейтенантка ымсындыргыч итеп карарга тырышты:

— Аның кем булуы нигә кирәк... Хатын-кызның яшен сорамыйлар. Үткәне турында да сөйләшү килешми.

— Хатын-кызның үткәне — аның булган байлыгы арасында иң кызыклысы... — Данишев хәзер төп юлдан читкә тайпылырга теләми иде.

Йозак шылтырады, әкрен генә ишек ачылды, урамнан балалар шаушуы ургылып керде. Бусагада урта буйлы, чандыр гәүдәле адәм күренде.

— Менә ирем дә кайтып җитте. — Найла сикереп торды, халатын рәтләде, лейтенантка борылып карамыйча гына, иренә аңлатып бирде: — Бу — милициядән килгән иптәш. — Шунда ук чатыр-чотыр килеп тезә дә башлады. — Сез мине кем дип белдегез?! Минем карчыга кебек ирем бар. Ял вакытында да гел аның турында гына уйладым. Сагындым. Санаторийдан аны күрер өчен бер тапкыр кайтып та килдем.

Мурлыкина күз ачып йомган арада пластинканы әйләндереп өлгергән, инде әүлия булып кылана иде. Ул бу рольгә шулхәтле тиз һәм оста керде, үз ялганына үзе үк ышана башлады бугай. Күрше бүлмәдә Данишев аны күпме генә юмалап караса да, рәтле җавап ала алмады.

Найла белән санаторийда бер бүлмәдә яшәгән Әхмәтшина Розалия дигән кызны эзләп табарга туры килде. Ул санаторийга ак «Жигули» белән килеп йөргән ирнең төс-кыяфәтен бик нечкәләп тасвирлады. Иң гаҗәпсендергәне шул: Розалия, әйтерсең лә, Мурлыкинаның вакытлы кавалеры түгел, ә лейтенант үз күзләре белән күргән җинаятьче турында сөйли иде. Ул кешенең исеме Федор булып чыкты. Найла белән алар, яңа гына өйләнешкән пар кебек, бик дәртле яшәгәннәр.

Бу мәгълүматлар кабат сорау алу вакытында Мурлыкинаның да телен ачты. Ул Федорның атасы буенча Николаевич булуын, сул кулында беләзектән өстәрәк «Газиз анамны онытмам» дигән классик татуировка йөртүен әйтте.

Ирнең фамилиясен һәм адресын Найла белми иде. Федор Николаевич аңа ел ахырындарак, озын сроклы командировкадан кайткач шалтыратырга вәгъдә иткән.

Гостиницага кайткач Данишев озак уйланып ятты. Күз алдыннан Мурлыкинаның оятсыз елмаюлары китмәде. Күпләргә мәгълүм мәзәк исенә төште. Имештер, бер акыл иясеннән: «Бу дөньяда ирләр күпме,

әллә хатыннармы?» — дип сораганнар. Тегесе ике дә уйлап тормыйча: «Хатыннар», — дигән. «Ничек алай тиз әйтеп бирә алдың?» — дип гаҗәпләнгәннәр. «Соң ул болай да билгеле: начар ирләр хатын-кыз санын арттыралар», — дигән аксакал. Бүгенге яшь хатыннарның кайберләре күбрәк әнә шундый ирләрне ауларга тырышалар. Бер дә булмаса, селекционерлык эшенә керешеп, ир-атны шундый нәселле итеп тәрбиялиләр: аны савып та булсын (сыер кебек), аңа атланып та йөреп булсын (ишәк кебек), шуның өстенә маңгаенда матур мөгезе дә булсын (башка хатыннар алдында мактанырга). Һәм ул хатыннар уңышка да ирешкәлиләр. Найла, мәсәлән, үзенең «уҗым бозавы»нда нәкъ шушы сыйфатларны үстереп җиткергән.

## 18. Хикмәтле талон

Данишев өчен авыр, мәшәкатьле командировка булды бу. Мурлыкинаның чыраен бүтән күрәсе килмәсә дә, тагын бер очрашырга мәҗбүр булды. «Жигули»ның номерын сорарга кирәк иде. Ханымны шәһәр милиция идарәсенә чакырттырды. Ләкин чибәр хатын машинаның төсен генә хәтерли алды.

«Крутушка» мажараларының герое — Цветованы үтергән, Аушева белән Гавашевны яралаган һәм, бәлки, Моратовка да аткан җинаятьчеме? Моны әле кистереп әйтү кыен, ләкин чын җинаятьчегә алып чыгачак сукмак шул тирәдәрәк булырга тиеш. Лейтенант моны күңеле белән сизә һәм шашкан кебек шәһәр буйлап йөгерә иде. Милиция идарәсеннән ул республика автоинспекциясенә юл тотты. Июнь аенда шәһәрдә яисә «Крутушка» юлында ак төстәге «Жигули» машинасы тотылмады микән дип белеште. Бөтен материалларны карап чыкты — тынычланырлык җавап ала алмады.

Театрда төшеп калган автобус талонын да әле тулысынча чишелеп бетмәгән табышмак дип саный иде Данишев. Дөрес, андагы адрес «Найла» дигән бер кыска гына җепнең очына чыгарга булышты...

Тишек талонның бөтен бәясе анда язылган шул адрес кына да булырга мөмкин иде, әлбәттә. Ләкин... Чү! Талон соңыннан гына килеп чыкты, ул кәгазь берлек эченә йомарланган иде, диде бит Нәгыймә апа. Әгәр болай булса... Автобустан төшкәндә, әйтик, контролер билет тикшерә башлый. Безнең пассажир каударланып кесәсенә тыгыла, кесәсендәге акча белән бергә талонын да йомарлый һәм, әлбәттә, аны таба алмый җаны чыга. Ул үзенең юл хакын түләгәнлеген яхшы белә, шуңа күрә контролер белән аяк терәп сөйләшә... Шул арада аңа квитанция язалар, яисә хәтта фотога да төшереп алалар... Ә бит шулай булуы да бик ихтимал!

Үзенең фаразын тикшереп карау өчен, көне буе Казанның троллейбус паркларын йөреп чыкты Нәҗип. Андый кешенең тотылуын хәтерләүче контролер яисә раслаучы документ табылмады.

Шәһәр транспортында июнь аенда тәртип бозган кешеләр турында белешү дә һичнинди нәтиҗә бирмәде. Дөресен әйткәндә, Данишев бу белешмәне аптыраганнан гына алган иде. Ниһаять, бөтен юллар бикләнде. Тотынып җеп калмады. Хәзер алга таба кармаланып кына барырга мөмкин.

Төшенкелеккә бирелгән тикшерүче гостиницага трамвай белән кайтырга чыкты. Салонда кеше аз иде. Төшүче, менүче күренми. Бер тукталышта гына, шыркылдап көлә-көлә, егет белән кыз сикереп менделәр. Буш урыннар күп булса да, нишләптер, Данишев янына ук килеп бастылар. Нәҗип йөзен тәрәзәгә таба борырга мәҗбүр булды.

— Ике генә талон сатмассыз микән, — диде егет, кулында вак акчаларын чылтыратып. — Минем автобус талоны бар да, трамвайныкы юк менә...

— Билет белән йөргәндә җайлырак иде ул,— дип белдекләләнде аның янындагы яшь кыз.

— Минем талоннарым юк шул, — диде Данишев.

Егет моны үзенчә аңлады.

— Безнең кебегрәк икән... Ярар, автобусныкын тиштерим булмаса. Дәүләткә барыбер бит. Әле өч тиенгә файдалырак та...

— Кара инде! — Үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде Нәҗип. — Ничек минем башыма килмәгән!

Егет белән кыз аңа сәерсенеп карап калдылар. Данишев урыныннан торып ишеккә йөгерде. Трамвай Куйбышев мәйданына килеп җиткән иде.

Автобус талонын бүтән транспортта да файдалану ихтималы Нәҗип өчен «ап-ачык — акылга сыймаслык» дигәндәй килеп чыкты. Соң булса да уң булсын: шушы хәл контролерлар белән тагын бер очрашу мөмкинлеге тудырды. Бу юлы инде — трамвай-троллейбус идарәсе контролерлары белән.

Июнь аенда билетсызлар витринасы өчен төшерелгән фотолар шактый иде. Аларны таратып салуга, лейтенант үз күзләренә үзе ышанмады... «куян»нар арасыннан аңа бик тә таныш чырай — Мәхмүт абзый өендә йөзгә-йөз очрашкан җинаятьче карап тора иде.

— Юк, ул түгелдер! — дип әйләндереп-әйләндереп карады Нәҗип. — Чынлап та шул үзе микәнни?!

Ул арада әлеге билетсыз кешене тоткан контролерны табып китерделәр.

— Без аны Кольцодагы тактага элеп куймакчы идек. Районнан килгән булып чыкты. — Контролер колак артын кашып алды. — Әллә Әлмәттән, әллә Бөгелмәдән инде. Без аның эшенә хәбәр итәргә булдык. Шуны сизгәч, миңа унлык төртергә маташты. Ә башта кыланмышы кырга сыймый иде. Билетым бар, әле арттырып та түләдем, фәлән-фәсмәтән, дип өскә җикеренде. Мин аны 2 нче маршрут троллейбусыннан элэктереп алдым. Студент-мазар булса бер хәл. Өстендә затлы кием, кыяфәте тук, кибән хәтле гәүдә үстергән... Ә культура юк кешедә... — контролер, гайрәте чигеп, җиргә төкереп куйды.

Күрәсең, эш нәкъ Данишев уйлаганча булып чыккан!

«Куян» турында мәгълүмат күп түгел, әмма инде бик аз да түгел иде. «Мревлиев Федор Николаевич, район башкарма комитетының көнкүреш хезмәте күрсәтү бүлегендә эшли», — дип язып алды лейтенант. «Бер үк шәһәрдә яшибез икән!»

Фотокарточкадагы Николай Федоровичны аның сөяркәсе дә таныды.

Шул ук көнне Данишев районга кайтып китте.

Озын юл аңа уйларын бер ноктага җыярга, алга таба исәп корырга мөмкинлек бирде. Мревлиевны кулга алырга әле иртәрәк булыр, дип уйлады лейтенант. Җинаятьне фаш итү җиңел булмаячак. Аның эзенә басу да әнә ничек озакка сузылды. Мревлиев, әлбәттә, бөтен гаепләрен күзгә карап таначак. Һич югы, башкаларга аударачак. Авылга, Мәхмүт абзыйга үзен, әйтик, Шпыру җибәрде, дияргә ихтимал. Цветованың үлемен дә шул ук Шпыруга, янсә Моратовка сылар. Ә ничек кире кагасың? Ничек дөресен исбатлыйсың? Шаһитлар кайда? Моратовның акылы сыекланды. Михаил Шпыру эзсез югалды, аны үтергән булулары да бар. Үзенең ерткыч җанын саклап калыр өчен бу бандит теләсә нинди юлга басарга мөмкин. Ул мүкәләп, түше белән шуышып булса да исән калырга тырышачак.

Кичен, кояш баеп барганда гына район милиция бүлегенә кайтып җитте Данишев. Гадәттә үзен тыныч тота алган начальник, аны күрү белән, түземсезләнеп урыныннан купты. Нәҗипнең сүзен ахыргача ук тыңлап та бетермичә, гасабиланып, кнопкага басты:

— Миңа Мревлиев Федор Николаевич турында кыскача информация әзерләгез әле.

Ике-өч минуттан шундый белешмә алып керделәр: Мревлиев Ф. Н. 1942 елда туган, өйләнгән. Көнкүреш хезмәте күрсәтү бүлегендә эшли, җеназа-күмү эшләре белән шөгыльләнә. Өй адресы: Яшь натуралистлар урамы, 3 нче йорт, «Жигули» машинасы бар.

Машинасының төсен ачыкладылар: ак икән.

Икенче көнне лейтенант көнкүреш хезмәте күрсәтү бүлегеннән белеште: безнең «зират башлыгы» чираттагы ялында, ике елныкын берьюлы алды, диделәр. Путевка буенча Казанга, санаторийга киткән икән.

Гавашевка һөҗүм булган вакытта да, Цветованың өе янган һәм Моратовны үлем хәлендә больницага озаткан көнне дә ул санаторийда булып чыга!

Вакыйгаларның мондый борылыш алуы Нәҗипнең күңелен төшерде. Акланырга шундый нык җирлек әзерләп куйганмы җинаятьче? Әллә без чыннан да ялгыштыкмы? Шулай да, кулга Мревлиевның фоторәсемен алып, тагын бер тикшереп карарга кирәк иде.

Лейтенант башта больницага юл тотты. Эт тешләгәч үзен Җамалетдин Силагаев дип белдергән кеше шул ук Мревлиев булмаганмы? Авыруларны кабул итү бүлегендә эшләүчеләр портретны әйләндереп-әйләндереп карадылар, ләкин анык кына берни дә әйтә алмадылар. Гавашев та гаепле кеше сыман аптырап калды:

— Шул үзе дип әйтеп булмый. Караңгы иде бит. Йөзен яхшылап күрмәдем. Тере килеш күрсәм — таныр идем... Җираф кебек озын ул.

Ә Моратов үзен бик сәер тотты. Фоторәсемне күргәч, ул агарынып китте, куллары белән стенага үрмәли башлады. Әйтерсең лә, аның йөзенә телен сузган агулы елан сызгырып килә иде.

Кайчандыр Шпыруны үзләренә сыендырган, аның әйберләрен ят кешегә биреп җибәргән карт белән карчык берничә рәсем арасыннан үзләренә таныш йөзне таба алмадылар.

Фотоларны участок инспекторы Шамовка күрсәткәч кенә, Нәҗипнең эченә җылы керде. Ул шунда ук Мревлиев портретын аерып алды:

— Менә ул! Силагаев үзе! Мин аны яхшы хәтерләп калдым.

Димәк, шушы шәһәрчекнең илле мең кешесе арасында без эзләгәне нәкъ шул бәндә?! Димәк, ул бу көннәрдә Казаннан кайтып йөргән!? Төннәрен үзенең кара эшен эшләгән дә, шома гына ычкынып, санаторий куенына яшеренгән?

Шул ук вакытта капитан Минаев та, Нәҗип тә яхшы белә: бу кадәресен ачыклаган тәкъдирдә әле Мревлиевның ялгыз карчыкны үтерүгә турыдан-туры катнашуын исбатлау мөмкин түгел. Үтерүдә гаепләү өчен кире кага алмаслык саллы дәлилләр кирәк.

## 19. Хата төзәтелергә тиеш

Бүген Минаев үзенең эш көнен сәгать җидедә үк башлады.

Берәр сәгатьтән Данишев килде.

Капитан, исәнләшергә дә онытып, сүзне сорау бирүдән башлады:

— Шпыруның ни өчен эзсез югалуы турында сезнең уйлап карагаңыгыз бармы, лейтенант?

— Күп уйладым, иптәш капитан. Баштан ук бер фикергә килгән идем. Хәзер шуңа ышана барам: аны, мөгаен, үтергәннәрдер. Моратовка һөҗүм итүләреннән соң, моңа бөтенләй шигем калмады.

— Дөрес. Дөрес, Нәҗип Гатауллович. Җинаятьчеләрнең берсе зирәгрәк булып чыккан. Үзенең иптәшләрен юк итеп, хәзинәгә ялгызы гына хуҗа булырга теләгән. Бер очтан үзенең эзләрен ераграк яшерү җаен да тапкан.— Капитан стенадагы Шишкин картинасы каршысына килеп басты, анда язылган фикерләрне укып баргандай, әкрен генә дәвам итте: —

Без шактый мәкерле җинаятьче эзеннән йөрибез. Иң мөһиме — ул беркемнең дә игътибарын җәлеп итмичә үтерә белә. Адәм баласы суга төшкән кебек юкка чыга. Газраил ул кешегә «гадәттәгечә» тәпиләп, я булмаса ак канатын җилпеп түгел, ә ап-ак «Жигули»да гына җилдереп килә... Аңа үзенең мәкерле эшен башкару өчен иң җайлы урын кайда булыр дип уйлыйсың? Минемчә, моның өчен идеаль шартлар — теге дөньяга иң якын торган урында. Әйе, әйе! Зиратның үзендә!— Капитан бүлмә буйлап тәрәзәдән ишеккә таба йөреп килде.— Әмма шунысы да бар: кешене бу рәвешле юк итү өчен газраил кем сурәтендә пәйда булырга тиеш?.. Минемчә, зират хуҗасы кыяфәтендә. Менә шул ук Мревлиевны алыйк. Аның кушуы буенча, әйтик, зиратта, бөтен дөнья күз алдында, рәсми рәвештә чокыр казып куялар. Ләкин... Ул чокырга кешене законлы рәвештә, бөтен шартын китереп күмәләрме, әллә юкмы — моны беркем дә белми. Каберләрне соңыннан ревизия үткәрелми. Үле җаннарны тикшереп кабул итүче дә юк. Кыскасы, дөнья рәхәте! Үзең теләгән кешене алып кер дә аллага тапшыр.

— Үзен зират капкасына таба өстери башлагач, җинаятьченең корбаны берни дә сизенмәс микәнни?

— Ул анда барып җиткәнче үк башына сугып миңгетелгән яисә үтерелгән булырга мөмкин. Әзер кабергә ташлап күмәсе дә, түбәсенә табличкалы тәре кадап куясы гына кала. Эшең бетте, кодагый... Менә шулай, иптәш лейтенант. Ә бәлки, Шпыруны ул алдап алып баргандыр. Урланган хәзинәне фәлән төшкә яшердем, әйдәле, шуны барып казып алыйк әле, дигән булыр... Һәм алтын-көмеш урынына тегесенең башына тимер таяк эләккән...

Минаев яшь тикшерүченең алдына ук килеп басты, аңа сынаулы караш ташлап, әкрен генә әйтеп куйды:

— Әгәр дә мәгәр Шпыруны зираттан таба алсак — үтерүче тәгаен билгеле булачак.

Капитанның карары ачык иде: хәзер һич тә кичекмәстән «Мревлиев хуҗалыгын» карап кайтырга кирәк. Бер минуттан дежурный кереп: «Машина әзер», — дип хәбәр итте.

Зиратка юл тоттылар. Данишев, зират дигәч тә Цветованы каберennән кузгаткан төнне исенә төшерде. Уй-тойгылар бүген дә нәкъ ул чактагы кебек авыр, бөтен тәнне киеренке халәт биләп алган. Көннең дә чырае караңгы. Болытлар киезләнгән мамык кисәкләренә охшап, оешоеш, йөнтәс булып тора. Кояш кына, шул болыт кисәкләре артында томаланып калырга теләмичә, әледән-әле җир өстенә үрелеп карый. Аның бер көлтә нуры сирпелүгә, табигать җанланып, бөтен төсләре белән балкып җавап бирә. Шаулатып кошлар сайрап ала, су өсләре көмеш көзге төсле яктырып китә. Суы чәчәк аткан иске сай күл генә зират капкасы төбендә һаман йокымсырап ята.

Арматура чыбылдыкларыннан ябыштырып ясалган тимер капка икеләй ачып куелган. Кайсыдыр наяны, эч пошканнан, тимер баганага «белдерү» язып ябыштырган:

«Рәхим итегез! Каберстан — кунакханә түгел: монда буш урыннар сезгә дә җитәрлек!»

Шушы язуны кычкырып укыган шофер төксе генә өстәп куйды:

— Район философы! Бәлки, инде үзе монда килеп ятарга да өлгергәндер.

Ә бит башкача әйтергә дә мөмкин булыр иде, дип уйланды Минаев. Мәсәлән, болай диярга: «Хөрмәтле гражданнар! Әгәр сезне ахыр чиккә җиткән комсызлык, шәфкатьсезлек басып китсә, көндәлек ыгы-зыгыдан, нужа куудан арына алмасагыз, дөньяның зират дигән бер почмагын ешрак искә төшерегез. Зиратка күңел бушатыр өчен дус-ишләр янына, ресторанга яки кино-театрга барган кебек килеп чыгыгыз. Әлбәттә, биредә сезне келәм җәелгән иданнәр, мул табыннар, затлы әчемлекләр

каршы алмас... Аның каруы: мал малга житкәнче, газраил җанга житә дигән сүзләрнең мәгънәсе турында уйланырсыз; күңелегез тулып, андагы пычрак-юшкын юыла башлар; дөньяның матурлыгын, яшәүнең кадерен, бәхетнең кыска гомерле булуын ныграк тоярсыз».

...Аллея буйлап зиратның түренә үттеләр. Ике яктан да балалар караваты кебек сирәк рәшәткәле чардуганнар тезелеп киткән.

— Цветова кайсы көнне үтерелгән әле? — дип сорап куйды Минаев.

— 25 июльдә. Экспертиза шулай дип билгеләгән.

— Димәк, безгә дә шул көннән башларга кирәк. Бүтән бөтен вакыйгалар аннан соңрак булган...

Капитан якындагы һәйкәлләргә, тәреләргә күз салып алды:

— Тикшерүне менә шуннан, уң як рәттән башлагыз,— дип күрсәтте. — Монда июль ахырыннан август уртасына кадәрге мәрхүмнәр күмелгән.

Зиратта төзелгән исемлекне район загсындагы документлар белән чагыштырырга кирәк иде. Минаев бу эшне Нәҗипкә тапшырды.

...Менә хәзер лейтенант үзе загс кәгазьләрен актара, ә күз алдында тимер чардуганнар биешә, башында әллә нинди уйлар бөтерелә.

Адәм баласының өченче туен — якты дөньядан күчүен дә загс үзенең хәтеренә язып куя, шул хакта махсус таныклык бирә. Кеше китә — аның эшләре, балалары кала, үлеме турында таныклыгы кала...

Нәҗипнең кинәт авызы кипкән кебек булды. Урыныннан торды. Су сорады. Аны көтелмәгән бер факт тетрәндереп җибәрде. Зираттагы каберләр саны үлем турындагы таныклыклар саныннан күбрәк иде... Су эчте. Тагын санады. Юк, һаман бер кабер артыграк чыга.

Бүлмәдә үзалдына нидер сызгалаган булып, әмма керфек астыннан гына Данишевның һәр хәрәкәтен күзәтеп яссы түшле бер чандыр кыз утыра иде.

— Таныклыкларны теркәү журналы кайда икән? — дип сорады Данишев.

Кыз журналны китереп бирде. Бер кабер — Челидов П. Е. дигән мәрхүм — анда да искә алынмаган булып чыкты.

— Әйтегезче, — дип тагын кызга эндәште лейтенант, — журналга язып куйганда, ялгыш берәр кешенең исеме төшеп калырга мөмкинме?

— Андый хәл була алмый. Һәр фамилия документ дигән сүз. Күрәсездер бит, һәр фамилия алдында туганнарының яисә якыннарының имзасы тора. Әгәр без онытсак, барыбер алар искә төшерәчәк.

Данишев милиция бүлегенә әнә шундый хәбәр алып кайтты.

...Кичкә таба һавадагы болытлар югара һәм җәелә төште. Аларны җил агымы котылгысыз бер юнәлештә куа иде. Шушы тотрыксыз соры катлам артыннан үҗәтләнеп ай карарга тырыша.

Айга ымлап:

— Лампаның керосины бетеп килә, егетләр. Аңа гына ышанып тору килешмәс, — дип шаяртты капитан Минаев.

Тәресе астына «Челидов П. Е.» дип язылган шикле калкулык тирәсен милиционерлар уратып алды. Аккумулятор белән яктырту урнаштырдылар. Кабер өстенә унлап кеше җыелды: уголовный розыск хезмәткәрләре, суд-медицина эксперты, фотограф, прокуратура вәкиле... Гүрдән Михаил Шпыру гәүдәсе һәм таланган байлыклар килеп чыгар дип өметләнәләр.

Дәшми-тынмый гына казый башладылар.

Чардуганнар, алар өстендә һәйкәлләр һәм тәреләр, караеп торган өрәңа калкулыклар, теләсәң-теләмәсәң дә, яшәү һәм үлем турында уйларга мәҗбүр итә икән. «Үлем — үзенең асылында бер чиктән икенче чиккә ташлана торган каршылыклар берлеге, — дип уйланды Минаев. — Ул карун — кешедән бөтенесен берьюлы тартып ала; ул юмарт — беркемне дә онытмый, һәркемгә үз өлешен алып килә; ул рәхимсез — кадерле кешеләребезне алып китә тора; ул шәфкатьле — дошманнарыбыздан мәң-

гегә коткара; ул дәһшәтле — аннан падишаһлар да курка; ул көчсез — җирдәге тормышны юк итә алмый...»

Казучыларның дәррәү җанланып китүе капитанны фани дөнья мәшәкатьләренә кайтарды. Табут капкачына төшеп җиткәннәр икән...

Ә бит табут булмаска тиеш иде! Җинаятьче үзенең корбаны өчен бөтен шартларны көйләп азапланырмы!? Табут ясату үзеңне үзең фаш итү белән бер булачак бит. Монда нәрсәдер аңлашылып җитми.

Минаев әкрен генә лейтенантның колагына пышылдады:

— Нәҗип Гатауллович, сез анда... загста... бутамадыгыз микән?

Әмма начальникның шиге дөрескә чыкты: табутта чал чәчле, озын буйлы бер карт ята иде.

Әллә артык борчылудан, әллә инде зират тәэсиреннән, Нәҗипнең башы әйләнеп китте, тын алулары авырлашты. Ул якындагы бер агачка сөялде.

Кемдер аңа тәмәке сузды:

— Тартып җибәрегез. Җиңелрәк була ул.

Лейтенант тирән итеп бер суырды һәм шунда ук булыгып-булыгып йөткерә башлады. Күзеннән яшь атылып чыкты.

Тәмәке бирүченең канәгать тавышы ишетелде:

— Тартмый торган кешегә дә әллә нигә бер төтен тәмен тоеп карарга кирәк. Мондый вакытларда — бигрәк тә.

Табуттагы чал чәчле картны фотога алгач, кабер өстен яңадан элекке хәленә кайтардылар. Барлык эш тәмамланганда, ай инде зират агачларының куе ябалдашлары артына төшеп бара иде.

Ул арада лейтенант Данишевка да хәл керде. Ләкин, авыр уйларын никадәр генә куарга тырышмасын, алар, әйтерсең лә ябышкак пәрәвез җебе кебек, йөзгә, бөтен тәнгә сырыша гына бара иде. «Әллә табутны алыштырдылар микән? Ничек килеп чыкты соң әле бу? Чынлап та, безне ялгыш юлга кертеп җибәрделәрме?..»

Икенче көнне иртән начальник кабинетына кергәндә генә аның кәефе бераз яхшырды. Капитан Минаев: «Җинаятьче, мөгаен, кабер өстендәге язуны алыштырып куйгандыр», — диде. Лейтенант та шундый ук фикергә килүен әйтте.

Хәзер әлеге идеянең ни дәрәҗәдә чын булуын тикшерәсе бар иде. Димәк, мәгълүматлар җыюны дәвам итәсе һәм беренче чиратта — Челидов фамилиясе астына кемнең күмелүен ачыклыйсы...

Кабер өстендәге язуларны теләсә ничек эвеш-тәвеш китерү җиңел түгел. Моны ялгыз-ятим кешеләр күмелгән очракта гына эшләп була. Җинаятьченең дә әнә шул юлны сайлавы мөмкин, дип уйлады Минаев.

Лейтенант Данишев белән уголовный розыск инспекторы Чаев каберләрне тану эшен оештырдылар. Бер студент кабере белән бераз мәшәкать килеп чыкты — туганнары бик ерак шәһәрдә яши икән.

Ә Нукимов дигән икенче берәү гүр иясе булганчы соңгы елларын картлар йортында яшәгән. Бер туган-тумачасы да юк икән. Картлар йортында аны, озын буйлы, чал чәчле бабай иде, дип искә алдылар.

«Челидов тәресе астында әнә шул карт ятмыймы икән?» — дип уйлап алды Нәҗип.

Нукимовның кая күмелгәнен берәү дә юньләп белми булып чыкты. Зираттагы бер кабер өстендә «Нукимов» дигән билге бар-барын. Аңа ышансаң, озын буйлы, чал чәчле мәрхүмнең гәүдәсе Челидовтан әллә ни ерак түгел, карагай янындагы бер кабердә булырга тиеш. Ләкин әгәр ул, үз урыныннан кубып, чынлап та, ниндидер билгесез Челидов кабере «кереп яткан» булса?.. Ә аның законлы урынына әлеге дә баягы Шпыруны «прописка»га кертсәләр?..

Берничә көннән прокурор, тикшерүче Нуркаев, капитан Минаев, Данишев, шулар өстенә берничә милиционер һәм пүнәтәйләр тагын бергә җыелдылар. Бу юлы төн болытлы, зиратта дөм-караңгы иде.

«Нукимов кабере» дип билгеләнгән урынга килеп басу белән, Нәҗип,

нәзер әйткән сыман, үз-үзенә сүз беркетте: «Әгәр бу эшне очлап чыга алсам — Асиягә тәкъдим ясыйм. Каршы килмәс бит?..»

Бер метр чамасы казып төшкәч, көрәкләр «чык» итеп каты әйбергә килеп бәрелде. Тагын бераз азапландылар. Кабер төбеннән каты калай белән капланган зур чуен килеп чыкты.

Чуенның капкачын күтәрделәр. Аның эченә салынган төргәк шактый саллы иде. Кат-кат төрелгән төенне сүтеп җибәрделәр. Кесә фонарьлары яктысында очкыннар чәчеп, күзләрне камаштырып асылташлар, алтын брошкалар, алкалар җемелдәде...

Теләгенең болай тиз кабул буласын көтмәгән иде Нәҗип. Яшь лейтенантны беренче зур уңышы белән котлый башладылар. Ул кинәт кенә игътибар үзәгендә калуына уңайсызланды, үзен ничек тотарга белми аптырады: «Мин башладым гына... Аны менә сез... тагын башка егетләр...»— дип сөйләнде.

Данишевның уңышы өчен барысыннан да ныграк аның начальнигы сөенде. Зиратта Михаил Шпыру гәүдәсе табылмаса да, капитан Минаевның ышанычы нык иде: җинаятьчене кулга төшерергә дә инде ерак калмаган булырга тиеш.

Капитан бу кабердән Шпыру гәүдәсе килеп чыкмауга артык көенмәде дә. Җинаятьченең гадәтләрен ул яхшы ук өйрәнеп өлгергән иде. Хәйләкәр һәм мәкерле бәндә булырга тиеш. Сак һәм уйлап эш итә торган юлбасар. Михаилның гәүдәсен дә шуңа күрә бик ерак яшергән. Бер үк чокырга урланган хәзинә белән кеше мәетен дә салырга башына тай типмәгән аның! Таланган, яшергән өчен берничә ел рәшәткә аша карарга туры килсә, кеше үтергән өчен — тимер рәшәткәне өстенә чардуган итеп корачаклар...

Студент каберен тану хәстәренә ныклап керешергә өлгерә алмый калдылар. Мревлиев ялдан кайтып, яңадан тыныч кына эшли башлаган иде.

Капитан Минаев белән тикшерүче Данишев кечкенә генә хәйлә кордылар. Загста эшләүче бер хатынга — Мревлиев белән сөйләшеп-аралашып йөри торган кешегә — «сер итеп кенә» шундый хәбәр җиткерелде: имештер, үткән елның июль-август аенда үлгән кешеләр белән милиция бик кызыксына; имештер, тегеләрнең каберләрен кире казып карамакчы булалар икән...

Мревлиев, комсыз балык кебек, күз ачып йомганчы бу җимгә капты. Шул ук кичне, эңгер-меңгердә, үзенең ак «Жигули»ена утырып, зиратка килде. Тирә-юньдә кеше юклыгына ышангач, машинасыннан көрәк алып, «Нукимов кабере» өстендәге туфракны тиз-тиз актара башлады. Ун-унбиш минут дигәндә, шабыр тиргә батып һәм ялт-йолт карана-карана зур чуенны казып чыгарды. Аны брезент капчыкка урнаштырды һәм... шунда гына үзен урап алган милиционерларны күрде.

Бандит бер генә мизгелгә каушап калды, аннары кесәсеннән пистолет йолкып алды, тик атарга өлгермәде: кулына суктылар.

Коралны җирдән инспектор Чаев иелеп алды.

— Уһу, минем пистолет та табылды. Ул, шәт, сиңа бүтән кирәкмәс инде...

— Әнә нинди дуамал бит ул, — дип өстәде Минаев. — Кулына пистолет эләктеме, хәзер атарга тора. Моратов Сәмәтны да чак кына теге дөньяга җибәрмәгән...

Җинаятьче шунда ук бөрешеп куйды, агарынды. Капитан, сүз уңаеннан сораган кебек кенә итеп:

— Карале, син Мишканы кая күмдең?— диде.

— Андый кешене белмим, — дип ырылдады Мревлиев.

Кулына богау салып, җинаятьчене аллея буйлап алып чыкканда, алданрак атлаучы капитан тагын бер кабер янына туктады.

— Федор Николаевич, — диде ул Мревлиевның күзләренә туры карарга тырышып, — синең монда тагын әйләнеп кайтасың киләме?

— Кемнең... Кемнең монда киләсе килсен...
— Алайса эшне бетереп китик. Син яхшы беләсең, менә бу — суга батып үлгән студент каберe. Шуннан үзеңнең җан дустың Мишка Шпыруны үзең казып аласыңмы, әллә безгә калдырасыңмы?..
Мревлиев сыгылып төште. Аның кул-аяклары үзен тыңламый, тәне тотлыга иде. Көч-хәл белән: «Үзегез казыгыз...» — дип аңлата алды.
Соңыннан, сорау алу вакытында тикшерүчегә ул:
— Әйт әле, миңа килеп тоташкан җеп очын сез кайдан таптыгыз? — диде.
— Эт ярдәм итте. Аннары — театр билеты... — диде Данишев.
Җинаятьченең йөзе чалшаеп китте.
— Ул азманны мин алып кайткан идем бит. Аннары Цветовага саттым. Каракларданн курка иде кортка. Түтәй теге дөньяга киткәч, агулаган идем мин ул этне. Үлмәде. Терелде бәдбәхет! Бер елдан соң кайдандыр килеп чыкты. Бер тапкыр өйгә ут төртәм дигәндә миңа да килеп ябышты.
— Җинаять урынында шундый эзләр калуын сез нишләп бер елдан соң гына искә төшердегез?
— Соңгы арада никтер эч поша башлады. Карчыкның каберен, өен барып карарга булдым. Каберен күргәч кот ботка төште: казыганнар! Димәк, эзли башлаганнар. Моны җүләр дә аңларлык. Ә минем эзгә төшерсә — шул эт төшерә дә, аны саткан картлач... Өстәвенә — Моратов Самат, бердәнбер шаһит, теләсә кайчан сатып әчәргә мөмкин... Шуларны дөмектерергә кирәк иде... — Мревлиев, бик каты теше сызлаган кебек, яңагын тотып, улап җибәрде.— Былтыр соң! Былтыр мин эзне чиста гына югалта ала идем бит. Чуендагы миллион белән җырлап яшисе идем мин. Эх, исәр, дивана, тинтәк! Мал кадерен беләм, янәсе. Бөртекләп тотам. Ул миңа үлгәнче җитәрлек иде! Ә хәзер — крышка. Шулдыр инде ул: баерга киткән түтекәй үлеп кайта, ләң-ләң... — Җинаятьче, акылга җиңеләеп калган кебек, үзалдына такмаклавында булды. — Ышанган тауда киек юк! Бөтенесе дә тынды, узды дип ышанасы калмаган... Тынлык — давылдан әшәкерәк икән...
— Сез, гражданин Мревлиев, үзегез дә белмәстән, иезуитлар принцибын кабатлыйсыз һәм үзегез дә шул принципка ябышып яшәгәнсез. Алар да бит: «Тынлык — теләсә нинди давылдан да куркынычрак һәм начаррак; иң хәтәр дошман — дошманнарның бөтенләй булмавы», — дигәннәр.
Җинаятьче, чебен куган кебек, кулын гына селтәп куйды: «Син, борын астың кипмәгән малай, яшәү рәтен беләсеңмени», янәсе.
Данишев, аның селтәнүенә игътибар итмичә, үзен күптәннән борчып йөргән сорауны бирде:
— Хәзинә турында кайдан белгән идегез?
Мревлиевка хәзер нинди сорауга җавап бирсә дә барыбер иде. Сорасыннар гына, сөйләргә ирек кенә бирсеннәр!
— Мин бит Цветовага чыбык очы булса да — туган тиешле кеше. Аның бертуган апасы — Анна әби аша — минем әни ягыннан... Менә шул... Әбидән хат калган. Минем аны табуыма ике генә ел әле. Хатны бай үзе язган. Аршев. Ул Анастасия Федоровнаны бик яраткан икән...
— Хәзинә турында хатта турыдан-туры әйтелгәнме?
— Турыданмы, кыектанмы?.. Шыр ялангач чыгып качуы турында язган. Алтын-көмешен дә алып китә алмавы турында... Мин менә шуннан шөрепләремне эшләтеп карадым. Ни дисәң дә, вуз бетергән кеше бит. Хәзинәсен күмеп калдыргандыр дип чамаладым. Ул шулай булып чыкты да. Ә теге саран кортка өенә якын җибәрмәде. Мин аның кәкрәйгәнен көткән дә булыр идем. Кемдер әйтте: имеш, йортны сүтәргә тиешләр, урынына кинотеатр салалар икән, дип. Менә шул... Көтеп торып булмады инде...
Данишев җинаятьчене алып китәргә кушты.

Участок инспекторы Шамов шалтыратты. Шәһәр читендәрәк бер кешенең соңгы арада үрдәк-тавыклары югала башлаган икән. Аптырагач, яшелчә бакчасына капкын куйган. Шул капкынга бер эт эләккән. «Бозау хәтле! Кыргыйланган. Беркемне дә якын китерми, — диде Шамов. — Әле генә мылтык алып килергә киттеләр...»

Данишев эшне тиз генә Минаевка аңлатып, рөхсәт сорады да, начальник кабинетыннан ук кебек атылып чыкты. Дежур «Москвич»ны алып, шәһәр читенә, Шамов әйткән адрес буенча җилдерде.

...Яшелчә бакчасына шактый халык җыелып өлгергән иде. Капкын хуҗасы ике көпшәле мылтыкны корып бетерүгә, бөтенесе, җил белән өргәндәй, читкәрәк тайпылды.

Этне шактый ярсытканнар. Ул йоннарын кабарткан, үзенә мылтык төбәгән кешегә әледән-әле зур казык тешләрен күрсәтеп, ажгырып тора. Эшнең ни белән бетәсен яхшы чамалый Барс. Ул әле авылда, сарык көтүе артыннан йөгереп йөргән бер көчек чагында ук, каеш тагылган бу таякның ничек итеп ут төкергәнен һәм көтүгә ябышкан ач бүреләрнең шуннан соң ничек итеп тынсыз калганын хәтерли иде.

Хәзер менә нишләптер кешеләр аның үзенә бүре итеп карыйлар. Барс аңлап тора: болар — явыз бәндәләр. Аның бөтен бәла-казалары да шундый кешеләр аркасында башланды. Ләкин Барсның язмышка һаман буйсынасы килми, үлемнең тагын бер һәм, күрәсең, иң соңгы кизәнүенә риза булып торасы килми. Нинди гарьлек: ул бу кешеләргә үзенең үрдәк-тавык урлап йөрмәвен дә аңлата алмый. Бирегә Барс бары кунып чыгарга гына кергән иде бит. Нишләптер, шәһәр читендәге шушы урын аның авылдагы туган йортын һәм бәхетле эт тормышын исенә төшергән иде...

Милиция «Москвич»ы яшел төскә буялган биек капкага терәлеп үк килеп туктады. Нәҗип машина ишегеннән туп-туры капкага ташланды. Мылтык төзәп торган ир-атны күреп, ул йөрәк яргыч тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Тукта-а-а-гы-ыз! Ниш-ли-и-сез! Тукта!

Әйтерсең, иң якын кешесенең тормышы куркыныч астында калган иде.

Теге ир аптырап, башын борды һәм, милиционерны күреп, мылтыгын түбән төшерде.

— Ә нишләтәсең аны, — дип сөйләнде хуҗа. — Әнә бит ул нинди җанвар... Башыңны тешләп өзәр...

Нәҗип овчаркага таба китте. Бер адым кала туктады.

— Ба-арсик! Ә мин сине күптән эзлим. Син каядыр китеп югалдың.

Эт үзенә исеме белән дәшкән кешенең мәрхәмәтле күзләрендәге тәвәккәл карашын тоеп, ырылдавыннан туктады. Аннары арт аякларына утырды да шыңшый башлады.

Данишев овчарканың тагын бераз тынычланганын көтте.

— Барсикның аягы авырта. Авыртамы? Авырта-а. Акыллы-ы бит ул, әйбә-әт бит ул. Я нишлибез инде, аягыңны капкыннан ычкындырабызмы? Ычкындыра-а-быз. Хә-ә-зер ычкындыра-а-быз... — Кулын әкрен генә капкынга таба сузды.

Эт, авыртуын сиздерергә теләмәгәндәй, башын читкә борды. Нәҗип шул арада сак кына капкынны ачты. Барс сикереп китәргә талпынган иде, әмма чинап, яңадан арт аякларына утырды.

— Ә син, Барсик, алай кинәт кузгалма. Әкренләп кенә йөреп кара. Төзәлер аягың. Хәзер икәү миңа китәрбез, син миндә яшәрсең. Ризамы шуңа! Дәшмисең — димәк, ризасың. Мин сине бер яхшы кеше белән таныштырырмын. Аның исеме Асия. Аннары без өчәү бергә яшәрбез: син — Барсик, Асия апаң һәм мин.

## Шамил Маннапов

# КҮҢЕЛЕМӘ КАГА ИГЕН КЫРЫ

### Мөлдер-мөлдер

Каерылып уңды быел ашлык,
Күңелләргә кага дулкын-шатлык.
Чү, һавада куера кара болыт:
«Мин үстердем аны, тимәгез!» — дип,
Күз яшьләрен түгә торып-торып.
Иген иелеп җирдән ярдәм сорый:
«Бир син, диеп, безне кешеләргә.
Комбайнда җырлап өйләник тә,
«Әпипә»гә биик көшелләрдә».

Юл кырыйлап таптап, сытып, изеп,
Машинасы белән узган кемдер.
Башаклардан бөртек — мөлдер-мөлдер...
Бу бөртекләр инде җиргә түгел,
Ялваралар кебек кешеләргә:
«Тик сез генә, тик сез генә безне
Кайтаралыр идегез көшелләргә.
Адәмнәрне сугыш изгән чакта
Күбрәк иде безне аяучылар,
Ялан тәпи килеш камыл ерып,
Берәмтекләп җыеп-санаучылар.
Тамаклары туйды...
Тик карагыз:
Без бит бөртек кенә түгелдер гел,
Тилмерешеп ачтан үлгәннәрнең
Күз яшьләре шулай — мөлдер-мөлдер...»

### Мишәрләрем

Туган ягым төсе — мишәрләрем,
Юлга чыксам, атым җиккәннәрем,
Юлдан язсам, тотып кискәннәрем,
Яхшы чакта — балым, шикәрләрем.
Ярсыганда дисәң, телегез — әрем.

Туган ягым төсе — мишәрләрем,
Туры әйтеп янган исәрләрем,
Наниларым, канәт, әзиләрем [1],
Онытылмый шул бер дә үткәннәрем —
Кулыгызга тотынып үскәннәрем,
Тормыш фәнен сездән өйрәнгәнем.
Үзем эшләп алган әпәй төмен,
Ишетәсезме, җырга гел кертәмен?..

Туган ягым төсле мишәрләрем,
Күңелемдә һәрчак исәннәрем,
Каты телле йомшак күңелләрем,
Наниларым, канәт, әзиләрем,
Сезнең белән үтсен гомерләрем!

## Имәнсәрдә ялгыз имән

Шагыйрь Тәүфикъ Камалиев истәлегенә

*Сабыр канатларым сынмас, диеп,*
*Кайчан гына берга җырлап бардың.*
*Кем уйлаган барыбыздан элек*
*Сынар диеп сабыр канатларың.*

Безне яшьли сугыш давылы суккан,
Азаябыз... шуңа күрәдер.
Япь-яшь килеш ауган яшьтәшләрем
Моңсуланып төшкә керә гел.

Калкулыкта урман шаулаганда
Имәнсәрдә ялгыз имәннең
Нигә шулай моңсу-тын торуын
Беләм инде хәзер, беләм мин...

Кадере дә аның зуррак юкса,—
Күләгәсе тансык һәр даим,
Тик шулай да
Бер туфракта үскән иңдәшләрен
Сагынадыр ул, сагына, мөгаен.

Ә якында япь-яшь урман шаулый,
Күкрәк ачып язгы җилләргә.
...Сугыш давылы кабат дуламасын,
Сабырлыклар иңсен илләргә.

## Охшашлык

Күз алдыма,
Бал кортына охшап,
Килә дә бит баса синең сының:

[1] Нани — әнем, канәт — иркәләп эндәшү, әзи — абый мәгънәсендә.

Бал кортыдай үзең кечкенә дә,
Төш кенәсең, тырыш авыл кызы.
Шул кортларның
«Без-з! Без-з-з!!» — дигән телен
Ничек кенә аңлыйсыңдыр дисәм,
Син үзең дә шушы бал кортлары —
Изге җаннар нәселеннән икән.

Сугыш елларының ачылыгы
Бал телеңне шулай чагар иткән.
Үткен угың дошманнарга — агу,
Ә дусларга — шифа, дәва икән.
Сансызланып балыңа кагылып кара,
Саксызланып җаныңа кагылып кара,—
Үзең үләсеңне белсәң дә,
Чагып үләрсең күк үлсәң дә...

## Бурыч турында

*Я в долгу...*
В. Маяковский.

«Бирәүгә дә бурычым юк, дидең,
Шулай яшәү тиеш дөньяда!..» —
Ышанып әйткән шушы сүзләреңә
Җавап тапмый тордым бер ара.

Әйе, бәлки, әҗәтләрең юктыр,
Ихтирамга лаек бу ягың.
Ләкин акча белән хисапланмас
Бурычларны кая куясың?

Бу дөньяга, әйтик, туган өчен
Ата-анага бурыч турында
Онытмадык микән?
Илне имин
Кем тапшырды безнең буынга?

Алар...
Алар яшел ябалдашка
Сутын биргән тамыр шикелле,
Бу дөньяны тагы да гүзәлрәк
Итсеннәр дип безне үстерде.

Рәхмәт барлык яхшы кешеләргә,—
Иңнәренә тотынып шуларның,
Яшьлек үрли һаман югарыга,
Галәмнәрдән күренә нурланып.

Һәм алардан башка барып чыкмый
Башкарганда бирәр зур эшне:
Елмаюы белән җылытып торган
Сөйгәннәргә дә без бурычлы.

Безгә бурычлылар бармы — белмим,
Без бурычлы, дускай, күпләргә.
Ул бурычны кирәк булыр әле
Гомеребез буе түләргә...

Ә син, минем бурычым юк, дисең,
Бүтән әйтмә болай беркайда.
Бурыч булмый икән,
Безгә нигә
Яшәргә соң фани дөньяда?!

## Чыгымчы ат уе

«Чыгымчы ат, дисез,
Чыгымчы ат!» —
Камчылап та мине,
Чыбыркылап.
Күзегездә тулы
Ачу-чаткы,
Бусы — барыннан да
Яман камчы.

«Чыгымчы ат!» — дисез,
Сүгеп кат-кат.
Ник мин шундый —
Бармы уйлаган зат?

Аркамнан бер сөеп,
Ялым тарап,
Бер алсагыз икән
Күзләремә карап,
Аңлар идегез — нигә
Шундый холык миндә...
Хәер, ат җанлылар
Моны күптән белгән:
— Атны кыйнап куа,
Ку син солы белән!..

## Еллар узган саен...

Улы инде егет булып килә...
Ә ул аны һаман төшендә
Сабый итеп күрә:
Еламсырап,
Көтә, имеш, тәрәз төбендә.
Әйе, инде шактый еллар акты
Оясыннан чыгып киткәнгә.
Тәкәбберлек — горурлыгы тотты
«Кайтыйм мәллә,
Барыйм мәллә?» дигән көннәрдә.

Сагынулары чиктән ашкан чакта
Шулай да ул килми калмады.
Килгән саен күрде: көнләп түгел,
Айлап үсте аның малае.
Үскән саен ләкин әтисеннән
Ераклаша барды-барды да,
«Әттә, китмә!» — дигән чагы гына
Торып калды аның җанында.

Күрешалмый сагынып узган еллар,
Атылудан калган явыз эттәй,
Сузылып яткан ике арага.
Шул араны узып чыгыйм дисәң:
Сикереп торып ябыша таларга...

Ә сабые һаман көтә аны,
Тәрәзәдән әнә күренә,
Көйгән иреннәре: «Әттә...» — дия,
Күзләреннән яше түгелә.

Еллар узган саен шул төш керә.
Кергән саен йөрәк өзелә...

## Энекәшләргә

Бәхәсләшмим, күбегез узды инде
Буй белән дә, уе белән дә,
Тик без сезнең өчен барыбер «абый»,
Тартынмагыз абый дияргә.

Олыларны без дә олылыйбыз,
Алар безне кече итсәләр,
Үпкәләш юк, сөенәбез генә
Якын күреп: «Энекәш...» — дисәләр.

Безнең абыйларның бик күбесе
Кайталмады сугыш кырыннан.
Гомер диген, инде кай арада
Аларның да яшен узылган...

Әмма... юк-юк, күңел риза түгел
Корбаннардан олы булырга.
Безне яклап, илне саклап калган
Абыйлар! — дип,
Яд итәрбез гомер буена...

Абыйлары булганнарга хәтта
Картаю да,
«Карт аю» да кыймый тияргә.
Энекәшләр, нинди бәхетле сез,—
Сезгә без бар абый дияргә...

## Иген кырың әгәр булмый икән...

Иген кыры — кеше гомередер ул...
Язын — сабый чагы.
Хәтфә кебек уҗым-чәчләреннән
Җилләр тарый аның.

Җәен уйный, дулкынлана басу,—
Яшьлек дәрте анда.
Күз яшедәй чыклар була таңда,
Гыйшкы бардыр җаңда.

Көзен инде сабырланган-тынган —
Башын түбән иеп,
Каушуларны сабыр гына көткән
Җиткән кызлар кебек...

Иген кыры — кеше гомередер ул,
Моңы җанны били.
Буразнада аунап үскән чаклар
Онытырлыкмыни?!

Җил кузгаткан иген дулкыныдай
Йөгереп узды яшьлек.
Без дөньяга: «Бар ул мәхәббәт!» — дип,
Шул кырлардан дәштек.

Шул кырларның йөрәк тибешеннән
Мин ритмны сиздем,
Тургайларның дәртле җырын тыңлап,
Шигъриятне сөйдем.

Үземнең дә күңел төпкеленнән
Ташып чыкты җырлар.
Күңелем иркенлеккә шулдыр сәбәп:
Анда — басу-кырлар.

Шуңа микән дөньям ямьле иткән
Серле таңнарым күп.
Иген кырың әгәр булмый икән,
Гомерең заядыр күк...

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

Яз, ни язсаң да, синең
бар — язганыңның нашире...

Г. Тукай. «Татар мөхәрриренә», 1910.



«Бәрадәран Кәримовлар матбагасы» типографиясе (хәзерге Киров урамы, 66 йорт). Биредә Тукай еш булган.

Татьяна Зуева рәсеме.

## Фәннур Сафин

### ТУКАЙ АЭСта

Тукай килде Кама Аланына,
«Әссәлам!» дип әйтте шикелле.
Яктылыкны ерак тарихлардан
Туган йортка гүя китерде.

Тукай кайтты!
Татар АЭСында —
Тау башында — шигырь бәйрәме.
Төзүчеләрне ул биеклеккә,
Яктылыкка таба өйдәде.

Бу егетләр баһадирдай көчле,
Таң нурларын җыйган кызлары.
Алар бүген Тукай йөрәгеннән
Килгән моңны гүя тыңлады.

Атомнардан якты алу өчен
Көрәш барган чакта илемдә,
Җиң сызганган егет һәм кызларның
Җан балкышы күчте шигырьгә.

Рәхмәт, Тукай, син бит, бары син бит
Тәрәзләрен яңа өйләрнең
Күңелләрдә туган таңнар белән
Тагын нурландырып җибәрдең!

# Солтан Шәмси

# ШҮРӘЛЕЛӘР КАЙДАН ТАРАЛГАН?

Бер уйлану

Шүрәле — татар халкының иң яраткан мифик образы. Һәм ул ифрат киң таралган. Дөньяга килгән һәрбер бала әкият-риваятьләрдән беренче булып, Шүрәле турындагысын ишетә, бер ишеткәч инде онытa алмый, хәреф таный башлагач та кат-кат Тукайның «Шүрәле»сен укый, күңеленнән ятлый. Бу образ татар гаиләсендә туып үскән кешенең аңына шулкадәр тирән кереп урнаша ки, Шүрәлене белмәгән татарны гомумән күз алдына китерүе кыен.

Бу образны яхшы белсәк тә, тагын бер кат ачыклап үтик: кем соң ул Шүрәле? Төсе-кыяфәте, холкы-фигыле, буе-сыны, яшәү рәвеше нинди аның?

Каюм Насыйри аның турында болай дип яза: «Шүрәлеләр урманда тора һәм алар ялгыз гына яшәмиләр. Алар татарларга кеше кыяфәтендә күренәләр. Шүрәленең имчәкләре бик зур була, аның берсен уң җилкәсенә, икенчесен сул җилкәсенә аркылы салган була, имеш. Әгәр урманда татар очраса, алар аны кети-кети уйнарга чакыралар; әгәр дә ул күнсә, аны үтергәнче кытыклыйлар. Ләкин татар Шүрәлене алдый ала... Әгәр дә татар, Шүрәленең: «Син кем?» — дип соравына: «Мин Былтыр атлы»,— дип әйтергә башына килсә һәм, Шүрәлене кыстырып, качып котылса, Шүрәленең: «Былтыр кысты, Былтыр кысты!» — дип кычкыруына җыелган иптәшләре хәйләкәр татар артыннан чабу түгел, бәлки: «Былтыргы елны каян эзлисең, табып буламыни аны!» — дип, Шүрәледән кычкырып көләләр генә, имеш. Күрәсең, шүрәлеләр бик аңгыра булалар икән» [1], дип К. Насыйри сүзен тәмамлый.

Тукай исә Шүрәленең портретын тагын да образлырак тасвирлый:

*Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Я әрәкме, нәрсә бу?*
*Коточарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!*
*Борны кәп-кәкре бөгелгәндер — тәмам кармак кеби;*
*Тәз түгел куллар, аяклар да ботак-тармак кеби.*
*Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,*
*Кот очар, күрсәң әгәр төнлә түгел — көндезләре.*
*Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;*
*Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе.*
*Кәкре түгелдер моның бармаклары — бик төз-төзен,*
*Тик килешсез — һәрбере дә ярты аршыннан озын.*

Инде йомгак ясап, Шүрәлегә нинди сыйфатлар хас икәнне ачыклыйк:

1) кешегә охшаган; 2) урманда яши; 3) башка шүрәлеләр белән күмәкләшеп тә яшиләр; 4) кешене кытыклый, мавыгып китеп, кайвакытта үтерә дә; 5) аңгырарак зат, кеше аны алдый ала.

Татарстанның кайбер районнарында аңа башка сыйфатлар да өстиләр, мәсәлән: 6) гәүдәсен йон баскан; 7) бармаклары бик озын; 8) мөгезе бар; 9) урманда кешене адаштыра; 10) атка атланып чабарга ярата; 11) төрле тавыш белән кычкырып, юлчыларны куркыта һ. б. [2].

Күренә ки, халык бу образны тудырганда хыялын чикләмәгән, аны буыннан-буынга бäетә барып, яңадан-яңа сыйфатлар өстәгән, күп нәрсәне Шүрәледән күргән. Ләкин барыбер урман иясе ул кадәр үк куркыныч зат түгел икән. Киресенчә, кайчакта ул тәрбияле дә була ала. Мәсәлән, адәмне кытыклыйсы килсә, башта аннан рөхсәт сорый, кеше риза булганда гына уйнарга-шаярырга, кытыкларга керешә. Дөрес, мавыгып китеп, үтереп тә ташлавы бар, ләкин ул бит моны явыз ният белән эшләми, уенга артык бирелеп китеп, вакытында тыела алмаганнан гына шулай килеп чыга. Нишлисең бит, шундый зат инде ул безнең Шүрәле!..

Шулай да бу образның тамырлары кая барып тоташа? Бу хакта кемнең дә булса

[1] Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Т. 2. Казан, 1975, 53 б.
[2] Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967, 361 б.

уйланганы, тикшеренеп караганы бармы икән соң? Бар икән, Р. Г. Әхмәтҗановның[1] кызыклы һәм мәгълүматларга бай китабында Шүрәле турында мәкалә урнаштырылган.

Мондый китапның дөнья күрүе куанычлы хәл. Халкыбызның рухи культурасына, гореф-гадәтләренә, йолаларына, мифологиясенә багышланган хезмәтләр бездә бармак белән генә санарлык. Бу өлкәдә эшләр әле башлана гына. Р. Г. Әхмәтҗановның китабын мин кызыксынып укыдым. Әмма авторның Шүрәле турындагы концепциясен кабул итә алмадым.

Ни өчен?..

Ул Шүрәле белән Ярымтык бер үк зат дип бара, дөресрәге, Шүрәле образы Ярымтыктан үсеп чыккан дигән фикер үткәрә.

Ярымтыкның нинди рәк зат булуын ачыклап китик.

Ярымтык («ярым» сүзеннән алынган) — Себер һәм Көнчыгыш Европа халыклары мифологиясендә очрый торган кәшегә охшаган, бер күзле, бер куллы, сыңар аяклы явыз зат. Гариплеген, ярым-йортылыгын күздә тотып булса кирәк, бу затны «ярымтык» дип атаганнар (русчасы — половинник). Адәмгә ул төрле зыян-зарар китерә. Татарстаннан читтә яшәүче татарлар арасында (мәсәлән, Пермь өлкәсе татарларында) һәм БАССРның кайбер районнарында аны Шүрәле белән бутау, бер зат дип карау очраклары да бар.

Ярымтыкка характеристика бирү гомумән авыр эш, моңа тотынсаң, төрле каршылыкларга килеп юлыгасың, чөнки бу затның исеме генә түгел, хәтта тышкы кыяфәте дә, мифологик функцияләре дә гел үзгәреп тора. Һәр халыкта аның үз исеме, үз кыяфәте бар. Удмуртларда ул, мәсәлән, «палэсмурт» (ярымтык кеше), чувашларда «ар чурри», «ама чурри» (ярымтык ир-ат, хатын-кыз), мансиларда «хумпал» (урман җене), ненецта — «парнэ» (түмгәк астында яшәүче ярымтык-карт), нганасаннарда, энкларда «баруси», «баручи» (бер күзле, бер аяклы, кеше ашаучы ярымтык-карчык), якутта — «сучунаа» (озын буйлы ярымтык-аучылар), эвенкларда — «чугулды» (ярымтык-тимерчеләр) һ. б.[2]. Шушыларга өстәп, автор ярымтыкларның кытайларда, кореялыларда, гарәпләрдә, фарсыларда һ. б. халыкларда да булуын әйтә.

Бер күзле, бер куллы, сыңар аяклы кешегә охшаган шушы гарипләр белән галимнәр күптән кызыксынып килә икән, чөнки бронзадан коелган нәкъ шундый сынстатуэткалар Тувадан Украинага хәтле җәелгән далаларда табыла тора. Археологиядә алар «бронзадан коелган гарипләр» дип атала. Әле үткән гасырда ук аларга А. Ф. Лихачев игътибар иткән. Соңрак А. А. Спицын бу хакта язып чыккан. Безнең көннәрдә дә әлеге «гарипләр» А. Л. Монгайт, П. М. Рутковская, Г. А. Пугаченкова, Л. И. Ремпель, А. Х. Халиков һәм башка галимнәрнең игътибарын җәлеп итте. Тикшеренүчеләрнең барысы да диярлек бу статуэткаларны борынгы төрки халыклар мирасы дип бара, алар белән бәйли. Кыскасы, әлеге гарипләрнең дала җирлегендә барлыкка килүе, төрки халыклар культурасына караvы фәндә инде күпмедер дәрәҗәдә исбатланган нәрсә. Үзләренең эшләнеше, үзгәрми торган иконографиясе (йөз төзелеше) белән дә алар төркиләрнең таш балбаларын хәтерләтә[3]. Шулай да бу фигураларны берләштерүче төп сыйфат — гариплек булып кала. Алар турында төрле гипотезалар яшәп килсә дә, хәзерге көнгә хәтле аны әле исбатлап аңлата алган кеше юк.

Бу гарипләр шулай ук болгарлар яшәгән территориядә дә очрый. Әлеге хәл исә без телгә алган ярымтыклар белән шушы гарипләр арасында нинди дә булса бәйләнеш, уртаклык булуы хакында сөйли кебек. Бәлки алар бер үк заттыр, чөнки икесе дә кешегә охшаган һәм, иң мөһиме, икесенә дә үзгәрми торган сыйфат — гариплек хас. Болгарлар яшәгән территориядә очрый торган бу статуэткаларның ярымтыклар турындагы легендаларның материаль чагылышы булуы да бик ихтимал. Бу исә үз чиратында Ярымтык белән Шүрәлене бер-берсеннән аерып торучы зур дәлил була алыр иде.

Чыннан да, ни өчен бер-берсеннән шулкадәр аерылып торган Шүрәле белән Ярымтык бер зат булырга тиеш соң әле? Бу ике зат арасында каршылыклар байтак бит!

---

[1] Ахметьянов Р. Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. М., 1981.

[2] Ахметьянов Р. Г. Күрсәтелгән хезмәт, 48 б.

[3] Халиков А. Х. Отражение космогонических и генеологических легенд волжских булгар в археологических материалах.— Китапта: Из истории ранних булгар. Казань, 1981, 12—13 бб.

Беренчедән, Шүрәле — урман иясе (алласы). Ярымтык — даланыкы, һәрхәлдә әлегә ачыкланып бетмәгән.

Икенчедән, Шүрәле татарда ифрат та киң таралган, халыкның аңына-канына сеңгән, культураның бөтен катламнарына үтеп кергән. Ярымтыкны татар белми диярлек, белсә дә башкорт белән катнашкан яисә Татарстаннан читтә яшәгәне генә белә.

Өченчедән, Шүрәле бер вариантлы, үзгәрми торган образ, ул хәтта башка халыкларга кергән очракта да (марида, чувашта, башкортта) төсен-кыяфәтен үзгәртми.

Дүртенчедән, Шүрәле — сау-сәламәт, бөтен җире үзенчә камил, төзек зат, ул гарип-гораба түгел. Ярымтык — гарип.

Бишенчедән, Шүрәле бары тик Урта Иделдә урнашкан халыкларда гына бар. Алай гына да түгел. Шүрәле ни өчендер элекке Болгар дәүләтенә кергән, яисә байтак заманнар шушы дәүләтнең көчле йогынтысы астында яшәгән халыкларда гына таралган. Ярымтыкны исә без кайда гына очратмыйбыз.

Алтынчыдан, Шүрәле археологик материаллар арасында бөтенләй очрамый. Гариплэр-Ярымтыклар очрый.

Кайбер төбәкләрдә Ярымтык белән Шүрәленең бергә кушылып китүе, халык күңелендә бер образ булып яшәве бик тә аңлашыла. Бу хәл Шүрәле таралган территория белән Ярымтык таралган территория чигендә генә күренә. Чөнки болары Ярымтыкның нәрсә икәнен белми (яисә онытып өлгергән!), тегеләре Шүрәлене белеп бетерми һәм нәтиҗәдә ике образ бергә кушылып яши. Шушыны күздә тотып булса кирәк, Р. Г. Әхмәтҗанов Ярымтыкны татар һәм башкорт өчен уртак образ дип саный.

Тагын шунысы кызык: Шүрәленең иң билгеле җире Татарстан, ягъни бу миф элекке Болгар дәүләте урнашкан территориядә һәм шушы дәүләтне төзегән төп халыкта гына киң таралган. Шулай булгач, ул археологик материаллар арасында да очрарга тиеш иде. Әмма юк. Ни сәбәпле? Шул ук вакытта Ярымтыкның төгәл копиясе булган «гарип»ләр Татарстан территориясендә табылган археологик материаллар арасында байтак очрый. Ә Ярымтык үзе татарга билгеле түгел дәрәҗәсендә. Моны ничек аңлатырга?

Моны бер генә төрле аңлатып була: Ярымтык бик борынгыдан килгән дала культы буларак, Шүрәле барлыкка килгәндә (яки болгар-татарга килеп кергәндә) инде онытылып беткән булса кирәк. Димәк, Шүрәле болгар-татар өчен чагыштырмача яңа миф, яшь миф. Ул соңрак чорларда туган булырга тиеш һәм бу чорда инде болгар-татар аның сыннарын-статуэткаларын ясамаган. Бу факт нәрсә турында сөйли соң? Бу факт Шүрәле киң тарала башлаган чорда болгар-татар тормышында ниндидер зур үзгәрешләр булуы турында сөйли. Бу үзгәрешләр хакында сүз әле булыр, ә хәзер үзебезгә тагын бер сорау бирик: «Шүрәле образы безнең халыкта (төрки халыкта!) кайчан туган? Үзенекеме ул аның, әллә читтән килеп кереп, кайбер үзгәрешләр кичереп, соңрак чорда гына үзеңеке булып киткәнме?»

Бик урынлы сорау. Мифларның бер халыктан икенче халыкка күчү гадәтен истә тотсак, мәсьәләнең үзәгендә торырга тиешле сорау. Аңа җавап бирмичә фикерне дәвам иттереп булмаячак.

Шүрәле — болгар-татар өчен яңа, яшь миф дидек. Бу чыннан да шулай булса кирәк, чөнки Шүрәлене без борынгы чорларда бер генә төрки халыкта да очратмыйбыз. Ул бары тик Урта Иделдә генә яши. Ә Урта Иделгә болгарлар VIII—IX йөзләрдә генә килеп урнашалар. һәм күп тә үтми, мәҗүсилектән аерылып, ислам диненә күчәләр.

Болгар өчен ислам динене күчү нәрсәне аңлата соң? Мәҗүсилек заманнарында төркиләрнең аллалары күп булган. Өске дөньяның (күкнең) үз алласы, аскы дөньяның (җир астының) үз алласы бар, аннан башка да аерым елга, су, күл, чишмә, урман, тау-кыяларның, юлларның, тау сыртларының, төрле урыннарның үз ияләре, хуҗалары, рухлары булуы билгеле[1]. Ул заманнарда болгарның да аллалары күп булган. һәм ул әле табигатьтән аерылмаган. Табигать каршында җенлек, кош-корт белән бер хокуклы җан иясе булып яшәгән. Шуңа күрә үзен шомландырган, куркыткан, аңлашылмаган, серле тоелган объектларның ияләре бардыр дип уйлаган, аларга табынган, корбан китергән.

[1] Алексеев Н. А. Ранние формы религии тюркоязычных народов Сибири. Новосибирск, 1980, 89—95 бб.

Ислам динен кабул итеп, болгар инде бер баскычка югары күтәрелгән. Монотеизм югарылыгына. Бу чорда аның аңында зур үзгәреш бара. Бер генә аллага ышану аны, бер яктан, табигать көчләренә ышанудан ераклаштырса, икенче яктан, авыр чакта аның хәзер килеп сыенып алласы бар. Бу исә аңа батырлык өсти.

Мондый шартларда, болгарлар инде феодализм чорына кереп, монотеизмга күчкәч, Шүрәле кебек мәҗүсилек бик нык сизелеп торган, әмма күп заманнар узу аркасында сюжет ягыннан да шактый камилләшкән миф туа аламы? Ислам бит үзенә хәтле яшәгән мифларны да кысрыклап чыгарырга, тамырын корытырга тырышкан. Шулай булгач, Шүрәле мифы мәҗүсилек заманнарында туып, ныгып, камилләшеп калган миф булса кирәк.

Мифлар, гадәттә, җәмгыять түбәнрәк баскычта торганда туалар. Шүрәленең мәҗүсилек дәверендә тууын бер деталь ачыклый төшә кебек. Мәсәлән, керәшен татарларында урманга барып Шүрәле хөрмәтенә ак этәч чалу гадәте саклануы билгеле. Бу нәрсә турында сөйли? Христиан диненә күчү сәбәпле, мөселманнар белән артык аралашмыйча күпмедер вакытлар консервациядә яшәгән керәшеннәрдә мәҗүсилектән калган бу гадәт ничектер сакланган. Димәк, Шүрәле кайчандыр тулы хокуклы зат булган, аңа табынганнар, хәтта корбан да китергәннәр.

Ә татарда Шүрәлегә мөнәсәбәт ничек?

Шүрәле аның өчен, куркыныч булса да, кәмитрәк бер зат, «урман сарыгы» гына. Ул аны алдый да ала, ат сыртына сумала ябыштырып, Шүрәлене әсирлеккә төшерә, кыйнап җибәрә («Шүрәле каргаган авыл» легендасы). Татарның Шүрәлегә булган ироник мөнәсәбәте, «Көн дә-көн дә ат чабыш, нишләп бүген арт ябыш?» — дигән мәкальдә дә чагыла[1]. Мәҗүси кеше урман алласы белән алай шаярып иде микән? Монда монотеизм югарылыгына күтәрелгән болгар-татарның һаман әле мәҗүсилек караңгылыгында тырмашкан адәмгә карата булган мөнәсәбәте ярылып ята. Шуңа күрә татар Шүрәлегә өстәнрәк, кимсетебрәк карый да.

Тагын бер момент игътибарны җәлеп итә — Шүрәле кешегә охшаган (антропоморфизм).

Гадәттә, мифология үсеш дәверендә ике этапны үтә: 1) зооморфизм этабын, ягъни мифик образларның хайваннар рәвешендә булуы, 2) аннан соң гына антропоморфизм этабы җитә, мифик образлар кеше рәвешенә керәләр. Дөрес, кайвакыт бер үк мифологик системада зооморфизм белән антропоморфизмның бергә яшәве дә очрый. Әмма барыбер мифларның иң югары ноктасы, кульминациясе антропоморфизм этабында була. Мәсәлән, борынгы грек мифологиясе, зооморфизм этабын тизрәк үтеп, антропоморфизмга килеп керә һәм шул кадәр матур мифлар тудыра. Безгә билгеле булган борынгы грек аллаларының барысы да диярлек кеше кыяфәтендә, бик сирәге генә яртылаш кеше, яртылаш хайван рәвешендә калган (мәсәлән, Пан).

Безнең Шүрәлегә килгәндә, бу образ чыннан да кешегә бик якын. Ул инде икенче этапка күчә башлаган, кешегә якынайган миф. Ә моңа ирешү өчен Шүрәле гаять озын юл үтәргә тиеш иде. Аның әзер килеш кинәт болгар-татарда яши башлавы шактый сәер. Өстәвенә ул безгә соңлабрак та килеп кергән кебек, чөнки болгар бу чорда инде шәрык культурасын үзләштерә, гарәп телен өйрәнә, мәдрәсә-мәчетләр төзи. Бәлки Шүрәле болгарларга Урта Иделгә күчеп килгәнче үк килеп кергәндер?

Кайчан һәм нинди халыктан?

Үзәк Азия далаларыннан Көнчыгыш Европага килеп чыккан һуннар безнең эраның 375 елында Иделне кичәләр. Халыкларның Бөек күчеш чоры башлана. Кайбер галимнәрнең әйтүенә караганда, болгарлар да һун союзында булганнар. Һуннар Идел бассейнында озак тормыйлар, яңа җирләр яуларга Көнбатыш Европага китеп баралар. Ә болгарлар Кара диңгез һәм Азов буйларында утырып калалар. Мөстәкыйль дәүләт төзиләр. Болгарларның беренче дәүләте — Бөек Болгария. Аның башкаласы Тамань ярымутравындагы антик чордан калган Фанагория шәһәрендә була. Шушы төбәктә болгарлар 350 елдан артык гомер кичерәләр.

Болгарлар биредә төрле халыклар белән аралашып яшиләр, күпмедер дәрәҗәдә шушы халыкларның йогынтысына эләгәләр. Аларга иң көчле тәэсир иткәне — аланнар

[1] Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. 3 т., Казан, 1967, 967 б.

булa, аннан кала Кара диңгез буендагы эллинлашкан шәһәрләрне күрсәтергә мөмкин.

Болгарлар белән тыгыз элемтәдә яшәгән аланнар кемнәр соң ул? Борынгы грек авторлары тарафыннан еш телгә алынган савроматлар, соңрак чордагы сарматлар аланнарның бабалары санала. Көнчыгыш Европа далаларын һуннар яулап алганчы бу регионда сармат-аланнар хөкем сөрә. Тарихчы-археологлар М. И. Артамонов, С. А. Плетнева, Э. А. Рикманнарның әйтүенә караганда, сармат-аланнар да Кара диңгез буе шәһәрләренең көчле йогынтысына эләгәләр. Бу күп төрле археологик материалларда чагыла. Сармат-аланнарга бер үзенчәлек хас булган: алар бергә тупланган этник масса хәлендә яшәмәгәннәр, гел башка халыклар арасына чәчелеп, кушылып киткән, хәтта туганлашып гомер иткәннәр. Бөек күчеш чорында бу нәрсә үзен бигрәк тә нык сиздергән. Ф. Энгельс сүзләре белән әйтсәк, бу чорда озак вакытлар дәвам иткән яулар ыруг-кабиләләрне генә түгел, хәтта тоташ бер халыкларны да кушып бетерә. Шул ук вакытта сармат-аланнарның да Кара диңгез буе шәһәрләренә тәэсире була. Антик чор археологиясенең зур белгече В. Д. Блаватскийның әйтүенә караганда, әлеге шәһәрләрнең элеккеге гражданинын күчмә халык киеме кигән атлы сугышчы алыштыра. Бу сүзләр шушы төбәк халыкларының тыгыз бәйләнештә яшәве хакында сөйли. Шулай итеп сармат-аланнар, болгарлар бу тирәгә килеп урнашканчы ук, байтак гасырлар дәвамында антик культураны сеңдергән булалар. Болгарлар монда килеп урнашкач, бу ике халык тыгыз элемтәдә яши. Археологлар һәм сәнгать белгечләренең күрсәтүенә караганда, аланнар болгарларның этнографик йөзе формалашуга да күпмедер өлеш кертәләр. Шулай ук болгар сәнгатендәге кайбер алымнар, алтын-көмештән бизәнү әйберләре ясау, бөртекле (зернь) һәм бөтеркәле бизәк (скань) төшерү, бронзадан коелган көзгеләрне киң куллана башлау, тагын кайбер этнографик элементлар болгарларга сармат-аланнардан күчә. Тора-бара аланнарның бер өлеше болгарлар белән кушылып китә. Шушы чорда ук болгарлар белән аланнарның уртак үзаңы формалаша башлый. Бу процесста Кара диңгез, Азов буйларында таралган антик культураның да тәэсире сизелә.

Шулай итеп, өч борынгы культура очрашкан шушы төбәктә VIII йөз урталарында гаять үзенчәлекле һәм заманына күрә югары баскычта торган культура барлыкка килә. Фәндә аны Салтау (яки Салтау-Маяк) культурасы дип йөртәләр.

Бу культураны өйрәнү белән 50 нче еллар башыннан бирле даими шөгыльләнгән күренекле археолог С. А. Плетнева фикеренә караганда, Салтау культурасын тудыручы болгарларга аланнар да күпмедер катнашкан була [1].

Сүз археологик культура турында бара икән, бу төшенчәне ачыклап та китик. Бу очракта сүзне археологның үзенә бирсәк дөресрәк булыр: «Археологик культура — бер вакыт, гомум территория һәм гомум матди культура белән характерланучы археологик истәлекләр комплексы ул. Археологик культураны тарихи-этник планда кабиләләр союзы һәм дәүләт белән тәңгәл итеп карарга кирәк. Теге яки бу союздан һәм дәүләттән калган матди культура истәлекләре һәм рухи культура элементлары (бу очракта күмү йолалары) бары тик шул союз һәм дәүләт өчен генә хас. Шул җирлектә бер археологик культура икенчесеннән аерыла да. Кабиләләр калдырган археологик культура гадәттә шул культураның иң беренче табылган һәм иң әһәмиятле истәлекнең исеме белән атала. Археологик истәлеккә атама ул урнашкан хәзерге авыл яки шәһәр исеменә карап бирелә» [2].

Салтау культурасына археологлар 1900 елны Северский Донец елгасының уң як ярында тап булалар. Бу культураның беренче истәлекләренә юлыгу белән ук галимнәр аны ул заманда өстенлек алган берәр халыкныкы булырга тиеш дип уйлыйлар. Ул заманда өстенлек алган халык хәзерләр икәне билгеле булганга, культура да аларныкыдыр дигән фикергә киләләр. Әмма бераздан бу культураның аланнарныкы икәне ачыклана (аланнар — осетиннарның бабалары). Күп тә үтми галимнәр Салтау культурасының тагын бер вариантына килеп юлыгалар. Аныcы болгарларныкы булып чыга. Шулай итеп, Донның төньягындагы вариантны — аланнар, көньягындагысын — болгар кабиләләре калдырганлыгы ачыклана.

Хәзер фәндә Салтау культурасының тагын берничә варианты билгеле — Төньяк Кавказ, Кырым, Идел Болгариясе, Дунай Болгариясе, Азов буе, Идел тамагы вариант-

[1] Плетнева С. А. От кочевий к городам. Салтово-Маяцкая культура. М., 1967, 33 б.
[2] Фахретдинов Р. Ташлар моңы. Казан, 1978, 17 б.

лары. Соңрак чорда Урта Иделдә үсеп чыккан Болгар дәүләте дә шушы культураның җирле вариантын тәшкил итә, аның нигезендә Азов-Дон буйларында барлыкка килгән культура ята.

VIII йөз урталарында Салтау культурасы үсеп чыккан төбәктә болгар кабиләләре утрак тормышка күчә башлыйлар, авыллар, шәһәрләр барлыкка килә. Утрак тормышта һөнәрчелек, сәүдә үсә. Бу шартларда гаять зур территориягә бер үк культура тарала.

Салтау чорыннан (VIII—IX йөзләр) Идел Болгариясенә нәрсә дә булса барып җиткәнме? Эзли торгач, шулай да кайбер эзләрне табып була икән әле...

Әхмәт Ибне Фазлан, 921 елны Болгарга килгәч, кояш баеганда күктәге гаҗәеп күренешләрне күзәтүе хакында яза. Әйтергә кирәк, Ибне Фазлан кайбер очракта, үз заманы укучыларының зәвыгын күздә тотып булса кирәк, ишеткән легендаларын, әкиятләрен үзе күргән хәлләр кебек итеп тасвирлаган. Язмаларындагы кайбер урыннарны башкача һич тә аңлатып булмый.

«...һавада көчле авазлар һәм каты шау-шу ишеттем,— дип яза ул.— Миннән ерак түгел ут шикелле кызыл болыт күрдем, ул тавышлар һәм авазлар шуннан чыгалар икән... (Болытта) кешеләр, атлар шикелле һәм ерактан караганда кулларына җәя, ук, сөңге һәм ялангач кылыч тоткан кешеләр кебек күренешләр һәм алар белән янәшә, алар шикелле кара отряд... Бу отряд теге отрядка һөҗүм итә башлады... Бу күренешләр төннең байтак вакытына кадәр дәвам итте... Бу турыда без падишадан (Алмыш ханнан) сорадык. Ул исә теге атлы гаскәрнең гадел (тугрылыклы) һәм ышанычсыз (мәкерле) җеннәр булу турында бабаларының сөйләп килгәнлекләрен әйтте. Алар һәр кичне сугышалар һәм, чыннан да, (дөньяда) яши башлаганнан бирле шулай эшлиләр, бер генә төндә дә аларның шундый сугышта катнашмый калганнары юк» [1].

Бу фантастик күренеш, әлбәттә. Моны мираж дип тә аңлатуы кыен. Беренчедән, Урта Иделдә мираж була алмый, икенчедән, булган очракта да көн саен кабатланмый. Димәк, бу хикәя хыял җимеше генә булып кала. Әмма нәрсәгә нигезләнгән? Тиктомалдан гына күз алдына мондый күк сугышчылары килеп басар микән? Дөрес, кайбер галимнәр моны Багдад дипломаты күзәткән төньяк балкышы дип уйлыйлар [2]. Ләкин моның белән дә килешүе кыен. Урта Иделдә төньяк балкышның күренүенә бер дә ышанасы килми. Төньякта да ул көн саен очрый торган хәл түгел.

Билгеле булганча, борынгы Иран мифологиясе бер-берсенә капма-каршы ике көчнең, үзара гел сугышып, гел тартышып яшәүче ике алланың көрәшеннән гыйбарәт. Шушы дингә нигез салучы Зәрәтүштрә тәгълиматы буенча, дөньяның асылын яктылык, көн, яхшылык алласы Аһура-Мазда белән караңгылык, төн, явызлык алласы Анхра-Майньюның көрәше тәшкил итә. Һәр алланың күп санлы ярдәмчеләре бар. Алар да бу көрәштә катнаша. Ибне Фазлан язып калдырган күк күренешләрен үз аллалары Тәңрегә табыну белән беррәттән иранлылар дине белән дә яхшы таныш булган бабаларыбыз болгарлар хыялындагы ышану дип кенә кабул итеп була. Иранлылар дине белән алар аланнар аркылы Салтау чорында танышканнар булса кирәк, чөнки Алмыш хан бу хакта «бабаларының сөйләп килгәнлекләрен» әйтә. Болгарларга күпмедер дәрәҗәдә этник компонент булып кушылган аланнар бу вакытта әле элеккеге дини карашларыннан бөтенләй үк арынып бетмәгән булганнардыр, күрәсең. Безнең көннәргә кадәр татарларда сакланып килгән мифик образ Азар-бизәрнең дә (Р. Г. Әхмәтҗанов, 13 б.) шул ук иранлылар алласы Аһура-Маздадан калган булуы шул хакта сөйли шикелле.

Салтау чорында болгарларга Иран культурасының тәэсир итүен башка образлар да раслый. Мәсәлән, Дию, Әзмәвер, Албасты, Аждаһа, Пәри, Пәһлеван, Сәмруг (кош) кебек образлар.

Идел буенда яшәүче халыклардан татар, удмурт, мариларда, тагын нугай, казах, караимнарда борын-борын заманнарда Идел буен яулап алган ниндидер мифик баһадирлар — алангасарлар турында риваятьләр яши икән (Р. Г. Әхмәтҗанов, 15 б.). Кайбер галимнәр бу сүзне аланнар белән хәзәрләр төзегән хәрби союз исеменнән килеп чыккан дип уйлыйлар. Болгарлар белән аланнарның Кубрат хан үлгәннән соң Хәзәр каганаты составына керүе тарихта билгеле факт.

---

[1] Борынгы татар әдәбияты. Казан, 1963, 26 б.
[2] Бонград-Левин Г. М., Грантовский Э. А. От Скифии до Индии. М., 1983, 150 б.

Бу фактлар Салтау чорында болгарларның аланнар белән тыгыз элемтәдә яшәүләре турында сөйли.

Әйткәнебезчә, болгарларның антик дөнья белән дә элемтәләре булган. Шул бәйләнешләрдән нинди дә булса эзләр сакланганмы?

Мәсәлән, борынгы грек легендаларында файдаланылган бер сюжет элементына Тукайның «Шүрәле»сендә тап булабыз.

«Одиссея» циклына кергән бер легендада Одиссей һәм аның юлдашлары корабларын зур гәүдәле циклоплар яши торган утрауга китереп туктаталар. Бер көнне, коточкыч зур гәүдәле циклоп Полифем яшәгән мәгарәгә килеп кереп, болар әсирлеккә төшә, фаҗигагә дучар булалар,— циклоп аларны берәм-берәм ашарга керешә. Үзен циклоп Полифемга Беркемтүгел (русчасы Никто) дип таныштырган Одиссейны циклоп иң соңгы кеше итеп ашарга вәгъдә итә. Тик Одиссей хәйләсен таба, циклопны шәраб эчертеп йоклата да янган кисәү агачы белән бердәнбер күзен яндырып качып китә... Циклоп авыртудан акырып җибәрә, тавышка башка циклоплар җыелыша.

— Ни булды, Полифем? Кем рәнҗетә? Әллә кәтүеңне куып алып киттеләрме? Нигә безне вакытсыз уяттың? — дип сорыйлар аңардан.

Акырып-бакырып утырган Полифем:

— Мине хәйлә белән Беркемтүгел харап итте! — ди.

Циклопларның ачуы килә.

— Беркем тимәгәч, ник алай акырасың! — диләр аңа һәм борылып китеп тә баралар [1].

«Шүрәле»дәге «Былтыр кысты!» түгелме соң бу?! Бу мотивның болгарларга Кара диңгез буенда яшәгән чорда күчкән булуы бик ихтимал.

Болгар культурасын дәвам иттерүче Казан татарларына бу эзләр, йогынтылар барып җиткәнме?

Бу сорауга җавап эзләп, мин сәнгать фәннәре докторы Фуад Хәсәнович Вәлиевкә мөрәҗәгать иттем. Мәгълүм ки, Ф. Х. Вәлиев бу өлкәдә озак еллар дәвамында эзләнеп эшләп килә. Ул «Казан татарлары орнаменты» (1969), «Урта Иделнең борынгы һәм урта гасырлар сәнгате» (1975) исемле хезмәтләре, болгар-татар культурасына багышланган күп санлы мәкаләләре белән укучыларга яхшы таныш. Галимнең «Казан татарларының декоратив сәнгате. Аның үсеш юлы һәм тамырлары» дип аталган докторлык диссертациясе дә шушы эшнең дәвамын тәшкил итә. Хәзерге көндә ул болгар-татар сәнгате буенча республиканың зур белгечләреннән санала.

Шушы сорауны мин аңа бирдем.

— Бу сорау Идел болгарлары һәм Казан татарлары культурасын өйрәнүдә әрҗәнә тема дип әйтер идем мин. Аннан соң ул Салтау проблемасына барып тоташа һәм без аңа хәзерге көндә әзерләнеп яткан хезмәтебездә байтак урын бирдек.

— Сез нинди хезмәтне күздә тотасыз?

— Хезмәт болгар-татар сәнгатенә багышланган. Иң борынгы дәверләрдән XVI йөз уртасына кадәрге чорны эченә ала. Безнең тикшеренүләргә караганда (без аны кызым Гүзәл белән бергәләп яздык), әүвәлге болгар сәнгате безнең эрага хәтле үк Таулы Алтайда яшәгән сак-масагет кабиләләре сәнгатенә барып тоташа. Шунысы әһәмиятле — әүвәлге болгар культурасы ул бит дала культурасының синтезы гына түгел, бабаларыбыз күршеләреннән дә кайбер нәрсәләрне алганнар... Дөрес, VIII йөз уртасы—IX йөзләрдә чәчәк аткан Салтау дәверенә хәтле болгар сәнгатенә синкретизм, ягъни сәнгатьләрнең үзара кушылганлыгы хас. Әмма Салтау чорында культура зур үзгәреш кичерә, кызыклы синтез барлыкка килә. Болгарларның үзләренә генә хас стиле үсеп чыга...

— Ә эллинлашкан шәһәрләрнең әүвәлге болгар сәнгатенә тәэсире сизеләме?

— Шуны әйтергә була: Идел болгарлары һәм казан татарлары сәнгатендә бу тәэсирләр архитектурада, йортлар төзүдә, нәфис металл эшкәртүдә, ювелирлык сәнгатендә, чүлмәк ясау алымнарында һ. б. сизелә. Әлеге хезмәттә без бу мәсьәләләргә дә урын бирдек.

— Сезнеңчә ничек, Салтау культурасы вәкилләре антик мифология белән таныш

[1] Кун Н. А. Легенды и мифы Древней Греции. М., 1957, 371 б.

булганнармы? — дип, әңгәмәне үземне кызыксындырган мәсьәләгә юнәлтергә тырышам.

— Әлбәттә! Өч гасыр аралашу, бу төбәктә күптән яшәгән аланнар белән туганлашу, тыгыз бәйләнешләргә керү антик дөньяга аларны һичшиксез якынайткандыр. Мифларны да ишеткән, белгән булырга тиешләр.

Әңгәмәдәшемә төп сорауны бирергә әзерләндем:

— Ә Шүрәле образы безгә антик дөньядан, шул исәптән грек мифологиясеннән килмәде микән? Пан бик тә Шүрәлене хәтерләтә!

Фуад Хәсәнович елмаеп куйды.

— Беләсезме, минем дә бу хакта уйлап караганым бар... Ләкин башка эшләр күп булу сәбәпле, тотынырга һаман вакыт җитми. Моның өчен ике якның да мифларын, легендаларын барлап чыгарга кирәктер, күрәсең...

Мин үземнең шушы турыда бер әйбер язасым килгәнне әйттем. Аннан соң:

— Моны бит, турыдан-туры булмаса да, сәнгать материалы да раслый ала,— дидем.

— Шулай, әлбәттә! Бу җәһәттән безгә археология бик нык ярдәм итә.

— Археология димәктән... Болгар материалында нинди дә булса антик мотивлар чагыламы соң? Берничә мисал китерә алмассызмы?

— Болгарларда елан һәм арслан башы сурәтләнгән бизәкләр очрый. Бу антик сәнгать йогынтысы, дип уйлыйм. Аннан соң сорау билгесенә охшатып ясалган алкалар, чигә чылбырлары, металл муенсалар... Күп инде алар...

— Пан образында тотемизм элементлары төсмерләнә кебек. Аның кәҗә тояклы, мөгезле кеше рәвешендә сурәтләнүе шуны күрсәтә шикелле.

— Дөрес. Грекләрдәгы урман-кырлар алласы Панның ни гомерләр Кара диңгез Азов, Дон буйларында яшәгән болгарларга «йогып» калуы бик ихтимал. Мәрхүм археолог М. И. Артамонов әйтүенә караганда, Салтау культурасын тудыручылар, Төньяк Кавказ аланнары кебек үк, күчмә халык булмаганнар. Дересрәге, утрак тормышка күчкән халык булганнар. Салтаулылар иген игеп, терлек асрап көн күргәннәр, һөнәрчелек бик нык үсеп киткән... Археологик материаллар арасында эш кораллары, төрле инструментлар күп. Бу ныклы дәлил.

— Шулай да нинди эш кораллары очрый?

— Мәсәлән, салтаулыларда еш очрый торган сабан, китмән, чалгы, урак, йөзем пычаклары, тегермән ташлары авыл хуҗалыгының шактый үскән булуы турында сөйли. һөнәрчелек коралларына килгәндә, төрле пычаклар, өтергә, игәү, бораy, авыр һәм җиңел чүкечләр, сандал, кайчы (шул исәптән металл кисү өчен дә), без, шөшле һ. б... Хәтта кыру станогы да табылган. Бу станокта агачтан савыт-саба ясаганнар.

Пан — борынгы грекларның урман-кырлар алласы. Атасы Гермес, шулай булгач, Пан — баш алла Зевсның оныгы булып чыга. Сакланып калган скульптураларда бу алла, әйткәнебезчә, кәҗә тояклы кеше кыяфәтендә сурәтләнә. Үзе мөгезле. Ул, Шүрәле кебек үк, урман ешлыкларын, тын су буйларын яраткан. Үен коралы курай уйлап тапкан, шушы инструментта яратып уйный торган булган. Сыннарында ул һәрвакыт кулына курай тоткан килеш тасвирлана. Пан шулай ук көтүчеләрне, көтүлекләрчә бөлә-казадан саклаган. Греклар аның хөрмәтенә кәҗә-сарык чалганнар, кайбер очракларда бал, сөт тутырылган савытлар куйганнар. Пан урман тынлыгын бозучыларны бер дә сөймәгән, шомлы тавышлар белән аларны куркыткан, юлдан яздырган. Бу алланың шушы гадәтенә бәйле рәвештә Европа телләренә «паника», «паник курку» кебек сүзләр дә килеп кергән. Тора-бара Пан да эволюция кичерә, урман-кырлар алласыннан бөтен табигать хуҗасына, иясенә әверелә. Христиан дине үсеп чыккач, бу монотеистик дин аның табигать хуҗасы булуын кичерә алмый — Панны дьяволга (шайтан, иблис) әверелдерә, шулай итеп мәҗүсилек алласының дәрәҗәсен, абруен төшерә. Соңрак чорда грекларны яулап алган римлыларда да нәкъ шундый алла бар — Фавн. Бу алла римлыларда мөстәкыйль туганмы, әллә инде грек культурасын күп очракта механик рәвештә, аллаларның исемен генә үзгәртеп үзләренә күчерергә яраткан бу халыкка ул шул ук греклардан күчкәнме — анысы ачык түгел. һәрхәлдә характерлары, кылган гамәлләре, кыяфәтләре белән Пан һәм Фавн игезәкләр кебек якын. Мөстәкыйль туган очракта да исемнәренең охшашлыгы (П-ф) — (а-а) — (н-вн) аларның кушылып, бер алла булып китүе хакында сөйли кебек.

Кара диңгезнең төньягындагы нык эллинлашкан әлеге төбәк безнең эрага хәтле беренче йөздә римлылар кул астына да төшә. Шулай итеп, Пан бу төбәккә өстәмә рәвештә тагын бер кат килә. Бу юлы инде Фавн сыйфатында!

Күргәнебезчә, Пан (Фавн) бик күп, шикләндерер дәрәҗәдә күп яклары белән безнең Шүрәлене хәтерләтә. Ярымтык белән Шүрәлене чагыштырып караган кебек үк, Пан белән Шүрәлене дә янәшә куеп карыйк:

| Пан (Фавн) | Шүрәле |
|---|---|
| 1) урман-кырлар алласы; | 1) урман иясе (алласы); |
| 2) кешегә охшаган, кәҗә тояклы, мөгезле; | 2) кешегә охшаган, мөгезле, аягын төрлечә күз алдына китерәләр; |
| 3) йонлы зат; | 3) йонлы зат; |
| 4) курайда уйный; | 4) озын бармаклы, кешене кытыкларга ярата; |
| 5) кешене куркыта, адаштыра торган гадәте бар; | 5) кешене куркыта, адаштыра; |
| 6) аның хөрмәтенә кәҗә-сарык чалганнар, савыт белән сөт-бал калдырганнар; | 6) керәшеннәрдә корбанга ак әтәч суюлары билгеле; |
| 7) мәҗүсилек алласы. | 7) мәҗүсилек нык сизелә. |

Дөрес, Шүрәлегә моннан тыш та кайбер сыйфатлар хас, әмма Пан белән дә уртаклык ифрат зур. Болгарларга ул нәкъ менә Салтау чорында «йоккан» булса кирәк. Без инде болгарларның нинди шартларда һәм кемнәр белән аралашып яшәвен, шул дәверләрдән калган кайбер рухи һәм материаль эзләрне күргән идек. Элгәрәк чорларда теркәлеп калмагач, заманнар үтү белән алар, әлбәттә, зәгыйфьләнгәннәр, күбесе онытылган, кысрыкланып чыгарылган, танып булмас хәлгә җиткән. Әмма җентеклебрәк тикшергәндә, халыкның үткән юлын күздә тотып эш иткәндә кайбер нәрсәләрне әле барыбер күреп була икән. Урман-кырлар алласы Панның да шушы юл белән болгарларга килеп керүе, тора-бара татарның милли Шүрәлесенә әверелеп китүе мөмкин эш түгелмени?!

IX йөз ахырларында Көнчыгыш Европа далаларына бәҗәнәкләр бәреп керә. Канлы сугышлар, бәрелешләр башлана. Бәҗәнәкләрнең көчле һәм житез гаскәре утрак тормышка күчә башлаган болгарларны кысрыклый. Алар торган авылларын, шәһәрләрен ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Тынычрак җирләр эзләп, Идел-Чулман бассейнына килеп урнашалар. Бу инде болгарларның икенче «дулкыны» була, беренчесе исә йөз ел элек, гарәп походлары башлангач, күчеп утыра.

Хәзер үзебезне гомер-гомергә далаларда яшәгән, Салтау чорында ук утрак тормышка күчә башлаган бабаларыбыз урынына куеп карыйк.

Идел-Чулман тирәләренә килеп урнашып, болгарлар һава шартлары белән дә, табигате, хайваннар дөньясы, үсемлекләре һ. б. үзенчәлекләре белән дә даладан шактый аерылып торган поясta яши башлыйлар. Мондый күчеш һәрвакыт яңа шартларга ияләшүне, күп нәрсәгә күнегүне таләп итә. Дөрес, алар бай табигатьле төбәккә килеп утыралар. Шулай да урманнарга ияләшү бабаларыбыз өчен җиңел генә үтмәгәндер. Дала кешесенә урман гомер-гомергә ят тоелган.

Татар халкының борынгы җырларыннан саналган «Иске кара урман»дагы:

> *Кара да гына урман, караңгы төн,*
> *Яхшы атлар кирәк лә үтәргә,*

— дигән юллар шул Идел-Чулман бассейнына күчеп утырган бабаларыбызның психологиясен, эчке халәтен чагылдырмый микән. Мондый урманнар аша үткән дала кешесенең күз алдына ниләр генә килеп басмас та, хыялында нинди генә образлар калыкмас? Элек-электән урман алласы Пан белән таныш та булсаң, бигрәк тә! Калын урманнары булган Урта Иделгә килеп урнашкан болгарларда Панның тагын да куркынычрак кыяфәт алып, башка сыйфатлар да өстәлүе бик тә табигый хәл. Пан образына шулай ук аралашып яшәгән угро-фин кабиләләре мифологиясеннән дә кайбер сыйфатлар өстәлүе мөмкин. Курайда уйнап күнеккән музыкаль, хәрәкәтчән бармакларының халык фантазиясендә адәмне кытыклау өчен җайлашуы да гаҗәп түгел.

Шушы уңайдан Шүрәле сүзенең мәгънәсе, килеп чыгышы турында да бер-ике сүз әйтеп үтәсе килә.

Р. Г. Әхмәтҗанов Шүрәле белән Ярымтыкның бер үк зат икәнен исбатлар өчен аның этимологиясен кыпчак телендәге «җараң» («ярым») сүзеннән китереп чыгара. Әмма «шүрәле»не кыпчак телендәге «җараң» белән аңлату мөмкин түгел, чөнки Шүрәле — урман иясе. Без монда каршылыкка килеп юлыгабыз. Минемчә, монда Шүрәленең холык-фигылен, аңа хас сыйфатларны, кыяфәтен күздә тотып эш итәргә кирәктер.

Бу сүздә сыйфат ясагыч «-ле» кушымчасы аермачык күренеп тора. Ягъни ул ниндидер «шүрә»се булган затны аңлата.

Мәҗүсилек чорында кайбер халыкларда куркыныч затларны, зыяны тимәсен өчен, үз исеме белән атамау гадәте булган. Аның исемен әйтү тыелган, «табу» салынган. Бу гадәт төркиләргә дә хас. Мәсәлән, татарларда урман хуҗасы аюны бүгенге көнгә кадәр «бабай» дип йөртү гадәте сакланган. Урман алласының (иясенең) курайда уйнавын күздә тотып, аны шүре(ле), ягъни «шүре»се булган зат дип атаулары мөмкин. («Шүре» — көпшә, «шүрелек» — шома көпшә, курай үләне). Ләкин моңа каршы: Шүрәле бит курайда уйнамый! — диючеләре бар. Күп гасырлар үтү сәбәпле, бәлки аның бу гадәте исемендә генә калгандыр. Ә менә музыкаль, хәрәкәтчән бармаклары сакланган!

Бу сүзнең шулай ук тышкы кыяфәткә, холыкка, кайда яшәүгә бәйле рәвештә дә барлыкка килүе мөмкин.

Мәсәлән: Шүрәле куркыта — шүрләү, шөлләү, шөр итү, шыр җибәрү һ. б. Кыяфәт, сыйфат, гадәт — шырсый (җилбәзәк акыллы һәм табигатьле); шырагай (беркатлы, «урман сарыгы»); шыр (шәрә, ялангач, әдәпсез, тәртипсез, тыйнаксыз); җор (шаян, шук); шәр(р) (явызлык, яман эш); шыр акыру (ямьсез тавыш белән кычкыру); шырантай (сузан, озын зат); шырлык (чытырман, урман ешлыгы) һ. б... Телләрәндә шушы сүзләрнең һәркайсыннан диярлек «шүрәле» сүзен китереп чыгарып булыр иде. Моны шулай да тел белгечләренә калдырасы килә. Ләкин «Шүрәле» сүзенең этимологиясен эзләгәндә шушы юнәлештә фикер йөртү дөресрәк булыр шикелле.

Шулай итеп, заманнар узу белән Пан Шүрәлегә әверелә. Болгар-татарның үз мифына әйләнеп китә, киң таралыш ала. Шүрәлене бер генә халыкта туган образ дип әйтүе кыен. Ул — гасырлар дәвамында кайбер үзгәрешләр кичергән җыелма образ булса кирәк. Ләкин Урта Иделгә аны болгарлар алып килгәннәр, үстергәннәр, төбәкнең башка халыкларына да ул болгарлардан күчкән булырга тиеш. Бу образның элекке Болгар дәүләтенә кергән халыкларда гына булуы шуны раслый шикелле.

Шулай итеп Шүрәле — борынгы бабаларыбыз болгарлар тарафыннан Салтау культурасы формалашкан чорларда ук үзләштерелгән образ. Димәк, Салтау культурасы варисларыннан берсе булган казан татарларында аның киң таралган мифик образ дәрәҗәсенә җитүе бер дә гаҗәпләнерлек хәл түгел.

Шүрәле — татар культурасына бик күп «хезмәт» иткән образ. Сәнгатебезнең бер генә төре дә бу образдан файдаланмый калмагандыр, күрәсең.

Фәнгә аны К. Насыйри кертсә, әдәбиятка — Тукай! Музыкага — Ф. Яруллин, сынлы сәнгатькә — Б. Урманче, ә Шүрәлене рәсемгә төшерүче рәссамнарның саны хәтсез. Нинди зур исемнәр, нинди шәхесләр! Шүрәле барысының да игътибарын тарткан, һәркайсы аны үз иҗатында гәүдәләндерергә тырышкан. Очраклы хәлме бу? Юк! Очраклы хәл була алмый! Бу — Шүрәле образының безнең халыкта борынгыдан килгән тамырлары булуы, күңел түренә кереп урнашуы турында сөйли.

К. Насыйри белән Г. Тукайның беренчеләрдән булып аңа мөрәҗәгать итүе үзе генә дә ни тора! Димәк, алар да Шүрәленең күп гасырлар буе халык күңелендә яшәвен аңлаганнар. Болгар-татар тарихы беренче адымнарын гына ясаган ул заманнарда аларга әле күп фактлар билгеле булмаган, әлбәттә. Әмма бу ике шәхес Шүрәленең культурабыз өчен мөһим образ икәнен сизенгәннәр, аны кәгазьгә теркәп, мәңгеләштереп калдырганнар.

**Шәмси Хамматов,**
тарих фәннәре кандидаты

# МУСА ҖӘЛИЛ—ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНДӘ

**Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлилнең иҗаты һәм батырлыгы турында инде шактый язылды. Ә гыйльми эзләнүләр дәвам итә. Бу эштә галимнәргә архив документлары гына түгел, газета-журнал укучыларының язган хатлары да, истәлекләр дә зур ярдәм. Әлеге мәкаләдә китерелгән яңа мәгълүматлар моңа ачык дәлил була ала.**

1924 елның җәендә яшь шагыйрь Муса Җәлил инде танылган әдип Мирхәйдәр Фәйзи белән очраша. Алар «Раскольников» исемле теплоходта, Идел буйлап, үзләренең туган-үскән җирләренә барганда күрешәләр.

1924 елда врачлар Мирхәйдәр Фәйзигә Казан шәһәреннән китәргә, авыл һавасы белән шифаланырга киңәш бирәләр. Ул үзенең туганнары яшәгән Балтач районының Шода авылы якларына барып тора. Бу аның бирегә соңгы тапкыр килүе була.

Аннан кайткач, 1924 елның 23 июлендә үзе үскән якларга — Орскига китә. Мирхәйдәр Фәйзи көндәлек язып бара. Аның белән танышканда, без мондый юлларны очраттык:

«Кесәдә акча кинәрәк җәелергә ирек бирмәстәй булгач, арзан билет алып, «Раскольников» исемле зур теплоходның өченче классында бер уңайлы гына урын биләдем. Третий класс булса да, теплоход булганга һәйбәт, таза, күңелле палубасы бар, пассажирлары юньлеләр.

Пристаньнан килеп кергән бер яшь татар егетен күреп тикшерә башладым. Өченчегә керде, урнашты. Шуның белән танышырга карар бирдем...

Теге егет янына бардым, сүз куштым; ул ачык кына сөйләшеп китте. Минем драматург Хәйдәр Фәйзи, аның шагыйрь Муса Җәлил булып чыгуларыбыз бик кызык туры килеш булды. Җитмәсә, икебез дә Оренбургка. Бу юлдан беренче йөрүе булганга, ул да юлдашка зар икән. Бу яктан эш рәтләнде. Икәүләп карап барып, Казанның матур күренешләрен күздән югалттык...»

Мирхәйдәр Фәйзи һәм Муса Җәлил. Тормышны өзелеп сөйгән, аның матурлыгын җырлаган бу ике шәхеснең юллары кайчан булса да бер очрашырга тиеш булган, әлбәттә.

Авыру Мирхәйдәр Фәйзи юлга чыкканда ук: «Кулым ике, йөрәгем саусыз, багажым дүрт... Ничек кайтып җитәрмен инде»,— дип борчыла. Пароходта Муса Җәлилне очраткач, ул бик шатлана. Бу — Мусаның татар рабфагында укыган чорда туган якларына ялга кайтып барышы була. Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләреннән күренгәнчә, Муса Җәлил аңа әйберләрен күчерешергә булыша, һәртөрле ярдәм итә.

Инде 27 июньдә Мирхәйдәр Фәйзи үзенең көндәлекләрендә болай дип яза:

«Мин хәзер Самара вокзалында: Муса Җәлил билет ала; мин нәрсәләр янында торам».

Алар Оренбургка кадәр бергә баралар. Иделдә пароходта барган чакта Мирхәйдәр Фәйзи Муса Җәлилгә Казан якларының матурлыгы, андагы кешеләр турында да сөйләми калмагандыр.

М. Җәлилнең Казанда, «Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасында эшләгәндә, рабфакта укыганда, Г. Ибраһимов, Г. Камал, М. Фәйзи, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Ф. Шәфигуллин, Ш. Әхмәдиев, Ш. Усманов, Г. Толымбайский, Ф. Сәйфи-Казанлы, һ. Такташ, Г. Кутуй, К. Нәҗми, А. Шамов, К. Әмири, Ш. Рамзи һәм башка әдип-публицистлар белән аралашуы аның иҗат үсешенә уңай йогынты ясаган.

«Татарстан» (аннары «Кызыл Татарстан») газетасында эшләү айларында газетаның җаваплы редакторы Фәтхи Бурнаш, «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналын оештыручыларның берсе буларак, Муса Җәлилгә матбугатта беренче мәкаләләрен, шигырьләрен бастыруда, җыентыкларга кертүдә турыдан-туры ярдәм итә. Мусаның әдәби-журналистлык эшчәнлеге Бурнашның рухи җитәкчелегендә үтә. Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Муса Җәлил 1939 елның азагында Казан шәһәр Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелә. Ф. Бурнаш газетада бу уңайдан «Татар халкының лаеклы улы» дигән мәкалә яза:

«1922 елны ук Казанга күчеп килгәч, аның «Кызыл Татарстан» газетасы, «Безнең юл» журналы битләрендә революцион романтизм белән сугарылган шигырьләре басылды. Шул вакыттан алып Муса Татарстан шагыйрьләре сафына басты...

Җәлил иптәш талантлы журналист, оста җәмәгать эшлеклесе».

Егерменче еллар башында милли әдәбиятыбыз һәм журналистикабыз үсешенә татар әдәбияты классигы, публицист, күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тәэсире гаять зур була. Ул яшь талантларга бик игътибарлы булган. Аның йогынтысы белән канатланган әдипләрдән А. Шамов, М. Максуд, Г. Кутуй, М. Җәлилне күрсәтергә мөмкин. Г. Ибраһимовның «Пролетар әдәбияты турында» Мәскәүдә 1924 елны басылып чыккан китабы әдипләр, журналистлар өчен кулланма булды. Г. Ибраһимов 19 яшьлек М. Җәлилгә биргән китабына менә шундый сүзләр яза:

«Яшь шагыйрь Муса Җәлил иптәшкә ядкарь итәм. Галимҗан Ибраһимов. 1925, февраль».

Муса Җәлилнең мемориаль музей-квартирасына куелган бу тарихи автографлы китапны дулкынланып карыйсың.

Безнең кулыбызда — М. Җәлилнең утызынчы еллар уртасында «Совет язучылары сүзлеге» өчен язган кулъязма автобиографиясе. Ул документта кызыклы мәгълүматлар бар.

«1921 елны,— дип яза ул,— ачлыктан качып, җәяүләп, Оренбург шәһәренә килдем, анда шәһәр базарында 2—3 ай ятим бала сыйфатында йөрдем. Ләкин Төркстан фронтының элекке политуправлениесе работниклары һәм «Кызыл йолдыз» газетасы редакциясе ярдәме белән, яшьлегемә карамастан, хәрби-политик мәктәпкә укырга алындым. Анда алты айлык партия укуында һәм хәрби хезмәттә булдым. Хәрби-политик мәктәпне тәмамлаганнан соң, тиф белән авырып киттем, бер ел чамасы больницада яттым...

1922 елда Казанга килдем. Тугыз ай буе «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә (Тат. ЦИК һәм ВКП(б) өлкә комитеты органы) күчереп язучы (переписчик) булып эшләдем. 1923 елда Татарстан рабфагына кердем, аны 1925 елда тәмамладым».

Чынлыкта исә Муса Җәлил «Татарстан» газетасында күчереп язучы булып кына эшләми, үзе әйткәнчә, «редакциядә эшче-хәбәрчеләрнең беренче оешмасында» була, «өч ай эшче-хәбәрче сыйфатында заводларда һәм фабрикаларда» йөри, «редакциядә газетаның эшчеләр бүлеге мөдире ярдәмчесе» вазифасын үти, эшче-хәбәрчеләр бюросында эшли, үзе дә «шул газетаның эшчеләр тормышы буенча корреспонденты» була.

Мәгълүм ки, М. Җәлил Мәскәү пролетар язучылар ассоциациясе (МАПП) беренче секретаре А. Фадеев белән тыгыз элемтәдә эшли. Ул 1932 елда МАППның өченче секретаре сыйфатында татар язучылары секциясенә җитәкчелек итә. Мәскәүдә яшәүче татар язучылары Ә. Фәйзи, М. Максуд, М. Крымов, М. Галәү, Ш. Маннур, Ә. Еникәй, И. Агишев исеменнән Совет Язучылар союзын оештыру комитетына хат белән ул мөрәҗәгать итә. «Докладная записка»да Мәскәү татар пролетар язучылары иҗатының илебездә милли әдәби хәрәкәте үсешенә җитди тәэсир итүе аңлатыла, әдипләрнең нәтиҗәле эшләве өчен вакытлы матбугатның ярдәмен тагын да көчәйтү кирәклеге әйтелә. Бездә саклана торган бу язмада:

«Мәскәүдә һәм Татреспубликадан читтә татарларның әдәби хәрәкәтен киң үстерү башкаладагы һәм башка районнардагы гаять зур татар язучылары массасының иҗади эшчәнлеген киңәйтү өчен хәзер Мәскәү шәһәрендә бер әдәби-художество журналын оештыру бик кирәк. Шунлыктан без, Мәскәү шәһәрендәге татар язучылары, Дәүләт художество әдәбияты нәшрияты каршында шундый журнал ачуга булышлык итүне оештыру комитетыннан үтенеп сорыйбыз»,— диелә.

«Казан утлары» журналы редакциясенә Астрахань педагогия институтында эшләүче Наил Бәшировтан Муса Җәлилнең Киленче авылында булуы турында ВЛКСМ өлкә комитеты органы — «Комсомолец Каспия» исемле газетада басылган ике мәкалә килде.

Әүвәл М. Җәлилнең Астрахань ягында булу тарихына бераз аңлатма биреп үтик. Коммунист-журналист Муса Җәлил партия Үзәк Комитетының күрсәтмәсе белән Мәскәүдә чыккан «Коммунист» газетасы редакциясе тарафыннан Түбән Идел крае (хәзерге Саратов өлкәсе) Дергач районына күчмә газетаның җаваплы редакторы итеп җибәрелә. «Коммунист» газетасының күчмә редакциясе Астраханьда чыккан «Ялкын» газетасы — ВКП(б)ның Түбән Идел крайкомы һәм башкарма комитеты органы белән берголәп эшли.

Казанга Астраханьнан 1933 елның 28 июлендә язган бер хатында М. Җәлил болай дип хәбәр итә:

«Мин 20 нче мартта Мәскәүдән Түбән Идел краена язгы чәчүгә чыгып киткән идем. Шуннан бирле кайтканым юк әле. Түбән Иделдә Дергач дигән бер район бар. Мин шунда күчмә газет чыгарып яттым. Язгы чәчү белән бергә утау, пар күтәрү, печән, уборкага әзерлек кампанияләрен үткәрүгә дә хезмәт иттем. Шул ук вакытта районда даими татар газеты чыгару шартларын тудырдым. Ул мәсьәлә районда чишелде, һәм наборщик, хәреф, типография, смета, кәгазь төсле кирәкле шартлар әзерләнде... Үзем 11 июльдә Дергачтан чыгып киттем».

М. Җәлил Дергач районында дүрт ай чамасы булган көннәрдә «Коммунист» һәм «Ялкын» газеталарында утыздан артык мәкалә, очерк, юлъязма, фельетон һәм шигырьләр бастырган.

Шагыйрь, күчмә газетада эшен тәгәлләгәннән соң, 1933 елның 16 июлендә Астраханьга килә. Ул анда әдәбият сөючеләр, журналистлар белән очраша, чыгыш ясый. Аның иҗаты турында матбугатта мәкаләләр басыла.

М. Җәлил «Ялкын» газетасы редакторы Шакир Фәтхуллин белән бергәләп Нариман районы Киленче авылына бара. Калинин исемендәге колхоз председателе Ибраһим Мәхмүдов белән таныша. Ибраһим Мәхмүдович аны «тәбәнәк буйлы, тыйнак, сөйкемле егет иде» дип искә ала. Август ае башында Муса авылда берничә көн яши. Мәхмүдовлар йортының түрендә хәзер дә шагыйрь йоклаган карават саклана. Ибраһим ага М. Җәлилнең «Күк юрга» шигырен укыгач, кадерле кунакның колхоз кырлары буеннан күк ат белән йөргәннәрен искә ала.

М. Җәлилнең Астрахань, Киленче якларында булу тәэсирендә язган, Ватаныбызны чит ил дошманнарыннан сакларга, уяу күзле булырга өндәгән шигырен рухланып укыйсың:

*Алтын бодай бу кырда —*
*Безнең көчнең җиләге.*
*Дошман килсә кыркырга,*
*Без бирербез кирәген,*
*Без бирербез кирәген,*
*Күк юрга!*
*Дошман килсә сөйрәлеп бу кырга...*

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивында Киленче авыл Советына кергән Калинин исемендәге колхозның ВКП(б) ячейкасының 1933 ел, 7 августта булган гомуми җыелышы беркетмәсенең күчермәсе саклана. Аны хәзерләүдә һәм үткәрүдә партия члены, «Коммунист» үзәк күчмә газетасы редакторы Муса Җәлил дә катнашкан.

Җыелышта беренче итеп РСДРПның II съездының утыз еллыгы һәм аның тарихи әһәмияте турындагы мәсьәлә тикшерелгән. Доклад белән колхоз председателе И. Мәхмүдов чыккан.

«Киленче колхозы бригадаларында партия-масса эшенең торышы, массовый эшне һәм авыл хәбәрчеләрен җанландыру бурычлары турында»гы икенче мәсьәлә буенча М. Җәлил доклад ясаган.

Коммунист-шагыйрь партҗыелыш карарының проектын үз кулы белән язган, проект үзгәрешсез диярлек кабул ителгән. Карарда түбәндәгеләр әйтелә:

«1. Калинин исемендәге колхозның производство бригадаларында партия-масса эшенең торышын канәгатьләнмәслек дип исәпләргә. Бригадаларда партия укуы буенча системалы занятиеләр үткәрелми, дип күрсәтергә. Бригадаларда стена газеталары регуляр чыгарылмый... Колхоз стена газетасы чыгарылмый. Газеталарга язылмыйлар. Культура эшчесе Хисмәтуллина культура эшен өзә. Комсомол ячейкасы эшен һич тә җитәрлек җәелдерми.

Шушы фактлардан чыгып, ячейка бригадаларда партия-масса эшен үзгәртеп коруны, аны яхшырту ягына таба текә борылыш ясауны кирәк саный. Моның өчен:

2. Парторглар һәм партия тарафыннан беркетелгән кешеләрнең эшенә нык контроль булдырырга. Аларга конкрет заданиеләр бирергә һәм ун көн саен үтәлешен тикшерергә.

3. Райкомның культура-пропаганда программасы буенча бригадаларда системалы партия укуын оештырырга...

4. Производствода активлыкны һәм кайбер коммунистларның норма өчен көрәшен тикшереп, производство эшен өзүче коммунистларны партия линиясе буенча җаваплылыкка тартырга.

5. Бригадаларда иң яхшы ударниклардан партиясез активның һәм аңа булышучыларның нык ядрәсен булдырырга, аларны партия укуына тартырга, тәрбияләргә һәм актив эшкә куярга.

6. Наданлыкны бетерү эшен оештырырга. Партия членнарын һәм комсомолларны укый-яза белмәүчеләргә беркетүне практикага кертергә. Бу эштә комсомол инициативасын күрсәтергә.

7. Социалистик договорларның үтәлешен тикшерергә һәм аның нәтиҗәләрен колхоз газетасында, ярыш такталарында игълан итәргә...

8. Бригада стена газеталарын биш көнгә бер тапкыр чыгаруга ирешергә...

9. Ударникларны аерып күрсәтү чараларын күрергә...

10. Газеталарга подпискалар җыю эшен көчәйтергә, аларны кычкырып укуларны оештырырга.

11. Сакчылар, каравылчылар, объездчиклар слетларын үткәрүне практикага кертергә.

12. Авыл хәбәрчеләре хәрәкәтен көчәйтергә...

13. Колхоз өчен 100 данә «Ялкын» газетасы һәм 100 данә «Коммунист» газетасы яздырырга. Бригадалар буенча шул кадәр үк подписка җыюга ирешергә».

ВКП(б) ячейкасының җыелыш беркетмәсе, аның Муса Җәлил кулы белән язылган күчермәсе, ВКП(б) ячейкасы секретаре Кильдеев имзасы авыл Советы печате белән расланган.

Шулай итеп, шагыйрь-журналист М. Җәлил, Калинин исемендәге колхозда командировкада булганда, иҗтимагый-политик эшлекле буларак, авылның партия-масса һәм культура эшенә шактый тирән үтеп керә.

Инде Астраханьнан килгән, «Комсомолец Каспия» газетасында басылган Н. Бәшировның мәкаләсеннән берничә өзек китерик:

«Без үзебез — төп шушы як кешеләре,— дип яза ул.— Әбием белән бабам Астрахань өлкәсе Киленче авылында яшиләр иде. Бабам — Ибраһим Мәхмүдов ул елларда колхоз председателе булып эшләде. 1933 нче елны Мәскәүдә чыга торган СССР Милләтләр Советы Үзәк Башкарма Комитеты органы булган «Коммунист» газетасы корреспонденты шагыйрь Муса Җәлил килде, дип сөйләде бабам. Әдәбиятсәнгать бүлеге мөдире булып эшләгән Җәлил, фольклор белән генә түгел, колхоз эшләре белән дә якыннан кызыксынган. Халык белән очрашканда ул әдәби мәсьәләләр, күмәкләшү турында, яңача хезмәт итүнең тәэсире хакында да сөйләгән. Муса

Җәлил колхоз кырлары буйлап та йөри, терлекчелек фермаларында була, балыкчылар белән дә очраша. Халык алдында берничә тапкыр чыгышлар да ясый... Ике атна эчендә Муса Җәлил бик күп эшләгән. Уйлавымча, безнең як Астрахань җирендә алган тәэсирләре яңа шигырьләр булып та дөнья күргәндер. Җирле «Ялкын» газетасында шул елларда чыккан мәкаләләре язучының актив эшләве турында сөйли...

Кичләрен Ибраһим өенә, шагыйрь янына колхозчылар килә торган була. Язучы алар белән бик теләп, бик озаклап матур итеп гәпләшә. Ә иртән иртүк, башка кешеләр уянганчы, торып, елгада су керә һәм кырларны әйләнеп кайта. Иртә белән бу якларда татар чәе эчәргә өйрәнгәннәр. Ләкин Муса Җәлилгә бу чәй ошамый. һәм аңа чәйне Казанча әзерлиләр. Председательнең тормыш иптәше Салиха апа сөйләвенчә, Муса Җәлил биредә күрше Мешәих авылында комсомол туенда да була. Кыскасы, шагыйрь Астрахань далаларындагы татар авылларының тулы тормышын күреп, тоеп, бу тормышта үзе катнашып китә. Күргәннәре, кичергәннәре тәэсирендә иҗат ителгән шигырьләр шактый. Ләкин бу якларда алган тәэсирләре «Моабит дәфтәрләре»ндәге кайбер шигырьләрдә дә чагыла».

М. Җәлил Мәскәүдә вакытлы матбугатта эшләгән дәвердә ВЛКСМ Үзәк Комитеты белән даими элемтәдә тора, төрле газета-журналларда бик еш чыгыш ясый. Журналист А. С. Лозовой редакциягә Казан химия-технология институтының күп тиражлы «Химик» газетасын китергән иде. Газетаның 1966 елгы 12 февраль санында партия, комсомол ветераны З. А. Әхмәтшин М. Җәлил турында болай дип яза:

«Беренче очрашу Мәскәүдә ВЛКСМ Үзәк Комитетында 1933 елда булды. Ул вакытта мин анда эшли идем. Муса ВЛКСМ Үзәк Комитеты белән тыгыз бәйләнгән иде, ул «Октябрь баласы» журналында хезмәттәшлек итә һәм еш кына «Коммунист» газетасы битләрендә мәкаләләр бастыра, яшьләр тормышын киң яктырта иде.

Ул вакытта аның кереп кул биргәнен, елмаеп, мине ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетындагы эш буенча күптән белүен әйткәен хәтерлим. Ул Саша Косарев (А. Косарев — ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре. Ш. Х.) янына килгәнен, әмма аның өлегә булмавын аңлатып бирде. Косаревны көткәндә без төрле темаларга сөйләшеп утырдык. Муса болай диде: «Сез мине комсомолда оештыру эшен яратасыз, ә мин яшьләргә каләмем белән йогынты ясарга тырышам. Мин шушы фронтны сайлап алдым, һәм аннан читенүнең булуы мөмкин түгел».

Чама белән 30 минуттан соң безнең янга Саша Косарев килеп керде. Мусаны күргә ул: «Саумы, комсомол шагыйре! Эшләр ничек? Киттек, сөйләшеп утырырбыз»,— диде, һәм алар чыгып киттеләр...

Муса Җәлил минем янга икенче тапкыр кызыл профессура тарих-партия институтында укыган чагымда килеп керде. Бу 1935 елның август-сентябрендә иде. Ул, минем бу институтта укуымны белеп, эзләп табуын, чөнки үзенең дә кызыл профессура әдәбият институтына укырга керергә ниятләвен һәм аңа консультация кирәк булуын әйтте. Аны мондагы тәртипләр, тормыш-көнкүреш һ. б. кызыксындырды».

М. Җәлил үзәк матбугатта татар әдәбияты классиклары иҗатын пропагандалауга зур игътибар бирә. Шәриф Камалның әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенә утыз ел тулу уңае белән ул «Правда» газетасының 1940 елгы 29 март санында махсус мәкалә бастыра. Казан китапханәләрендә сакланмаганлыктан, без ул язманы Мәскәүдән, СССРның Ленин исемендәге дәүләт китапханәсеннән соратып алдырдык, аннан шундый юллар укырга мөмкин:

«Бүген зур татар совет язучысы Шәриф Камалның әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенә 30 ел тула,— дип яза М. Җәлил.— Ш. Камал яшьлек елларыннан бирле үзенең язмышын хезмәт иясе халкы тормышы белән бәйли. Әле дини схоластик мәктәптә — «мәдрәсәдә» укыган елларында ук ул Мәскәү—Казан тимер юл төзелешендә кара эшче, ә аннары Екатеринослав губернасындагы күмер шахталарында сәнәкче һәм забойчы булып эшләгән... Ул әдәбиятка татар эшчеләре тормышына багышланган кечкенә хикәяләр сериясе белән килде.

Аның «Уяну» исемле беренче хикәясе (1909 ел) капиталистик изү аркасында кешелек хисләрен югалткан гомерлек ачулы һәм сәрхүшнең, җәберләнгән эшченең образын сурәтли. Шәриф Камалның башка хикәяләре дә хезмәт кешеләренә кайнар мәхәббәт һәм изүчеләргә карата нәфрәт белән сугарылганнар: «Чит илдә», «Козгын-

нар оясында», «Ата», «Бәхет эзләгәндә», «Сукбай» һәм, ниһаять, сокландыргыч «Акчарлаклар» повесте...

Татар халык шагыйре Г. Тукай (1886—1913) һәм драматург Г. Камал (1879—1933) белән бергә, Шәриф Камал революция алды елларында татар демократик әдәбиятының күренекле вәкиле була.

Октябрь социалистик революциясе җиңүеннән соң Шәриф Камалның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге аеруча киң колач ала. Революциянең беренче көннәреннән ук әдип нык инану белән Совет властен яклаучылар сафына баса. 1919 елда ул Коммунистлар партиясенә керә һәм Оренбургта Кызыл Армиянең фронт матбугатында актив иҗтимагый-политик эш алып бара. Оренбургта Совет властен урнаштыру өчен көрәш чорын язучы «Таң атканда» исемле зур күләмле романында яктырта...

«Таң атканда» романыннан соң ук Шәриф Камал авыл хуҗалыгында социалистик үзгәртеп корулар һәм авылда сыйнфый көрәш турында зур эпопея иҗат итәргә керешә; беренче китап — «Матур туганда» — 1937 елда дөньяга чыкты; икенче китап — «Ныклы адымнар» — басарга хәзерләнә...

Октябрь революциясеннән соң Шәриф Камал эшчеләрнең революцион көрәше һәм СССРда социалистик төзелештәге җиңүләр турында күп кенә пьесалар иҗат итте.

Шәриф Камалның әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенең утыз еллык юбилее — татар совет культурасының зур бәйрәме».

КПССның Татарстан өлкә комитетының партия архивында, Татарстан АССР Үзәк дәүләт һәм СССР Оборона министрлыгының Үзәк архивларында Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Муса Җәлилнең каләмдәшләре Нур Баян, Гомәр Бәширов (Г. Разин), Гази Кашшаф, Ибраһим Гази, Әхмәт Исхак, Әхмәт Ерикәй турында Бөек Ватан сугышы алдыннан, 1939—1941 елларда, рус телендә язылган иҗат характеристикалары сакланган. Шулардан кайбер өзекләр китерик.

«Нур Баян,— дип яза ул Нур Баян иҗатына карата,— өзлексез әдәби иҗат эшчәнлеге унбиш еллык стажга ия булган күренекле татар совет шагыйре. Аның шигырьләре һәм поэмалары халкыбызның оборона, Совет илен ныгыту өчен героик көрәшен чагылдыралар. Аның әсәрләре матбугатта 1925 елдан басыла башлый. Озак та үтми, татар укучылары арасында танылa. Иптәш Нур Баян, партия һәм комсомолның актив работнигы булган хәлдә, үзенең иҗатында политик яктан актуаль һәм мөһим проблемаларны тирән тойды һәм үз вакытында чагылдырды...

Нур Баян заманыбызның иң кискен темаларын тотып ала белә һәм аларны югары осталык белән чишә. Хәзерге вакытта ул Вахитов исемендәге заводның производство уңышларына багышланган «Гөләндәм» исемле поэмасын тәгәлләде һәм бастырып чыгару өчен тапшырды. Бу поэмада социалистик промышленность геройлары күрсәтелә.

Коммунист-язучы буларак, ул үсеп килүче яшьләргә актив ярдәм күрсәтә, җәмәгать эшендә актив катнаша, Язучылар союзының барлык мөһим мәсьәләләренә сизгер карый һәм аларны дөрес хәл итәргә булыша. Хәзерге вакытта ул — Татарстан Язучылар союзының башлангыч партия оешмасы секретаре.

Нур Баян рус әдәбияты классиклары һәм тугандаш халыклар әдәбиятларын татар теленә тәрҗемә итүдә күп эш башкарды. Мәсәлән, Пушкин, Некрасов, Лермонтов, Шевченко, Руставели, Җамбул һәм башкаларның әсәрләрен тәрҗемә итте».

Гомәр Бәширов турында М. Җәлил болай дип язган:

«Иптәш Гомәр Разин — татар совет әдәбиятының танылган язучыларының берсе. Ул 1933 елда иҗат итә башлады, балалар өчен язды. Бу — аның иҗат эшенең башлануы. Шуннан соң ул гражданнар сугышы тарихыннан «Сиваш» повестен язды. Татар укучылары бу китапны бик яратып укыйлар.

1939 елда ул «Урман шаулый» дигән яңа хикәяләр бирде. Алар совет интеллигенциясе һәм бүгенге колхозчылар тормышын чагылдыра. Иптәш Разин нәфис сүз остасы буларак танылды.

Моннан тыш ул татар халкы фольклорын җыйнау һәм классификацияләү буенча эшли. Иҗтимагый-политик тормышта актив катнаша».

Тәнкыйтьче, әдәбият белгече Гази Кашшаф турында мондый юллар бар:

«Иптәш Г. Кашшаф прозаик һәм тәнкыйтьче буларак танылды. Аның беренче хикәяләре һәм тәнкыйть мәкаләләре 1928 елда басылып чыкты... Ул ике повесть язды: производство темасына «Фазлыев» һәм оборона темасына — «Чик буенда» дигән повестьлар.

Әмма ул тәнкыйтьче буларак активрак яза. Ул — татар совет әдәбиятының алдынгы тәнкыйтьчеләреннән берсе. Аның Тукай, Г. Камал, һ. Такташ һәм башкалар иҗаты турындагы мәкаләләре тирән эчтәлекле, мәсьәләне аңлап язылганнар.

1940 елдан ВКП(б) членлыгына кандидат. Җәмәгать тормышында актив, политик яктан грамоталы».

«Татар совет язучысы Ибраһ Гази,— дип яза М. Җәлил,— әдәби эшчәнлеген 1929 елда эшчеләр тормышыннан хикәяләр сериясе белән башлады. «Бөек борылыш еллары», пролетариатның бөтен фронт буенча һөҗүме аның «Кичке алтыда», «Көмеш сулы Нурминка», «Бригадир кыз» дигән хикәяләрендә чагылды. 1939 елда ул совет яшьләре тормышыннан, Ватанга бирелгәнлек, патриотизм турында «Катя Сорокина» исемле яңа повестен тәмамлады...

Аның әсәрләре теленең, образларының җентекләп эшләнгән булулары белән аерылып тора. Политик яктан бик грамоталы, тотнаклы һәм дисциплиналы иптәш».

СССР Оборона министрлыгының Үзәк архивында М. Җәлилнең Әхмәт Исхакка биргән характеристикасы бар. Менә аннан бер өзек:

«Иптәш Әхмәт Исхак татар совет поэзиясенең иң күренекле вәкилләреннән берсе һәм талантлы шагыйрь булып санала. Ул 1924 елдан үзенең шигырьләрен бастыра башлады. 15 ел дәвамында безнең илебездә социализмның җиңүен чагылдырган, поэтик формада бөек совет патриотизмы хисләрен, коммунизм эшенә бирелгәнлекне, безнең совет яшьләренең хезмәткә яңа мөнәсәбәтен гәүдәләндергән күп әйбәт поэмалар һәм шигырьләр язды. Иптәш Исхаков тарафыннан совет тематикасына күп җырлар язылды, алар массалар арасында киң популярлык казанды...»

СССР Язучылар союзы идарәсе җитәкчесе А. Фадеевка 1940 елның 4 февралендә язган хатында Әхмәт Ерикәй турында менә нәрсәләр хәбәр итә:

«Иптәш Ә. Ф. Ерикеев — татар совет поэзиясен үстерүдә мәгълүм хезмәтләре булган күренекле татар шагыйрьләренең берсе. Ул бөтен бер цикл гүзәл лирик шигырьләр һәм җырлар иҗат итте...

Моннан тыш, иптәш Ерикеев художестволы тәрҗемә өстендә дә эшли. Ул Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Хетагуров, Руставелиның һәм совет шагыйрьләренең шигырьләрен тәрҗемә итте...

Иптәш Ерикеев шулай ук опералар өчен либреттолар өстендә дә яхшы эшли».

1929 елдан КПСС члены М. Җәлил Коммунистлар партиясенең алдынгы интеллигенция вәкилләре исәбенә үсүенә дә игътибар итә. Ул, мәсәлән, язучы Гази Кашшафка, артисткалар Мәрьям Рахманкулова, Мөнирә Булатовага партиябез сафларына керергә рекомендацияләр бирә. Ул 1941 елның 5 маенда ВКП(б) членлыгына керү өчен Мәрьям Маннаповна Рахманкуловага биргән рекомендациясендә аны «политик яктан хәзерлекле, кешеләргә игътибарлы» дип күрсәтә. М. Җәлил биргән рекомендацияләр КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивында сакланалар.

Татарстан АССР Үзәк дәүләт архивында «Кызыл Татарстан» газетасына утызынчы-кырыгынчы елларда язган әдипләрнең шактый кульязмасы бар. М. Җәлилнең газетада басылган «Татар опера театры ачылу алдыннан» исемле мәкаләсенең 1939 елның җәендә язылган кульязмасы табылды. Мәкаләдә М. Җәлил болай дип яза:

«Татар совет операсының төзелүе — бик зур тарихи политик әһәмияткә ия булган факт. Театрның ачылу көне халкыбызның зур культура бәйрәме көне булачак һәм большевиклар партиясе җитәкчелеге астында, халкыбызның тирән мәхәббәте, ярдәме нигезендә опера көннән-көн үсә, тулылана һәм яхшыра барачак».

М. Җәлил Татарстан Совет язучылары каршындагы әдәби секцияләрнең эшен даими игътибар үзәгендә тота. Секция бюросы җитәкчеләреннән конкрет эш планы төзүне, аны коллектив тикшерүгә һәм идарә каравына кертүне таләп итә. Ул, мәсәлән, 1940 елның 25 гыйнварында фольклор секциясе бюросы җитәкчесе Хәмит Ярмига менә мондый хат җибәрә:

«План төзегәндә төп мәсьәләләр итеп иҗат мәсьәләләрен куйган хәлдә, эш формаларын төрләндерү һәм җанландыруны күздә тотыгыз. Секция утырышлары гел

бер төрле, бюрога тәкъдим ителгән әсәрләрне генә укудан гыйбарәт булып калмасын, бюро үзе язучылар алдына актуаль проблемалар куйсын, аерым иҗат мәсьәләләре буенча дискуссияләр оештырсын, аеруча язучыларның игътибарын партия һәм хөкүмәтнең куйган актуаль политик бурычларга тупларга кирәк...

План 1/II да тапшырылырга тиеш.

Сәлам белән: М. Җәлил.

25/II-1940 ел».

Татарстан АССР Үзәк дәүләт архивында республика Язучылар союзы җитәкчеләгенең 1941 елның сентябрь аенда СССР Язучылар Союзы Президиумы идарәсенең җаваплы секретаре А. Фадеевка язган хаты саклана. Анда Татарстан Совет Язучылар союзы идарәсе, аның башлангыч партия оешмасы халык тарафыннан үзләренең әдәби әсәрләре белән күптән танылган күренекле әдипләр Муса Җәлил, Мәхмүд Максуд, Сибгат Хәким, Абдулла Алиш, Гариф Галеевларның Бөек Ватан сугышы фронтының алгы позициясеннән, аларны саклап калу өчен, тылга җибәрүне үтенеп хат язалар.

М. Җәлилгә Минзәләдә, хәрби-политик курсларда укыган көннәрдә армиядә хезмәт итүдән азат итәргә дигән хәбәр килә. Ләкин ул үзе тылда калудан баш тарта. М. Җәлил белән курсларда бергә укып, аны тәмамлаган партгрупорг Әхмәдел Исхаков үзенең истәлекләрендә болай яза:

«Шулай курсантлар белән сөйләшеп торганда, Җәлил килеп чыкты»,— ди ул.— Күрештек. Ул миннән:

— Китәсеңме?— дип сорады. Без инде приказ алган идек, шуңа күрә:

— Китәм. Ә сез?— дип сорадым.

— Миңа миңа китмәскә диләр бит әле. Ләкин мин монда калмыйм. Барыбер фронтка китәчәкмен,— диде Җәлил.

Чыннан да, Муса Җәлилне курсларның партия комитеты секретаре итеп калдырырга булганнар иде. Ләкин ул фронтка җибәрүләрен нык даулап йөрде».

Төньяк Осетия автономияле республикасында туган, хәзер Кисловодск шәһәрендә яшәүче партия, сугыш ветераны ике Ленин ордены кавалеры, отставкадагы майор Сәид Токаевның «Социалистик Татарстан» газетасы музеенда саклана торган хатында да шагыйрь иҗатына һәм тормышына кагылышлы мәгълүматлар бар:

«Мин Ставрополь, Краснодар крайлары, Ростов өлкәсе, Төньяк Кавказ, Идел буе автономияле республикаларыннан, шул исәптән, Татарстан АССРдан да килгән егетләр белән Курск өлкәсенең Марьино авылында урнашкан политработниклар курсларында укыдым. Укулар 1941 елның 28—29 июнендә башландылар. Без анда өч ай дәвамында белем алырга тиеш идек... Бүлмәдә без биш кеше яшибез. Шуларның дүртесе татарстанлы иптәшләр. Кайберләренең исем, фамилияләрен яхшы хәтерлим: М. Байчаев, Ә. Фәйзалиев, Муса Җәлил.

Мусаның танылган татар совет шагыйре икәнен белә идем. Аның турында миңа татар егетләре тәфсилләп сөйләделәр. Мусаны без уен-көлкеле, көләч йөзле, оптимистик рухлы булганлыгы өчен бик ярата идек. Аның үзе укып күрсәткән шигырьләрен йотлыгып тыңлыйбыз. Җәлилнең әсәрләре тирән патриотик рух белән сугарылган. «Фашист җанварларына үлем!»— дигән сүзләре әле дә хәтеремдә саклана. Занятиеләрдә ул иң активлардан саналды... Марьино курслары 1941 елның 30 сентябреннән 1 октябрьга төндә ябылдылар һәм курсантлар берничә зур эшелонда Мәскәүгә озатылдылар. Анда курсларны тәмамлаучылар баш ПУРККАга, ә аннан хәрәкәттәге армиягә җибәрелде. Шулар белән мин дә фронтка киттем. Ә Муса Җәлил группасы курсантлары укуны дәвам итү өчен Татарстанның Минзәлә шәһәренә җибәрелделәр...

Бу Муса белән соңгы очрашу булган икән. Фронтта мин бик күп авыр юллар үттем. Тик, кызганыч, Марьинода бергә-бергә укыган иптәшләрнең берсе белән дә очрашырга туры килмәде. Инде сугыштан соң бик күп еллар үткәч, мин Муса Җәлилнең фаҗигале язмышы һәм героик көрәше турында ишеттем».

Күргәнегезчә, хөрмәтле укучылар, халкыбызның батыр улы узган данлы юлда яңадан-яңа мәгълүматлар ачу мөмкинлекләре шактый күп. Муса Җәлил — халкыбыз күңеленә тирән эз салган шагыйрь. Без журналның бу санын укучылар арасында да әлеге эзләнүләргә яңа мәгълүматлар өстәрдәй иптәшләр булуына ышанып калабыз.

## Хәмзә Бәдретдинов

# БИШЬЕЛЛЫКЛАР ТӨСЕ

ОЧЕРК

Туган авылы Янгилде басуында салам җыя иде. Төшке ял җитеп килсә дә, ул колхоз үзәгендәге ашханәгә трактор куарга ашыкмады. Мондый якын җирдә эшләгәндә, аңа диган сыйны кырга китереп бирәләр.

Әтиләренә аш илтүне җиде яшьлек Наташа белән алты яшьлек Сергей үз өсләренә алдылар. Әниләре Валентина төйнәп биргән ризыкларны сумкага утыртып, ике яктагы баудан икесе тотып, шактый ерактагы эскертләргә таба, горур атлап китә торган булдылар. Әниләре аларны тәмле сүз белән озатып кала.

Авыл кешеләре Наташа белән Сергейга сокланып карыйлар, кыз белән малайның бик дус йөрүләренә ихлас күңелдән шатланалар. Шул ук вакытта, чаклы пальто, җылы бүрек, чигешле бияләй кигән Наташаның йөзендә якты дөньядан иртәрәк киткән Татьянаның — Василийның беренче хатынының чалымын күреп, эчтән генә сызланалар да.

— Бу матур кызыкайга үз әнисенең назы насыйп булмады шул,— диләр алар үз-үзләренә.— Наташа беренче сулышын алганда, больницаның операция өстәлендәге Татьяна дөньядан күчте...

Шушы көнне, моннан сигез ел элек, инде ике кызга — Галя белән Надяга ата булырга өлгергән Василий тол калды. Ана сөтеннән өзелгән өченче ятимәне — Наташаны исә, бөтен авыл күз алдында балалар йортына алып киткән иделәр. Василий бу нарасыен да читтә озак яшәтәсе килмәде, аны төп нигезгә тизрәк кайтарырга теләде. Шуны уйлап, ярты ел узгач, ул өйләнде. «Кызларны чит итмәм», диючесе, ирдән яшьли калган Валентина Федоровский авылыныкы иде.

Сергей — Василий белән Валентинаның уртак бәхете, ул гаиләдә бердәнбер малай. Зур үсте инде. Апасы Наташа белән әтисенә аш илтерлек булды.

Бүген алар әтиләренә аш-сулар гына китермәделәр.

— Әти, монда синең турыда язганнар! — дип, тракторчының майлаган кулына газета да тоттырдылар.

Газетага СССР Верховный Советы Президиумының чираттагы Указы басылган, анда Татарстанның Апас районы Тукай исемендәге колхоз тракторчысы Василий Игнатьевич Аверьяновның I дәрәҗә Хезмәт Даны ордены белән бүләкләнүен хәбәр иткәннәр иде.

«Сельская жизнь» газетасын бригадир Мөнирә Камалиева да кырда ук укыды.

— Котлыйм, авылдаш! — дип, кулын Василийга сузды ул. Аннары: — Син Хезмәт Герое бит хәзер! — диде.

— Артык зур үстермә! — Василийның тыйнаклыгы билгеле иде инде. Бу юлы да ул үзе турындагы сүзне куерту ягында түгел иде.— Нинди герой булыйм мин?

— Нишләп? Бөек Ватан сугышында Дан орденының өч дәрәҗәсен дә алган Ислам Насыйбуллин исемен, әнә, Советлар Союзы Геройлары белән бергә йөртәләр ич!

— Анысы шулай да инде, тик барыбер алай ук кычкырмыйк әле. Орден минем өчен — унберенче бишьеллык төсе ул.

Алдагылары да шулай — тугызынчы, унынчы бишьеллыкларны хәтерләтеп торалар...

Илебезгә Советлар Союзы Герое Салават Кәримовны, Социалистик Хезмәт Герое, академик, кукурузчы-селекционер Гайфетдин Галиевне биргән, руслар һәм татарлар гасырлар буе бердәм гаилә булып яшәп ятучы кечкенә генә Янгилде авылының хат ташучысы Руфия бу көнне Аверьяновлар йортына котлау телеграммалары да китергән иде. Тик Сергей белән Наташа аларын кырга алып бармадылар. «Терлек карап көрсәм хәлем яхшыра, өйдә генә утырсам — авырый башлыйм»,— дип сөйләнергә яратучы сиксән өч яшьлек Игнатий ага телеграммаларны кичен генә, Василий эштән кайткач кына бирде.

Берсе — КПССның Татарстан өлкә комитетыннан, икенчесе — КПССның Апас райкомыннан, өченчесе — Игнатийның Мурманск шәһәрендә токарь булып эшләүче улы Владимирдан. Ул да, күрәсең, газеталарны укып өлгергән. Сигез егет-кызга канат биргән төп нигездәге шатлыкны уртаклашырга ашыккан. 1982 елда һәр гектардан утыз дүртәр центнер уңыш алып, игенчелек буенча Апас районында дан тоткан үз колхозындагы абыйсының Хезмәт Даны орденнарының тулы кавалеры булуын ишеткәч, ничек ашкынмасын!?

Шул ук көнне Василийга «Йолдыз» газетасы каршындагы «Тамчылар» әдәбият һәм сәнгать берләшмәсе члены, һәвәскәр шагыйрь Габбас Хафизовтан да хат килде. Хезмәт батырын тәбрикләп, үз итеп шигырь җибәргән иде ул!

— Авылда калмасаң, бу орденнарның йөзен дә күрмәс идең әле,— диде Игнатий ага әлеге кадерле кәгазьләрне улына сузгач.— Хәтерендәме, 1958 нче елда, армиядән кайткач, читкә китмәкче идең. Мин каршы төштем. Сине үзем эшләгән Мөрәле МТСына укырга җибәрдем.

— Рәхмәт, әткәй! — Василий шулай җавап кайтарды.— Һөнәр сайлаганда, киңәшче бик кирәк ул! Кайберәүләр шикелле: «Авылда нужарып ятма»,— дип шәһәргә китәргә үгет бирмәвең өчен рәхмәт!

— Үзеңә дә рәхмәт, улым,— диде ата баласына.— Син дә безне ташламадың бит. Картлыгыбызга рәхәтлек алып килдең. Синсез, сиксәнгә җиткәч, сыер да асрый алмаган булыр идем әле. Ә авылда сыерсыз яшәү — мәгънәсезлек. Бу — итсез, сөтсез, катык-майсыз, эремчексез калу дигән сүз. Дөрес, сатып алыр идең анысы. Ә без дә сатып алгач, кала кешесе нишли инде? Ит-сөт авылда чыгарга тиеш бит инде ул...

Игнатийның үзен дә колхозның беренче председателе Әкрам Вәлиев МТСка җибәргән иде.

— Укы, тракторга утырырсың,— диде.

Тик, кызганычка каршы, «корыч айгырны» йөртергә насыйп булмады шул егеткә. Рәхимсез авыру укуын өзде. Ә терелгәч, Игнатий кулына сажен тотты. Көннәр буе басуларда булды. Тракторчылар хезмәтен төгәл исәпләп йөрде.

Ул башкарган эшкә социалистик ярышның тәэсирле көче турыдан-туры бәйле иде. Уңганнарның күрсәткечләре аны да шатландырды. 1935 нче елның декабрендә илебез Татарстан тракторчыларының хезмәтен югары бәяләп, унбиш иптәшне Ленин ордены белән бүләкләгәч, Игнатий Зур Русак егете Кашаф Садриев белән Шыгайда туып үскән механизатор Гали Гатиятуллинның кулларын кысты. Мөрәле кызы, тракторчы комсомолка Нурдидә Вәлиеваның колхозчы-ударница булып танылуын күргәч тә сөенде Игнатий.

Аксакал бүген дә горурланып искә төшерә әле:

— Аларның исемнәре Татарстан тарихына кереп калды бит! — ди.

Аның улы Василий да, әлеге кыр батырлары юлыннан үтеп, республикада беренче буларак, Хезмәт Даны орденының һәр өч дәрәҗәсен алды менә! Дөрес, Василий Игнатьевич бу зур бүләкләрне үзенеке генә дип кабул итми.

— Миннән чын тракторчы «ясауда» Нәфикъ абыйның өлеше бик зур! — ди ул.

Нәфикъ Сафин — Василийның буразнадагы беренче укытучысы. Күрше Сатмыш авылыннан ул. 1945 елны сугыштан яраланып кайткач, ул тракторга утырган. Башта, колхоз председателе Нуретдин Гайфетдинов кушуы буенча, Ләбибә Сәе-

тованың ЧТЗ-65 ендә сабанчы булып эшләгән. Икәүләшеп бер тәүлеккә егерме бишәр гектар мәйданны эшкәрткәннәр. Берничә елдан, Тәтештәге авыл хуҗалыгы училищесында укып кайткач, Нәфикъның үзенә дә трактор биргәннәр. Мәрәле МТСына эшкә килүче егетләр аның кулы астында практика үтә башлаганнар. 1959 нчы елда, ДТ-54 белән җир сөргәндә, тәбәнәк буйлы, артык күп сөйләшмәүче, татарча яхшы белүче рус егете Василий Аверьянов та аңа ярдәмче итеп билгеләнгән.

— Егерме дүрт сәгатьне яшь курсант белән урталай бүлә идек,— дип искә төшерә бу чорны Нәфикъ ага.— Колхозда ике генә трактор булганга, тәүлек буе эшли торган идек.

— Акчаны да тигез бүлә идек,— дип, Василий да сүзгә кушыла.— Олы кеше белән тигез хезмәт хакы алу мине намуслы булырга да өйрәтте. Көн саен үз-үземә: «Мин Нәфикъ абыйдан аз эшләргә тиеш түгел!» — дип киртләп куя идем. Шунда, бураэна арасында, мин беренче тапкыр социалистик ярыш төшенчәсенең чын мәгънәсенә төшендем...

Яшь тракторчыга кыен хәлләр дә очраштыргалый. Берсендә, төнлә трактор тынып калды. Күпме генә казынса да, төзәтә алмады ул аны. Шулай да, кайберәүләр кебек: «Иртәгә төзәтербез әле»,— дип, тынычланып, йокларга да ятмады. Нәфикъ абыйсының: «Белмәүнең ояты юк, белергә теләмәүнең ояты зур».— дигән сүзләрен истә тотып, сабанчысын авылга, өйрәтүчесе янына йөгертте. Үзе, алар әйләнеп килгәнче, техниканың ватык җирен сүтеп куйды...

Апастагы 26 нчы авыл профессиональ техник училищесын тәмамлап үз колхозларына эшкә кайткан егетләр белән очрашкач, Василий башыннан узганнарны сөйләде дә, нәтиҗә итеп:

— Яшь механизаторны тәҗрибәле тракторчының күзәтеп-тәрбияләп торуы бик кирәк ул,— дип куйды.— Остазы яшь кешенең хезмәткә карашын ныгыта, сайлаган һөнәренә тугрылык сакларга өйрәтә...

Хуҗалык җитәкчеләре, инженер-техник хезмәткәрләр кайчак бу чараны онытып җибәрәләр. СПТУны бетереп кайтучыга таушалып беткән, куллану срогы чыккан техника бирәләр дә тынычланалар. Егет эшен матур гына башлап җибәрә алмаса, аны тәнкыйтьләп ташларга ашыгалар. Киресенчә дә булгалый. Хезмәт күнекмәсе алмаган берәүгә буяу исе аңкып торган әр-яңа трактор, автомашина, комбайн тапшыралар. Тәҗрибә җитмәү сәбәпле, яшь егет яңа машинада да әллә ни майтара алмый. Аны да җыелыш саен әрлиләр. Двигательгә зарар килгән яңа техниканы ремонт мастерскоенда күрсәләр, бар гаепне яшьләргә аударалар. Гомум эшкә дә зыян, яшь кадрның да күңеле кителә.

Василий Игнатьевичның бу җәһәттән үз фикере бар: «Укуын тәмамлап колхозга кайтучы механизатор бер ел дәвамында белемле, ярдәмчел, тәҗрибәле кеше янында эшләргә тиеш»,— дип бара ул. Мондыйлар бездә аз түгел бит: «ЗИЛ» автомашинасында егерме ел буе ягулык-майлау материаллары ташучы коммунист Хәлиулла Салахов, чәчү чорында ДТ-75 тракторы белән иң югары күрсәткечләргә ирешүче Назыйм Хәкимов, комбайнчы Дәнияс Гайфетдинов...

Василий Игнатьевич механизаторларның эшендәге сыйфат мәсьәләсенә дә җитди карый.

— Без элек-электән халык контролерлары куйган таләпләргә җавап бирерлек итеп сөрә идек,— ди.

Ә эш ул чакта, хәзерге кебек, җиңел генә бармый, югыйсә. Сукаларга чыгасың — сабанда гидравлик насослар юк, җайлавы кыен, еш кына туктарга туры килә. Кантар тәрәннәрне өскә күтәрә, ызанга кабат борыласың.

— Сәмикъ Галимов (хәзер атаклы чөгендер үстерүче) белән Рәһип Сөнгатов (бүгенге тимерче) тагылма сабанның тәрәнен егерме биш сантиметр тирәнлектә алып бару өчен, штурвалны әле уңга, әле сулга бора-бора, тиргә баталар иде,— дип хәтеренә төшерә Василий Аверьянов.— Хәзер сыйфат комиссияләре элеккечә тегәл тикшерү алып бармыйлар, сөрү тирәнлеге тиешле дәрәҗәдә сакланмый. Кайберәүләр тракторларын зур тизлек белән куып, басуны бозалар. Үзләре: «Норманы арттырып үтәдек!» — дип күкрәк кагалар. Уңышның тамырын кисәләр...

Димәк, бу эштә бик сизгер, намуслы кешеләрнең күз-колак булып торулары кирәк. Хезмәтне ике сменада оештыру мәсьәләсенә дә илтифатсыз карарга ярамый. Төннәрен куәтле тракторлар тулы куәтенә эшлиләр! Шуңа күрә, хуҗалыклар кулында дистәләгән техника булып та, кайбер елларда басуларны көздән сукалап калдыра алмыйбыз. Тиешле дым тупланмау сәбәпле, тагын туфракның көче кими. Чәчкәндә дә тоткарлыклар булгалый: трактор ватылса, техник хезмәт күрсәтүчеләрне эзләп, күпме вакыт уза; чәчүлек белән тәэмин итүдә өзеклеккә юл куела; ягулык китермәсәләр дә, эш туктала. Ә бу чорда җирдәге дым тонналап парга әйләнә — киләчәк уңыш күккә оча, дигән сүз.

Бу фикерләрдән Аверьянов тагын бер нәтиҗә чыгара: «Эшнең сыйфатына игътибарлырак булсак, уңдырышлы кара туфракның гектарыннан 34 әр центнер уңыш алу белән генә чикләнмәс идек әле без! Игенчелек буенча, республика күләменә ук чыгар идек!» — ди.

Колхозның баш инженеры, коммунист Заһит Ибраһимов та Василий Аверьяновның техниканы ничек кулга «иялэштерүен», кадерләвен сөйләде.

Заһит әйткәннәрдән күренгәнчә, Василий Игнатьевич, бик гади чәчкечләр белән, колхозда беренче булып, чөгендер чәчүне юлга салдырган икән. 1975 нче елда, районда беренче тапкыр, ул КС-6 маркалы чөгендер комбайны сынап караган. Башка авыл хуҗалыгы машиналарын басуда көйләгән шикелле, монысының холкын да буразнада өйрәнгән. Берничә тапкыр сүтеп җыйгач, гидросистеманың да җаена төшенгән. Ә быел Василий Игнатьевич шул техника белән чөгендер плантациясендә тугызынчы җөен уздырды.

— Технологик срок буенча, комбайнның эшләү вакыты бетте,— ди баш инженер,— КС-6 гамәлдән чыкты, дип исәпләргә мөмкин. Тик Аверьянов моңа каршы. Техникага җансыз тимер итеп кенә карамаганлыктан, бу комбайнның 7888 сум 19 тиен торуын белгәнлектән, Василий чөгендер алгыч җайланманы бик кадерләп йөртте, аны тагын эшләтәчәк! Чөгендерчеләрне шактый авыр кул хезмәтеннән коткарачак.

Баш инженер Василий Игнатьевичның яңа техниканы оста сынаучы икәненә дә күп мисаллар ала.

— 1978 нче елда хуҗалыкка универсаль пневматик асылмалы кукуруз чәчкеч кайткан иде,— дип сөйли Заһит Ибраһимов.— Шуны берәү кырга алып чыкты. Чәчеп карады. Тик җаен тапмады — я чәчү тирәнлеге бозыла, я орлык төшми. Әлеге механизаторыбыз, җенләнеп, машина-трактор паркына әйләнеп кайтты. «Кырны чи калдырып, үземнән көлдерәсем юк әле»,— дип, яңа чәчкечне урынына кертеп куйды да искесен такты. Шуннан бу яңа машинаны, безнең якта эшләтү өчен яраксыз, дип, сүтә дә башладылар, борып алырдай нәрсәләре беткәч, чәчкечнең кысасын, тимер-томыр җыю планын үтисе барын уйлап, иске-москылар янына илтеп ташладылар. Әгәр Василий абый күреп алмаса, аның рамын да берничә кисәккә тураган да булырлар иде. Бәхеткә, ярышташ Муса Җәлил исемендәге колхозга баргач, ул әлеге кукуруз чәчкечен күреп кайтты. Монда аңардан бик әйбәтләп файдаланалар икән. Аннары, аның үтенечен искә алып, слесарьлар Кәбир Әхмәтвәлиев, Разыйм Нургалиев, Шәүкәт Кашапов, токарьлар Зөфәр Гәрәев белән Фәрит Шәрәфиев, китапка карый-карый, чәчкечне яңадан җыйдылар. Василий шуның белән кукуруз басуына чыкты. Көйсезләнсә, буразна арасында ук төзәтеп, күтәрү-төшерү системасын да кабинадагы идарә итү рычагына буйсындырды.

Шпагатлы салам җыйгыч белән дә шундый ук хәл була язды: күп эзләп тә бәйләвеч таба алмагач, саклауга куярга теләделәр. Елдагы тәртипне бозып, кешеләргә процентка каралган саламны эскерттән тәятергә уйладылар. Дөресрәге, бригадирлар һәм белгечләр шулай карар кылды. Тик моннан берничә ел элек кенә әллә кайлардан, мең бәясенә төшереп, салам ташыта-ташыта алҗып беткән колхоз председателе Рим Хәлимович Вәлиевнең моңа юл куясы килмәде.

— Азыкны әрәм итәбез бит,— диде ул.— Шпагат булмагач, тимер чыбыкка көйләргә кирәк иде! Анысы складта өелеп ята ич.

Инженер тагын Аверьяновка мөрәҗәгать итте: бәйләү системасына бергәләшеп үзгәреш керттеләр. Аннары салам тыгызлагычны эскерт буенда сынап карадылар.

Пресслауга Василий үзе алынды.

— Көнгә 8,4 тонна салам хәзерләргә тиешсез,— дип баш экономист Ләмига Гыймадиева аңа көнлек бурыч күләмен әйтте.— Бу, егермешәр килограммнан исәпләгәндә, 420 бәйләм дигән сүз...

Экономистның сүзен аңлаган диярсең, машина яхшы эшләде. Норманы арттырып үтәделәр. Саламны ай буе өзлексез бәйләделәр. Колхоз составына кергән дүрт авыл — Сатмыш, Шыгай, Җидекизләү, Янгилде кешеләрен салам белән тулысынча тәэмин иттеләр. Фермадагы сыер-бозаулар өчен дә салам мул әзерләнде.

Василий, эше ипле баргач, гадәттәгечә, хезмәттән тәм табып, өенә балкып кайта торган булды. Ә туган нигезенең бусагасын атлап кергәч, аның шатлыгы тагы да арта. Әниләреннән бик яшьли калсалар да, үгилекне һич тоймаган, келәч йөзле балаларын күреп, мең сөенә ул, җанында хатынына да рәхмәт хисләре сүнми.

Икенче көнне иртән ул тыныч күңел белән тагын эшкә чыгып китә. Кушканны тегәл үти — утынга да бара, кырга ашлама да ташый, төзелеш өчен ком-кирпеч тә алып кайта, чәчә, чөгендер ала... Югары хезмәт җитештерүчәнлегенә ирешә. Тукай исемендәге колхозның партия оешмасы секретаре Заһит Зәйнетдинович Шәрәфиев әйткәнчә, социалистик ярышта беренчелекне үз кулыннан ычкындырмый. Узган елда, әнә, ул ЮМЗ-6 тракторы белән 3075 гектарда эш башкарган. Ә менә район буенча көпчәкле тракторларның уртача эш күрсәткече — 1380 гектар гына.

Шуны истә тотып, аңа «Районның иң яхшы тракторчысы» дигән исем дә бирделәр. Бишьеллыклар төсе булган Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Хезмәт Даны орденнары тагып төшкән фоторәсемен районның мактау тактасына куйдылар.

# ЯКТЫ ЮЛ

*Каләмдәшебез Ф. Миңнуллинга — 50 яшь*



*Фәрваз Миңнуллин әдәбиятка алтмышынчы еллар башында килә. Шул чорда көндәлек матбугатта басылган беренче әдәби тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләре белән үзен нечкә зәвыклы, әдәби әсәрне дәлилле рәвештә анализлый һәм аның идея-эстетик кыйммәтен төгәл күрсәтә белгән сәләтле әдәбиятчы итеп таныта.*

*Хәзер ул — татар әдәбиятының җанлы процессында даими катнашучы, аның үсеш тенденцияләре, ирешкән уңышлары һәм хәл ителергә тиешле проблемалары хакында башлап сүз әйтүче актив тәнкыйтьчеләрдән берсе.*

*Ф. Миңнуллин бигрәк тә проза һәм прозаиклар турында яратып яза. Аның татар прозасының күренекле вәкилләре Г. Бәширов, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Г. Әпсәләмовларның аерым әсәрләренә багышланган мәкаләләре, Р. Төхфәтуллин, М. Мәһдиев турындагы иҗат портретлары һәм, ниһаять, «Казан утлары» журналының төрле еллары саннарында даими басыла килгән күзәтү характерындагы хезмәтләре үзләренең актуаль проблемаларны күтәрүләре, әһәмиятле теоретик күзәтүләре, гомумиләштерүләре һәм оригиналь фикерләре белән кызыклы.*

*Фәрваз Миңнуллин — «Якты юллар» (1975), «Прозаның гражданлык йөзе» (1983), «Талантлар юлы» (1984) исемле китаплар авторы. Бу китаплар уңае белән шуны әйтми мөмкин түгел — алар барысы да тормыш белән тыгыз бәйләнештә торып язылганнар. Автор әдәбиятыбыз өчен мөһим булган нинди генә мәсьәләне алса да, иң элек аның реаль чынбарлыктагы чыганагын, тормыштагы тамырын игътибар белән күзәтә. Тормышның язучы шәхесенә һәм язучы шәхесе аша әдәби әсәргә булган тәэсирен өйрәнә. Һәр мәсьәләне шундый киң бәйләнештә карау тәнкыйтьчегә күп күренешләрне дөрес һәм дәлилле аңлатырга ярдәм итә. Ә икенче яктан, тормыш белән ныклы бәйләнеш тоеп язу Ф. Миңнуллинның әдәби тәнкыйть жанрына караган әсәрләрен уку өчен кызыклы итә. Алар, матур әдәбият әсәрләре сыман, мавыгып укылалар.*

*Ф. Миңнуллин — гомуми белем мәктәбенең җиденче класс укучылары өчен татар әдәбияты буенча дәреслек авторларыннан берсе буларак та билгеле.*

*Ул шулай ук әдәби тәрҗемә эше белән дә актив шөгыльләнә. Аның тәрҗемәсендә Герберт Уэллсның «Күренмәс кеше» («Человек-невидимка», 1979) һәм Джек Лондонның «Мартин Иден» (1982) романнары басылып чыкты.*

*Каләмдәшебез Ф. Миңнуллинга шушы айда илле яшь тула.*

*Аны чын күңелдән котлыйбыз һәм яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез!*

# Фәрваз Миңнуллин

# ШАГЫЙРЬНЕҢ ПРОЗАСЫ

Бүгенге әдәбияттан кимчелек эзләү шаукымы киңрәк таралган һәм прозабыз үсми, прозаиклар эзләнми, дип зарланулар ешайган саен, күңел түрендә бер шик кочәя бара. Без соң, булганны күрмичә, булмаганны эзләп баш ватмыйбызмы?.. Ныклабрак уйлаганда, прозабыз гел бер урында таптанмый лабаса. Прозаикларыбыз да такыр сукмаклар буйлап бер-берләренең итәкләренә тагылышып кына йөрмиләр. Талант һәм сәләт дәрәҗәләренә карап, яңа алымнар, яңа формалар эзлиләр. Шул фикерне раслардык мисал кирәк булдымы — тел очына беренчеләрдән булып Әхсән Баянов исеме килә. Ул — әдәби җәмәгатьчелек арасында күптән инде яңалык эзләүче язучы буларак танылган кеше. Роман, повестьлары тирәсендә «шау-шу» күп булса да, прозаик буларак аның иҗатының нык-лап тикшерелгәне, төпле бәя алганы юк әле.

«Яшьлегемне эзлим» дигән беренче повесте (1964—1966) белән үк Ә. Баянов әдәбият дөньясында төрле характердагы кызу бәхәсләр уятты. Үз вакытында «Казан утлары» журналы бу повесть уңае белән бәхәс тә башлап караган иде, тик ул ярты юлда туктап калды. Хәзер инде шактый усал һәм кыю тәстә башланып та, кинәт туктап калган ул бәхәснең бөтен якларын, вак-төяк детальләрен искә төшерүнең хаҗәте юк. Ул безне әдәби тәнкыйть өлкәсендәге иске карашлардан, ияләнеп һәм күнегелеп, норма төсенә кергән критерийлардан арынуның нихәтле кыен булуы, әдәбиятта һәр яңалыкның нинди киртәләр, нинди каршылыклар аша үзенә юл яруы хакында сөйли торган бер мисал буларак кызыксындыра.

Бу яктан М. Маликованың «Кем ул Әнис Бадыгин» исемле мәкаләсе («Казан утлары», 1967 ел, 8 нче сан, 144—146 битләр) бик тә гыйбрәтле. Мәкаләнең исеменнән үк аңлашыладыр: автор төп игътибарын Әнис Бадыгин образына, дөресрәге, аны тәнкыйть итүгә юнәлтә. Ул Әниснең күп кенә начар гадәтләрен, ямьсез эшләрен санап чыга. Аны «нинди дә булса эшкә тәвәккәллек итә алмый торган» ихтыярсыз һәм җебегән кеше дип атый, туганнары һәм якыннары хакында кайгыртмаганы, аларга кыен чакта ярдәм итмәгәне өчен гаепли. Әниснең максатсыз яшәвен һәм, бары үз шәхесе белән генә мәшгуль булып, башкалар өчен, җәмгыять өчен берни эшләмәвен дә, эгоистлыгын да, куркак һәм ышанычсыз булуын да — берсен дә калдырмый мәкалә авторы. Шулай да М. Маликованы барыннан да бигрәк Әниснең хатын-кызларга, аерым алганда, Фәһимә белән Ленага карата шәфкатьсезлеге рәнҗетә. Саф күңелле, тыйнак Фәһимәнең дә, «тирән хисле, сөя белә торган, сөйгәнә хакына теләсә нинди корбаннарга әзер булган» Ленаның да фаҗигале язмышлары өчен Әнис Бадыгин, бары тик ул гына гаепле дип саный. М. Маликова повестьның төп героена очып-очып куна, бөтен көчен куеп аны гаепли. Әсәрнең тема-проблемасы, үзенчәлеге белән әллә ни санашып тормастан, ахырдан «киңәшләр» бирергә тотына. «Вакыйгалар үсешеннән күренгәнчә,— ди ул,— Әнис рухи фаҗигага кичерергә һәм тормышка, кешеләргә яңача карарга яки ялгызлыкка, бәхетсезлеккә дучар кеше булып калырга тиеш иде. Кызганычка каршы, язучы моны эшләми, аның бөтен симпатиясе Әнис ягында... Шулай итеп, автор, телиме-теләммиме, эгоизмны, кешеләргә, бигрәк тә хатын-кызларга карата шәфкатьсез мөнәсәбәтне яклый булып чыга» (146 бит). М. Маликованың нияте ачык: әсәр ахырында Әнис Бадыгин «тезләнергә», тезләнми икән, «җәзага тартылырга» тиеш. Бу — мәсьәләне гадәттә әсәр ахырында була торган бер-ике битлек мораль хәл итә дип ышанудан чыгып әйтелгән теләк.

Китерелгән өзектән күренгәнчә, мәкалә авторы нигездә «ошый-ошамый», «яратам-яратмыйм» принцибына таянып эш йөртә. Шәфкатьсез, мәрхәмәтсез булганы өчен, Әнис Бадыгинны тирги, Әнис Бадыгин начар кеше булган өчен, авторны гаепли. Һәм үзе дә сизмәстән, норматив тәнкыйть тегермененә су коючы бер кешегә әйләнә. «Әнис рухи фаҗига кичерергә, тормышка, кешеләргә яңача карарга яки ялгызлыкка, бәхетсезлеккә дучар кеше булып калырга тиеш иде»,— ди М. Маликова. Моның белән ул үзе дә сизмәстән авторны бәхетле тәмамланышка чакыра, аны бөтен бәлаләрдән коткаручы берденбер чара дип саный. Инде шәфкатьсез, мәрхәмәт-

сез кеше булганы өчен, Әнис Бадыгинның үзен һәм авторны тиргәгәндә, әдәби әсәрләрдәге геройлар диалектикасын дөрес аңламавын, укучыны бары уңай геройлар гына тәрбияли дип ышануын күрсәтә.

Әмма ни генә булмасын, мәкалә авторы үз фикерен курыкмый әйтә, уйлаганын ихлас ышанып яза. Шул ягы белән ихтирам уята. Һәм А. Гыйләҗевның аны «түземсез кискенлек, диктаторлык рухы белән сугарылган мәкалә»[1] дип бәяләве белән килешеп җитәсе килми. Сүз, мәкалә авторын диктаторлыкта гаепләүдән бигрәк, әдәбияттагы яңалыкны аңлау һәм аңлатуның кыенлыгы, иске карашларның, күнегелгән критерийларның яңалыкны аңларга комачау итүе хакында барырга тиеш. Бу җәһәттән А. Гыйләҗев үзе дә еш кына аптырап кала, кыенлыклар кичерә.

Дөрес, Әнис Бадыгин образына мөнәсәбәттә мәкалә авторлары бер-берләреннән әллә ни аерылмыйлар. А. Гыйләҗев та яратмый бу образны. Яратмый дию генә аздыр, ихтимал. Әниснең «тозсыз мәхәббәт маҗаралары һәм төпсез эгоизмы», «кешелек моралена сыешмаслык тупаслыклары»[2] авторның ачуын чыгара, җанын әрнетә. «Бәхет өчен көрәшергә көчсез булган», «гарип күңелле, кара эчле» бу әшәке образны ул хәтта күрәлмас дәрәҗәгә җитә. Шул ук вакытта, М. Маликовадан үзгә буларак, А. Гыйләҗев әлеге геройга нәфрәт белдерү белән генә чикләнми. Ул авторны һәм геройны аңларга да тырышып карый. «Ләкин бу — тормыш,— ди ул.— Бар бит, Леналар да бар, аның абыйлары да бар, аларга койрык булып киткән Бадыгиннар да бар. Без аларны белергә, нәфрәтләнергә тиеш» (156 нчы бит). Өзектән күренгәнчә, мәкалә авторы Әнисне генә түгел, Ленаны да өнәп бетерми; кызның мәхәббәт хисләрен шик астына ала, хәтта аны Әнисне ялгыш юлга этәрүдә гаепли. Мәкалә авторлары Лена образына капма-каршы бәя бирәләр.

Әмма ике мәкалә арасындагы төп аерма монда да түгел әле. Төп аерма повестька гомуми бәя бирүдә. Әгәр «М. Маликова Әнис Бадыгинга, аның белән бергә, повестька да хөкем арты хөкем чыгарса», А. Гыйләҗев өчен «әсәр үзенең мәгънәви эчтәлеге, тормыш күренешләренә үзенчә үтеп керә алуы белән, дөреслеге белән кыйммәтле» (156 нчы бит). Шул көчле якларына таянып, әсәрне «норматив» тәнкыйтьнең урынсыз һәм нигезсез һөҗүменнән яклап-саклап калырга тырыша. Аның төп максаты шул.

А. Гыйләҗев язучының шәхси осталыгын, стиль үзенчәлеген, иҗатының идея-эстетик юнәлешен ачарга омтыла. Әсәрнең үзенчәлеген тоеп, аңлап эш итүе дә нык сизелеп тора. Әйтик, ул әсәрдә мәхәббәт маҗараларының күп урын алуын әйтә, фәлсәфи чигенешләр күп булса да, реаль тормыш тасвирлары «сараналандырылган», ди. Кыскасы, ул авторның иҗатын тирәнрәк аңлый, повестьның үзенчәлеген нечкәрәк сиземли. Ләкин дөрес күзәтүләрдән ялгыш нәтиҗә чыгара. Мәкаләнең буеннан-буена А. Гыйләҗев лирик повестьтагы эпик урыннарга басым ясый. Ул «әсәрдәге күңелне тетрәтерлек, тормыш дөреслеген мастерларча ачып салган» битләргә соклана, сугыш чоры авылына хас кырыс күренешләргә, шул чорда колхоз председателе булып эшләгән Сафуан образына югары бәя бирә. Ә менә повестьның үзәк героен күрмәмешкә салына, әсәрнең үзенчәлеген билгели торган, аның асылын тәшкил иткән төп моментларын хуплап һәм өнәп бетерми. Хәер, моны конкрет мисал белән аңлату җиңелрәк булыр. «Ләкин повесть бер Әнис Бадыгин турында гына түгел,— ди ул.— М. Маликова әсәрнең кыйммәтле ягына, Әнистән башка якларына бөтенләй игътибар итми. Әсәр шушы пешмәгән үсмернең тозсыз мәхәббәт маҗарасына гына корылса һәм нибарысы аның төпсез эгоизмын күрсәтүгә генә хезмәт итсә, повестьның бәясе бик чамалы булыр иде. Дөрес, автор «лирик повесть» дип аның жанрын дөрес билгеләмәгән, гомумән мәхәббәт линиясенә артык игътибар биреп, кирәкле-кирәксез фәлсәфи чигенешләр белән мавыккан, тормыш тасвирларын саранландырган. Ләкин автор теләгәнме-теләмәгәнме, әсәр, Бадыгинның мәхәббәт маҗараларыннан узып китеп, тормыш чынлыгына үтеп керергә омтылыш ясаган. Бу омтылышны, һичшиксез, хупларга кирәк» (155 нче бит). Күрәсез, мәкалә авторы, тырышып-тырышып, повестьның төп үзенчәлеген билгели торган якларын тәнкыйтьли, бу әсәр өчен характерлы

---

[1] «Казан утлары» журналы. 1967 ел, 11 сан, 154 нче бит.

[2] Шул кадәресен дә әйтеп үтәргә кирәк: соңыннан язучы Әниснең «кешелек моралена сыешмаслык тупаслыкларын» шактый киметкән. Повестьның яңа вариантында Әниснең кош балаларын кырып йөрүе дә, теш белән тере куян бугазлавы да кыскартылган. Шулай ук Әнис комсомол секретаре булып сайланмый, Фәһимә атылып үлми (Ә. Баянов. Язмыштан узмыш. Казан, 1975 ел).

булмаган моментларны исә, киресенчә, үстерергә, киңәйтергә куша. Җыйнап әйткәндә, А. Гыйләҗев лирик әсәрдән традицион типтагы эпик әсәр ясарга тырыша, лирик повестька эпик проза таләпләреннән чыгып якын килә. Эш тагын яңача язылган әсәрне аңлау-аңлатуның кыенлыгына килеп терәлә.

Автор әсәрнең жанрын дөрес билгеләмәгән, «Яшьлегемне эзлим» лирик повесть түгел, ди А. Гыйләҗев. Мондый фикерне ул, һичшиксез, М. Әмирнең «Агыйдел»е, Ф. Хөснинең «Йөзек кашы» кебек әсәрләрне истә тотып әйтә. Мәкалә авторы эпик әсәрләрдәге «лирик чигенешләр»не, безнең традицион типтагы эпик әсәрләребезгә үзенчәлекле яңгыраш бирә торган лирик җылылыкны күздә тотып фикер йөртә. Андый урыннар Ә. Баянов повестенда да бар (Агыйдел буйларын сурәтләгән битләр, сугыштан соңгы авыл күренешләре). Тик повестьның лириклыгын алар билгеләми. Лириклык — әсәрнең язылу алымнарында. Кызганычка каршы, безнең әдәбият фәнендә лирик прозаның үзенчәлекләре, лирик прозада образ иҗат итү, сюжет-композиция төзү алымнары, автор позициясе кебек мәсьәләләр бөтенләй өйрәнелмәгән. «Яшьлегемне эзлим» повестен бәяләүдәге төп кыенлык, беренче чиратта, шуңа килеп терәлә.

Әсәрнең жанрын билгеләү мәсьәләсендә хәтта Р. Мостафин кебек тәҗрибәле тәнкыйтьче дә аптырабрак кала. «Әсәрнең жанрын ачыклау да шактый кыен,— ди ул.— Автор үзе аны «лирик повесть» дип атаган. Моның өчен беркадәр нигез дә бар: повесть төп геройның эчке монологы рәвешендә язылган, әсәрдә лирик чигенешләр, фәлсәфи уйланулар, көтелмәгән ассоциацияләр тулып ята»[1]. Ныклап уйлаганда, монда әллә ни аптырарлык урын юк. «Яшьлегемне эзлим» повестеның жанр үзенчәлеген ахыр чиктә Р. Мостафин санаган шул сыйфатлар (эчке монолог рәвешендә язылу, фәлсәфи уйланулар, көтелмәгән ассоциацияләр муллыгы) билгели бит инде. Ә. Баянов повесте нигездә лирик әсәр рәвешендә, лирик чаралар ярдәмендә язылган. «Яшьлегемне эзлим» — шагыйрь каләме белән язылган проза әсәре. Повестьның лириклыгы да, яңалыгы да әнә шунда.

Эпик проза алымнарыннан баш тартып, автор еш кына образлы чагыштыруларга, ассоциатив сурәтләргә мөрәҗәгать итә. Яраткан кызларын искә төшергәндә, аларга карата үзенең мөнәсәбәтен ачыкларга тырышып баш ватканда, Әнис күз алдына — Фәһимә гел генә печәне чабылмаган яшел болын, Лена исә өлгергән иген кыры рәвешендә килеп баса. Шуннан инде озаклап аңлатуның кирәге дә калмый: яшел болын, андагы чәчәкләр соклану өчен яхшы, аларны алыштырган өлгергән иген төме — «бөтенләй башка, бөтенләй башка». Менә тагын бер мисал: «Кояшның яктылыгы, җылысы күп мәртәбәләр кимеде. Кичләрен әллә нинди әйтеп аңлата алмаслык шомлы тынлык урнаша. Ул тынлыкны җимереп, тирә-якта әллә нинди ямьсез өннәр кузгалып китә: якында гына, сазлык артындагы басуда, бүреләр улый, этләр чиный-чиный күтәрмә астына кереп кача»[2]. Оста табылган берничә образлы деталь ярдәмендә (яктылыгы һәм җылысы күп мәртәбәләр кимегән кояш, сазлык артындагы басуда улаган бүреләр) язучы сугыш чорындагы авылның шактый төгәл картинасын бирә алган. Тик әсәрнең үзенчәлеген шушындый образлы сынландыруларга гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Төп үзенчәлек, төп яңалык повестьның язылу рәвешендә, аның сюжет-композициясе, образны ачу алымнары традицион типтагы эпик әсәрләрдән үзгә булуда.

Алда әйтелгәнчә, «Яшьлегемне эзлим» повесте төп геройның эчке монологы рәвешендә язылган. Безнең прозада «автор катнашыннан тыш» язылган повестьлар байтак. Арада төрлесе бар. Г. Ахуновның «Чиклəвек төше»ндә Халикъ Саматовның тормышы белән безне геройның хатыны Рокыя таныштыра. Халикъ турындагы хакыйкать кешеләргә кирәк, дип уйлый. В. Нуруллинның барлык повестьларында диярлек хикәяләү төп герой исеменнән алып барыла. Иң якын дустына эч серләрен сөйләгән кебек итеп, алар безне үз башларыннан узган гыйбрәтле хәлләр белән таныштыралар. Болардан үзгә буларак, Әнис Бадыгин яшьлеген үз-үзен аңлау өчен искә төшерә, күңеленең иң яшерен почмакларына укучыны үзе алып керә. Бу — исповедь характерында язылган әсәр.

Белгәнебезчә, Әнциснең яшьлеге авыр сугыш елларына туры килә. Кырыс чынбарлык йомшак холыклы һәм шактый иркә малайны күп төрле сынаулар алдына

[1] Мостафин Р. Алга барышлый. Тәнкыйть мәкаләләре. Казан, 1977 ел, 66 нчы бит.
[2] Баянов Ә. Язмыштан узмыш. Лирик повестьлар. Казан. 1975 ел, 7 бит. Алга таба барлык өзекләр шушы басма буенча китерелә. Ф. М.

куя. Геройның яшьлеге тормышка ашмаган гарип хыяллар, мәхәббәт газаплары, дөньяны, кешеләрне аңлый алмый иза чигүләр, «намус» дигән сызыкның әле бер, әле икенче ягына чыгып интегүләр, тормыш хакыйкате алдында югалып-каушап калулар, кырыс чынбарлыктан хыял иленә качып котылырга азапланулар, барыр юнәлешен югалтып, җәтмәдәге балыктай чәбәләнүләр, үкенеч гомер буена җитәрлек хаталар, ялган батырлыклар, һәр ялгыштан соң яңача яшәп калырга тырышулар, күп төрле кимсенүләр-кимсетелүләр белән тулы. Ахыр чиктә, бу — Әниснең үз-үзен, тормышта үз урынын эзләве.

Әнис үзенең бер генә хатасын, бер генә ялгышын да яшереп калмый төсле. Тик нинди максат белән эшли ул моны? Әнис ни өчен яшьлегенә кайта, ни өчен яшьлек хаталарын искә төшерә? Үкенү, гыйбрәт алу өченме? Алай ук түгел кебек. Хатаның үзеннән бигрәк, аны шул чактагы рухи һәм психологик халәте, тегеяки бу вакыйгага шул чактагы мөнәсәбәте, бәясе, реакциясе күбрәк кызыксындыра. Конфликт геройның күңеленә күчерелгән. Унҗиде яшьлек Әнис үз-үзен, үзенең хисләрен һәм кичерешләрен аңларга тырыша. Шул нәрсә повестьтагы хикәяләүнең дә үзенчәлекле булуына китергән. Ә. Еники әсәрләрендә, әйтик, геройларның бер генә гамәле, бер генә эше дә безне гаҗәпкә калдырмый. Чөнки геройның һәр адымы алдан әзерләнгән, психологик яктан акланган була. Ә. Баянов повестенда эш башкачарак тора. Әнис башта нинди дә булса гайре табигый берәр эш эшләп ташлый, аннары шул эше, гамәле турында фикер йөртә, уйлана башлый. Шулай әсәргә күп төрле һәм күп санлы фәлсәфи уйланулар, аңларга һәм акларга тырышулар, мөнәсәбәт белдерүләр килеп керә. Автор чор һәм кеше язмышы, алар арасындагы бәйләнеш кебек мәсьәләләрне фәлсәфи ноктадан карап чишәргә омтыла. «Яшьлегемне эзлим» повесте — интеллектуаль укучыга исәп тотыбрак язылган әсәр.

Повесть унҗиде яшьлек Әниснең эчке монологы рәвешендә язылган, дидек. Шул ук вакытта унҗиде яшьлек Әниснең һәр адымын бер читтән егерме дүрт яшьлек студент Әнис карап, күзәтеп, тикшереп тора. Кыен хәлдә калса, ярдәмгә килә, ялгышса — төзәтә. Олы Әнис — кече Әниснең ярдәмчесе һәм киңәшчесе, остазы һәм оппоненты да, мәгълүм бер дәрәҗәдә автор позициясен белдерүче герой да.

Сафуан абзыйсы:

— Бүген мин Әшмәнгә барам. Кайтасыңмы? Үзем белән алып кайтам,— дип әйтеп тә өлгерми, Әнис ашыгып-ашыгып кайтырга җыена башлый. Әле кайчан гына сөепяратып йөргән Фәһимәнең дә, иптәшләренең дә башка кирәге калмый. Бераздан бу эшенә үзе үк аптырап кала. Шул чак ярдәмгә олы Әнис килеп җитә.

«Соңыннан озак уйланып йөрдем,— ди ул,— Фәһимәнә калдырып китәргә шулай ни йөрәк белән җыенган идем соң әле мин? Яшьлек, әллә балалыкмы?.. Әллә минем күңел генә шундый булганмы? Бу җиңеллек мәхәббәттәге һәртөрле фаҗиганең башы түгелме икән?.. Бу сорауларга җавапны мин соңрак таптым һәм артык соңга калып таптым. Минем башка мондый сораулар чак кына алданрак килгән булса, мәхәббәтем, хәтта киләчәгем бәлки бөтенләй икенче төрле хәл ителгән булыр иде. Бәлки. Әмма мин ул чакта берни дә уйлый белмәгән, бары тик дөньяда яшәвемне онытырлык дәрәҗәдә мавыга гына белгәнмен шул» (25 нче бит). Гел шулай: унҗиде яшьлек Әнис Ленага булган катлаулы һәм каршылыклы мәхәббәт хисләренең очына чыга алмый интеккәндә дә, Сафуан абзыйсы белән соңгы сөйләшү һәм очрашудан соң югалып-аптырап калган чакта да аңа студент Әнис булыша. Фикерләрен ачыклый, юнәлеш бирә, яки әрләргә, тиргәргә тотына. Ара-тирә нык кына бәхәсләшеп, чәкәләшеп тә алалар. Бер мәлне тәмам аптырап калган Әнис, «намус дип исемләнгән, юк дәрәҗәсендә тар бер сызыкны атлап чыгып», Шәймиләр, Леналар кебек яшәп карамакчы була. Кыш уртасында Шаһиәхмәтовны квартирадан куып чыгарыша, Ленаның туганнары оештырган туй дигән фарста катнаша. Шул хәлләрдән соң ике Әнис күзгә-күз очрашалар. Берсе — яшь, ваемсыз, һавалы һәм тәкәббер. Икенчесе — аның кыланышларыннан нәфрәтләнә, кимсенә, хурлана торган герой. Шул күренештә аларның төп вазифалары бик ачык күренә.

Әсәр кече Әниснең берничә еллык тормышын иңли. Шул еллар эчендә герой гомеренең бер өлеше, бер этабы тугәрәкләнә. Шуннан яңасы башланачак. Ул инде, ихтимал, унҗиде яшьлек Әниснекеннән мәгънәлерәк, үзгәрәк булыр. Тик хәзергә ул нәтиҗәләр ясарга ашыкмый, үз алдына кем мин, нинди кеше, җәмгыятькә нинди фай-

да китердем? — дигән сорауларны бөтен кискенлеге белән куймый. Бу яктан аңа олы Әнис тә әллә ни ярдәм итә алмый. Чөнки аның да максаты башкарак. Туган ягына ул «яшьлеге белән очрашу, туйганчы бер сөйләшү, уйлашу, киңәшү өчен» кайта. Һәм шулай эшли дә. Шуның аркасында безне кызыксындырган сорауларның байтагы, бигрәк тә «Кем ул Әнис Бадыгин?» дигән төп сорау җавапсыз кала.

Дөрес, повестьның төп герое М. Маликова һәм А. Гыйләҗевлар уйлаганча ук беткән кеше түгел. Аның күңелгә ятышлы эшләре, уңай сыйфатлары байтак (музыкаль сәләте шик уятмый, туры сүзле булуы ошый, весовщик булып эшләгәндәге гаделлеге әйбәт тәэсир калдыра, Хәбир һәм Леналар кара ягарга йөргәндә Фәһимәне яклап кала, күпме тырышсалар да, Фәйзи һәм Шәйми кебекләр коткысына бирелми һ. б.). Шулай да Әниснең иң зур егетлеге — кимчелекләрен, хаталарын курыкмыйча, яшермичә әйтә алуында. Теләсә яшерә дә алыр иде. Бу — аның үз ихтыярында. Курыккан, яшергән очракта ул безнең хәтердә шактый шома һәм матур бер егет булып калыр иде. Ихтимал, мондый «шау-шу» да кузгатмас иде. «Яшьлегемне эзлим» повестенең төп һәм принципиаль яңалыгы шунда. Моны аңламаган килеш әсәргә һәм аның төп героена дөрес бәя бирү кыен булачак.

«Яшьлегемне эзлим» — авторның эчке монологка корылган лирик повесть язу юлындагы беренче адымы. Лирик прозаның Балтик буе республикаларында, бигрәк тә литва әдәбиятында шактый киң таралган төрен бездә иң элек Ә. Баянов куллана башлады. Повесть хакында фикер йөрткәндә, нәтиҗәләрдән бигрәк, тәҗрибәләр хакында, аларның никадәр кызыклы һәм үзенчәлекле, кирәкле һәм файдалы булуы хакында сүз алып барырга туры килә. Яңа форма авторга үз героеның күңеленә, эчке дөньясына тирәнрәк үтеп керергә, әхлак мәсьәләләрен калку һәм кискен итеп куярга булышкан. Шул ук форма геройларның эш-гамәлләренә анык бәя бирергә комачау да иткән төсле. Повесть төп геройның эчке монологы рәвешендә язылганлыктан, Әнистән калган персонажлар үзләрен аклый да, яклый да алмыйлар. Алар — сүздән мәхрүм ителгән кешеләр. Язмышлары тулысынча Әнискә бәйле. Аның башкаларга мөнәсәбәте исә асылда шәхси симпатия һәм антипатияләргә нигезләнгән. Лирик проза алымында язылган бу повестьның кимчелеге икенче дәрәҗәдәге персонажларны тудырганда аеруча ачык күренә.

Алга таба Ә. Баянов яңа форма, яңа алымнар эзләвен тагын да көчәйтә төшә, шул өлкәдәге тәҗрибәләрен камилләштерә бара. Һәм аның әсәрләрендә без тагын ике мәртәбә Әнис Бадыгин белән очрашабыз. «Яшьлегемне эзлим» повестеннан аермалы буларак, анда инде ул үз тормышы, үз хисләре турында түгел, башкалар тормышы турында сөйли, аларның эш-гамәлләренә бәя бирә. Әнис хикәяләүче геройга, автор вазифасын башкаручы персонажга әйләнә. Тагын шунысы бар, хикәяләүче герой ике әсәрдә ике төрлерәк тәэсир калдыра. Әгәр «Аязучан болытлы һава»да (1977—1978) ул хәзер генә тикшергән Әнис Бадыгинны хәтерләтсә, «Дүрт монолог»та (1968) ярыйсы ук сөйкемле һәм мөлаем кеше булып күз алдына килә. Шул нәрсә әлеге повестьларның һәркайсына үзенчәлекле яңгыраш бирә.

Композицион төзеклеге, бөтенлеге һәм җыйнаклыгы ягыннан да, формасының яңалыгы белән дә «Дүрт монолог» — Ә. Баянов иҗат иткән иң үзенчәлекле һәм кызыклы әсәрләрнең берсе. Повесть төрлесе төрле зурлыктагы дүрт монологтан, дүрт бүлектән тора. Күләмнәре белән генә түгел, характерлары, башкарган вазифалары белән дә алар бер-берләреннән шактый аерылалар.

Беренче бүлек, тыштан караганда, Әнис монологы рәвешендә язылган. Тик аны шартлы рәвештә, форма ягыннан чыгып кына монолог дип атарга мөмкин. Сүз анда Әнис тормышы, турыдан-туры аның үзенә кагылышлы вакыйгалар турында бармый. Әнис исеменнән язылган бу беренче бүлектә повестьның нигезен тәшкил иткән төп вакыйга, төп ситуация сөйләнә. Ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

...Әниснең Илдархан исемле абыйсы, Нәркәс исемле чибәр кызга өйләнеп, матур гаилә тормышы корып җибәрә. Әмма бер-берләренә ныклап ияләшеп, сөеп-сөешеп калырга да өлгермиләр, Илдарханны армия хезмәтенә алалар. Ул хезмәт срогын тутырып, бүген кайтам, иртәгә кайтам дип йөргәндә — Бөек Ватан сугышы башлана. Фронттагы абыйларын — Илдархан белән Әсләмне — сагынып, сугыш китергән кыенлыклар турында борчылып яшәгән көннәрнең берсендә Әнисләргә Урал якларыннан якын кардәшләре Исәнбәк кайтып төшә. Ут эченә китәр алдыннан туганнары, якын-

нары белән саубуллашырга дип, аннан да бигрәк, заводта бронь биреп куярлар да, фронтка бөтенләй җибәрмәсләр дип, куркып кайта. Унбиш көн — бер ай чамасы ул Әнисләрдә яши. Яшь, чибәр килен Нәркәс белән карт буйдак егет Исәнбәк бер-берләренә бик тиз ияләшеп китәләр. Велосипедка утырып, район үзәгенә барулар, күрше авылларга кибеткә йөрүләр ешая. Бергәләп урман-кырларга чыгалар, бүләкләр бирешәләр. Ә кыш җиткәч, Исәнбәк сугышка китә. Китә дә мәңгегә югала. Әнис кулында ул язган серле хат кала. Авыл халкы арасында Нәркәс белән Исәнбәк хакында төрле «чыш-пышлар», ямьсез хәбәрләр тарала.

Сугыш бетүгә, Илдархан ялга кайта. Беренче төнне үк теге «чыш-пышлар» раслана. Дөресрәге, Илдарханга аларны Нәркәс үзе сөйли. Илдархан хатынының хыянәтен оныта, гафу итә алмый. Ахырдан, тайгак юлдан китеп, тәмам кешелеген югалта. Нәркәс исә башка кешегә кияүгә чыга... Шулай матур башланган гаилә тормышы фаҗига белән бетә. Моңа кем гаепле? Нәркәсме? Исәнбәкме? Әллә моның тирәндәрәк яткан башка сәбәпләре бармы?..

Повестьның алдагы өлешләре шул сорауларга җавап эзләү — төп геройларның (Нәркәс, Илдархан, Исәнбәк) монологлары рәвешендә язылган. Ул монологларны укыганда, без геройларның үзләре, тормыш юллары, дөньяга карашлары белән киңрәк танышабыз һәм, әлбәттә, бер-берләренә, әлеге күңелсез хәлгә булган мөнәсәбәтләре белән танышабыз. Бер үк вакыйгага төрле яктан һәм төрле ноктадан карап якын килү, берничә кешенең бәясен һәм мөнәсәбәтен белдерү авторга әдәп-әхлак һәм мәхәббәт мәсьәләләренә, интим хисләр даирәсенә ныграк үтеп керергә, интим мөнәсәбәтләрнең башка язучылар тотынырга кыенсынып йөргән четерекле якларын күрсәтергә, мәхәббәткә хас каршылыкларны ныграк аңларга, барыннан да бигрәк, геройларның эчке кичерешләрен һәм рухи халәтен, психологиясен тирәнрәк ачарга ярдәм иткән.

Ә. Баяновның бу повестенда да һәммә нәрсәне алдан күреп, белеп торган автор образы юк. Ул хикәяләүгә «катнашмый», вакыйгаларга һәм геройларга карата «мөнәсәбәтен белдерми». Бу эшне ул тулысы белән «Яшьлегемне эзлим» повесте буенча һәммәбезгә таныш Әнискә ышанып тапшырган. Беренче бүлектә телгә алынган вакыйгаларны ул сөйли. Вакыйга белән вакыйганы, бер герой белән икенче геройны ул тоташтыра. Шул ук вакытта ул гади хикәяләүче, вакыйгалар барышын читтән күзәтеп торучы гади персонаж гына да түгел. Әнис — бу гаиләнең үз кешесе. Кечкенәдән үз араларында бөтенесен күреп үсә. Аның Илдархан, Нәркәсләргә үз мөнәсәбәте бар. Әсәр геройлары (Илдархан, Нәркәс, Исәнбәк) үзләре дә Әнискә карата битараф түгелләр. Исәнбәк сугышка китәр алдыннан язган серле хатын Әнискә биреп калдыра. Бик тә, бик тә якыннар идек бит без синең белән, ди аңа Нәркәс. Ә монологларның өчесе дә Әнискә мөрәҗәгать, аңа аңлатма-җавап рәвешендә язылган. Әнис хикәяләүче һәм геройлар тормышының шаһите дә, шул вакытта аларга хөкем чыгаручы да. Телибезме-теләмибезме, без вакыйгаларга аның күзләре белән карарга, геройларны, аларның эш-гамәлләрен аның бизмәне белән үлчәргә мәҗбүрбез. Әгәр төп геройларның үзләрен генә тыңласак, Әниснең аларга мөнәсәбәтен, шәхси симпатиясен сизеп тормасак, ихтимал, Нәркәс белән Исәнбәкнең әлеге эшләренә башкачарак карар, аларны кырысрак хөкем итәр идек. Әнис исә аларны гаепләргә ашыкмагыз, аңларга тырышыгыз, дип кисәтеп тора шикелле. Шул нәрсә повестька үзенчәлекле яңгыраш бирә, эчке монологка корылган лирик повестьта автор позициясен белдерүнең яңа бер формасын тудыра.

Авторның «Аязучан болытлы һава» повестенда да Әнис Бадыгин шул ук вазифаларны башкара. Ул — хикәяләүче герой да, автор позициясен белдерүче дә. Тик монда инде ул повесть геройларын аңларга һәм аңлатырга тырышудан бигрәк, аларның гаепләрен эзләргә ашыга. Ике повесть, ике Әнис арасындагы төп аерма шунда.

Ә. Баяновның күпчелек әсәрләре кебек үк, бу повесть та иң элек формасының яңалыгы белән аерылып тора. Кеннернең берсендә Әнис Бадыгинга берьюлы өч хат килеп төшә. Өчесе дә язучының туган ягыннан килгән, өчесе дә аңардан киңәш һәм ярдәм сорап язылган.

Беренче хат Әниснең «яшьлек дустыннан» булып чыга. «Гаделлек өчен көрәшүче бер кешене коткарырга кирәк,— ди ул хатында.— Дөреслекне ачсагыз, гаделлекне тапсагыз бары тик сез генә табачаксыз».

Сәеррәк эчтәлекле икенче хатны Байслам Гыйбадулласы дигән кешенең хатыны

җибәрткән. Бәләкәй чагында Әнис аның ирен каргаган булган. Шул кеше хәзер бик каты чир белән түшәктә ята икән. Каргышыңны кире ал, иремнең чирен куккә очыр, дип ялвара бичара хатын.

Ниһаять, соңгы өченче хат Җирекле күл колхозында председатель булып эшләүче Ильяс Җантурин исеменнән язылган. Ул арада иң күләмлесе. Ильяс башта кыскача гына кем булуы, ничек председатель итеп куюлары белән таныштыра, аннары артта калган хуҗалыкны алдынгылар рәтенә чыгару өчен ничек итеп тырышуы, ниләр эшләве турында сөйли, эшкә аяк чалучылардан зарлана. Кыскасы, ул да Әниснең ярдәменә мохтаҗ икән.

Шул хатларда язылганнарны ачыклау нияте белән һәм якташларының гозерен тыңлап, Әнис Бадыгин юлга чыга. Туган ягына кайтып, газета хәбәрчесе кебек, авылдан авылга йөри башлый. Башта ук ачыклана: өченче хатның авторы Ильяс Җантурин түгел икән. «Юк, минем язу түгел, әмма барысы да дөрес язылган, үзем дә кул куя алыр идем», ди Ильяс. Морадым карт, Миңләхмәт, Зәлхиҗә кебек кешеләр ярдәмендә авыл белән, кешеләр белән таныша. Акрынлап район күләмендә күп еллардан бирле барган гауганың эченә керә, асылына төшенә бара. Яшәү рәвешләренә, тормышка, игенче хезмәтенә мөнәсәбәтләренә карап, кешеләр ике лагерьга, ике төркемгә бүленә. Бер якта — Зәлхиҗә, Вәҗиһә, Миңләхмәт, Ильяс, Рамазановлар. Болар — иген үстерүчеләр. Аларның һәркайсы — яратып эшләнгән, мөлаем һәм сөйкемле образлар. Икенче якта — Сәлимгәрәй, Госман Фәсихов, Хәмәтдиновлар. Болары — иген үстерүчеләргә комачау итүчеләр. Бүгенгә мул һәм матур тормыш, Миңләхмәтләрнең иген үстерү өчен фидакарь көрәше фонында Фәсихов, Сәлимгәрәй кебекләрнең өшкелеге аеруча нык нәфрәт уята. Әмма, туган ягына кайтып күпме генә эзләмәсен, Әнис анда ярдәм итәрдәй кешеләр таба алмый. Берәүләр — иген үстерүчеләр — ярдәмгә мохтаҗ түгел. Икенчеләре — аларга комачау итүчеләр — ярдәмгә лаек түгел. Өченчеләренә — Сәттар, Үрәзмәт кебекләргә — ярдәм итәргә соңгарак калган...

Бу кадәресе аңлашылсын да, ди. Тик Әнис Бадыгинның шуннан соңгы эшләре шактый аптырашта калдыра. Якташларының гозерен тыңлап туган якларына кайткан Әнис, бер заман кайчандыр үзен кыерсыткан, үзенә зыян салган кешеләрне эзләп табып, аларның бәхетсезлеген тамаша кылып, шуларның аяныч хәленнән тәм табып, ләззәт алып йөри башлый.

Беренче хатның авторы Фәсиховның хатыны Нәзилә булып чыга. Төптән уйлап карaганда, Нәзиләнең ирен яклап калырга, аңа ярдәм итәргә тырышуы табигый хәл. Яклашмаса, ярдәм итәргә теләмәсә, сәеррәк булыр иде. Әнис исә, бөтен көчен куеп, Нәзиләне бозык, начар хатын итеп күрсәтергә тырыша. Нигә алай эшли диярсез? Яшьлегендә Нәзилә аның мәхәббәт хисләрен уртаклашмаган икән. Т. Миңнуллинның Хәсән Вагыйзовичы кебек, хәзер шуның өчен үч алуы. Инде Гыйбадулла Байсламовка килеп җиткәч, Әнис чама хисен бөтенләй оныта. Башта улы Сәлимгәрәйнең физик кимчелегеннән көлә. Сәлимгәрәй белән эшне бетергәннән соң «утны» Гыйбадулла өстенә күчерә. Соңыннан ачыклана, Гыйбадулла да кайчандыр Әнисне рәнҗеткәч, аңа күп кенә зыян салган кешеләрнең берсе икән. Янәсе, хәзер шуның җәзасын ала. Шулай итеп, сүздә туган якларына ярдәмгә мохтаҗ кешеләр эзләп, район күләмендә күптәннән барган гаугага чик куярга дип кайткан Әнис эшкә килгәндә шәхси дошманнарының аяныч язмышын тамаша кылып, шуннан ләззәт алып йөри.

«Яшьлегемне эзлим» повестендагы кебек үк монда да Әнистән калган геройлар үзләрен аклау һәм яклау хокукыннан мәхрүм ителгәннәр. Әсәрнең формасы аларга андый мөмкинлекне бирми. Әгәр сүз бирелсә, шик юк, алар Әнис Бадыгинның кызганып тормаслар иде. Эш тагын Ә. Баянов сайлаган алымның үзенчәлегенә, дөресрәге, аның кимчелекле булуына килеп терәлә. Хикәяләүче герой Әнис кебек үч саклаучан кеше булганда, тормышчан образлар иҗат итү, аларга гадел һәм объектив бәя бирү кыен икән. Хикәяләүче дә, берүк вакытта автор позициясен белдерүче дә герой олы йөрәклерәк, киң күңеллерәк булырга тиеш! «Аязучан болытлы һава»га болай киң туктaлуыбызның төп сәбәбе шул...

«Яшьлегемне эзлим», «Дүрт монолог» кебек әсәрләрендә язучы сугыш чоры һәм сугыштан соңгы авыл турында, кешеләр күңелендә шул авыр еллар калдырган җәрәхәтләр турында язган иде. «Тау ягы повестенда (1972) ул яңадан шул чорга әйләнеп кайта. Ләкин үзенчәлекле төстә әйләнеп кайта. Шул чор тормышының башкалар

кулы тимәгән ер-яңа катламын күтәрә, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтенә кагылышлы житди проблемалар кузгата.

Приютта үсеп, унны бетергән, аннары солдат хезмәтендә булган егет, әти-әнисен, туганнарын эзләп, Тау ягына кайтып төшә. Тугаш карт, Сөембикә, Гөләндәм кебек бик тә ягымлы һәм мөлаем кешеләр, бүгенге авыл тормышы белән таныша. Алардан сорашып, әнисенең туганнарының язмышын ачыкларга керешә. Шулай Тәбрик язмышына бәйле кешеләр тормышы, алар башыннан узган фаҗигале вакыйгалар җанлана. Үткән белән бүген чиратлашып, әсәргә үзенчәле төс бирә. Бүгенге тормыш фонында үткәннең фаҗигасе тирәнрәк һәм калкурак булып күз алдына баса.

Әнисе Көләмсәрнең яшьләгән, сугыш елларындагы тормышын, ахыр килеп, фаҗигале мәхәббәт тарихын һәм үлемен сурәтләгән битләрне тетрәнми уку мөмкин түгел. Фашистлар башлаган сугышның тагын бер зур фаҗигасе ачыла. Ул Көләмсәрне яшьли кабергә керткән, Фәхретдинне ике баласыз һәм хатынсыз калдырган, Мирсәетнең бөтен тормышын айкап ташлаган. Моны, билгеле, Тәбрик тә аңлый. Ләкин аны мәсьәләнең мораль ягы күбрәк кызыксындыра. Нигә әтиләре — үзенеке дә, үгие дә — әнисе Көләмсәрнең гомерен саклап кала алмаганнар? Мирсәет дигәне нигә йөкле хатынны чыгарып җибәргән? Фәрхетдин дигәне нигә әнисен Мирсәеттән барып алган, ә барып алгач һәм торып булмаганлыгын белгәч, нигә өйдән үзе чыгып китмәгән? Нигә аларның берсе дә Тәбрик белән, аның язмышы белән рәтләп кызыксынмаган? Әнә шундый сорауларга җавап эзләп, Тәбрик әтиләре янына китә. Ләкин өмете акланмый, әтиләренең икесе дә Тәбрикне шикләнеп һәм сагаеп каршы ала. Фәрхетдиннең үги улым өй сорап кайткан дип коты очса, Мирсәете акча сорарга килгән дип курка. Шуннан егет катгый фикергә килә: «Үзе әйбәт, үзе куркак,— дип уйлый ул әтисе Мирсәет белән очрашканнан соң.— Фәрхетдин шәфкатьсез куркак булса, монысы — нечкә күңелле куркак! Куркаклык! Менә нәрсә үтергән икән минем әнине! Менә нәрсә!»

Моңарчы тикшергән әсәрләрендә автор вакыйгаларга үзе катнашмый иде. «Тау ягы повесте» бу яктан да аерылып тора. Повесть, тыштан караганда, автор исеменнән хикәяләүгә корылган кебек. Ләкин ул үзе алга чыгарга, күренеп торырга яратмый. Әле Сөембикә, әле Тугаш карт булып сөйли. Күпчелек очракта исә тормышка, кешеләргә яшь егет Тәбрик күзләре белән карый. Урыны-урыны белән тәмам Тәбриккә әйләнеп, аның эчендә эреп бетә. Шулай лирик һәм эпик алымнарның бердәмлегенә, үзенчәлекле төстә үзара чиратлашып, үрелеп баруына ирешә. Әмма барыбер лирик проза алымнары алгарак чыга, өстенлек итә. Бу — табигать күренешләрен сурәтләгән урыннарда, табигать күренешләре ярдәмендә тормышта үз урынын эзләүче геройның рухи халәтен күрсәткәндә аеруча ачык күренә. Вакыйгаларның тышкы кабыгыннан бигрәк, авторны Тәбрикнең хисләре, кичерешләре, тормыш турында уйланулары күбрәк кызыксындыра.

Тугаш карт образына ияреп, повестька туган җир һәм туган илгә мәхәббәт, борынгы традицияләр һәм аларга мөнәсәбәт, буыннар арасындагы бәйләнеш мәсьәләләре килеп керә. Әсәрнең журнал вариантында алар шактый озынга сузыла, ялыктыра башлый, барыннан да бигрәк, әсәрне таркауландыра иде. Хәзер алар шактый кыскарган. Автор шулай ук шартлы алымнарны киметә төшкән. Әсәр җыйнакланып, тагын да бөтенәеп киткән. Шулай ата-ананың бала алдында, баланың ата-ана һәм туган ил алдында җаваплы булуын яңача ачкан, буыннар белән буыннар арасындагы мөнәсәбәтләрне, үткән тормыш белән бүгенге арасындагы бәйләнешләрне үзенчәлекле төстә сурәтләп биргән кызыклы, яңа әсәр барлыкка килгән.

Әхсән Баянов — тормыштагы, әдәбияттагы яңалыкларга аеруча сизгер язучыларның берсе. Чордашларының байтагыннан үзгә буларак, ул заманча уйларга, алай гына да түгел, заманча яшәргә, заманча киенергә ярата. Партиянең XX съездыннан соң тормышыбызның барлык өлкәләрендә урнашкан яңалыкны башлап тоеп-сизеп алып, шуны иҗатында чагылдырган язучыларның берсе нәкъ менә ул булды. «Яшьлегемне эзлим», «Дүрт монолог» повестьларында бу нык сизелә. Илдә фән-техника революциясе ныклап колач җәйгәч тә шундыйрак хәл кабатланды. Могҗизалы заман — ясалма йон, ясалма күн заманы — тормышка бик күп яңалыклар алып килде. Яңалыкларның шатланырлыклары күп, борчылырлыклары да бар иде. Беренчеләренә

сөенгән хәлдә, язучыларны кешенең җиргә, табигатькә һәм табигый байлыкларга мөнәсәбәте, материаль һәм рухи байлыклар арасындагы гармония кебек мәсьәләләр борчый башлады. Заман җилләренә сизгер язучы буларак, табигый, Ә. Баянов бу процесстан берничәк тә читтә кала алмый иде. Табигать белән кеше хисләре арасында гармония эзләү — язучының бөтен иҗатына хас сыйфат. «Тау ягы повесте»нда һәм шуннан соң чыккан «Төлке тоту кыен түгел» (1975), «Тавыш — табигать бүләге» (1977) кебек әсәрләрдә бу мәсьәләләр тагын да үткенәйтеп, калкурак итеп куела. Шуның белән бергә, бу повестьларында, бигрәк тә соңгы икесендә, язучы лирик проза өлкәсендәге тәҗрибәләрен дә төрләндерә төшә. Шартлы алымнар, символлар белән мавыгу нык көчәя, нәтиҗәдә авторның фикер агышын аңлау кыенлаша, күп очракта эчке тоемга, чама хисенә таянып кына фикер йөртергә кала. Укучының хәзерлек дәрәҗәсен исәпкә алмау Ә. Баяновның байтак әсәрләрендә сизелә иде. «Төлке тоту кыен түгел» һәм «Тавыш — табигать бүләге» кебек повестьларында ул эчке монологка корылган лирик проза өлкәсендәге тәҗрибәләрен тагын да катлауландырып җибәргән. Әйтик, «Төлке тоту кыен түгел» повестеның төп герое, үткән гомерен искә төшерә-төшерә, көннәр буе боз тавын чаба. Озак уйлангач, күп баш ваткач аңлый башлыйсың: бу — Үләмә елгасы ташыганда Татаның алма бакчасына кереп калган гади боз гына түгел икән. Боз тавы — символик образ. Ул — салкынлык символы да. Кешенең бөтен гомере салкынлык, ягъни боз тавы белән көрәштән гыйбарәт, ди Тата. Боз тавы — кешеләр арасындагы явызлык, мәкер һәм хәйлә дә, ямьсезлек, усаллык һәм гамьсезлек тә, үкенечле хәлләр, ялгышлар, кайгылар символы да. Ахыр килеп, боз тавын чабуны Татаның үзен якасыннан алган үлем белән, үлем газаплары белән тартышуы дип тә аңларга була. Кыскасы, бу — шартлы алым, символ. Аның күп төрле мәгънәләре һәм мәгънә төсмерләре бар.

Безне исә бу символның күбрәк Татаның үткән гомере, башкарган эшләре белән бәйле ягы кызыксындыра. Нинди батырлыгы өчен аңа Тата, ягъни зур, көчле кеше дигән исем биргәннәр? Төлке тоту кыен булмагач, нәрсә, нинди эш кыен икән? Әсәрне укыганда, безне шул сораулар ныграк кызыксындыра, шуларга җавап табасыбыз килә.

Повесть төп геройның үткән гомерен искә төшерү рәвешендә язылган. Геройның искә төшерүе еш кына үлем ачысы белән тартышып газапланган җешенең саташуын хәтерләтә. Ул кинәт кенә бер вакыйгадан икенчесенә, бер чордан икенче чорга күчә. Дөрес, нык тырышканда, чуалып-чәбәләнеп беткән хатирәләр, кечкенә-кечкенә эпизодлар, өзек-өзек җөмләләр аша да геройның шактый тулы биографиясен күз алдына бастырырга мөмкин. Татаның тормыш һәм хезмәт юлы гражданнар сугышы фронтларыннан башлана. Егерме беренче елгы ачлык вакытында Донбасска китеп, күмер шахталарында эшли. Туган җирен сагынуга түзә алмыйча, яңадан авылына кайта. Җиһанга өйләнеп, матур гына тормыш корып җибәрә. Коллектив хуҗалыклар төзелә башлагач, колхозга иң алдан керүче, хәтта аны оештыручыларның берсе була. Кошчылык фермасының мөдире булып эшли. Авыр сугыш елларында һәм сугыштан соңгы чорда үз колхозларында председательлек итә. Беренче хатыны үлгәч, Кояш исемле өч балалы тол хатынга өйләнә. Колхозларны эреләндерү кампаниясе вакытында председательлектән төшеп кала. Пенсиягә чыгып, тәмам картаеп беткәнче туган авылында яши...

Бер уйласаң, типик бер колхозчы тормышы. Тата биографиясе — меңнәрчә, миллионнарча крестьян биографиясе. Ил ни күрсә, ул шуны күргән, халык ни эшләсә, ул шуны эшләгән. Халык һәм ил язмышына туры килгән шатлык-кайгыларның берсе дә аны читләтеп узмаган. Тата — халыкның үз улы, типик бер вәкиле. Инде төптәнрәк уйлап карасаң, биографиясе, аның тормыш юлы зур да, мәгънәле дә. Зурлыгы — гадилегендә. Тата гомере буе, үзәккә җигелеп, йөкнең авырын тарткан. «Башка председательләр кебек, Тата үз гомерендә район үзәгенә шәп айгыр җигеп һәм кара тарантаска утырып, арка терәп исмасам бер генә тапкыр барса икән. Юк. Колхозның иң гади бер әгъзасыннан өстен булуны, әйбәтрәк яшәүне вөҗданы кабул итмәде. Халык нинди хәлдә булса, аның җитәкчесе дә шундый булырга тиеш, дип исәпли иде. Җитәкче кеше халыкның үз тормышы белән яшәмәсә, аңарда мин-минлек, үзен югары тоту, һавалану дигән яман чир кузгала... Аның Тата, икенче төрле әйткәндә, көчле дигән кушамат алуының сере дә шунда иде, мөгаен» (188 нче бит).

Бу юлларда — Татаның кредосы, яшәү рәвеше. Бу юлларда безне кызыксындырган сорауларның берсенә җавап та бар. Татаның зурлыгы — аның гадилегендә. Искә төшерүнең максаты да зарлану яки мактану өчен түгел. Шапырынудан бигрәк, ул гомер юлына нәтиҗә ясарга тели. Дөрес яшәгәнме ул? Якты дөньядан тыныч җан белән китәргә хакы бармы? Гомумән, кеше ни өчен дөньяга килә, ни өчен яши, ни өчен яшәргә тиеш? Кеше гомеренең мәгънәсе нәрсәдә? Шуңа күрә, мактану яки зарланудан бигрәк, тормыш юлындагы гыйбрәтле хәлләрне исенә төшерә. Кеше өчен түгел, үзе өчен, вөҗданы алдында хисап бирү өчен исенә төшерә. Беренче карашка ул тормыш юлындагы әллә ни зур һәм мөһим булмаган вакыйгаларны искә төшерә кебек (үз әтәче һәм танасы белән бәйле вакыйгалар, төлке тоту, бүре куу, Петруха малае белән бәрелеш һ. б.). Уйлый торгач, төшенәсең: Татаны вакыйгаларның зурлыгыннан бигрәк гыйбрәтле булулары кызыксындыра икән. Бу — кеше хәтеренең бер үзенчәлегедер, күрәсең.

Җиңел дә, тигез дә булмаган Татаның гомер юлы. Шатлык-сөенечләр, горурланырлык эшләр белән бергә, үкенечле хәлләр һәм ялгышулар да, эреле-ваклы гөнаһлар дә җитәрлек. Хәзер ул шуларның һәркайсын яңабаштан күздән кичерә. Гүяки үлчәүнең бер тәлинкәсенә саваплы эшләрен, икенчесенә төрле характердагы ялгышларын өя бара. Кайсы күбрәк, кайсы тартыр?..

Татаның иң зур үкенече шул: ул тормышның салкын җилләреннән беренче хатынын — саф, изге күңелле, ярдәмгә, яклауга бик тә мохтаҗ Җиһанны — саклый алмаган. Иң зур җиңүе — куркыныч, тайгак юлга кереп барган Петруха малаен коткару.

Шул рәвешчә, барлык эшләрен күздән кичергәч, аларның һәркайсына бәя биреп чыккач, тыныч җан белән китәргә хаклы булуын аңлый. Гомерен авырлыклар белән көрәшеп уздырган Тата дөньяны имин калдыра, балалар, оныклар калдыра, табигатьне, алма бакчаларын боздан әрчеп, чистартып калдыра. Иң мөһиме: кешеләргә якты, тыныч дөнья калдыра. Төлке тоту кыен түгел, Тата кебек яшәү, шундый булу кыен икән. Бик кыска итеп әйткәндә, әсәр укучы күңелендә шундыйрак уй-хисләр, тойгылар уята.

Бу повестьтан соң дөньяга чыккан «Тавыш — табигать бүләге» тәнкыйтьчеләр арасында тагын да зуррак ризасызлык уятты. Мин беренче чиратта И. Нуруллинның «Әдәбиятта шартлылык турында»[1] исемле мәкаләсен күздә тотам. Күп көч куеп язылган әлеге кызыклы мәкаләсендә, әдәбият тарихында очраган байтак шартлы әсәрләрне күздән кичереп, аларга мөнәсәбәтен белдергәннән соң, тәнкыйтьче «Тавыш — табигать бүләге»нә дә туктала. Һәм аны башта ук шартлылыкның үзен акламый торган очрагына бер мисал итеп китерә. Тәнкыйть итүне ул әсәрнең исеменнән үк башлый. «Тавыш дигәннән, бу детальне уйнатып, автор ниндидер фикер, ниндидер идея үткәрергә омтыла булса кирәк. Әсәрнең исеме дә шул турыда сөйли,— ди ул...— Тик менә тавыш мәсьәләсендә логика җитеп бетми. Туры мәгънәсендә тавышсыз калган Нажар ресторанда көчле тавыш белән Үзбәкстанның танылган артисты Таһир Закиров булып җырлый. Аннары, авторга кирәк булгач, тагын тавышсыз кала» (62 нче бит). «Әлеге кенә ресторанда кычкырып җырлап йөргән Нажарның кинәт тавышы бетә»,— дип, заманында повестьтагы бу моментка Р. Сверигин да игътибар иткән иде. Башта шушы мәсьәләгә ачыклык кертеп үтик.

Хөрмәтле тәнкыйтьчеләр бер нәрсәне истән чыгаралар: повесть каты авыру хәлендәге Нажарның сәяхәткә чыккан аюны атып үтерү күренешеннән башланса да, төрле чигенүләр, искә төшерүләр һәм фәлсәфи уйланулар белән үрелеп барган повестьта вакыйгаларның реаль тәртибе һәм эзлеклелеге бөтенчәрәк. Аннары, Нажар да «авторга кирәк булган саен» тавыш югалтып тормый. Ул тавышын бер генә тапкыр югалта.

Эш болай тора. Көннәрнең берендә Нажар Габбасов эшли торган институтны, «Агулы матдәләргә кеше организмының адаптациясе» дигән темага доклад ясау өчен, Парижга симпозиумга чакыралар. Докладны кем язарга тиеш? Ул доклад белән Парижга кем барырга тиеш? Шул сораулар тирәсендә ыгы-зыгы куба. Реаль эзлеклелеккә салганда, вакыйгалар шулай башланып китә. Симпозиумга чакыру хатын Мөдир өштырган икән. Доклад язарга көче җитмәсә дә, Парижга үзенең барасы килә. Кем

[1] Нуруллин И. Тормыш һәм сәнгать чынлыгы. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан, 1983 ел, 47—66 битләр.

язу һәм кемне җибәрү мәсьәләсен хәл итү өчен, тема өстендә конкрет эшләгән кеше буларак, директор бүлмәсенә Нәҗарны да чакыралар. Җавапны ул бирергә тиеш. Тик аны, кем язу һәм кем барудан бигрәк, ачыш дигәннәре үзе шиккә калдыра. Шул шиген Мөдиргә дә аңлату нияте белән, директордан, уйлашу өчен дигән булып, берничә көн вакыт сорый һәм Мөдирне ресторанга чакыра. Мөдир исә бу вакытны да, ресторанга баруны да үзсүзле, кире беткән Нәҗарны уеннан чыгарып ташлау өчен файдалана. Вәкил ярдәмендә оештырылган анонимкалар, фотолар аркасында Нәҗар адәм мәсхәрәсенә кала. Шул арада вакыйгалар тагын да куерып, катлауланып китә. Мөдир газетада ачыш хакында зур, әмма нигезсез мәкалә чыгарып өлгерә. Ул да түгел, тәҗрибә кошының агуланып үлүен хәбәр итәләр. Җитмәсә, шул ук Мөдир, бернибелән дә санашып тормастан, Нәҗардан: «эксперимент инде тәгәлләнде, нәтиҗә уңай» дигән фатиха бирүен таләп итә. Шул хәлләрнең һәммәсенә кәефе кырылган, кая барырга, җанын кая куярга белмәгән Нәҗар: «Шөһрәт һәм дәрәҗә өчен талашу минем профессия түгел, үз белгечлегем буенча эш яңадан чыкса, чакырырсыз», дип институтның ярдәмче хуҗалыгына — җәнлекләр арасына китеп бара.

Анда баргач, ниләр эшләве билгеле: берничә көн урын өстендә авырып ята, урыннан торып йөри башлагач, нервылары таушалган, арыган-талган, каты авыру хәлендәге Нәҗар, кабан дуңгызы дип уйлап, бер гаепсез аюны атып үтерә, ялгыш Әпәгә ата яза. Прораб авызыннан хатыны турында ямьсез хәбәр ишетә... Шундый тетрәнүләрдән соң, Нәҗар туры мәгънәсендә тавышын югалта.

Вакыйгаларны үз тәртибенә салып фикер йөрткәндә, И. Нуруллин кебек «кабан дуңгызы аңа никтер Мөдир булып, ә Мөдир кабан дуңгызы булып тоела» дип гаҗәпләнергә дә урын калмый, Мөдирнең бөтен этлеген, явызлыгын үз җилкәсендә татыган Нәҗарның аны кабан дуңгызы кыяфәтендә күз алдына китерүе бик тә аңлашыла. Мөдир оештырган кәмитләрдән, институтның ярдәмче хуҗалыгында булып узган хәлләрдән соң, геройны авыр истәлекләр, газаплы тойгылар, үкенечле хисләр белән алуы шулай ук табигый хәл. Мондый чакта гомереңнең һәм хезмәтеңнең мәгънәсе хакында уйланмау мөмкин түгел. Нәҗар шулай эшли дә. Тагын ике көннән соң — булмаган тавышы белән Мөдирнең чын йөзен ачканнан һәм, институтның ярдәмче хуҗалыгын су басып, бердәнбер кызын югалтканнан соң — тавышы кире кайта. Нәҗар көчле тавыш белән «Үтерделәр, үтерделәр!» дип кычкырып җибәрә. Туры мәгънәсендә тавыш югалту һәм тавыш кире кайтуга килгәндә, эш шулай тора. Вакыйгаларның реаль агышы һәм тәртибе менә шундый.

Шуның белән бергә, «Төлке тоту кыен түгел» повестендагы боз тавы кебек үк, бу әсәрдәге тавыш та — күп мәгънәле, символик образ. Прорабны табигать корткычы дип атаган шикелле, Нәҗарны гомер буе «тавышсыз кешегә» санап йөриләр. Бу — аның кушаматы. Хатыны Фәнүзә: «Мөдирләр биеклеккә синең кебек тавышсызлар башына баса-баса менәчәкләр», ди. Бу очракта сүз Нәҗарның яшәү рәвеше, характеры хакында бара. Геройларга еш кына теге яки бу мәсьәләне кул күтәреп, ягъни тавыш бирү юлы белән хәл итәргә туры килә. Образның мәгънәсе һәм эчтәлеге янә үзгәрә. Бер урында, Вәкил белән бәхәскә кереп, Нәҗар болай ди: «Тавыш, күзләр тирәнлеге, йөзләр чибәрлеге кебек үк, бүтәннәрдән таләп та, хәйләләп тә алынмый, ул — табигать бүләге, талант шикелле үк. Тик тора-бара күзләр тоныклана, сүрелә, йөзләр җыерчыклана, ә тавыш... тавыш карлыга, дус кеше» [1]. Монда инде, барыннан да бигрәк, кешенең иҗади таланты күздә тотыла. Бугаз ерту, акыру, бакыру турында сүз барганда, акырбайлыкны төп профессиясенә әйләндергән Мөдир кебек кешеләр искә алына һ. б. һ. б. Шуларның һәммәсе өстенә, тавыш образының тагын әле табигать тавышы, тормыш закончалыгы дигән мәгънәсе дә бар. Бусы — иң мөһиме, тавыш образының барлык мәгънә төсмерләрен бергә туплый, үз эченә ала торганы. Геройларның чын йөзе тормыш закончалыкларына, табигать тавышына, гаделлеккә нинди мөнәсәбәттә булуларына карап ачыла. Кыскасы, тавыш — күп сыйдырышлы, киң мәгънәле образ. Ләкин ни хәтле генә киң мәгънәле, күп төсмерле булмасын, алар берберләрен үстереп, көчәйтеп, ачыклап киләләр, алар арасында эчке бәйләнеш бар. Тавыш образы әсәрнең яңгырашын, мәгънәви эчтәлеген билгели. Кайбер тәнкыйтьчеләрне образның шул үзенчәлеге аптырашта калдырган булса кирәк. Хәлбуки, «Та-

[1] Ә. Баянов. Аязучан болытлы һава». Повестьлар. Казан, 1981 ел. 50 нче бит. Барлык өзекләр шушы басма буенча китерелә. Ф. М.

выш — табигать бүләге» алар уйлаганча ук аңламаслык әсәр түгел. Ә. Баянов, «повестьның сюжет скелетына аллегория һәм җәенке метафора, символ һәм киная, сатышып сөйләнү һәм сәер кыланмышлар кебек парчалардан җыеп типчелгән корама бишмәт кидереп» (И. Нуруллин, 61 нче бит), эшне никадәр генә катлауландырмасын, тырышканда һәм бик теләгәндә, әсәрнең төп фикерен дә, идеясен дә, образларын да аңлап һәм аңлатып була. Повесть табигатьне саклау белән бәйле җитди проблема күтәрә. Һәм ул проблема Нәҗар белән Мөдир арасындагы көрәштә чишелә.

Һич шик юк ки, повестьның төп герое — Нәҗар Габбасов, Әсәр аңа багышланган, сүз аның тормышта үз урынын, үз юлын, үз йөзен эзләве, гомер буе «тавышсыз кеше» кушаматы белән йөргән Нәҗарның «тавышлы кешегә» әйләнә баруы турында. Повестьның соңгы битләре буенча фикер йөрткәндә, ул, чыннан да, үзенең ялгышларын аңлый, тормыш юлын яңадан башларга дигән карарга килә. Мондый карарга килүе җиңел булмый, билгеле. Күп хәсрәтләр, төрле-төрле авырлыклар күрергә, бик нык уйланырга туры килә.

Нәҗарның бала чагы авыр сугыш елларына туры килә, күп кыенлыклар һәм мохтаҗлыклар күреп уза. Сугыш аның тәнендә зәгыйфьлек булып гомергә урнаша. Нәҗар «нервылары какшау, тиз уалучан, янып чыгучан, әз генә салкын тисә, сулыш юллары, үпкәсе җилсенеп чыгучан» кеше булып кала. Тырышлыгы, үз-үзен аямавы аркасында университетка кереп уку бәхетенә ирешә. Исемле стипендиант дәрәҗәсендә укыганга күрә, соңыннан ике еллык эш стажы да сорамыйча, аны аспирантурада калдыралар. Молекуляр биологиянең иң популяр темасы буенча вакытында һәм әйбәт итеп диссертация яклый. Аннары бар белгәнен, бөтен тормышын микродөньяга багышлый. Кешеләргә караганда хайваннарны күбрәк аңлаучан «саф» галимгә әйләнә. Зур, катлаулы тормыштан читкә китеп, үзенә тыныч дөнья сайлый. Хатыны Фәнүзә күп тапкырлар: «Эштә, тормышта актив бул. Җыелышларда, тантаналарда су эчә-эчә нотыклар сөйлә, бюроларга сайлан, лаборатория мөдире бул, начальник хатыны буласым килә» дип ялвара. Нәҗарның үз туксаны туксан. Чын галим үз эшен башкарырга тиеш, дип саный. Инде кемнеңдер чын фәнгә түземлеге, сәләте җитми икән, ул кеше чыгышлар ясасын, мөдир булсын, директор булсын, дип уйлый. Шулай уйлый, шулай яши, шуңа ышана. Һәм шулай уйлаганга күрә үзе ук Мөдиргә үсәргә, түрә булырга ярдәм итә. Башка шәһәрдән ялварып хатлар яза, ярдәм сорап янына торгач, аны үз янына эшкә урнаштыра. Үземнең андый эшкә сәләтем юк дип, мөдирлектән баш тарта. Фән өчен сәләтсез булса, бәлки оештыру эшен шәп башкарыр дип, аны мөдирлеккә тәкъдим итә.

Баштарак бик тә тыйнак, әдәпле һәм ярдәмчел кеше булып тоелган Мөдир, лаборатория җитәкчесе булып алгач, кинәт үзгәрә, бөтенләй икенче кешегә әйләнә. Дөресрәге, ул башта ук әшәке кеше булган, тик моны яшереп йөргән. Хәзер инә әрсезлеге белән хәтта директорны да үзенә хезмәт иттерә башлаган. Көн-төн директор кабинетыннан чыкмыйча, яңадан-яңа уңышлар, идеяләр турында мактанып үзен күтәрә. Шик юк, директор алдында ул үзен җир язмышын, табигатьне яклап калган акыл иясе дип исбатларга йөри, бөтен цивилизацияне саклаучы куәт иясе булып шауларга җыена. Нәҗар һәм башка галимнәрнең уңышлы эшләрен үзенеке итеп директорга һәм гыйльми советка җиткерә тора. Газета аша исемен бөтен илгә шаулата. Үз максатына ирешү өчен берни белән дә санашып тормый. Вәкилне эшкә куша. Югыйсә бит ул эшнең тәгәлләнмәгән булуын да, тәҗрибә кошының агуланып үлгәнен дә белә. Тик боларның берсенә дә исе китми, аңа дан, шөһрәт — Парижга бару кирәк. Нәҗар бик яхшы аңлый: «соңыннан ачышның ялган икәнлеге тормышта мең кош һәм җәнлек үлеме аша фаш ителгәч, бөтенләй бүтән кешеләр, ихтимал, бөтенләй бүтән институт кешеләре, яңадан бөтен бер лабораториягә гаять зур эш хакы түли-түли» әле ул, ягъни Нәҗар, әйткән нәтиҗәне кабатларга мәҗбүр булачаклар. Әмма Мөдирләргә һичнинди зыян килмәячәк, чөнки алар инде ул вакытта кул җитмәс биеклектә булачаклар, алай гына да түгел, агулы химикатларны басуларга күпләп чыгарырга фатиха бирүче кеше сыйфатында Нәҗарны фаш итәчәкләр, аны гаепкә тарттырачаклар.

Әсәрнең үзәгенә Нәҗар белән Мөдир арасындагы конфликт салынса, ул конфликтның асылын тормышка капма-каршы караш билгели. Нәҗар белән Мөдир арасындагы бәхәс берничек тә микродөнья, биология проблемалары белән генә чикләнми. Аның мәгънәсе күп тапкыр киңрәк. Саф фәнни проблемалардан тыш, биоло-

гия проблемаларыннан бигрәк, ул табигатькә һәм табигый байлыкларга мөнәсәбәт, галимнең кешелек җәмгыяте алдындагы җаваплылыгы, кеше гомеренең мәгънәсе кебек мораль-әхлак мәсьәләләрен дә үз эченә ала. Шул бәхәстә, шул мәсьәләләргә мөнәсәбәттә геройлар, беренче чиратта, Нәҗәр, Мөдир, Фәнүзә кебек төп геройлар ачыла. Алар тирәсенә повестьның эреле-ваклы башка персонажлары җыела. Тегеяки бу яктан килеп, алар төп геройларны ачарга, тулыландырырга булышалар.

Ә. Баяновның моңарчы тикшергән күпчелек повестьлары я төп геройның эчке монологы рәвешендә язылган була, яки аларда барлык хокуклар хикәяләүче герой кулына тапшырылган була иде. Бу яктан карaганда, «Тавыш — табигать бүләге» шактый аерылып тора. Әсәрнең күп бүлекләре төп геройның эчке монологы рәвешендә язылса да, хикәяләүгә әледән-әле автор үзе катнаша, Фәнүзә катнаша, хәтта Мөдиргә дә сүз бирелә. Бу — геройларны тулырак ачарга булышкан, аларга үзләренең эш-гамәлләрен аклау һәм яклау мөмкинлеге биргән. Дөрес, Нәҗәрдән калган геройларның шәхси тормышы аз яктыртыла. Аның каруы, аларның иҗтимагый йөзе ачыла, кыйблалары һәм төп принциплары ныграк аңлашыла. «Әсәрдәге кайбер персонажларның исем-фамилияләре булмаган кебек, индивидуаль йөзләре дә юк,— ди И. Нуруллин.— Алар тегеяки бу принципның кеше кыяфәтендәге гәүдәләнеше генә» (61 нче бит). Аның бу сүзләрендә дөреслек бар. Чыннан да, каравылчы, тере, җанлы кеше булудан бигрәк, табигать сакчысы вазифаларын гына башкара. Прораб белән Вәкил дә шундыйрак. Кеше була алмаганга, бары прораб, вазифа башкаручы гына булганга, берсенең исеме юк, табигать корткычы дигән кушаматы гына бар. Мөдирнең курчагына әверелеп йөргән өчен, икенчесе Вәкил генә булып калган. Автор махсус шулай эшли. Бу аңа үзе күтәргән проблеманы үткенрәк итеп кую өчен кирәк. Аннан соң «Тавыш — табигать бүләге» кебек шартлы алымнар белән язылган әсәр өчен аларның шул сыйфатлары да җитә. Исемсез геройлар рәтенә И. Нуруллин директор белән каравылчыны да кертә. Бу — төгәл фикер түгел. Вакыйгалар барышында күбрәк үз вазифаларын башкаручылар буларак катнашсалар да, алар исем-фамилияле геройлар. Каравылчы Әмән исемле кеше. Директорны Александр Иванович дип йөртәләр. Аннары И. Нуруллин Директорны «Мөдир һәм Вәкил кебек дөнья корткычлар» рәтенә кертә. Бу да бәхәсле фикер. Александр Иванович — үз вазифаларын, директорлык хезмәтен нык кул белән җиренә җиткереп башкара торган объектив кеше. Әгәр ул шундый булмаса, Мөдир әллә нинәр эшләп, әллә нинәр кыланып, Нәҗәрне күптән үз юлыннан алып аткан, кеше көлкесенә калдырып, тәмам эштән чыгарып бетергән булыр иде.

Ниһаять, соңгы һәм төп мәсьәлә. Бүгенге тормышның җитди проблемаларын күтәргән, кыю итеп күтәргән бу повестьны И. Нуруллин ни өчен бу хәтле өнәми соң? Повестьны И. Нуруллин мәкаләсе белән янәшә куеп тикшергәндә, бу сорауга да җавап табып була төсле. Тагын мәкаләгә мөрәҗәгать итик. «Әйтелгәннәрдән күренгәнчә,— ди тәнкыйтьче,— бәхәс сатира тәренә карамаган реалистик проза һәм драматургиядә шартлылык ни дәрәҗәдә зарур дигән мәсьәлә тирәсендә генә барырга тиеш. Чөнки аллегория һәм гипербола, гротеск һәм фантастика алымнары әдәбиятның сатира һәм лирика төрләрендә үзләрен үз өйләрендә кебек хис итәләр, һәм беркемнең дә бу хакыйкатьне шик астына алганы юк» (53 нче бит). Бу өзектән күргәнчә, И. Нуруллин әдәбиятның эпик проза төрендәге шартлылыкка каршы икән. Шунда ук яңа сорау туа: Ә. Баяновның «Тавыш — табигать бүләге» һәм «Яшьлегемне эзлим», «Төлке тоту кыен түгел» һәм «Аязучан болытлы һава» кебек повестьлары эпик проза үрнәкләремени?! Аларның барысы да диярлек әдәбиятның лирик төренә тартым яки лирик проза алымнары белән язылган әсәрләр ләбаса. Эпик прозадан аермалы буларак, лирик проза күбрәк геройның эчке дөньясы, рухи халәте белән эш итәргә ярата. И. Нуруллинның үз сүзләре белән әйткәндә, «ә кеше күңелендә, әгәр ул шагыйрь табигатьле дә булса — нинди теләк һәм хыяллар булмас!» (52 нче бит.) һәм нигә әле лирик проза вәкиле булган Ә. Баяновка шартлы алымнардан файдалану, аллегория һәм гиперболалар куллану тыела?!

Инде әсәрнең кимчелекле якларына килсәк, алар чыннан да бар. Әйтик, директорның кабул итү бүлмәсендәге секретарь кыз, нихәтле генә шәп эшләнгән булмасын, күпкә киткәч, ялыктыра башлый. Повестьның ахыры шактый сузылган. Су басу күренешләре, геройларның, спектакль ахырында сәхнәгә җыелган артистлар кебек, Нәҗәрләр фатирында яңабаштан мөнәсәбәт ачыкларга тотынулары ялыктыра төшә, әсәрне

таркауландыра. Ләкин моның өчен шартлы алымнар да, повестьның лирик проза алымнары белән язылуы да гаепле түгел. Сүз ул алымнардан нихәтле уңышлы файдалану, аларның органик берлеге, повестьның бөтенлеге, сәнгатьчә камиллеге хакында барырга тиеш.

Мәсьәләгә шушы яктан якын килгәндә «Тавыш — табигать бүләге»нә дә, авторның башка повестьларына да бәйләнергә була, бәйләнер урыннар байтак. Ә. Баянов повестьларының иң йомшак урыны — ахыргы өлешләре. Язучы барлык әсәрләрен диярлек, хәтта иң җитди проблемалар күтәргән повестьларын да пафослы сүзләр белән шомартып тәмамларга ярата. Игътибар итсәгез, «Яшьлегемне эзлим»дә, «Аязучан болытлы һава» белән «Тавыш — табигать бүләге»дә нәкъ шулай — матур сүзләр белән тәмамлана. Ләкин ул пафослы сүзләр вакыйгалар агышыннан, геройларның характерлары үсешеннән логик рәвештә килеп чыкмый. Алар укучыны тынычландыру һәм юату, тагын да турырак әйткәндә, йоклату өчен кирәк. Уртак геройлы һәм дәвамлы әсәрләрдә бу нәрсә аеруча күзгә ташлана. «Яшьлегемне эзлим» белән «Аязучан болытлы һава» повестен янәшә куеп тикшергәндә, шундый хәлгә бер юлыккан идек. «Тавыш — табигать бүләге»н «Аргы яр» (1979) белән чагыштырга башлауга кабат шундыйрак күренешкә юлыгабыз. Алда әйтелгәнчә, «Тавыш — табигать бүләге» дә шактый оптимистик рухта, мажор тоннарда тәмамлана. Мөдир белән булган бәрелештән соң, Нажар Габбасов үзенең хаталарын тәмам аңлый, аларны башка кабатламаска, тормыш юлын яңадан башларга сүз бирә. Аңа ышансаң, бу кеше алга таба башкачарак яши башлар, талантлы галим булу, фәнни эшләр белән шөгыльләнү өстенә, тормышка актив позициягә басар, фәнне оештыру һәм аңа җитәкчелек итү җәһәтеннән дә зур эшләр башкарыр дип уйлыйсың. Алай ук булып чыкмый. «Аргы яр» повестен укый башлауга бу бик ачык күренә.

«Аргы яр»— сөяркәләр мәхәббәтенә, ул мәхәббәтнең үзеннән дә бигрәк, аның фәлсәфәсенә, әгәр шулай әйтергә яраса, интим хисләр һәм җенси мөнәсәбәтләрнең психологиясенә багышланган әсәр. Повесть төп геройларның күңел дуэтлары рәвешендә язылган. Төп геройлар — икәү. Берсе — «Тавыш — табигать бүләге» буенча безгә таныш Нажар. Монда ул бөтенләй башка кеше булып, башка планда, башка яктанрак ачыла. Район түрәләре белән күңел ачу, мәҗлестә кызган баштан табигатьне саклау өчен тостлар әйтүдән ерак китми. Нажар монда — дөнья мине эштә, хыялда, мәхәббәттә алдады дип, каш-күз җимереп, йодрык төйнәп йөри торган шактый һавалы һәм тәкәббер бер кеше. Хәр, ирекле булырга, ни теләсә шуны эшләргә, дөньяда яшәү, сөю-сөешү турында фәлсәфә сатарга ярата.

Гөлчәчәк исә — шактый катлаулы, аяныч язмышлы, тормышта алданган бер кеше. Өстәвенә, мәхәббәт мәсьәләләрендә, интим хисләр өлкәсендә аптырап, буталып беткән кеше. Үзе Нажарны яратам ди. Шул ук вакытта элекке сөяркәләрен дә онытa алмый, алар белән араны өзә алмый иза чигә. Кечкенәдән үк тыелган нәрсәләргә, елганың аргы ярына чыгарга кызыгып яшәгән кыз. Шулардан ләззәт табып яши. Ихтыярсыз, бойлыксыз кыз. Эш юклык, вакыт күплек аркасындамы? Әллә инде, чыннан да, кызның баш миендә эндорфиннар җитмиме? Белмәссең.

Эштән туеп, хатыныннан бизеп торган арада Нажар шул кыз белән якынаеп китә. Танышып, якынаеп алгач, болар күпмедер вакыт күңел ачалар, сөешәләр, үпкәләшә һәм каргашалар. Эшләр тирәнгә китеп, күңелсез төс ала башлагач, аерылышалар. Яңача яши башларга, фән белән генә яшәргә булып, Нажар хатыны янына кайта. Гөлчәчәк тә, тынычрак эшкә күчеп, алга таба дөрес яшәргә хыяллана.

Тормышчанлык ноктасыннан чыгып якын килгәндә, повестьның әллә ни бәйләнер җире юк. Кызганычка каршы, соңгы вакытта интим хисләр, мәхәббәт мәсьәләләрендә чыннан да артык иркенәеп барабыз. Әдәп-әхлак нормалары шактый йомшарды. Ә. Баянов булганны яза. Тик булганны язу гына җитми, әдәбият кешене тәрбияләргә дә тиеш бит әле. Безнең язучылар, шулар җөмләсеннән Ә. Баянов та, уйлары чиста, хисләре саф булган кеше тәрбияләргә тиеш икәнлекләрен истән чыгармасыннар иде. Бу — мәсьәләнең бер ягы.

Инде мәсьәләнең икенче ягына килсәк, без интим хисләр, интим мөнәсәбәтләрне сурәтләү нигә кирәк, алар әдәбиятка нәрсә өсти? — дигән сорауга җавап табарга тиеш булырбыз. Ә. Баянов әсәрләрендә интим мөнәсәбәтләргә зур урын бирелә. Әмма

бер генә әсәрендә дә ул интим мөнәсәбәтләрнең ямьсез моментлары, эротик ягы белән мавыкмый. Алардан бигрәк, язучыны интим хисләрнең фәлсәфәсе, гашыйкларның күңел дөньясы, психологик кичерешләре кызыксындыра. «Аргы яр» повестен шул фикерне раслардык бер мисал дип санарга була.

Алда Ә. Баяновның заман темасына, тормыштагы яңалыкка аеруча сизгер язучы булуы әйтелгән иде. «Ут һәм Су» романы белән ул шуны тагын бер кат раслады. Татарстан җирендә гигант автомобиль комплексы әле колачын гына җәеп килә иде, «Казан утлары» журналында авторның шул төзелешкә һәм Түбән Кама ГЭСы төзүчеләренә багышланган өлеге романы басыла башлады. 1973 елда инде Татарстан китап нәшрияты аны аерым китап итеп чыгарды. «Ут һәм Су» КамАЗга багышланган төүге шигырьләр, очерклар белән бергә дөнья күрде.

Стиле һәм алымы, язылу рәвеше ягыннан ул авторның без алда тикшергән повестьларыннан әллә ни аерылмый диярлек. Шул ук көтелмәгән ассоциацияләр, аллегорияләр, символ дәрәҗәсенә җиткән образлар. Авторның күпчелек повестьлары кебек үк, «Ут һәм Су» да — эпик прозадан бигрәк лирик прозага якын алымда язылган әсәр. Алда тикшерелгән повестьлары кебек үк, роман фәлсәфи уйлануларның муллыгы, әзләнүчән рухы, яңа сүз, яңа фикер әйтергә омтылуы белән игътибарны җәлеп итә. Автор табигатьне һәм табигый байлыкларны саклау мәсьәләләренә зур урын бирә, аны КамАЗ төзүчеләрнең тормыш-көнкүреше, үзара мөнәсәбәтләре, дөньяга карашлары, эшкә мөнәсәбәтләре белән бәйле күп төрле мәсьәләләр борчый. Әмма барыннан да бигрәк, төзелештә эшләүче кешеләрнең күңел дөньялары, рухи кичерешләре, мораль йөзе кызыксындыра.

Романның эчке конфликтын дөньяга ике төрле караш, капма-каршы ике характер билгели. Аларның берсе — Фәез Насыйбуллин, икенчесе — Борис Филинов. Икесе дә бер үк институтны тәмамлаган белемле инженерлар, икесе дә күп төзелешләрдә катнашкан тәҗрибәле белгечләр. Зур төзелешләрдә генә очратырга мөмкин булган кызыклы, каршылыклы, колоритлы фигуралар, үзенчәлекле типлар.

Фәез — чыгышы белән авыл малае. Табигатькә гашыйк кеше. Бик тә тырыш, эшчән, булдыклы егет. Мәшәкать күп дип зарланмый, эш авыр дип сыкранмый. Ул үз стихиясендә, төзелешнең уртасында кайный. Таңнан алып кичкә кадәр төзелеш буйлап чаба, прораблар белән тиргәшә, кайда юмалап, кайда куркытып материал таба, эш мәйданы булдыра. Кичләрен исә иге-чиге булмаган киңәшмәләрдә, төрле җыелышларда уздыра. Фәез — бөтен вакытын, көчен, җанын-тәнен төзелешкә багышлаган герой. Кара эштән тайчынмый, кирәк икән — толкачка, кирәк икән — тәэминатчыга әйләнә. Шуңа күрә аны яраталар, фартлы егет, бәхетле егет дип йөртәләр. Ике ел вакыт эчендә ул гади инженердан баш инженерга, участок башлыгыннан идарә башлыгына хәтле күтәрелә.

Борис Филинов — бөтенләй башка төрле кеше. Ул Фәездән өлкәнрәк тә, тәҗрибәлерәк тә. Куйбышев ГЭСын төзүдә катнашкан, дүрт ел Иранда эшләп кайткан. Талантлы уйлап табучы. Экономик яктан бәйсез кеше. Борис хезмәтне фәнни нигезләрдә оештыруны яклый, акыл белән, тәртип һәм план белән эшләргә ярата. Ул ватылмыйча, көченмичә эшләргә күнеккән, эшкә вакытында килеп, вакытында китеп йөрергә гадәтләнгән. Сәләтле инженер, шәп уйлап табучы булганы өчен аны мактыйлар, сәгатьтән-сәгатькә кадәр генә эшләргә ратканы өчен тиргиләр. Аны күтәрмиләр, үстермиләр. Кайчандыр участок башлыгы, баш инженер булып эшләгән кеше, бирегә килгәч, төше-төше гади инженер булып кала.

Фәез белән Борис шәхси тормышларында да бер-берләреннән нык аерылалар. Фәез — романтик табигатьле, мәхәббәт мәсьәләләренә артык сак караучан, сайлаучан һәм сайланучан егет. Очраган бер хатын-кызның итәгенә тагылып китми. Ул хыялындагы мәхәббәтен эзли, шуңа күрә Кама — Камиләләр белән саташып йөри. Реаль кызларга караганда, аңа хыялындагы мәхәббәт, уйлап чыгарган мәхәббәте якынрак.

Борис — үз күңелен үзе күреп, үз рәхәтен үзе кайләп яши торган, хатын аерган ир. Шәп машинасы, менә дигән фатиры бар. Машинасында чибәр кызлар йөртә, фатирында күңелле мәҗлесләр өзелми. Кыскасы, Фәез дә, Борис та — заман геройлары. Әмма заманча яшәүне капма-каршы аңлый торган кешеләр. Икесе дә зур төзелеш өчен хас кызыклы һәм каршылыклы типлар. Тик берсе дә идеаль геройлар түгел. Фәезнең чатаклы-ботаклы яклары күп булган кебек, Борис та бөтенләй беткән

кеше түгел. Ахыр чиктә, Камиләне агулы елан чаккач, кызны үлемнән нәкъ менә Борис алып кала...

Шулай да авторның симпатиясе күбрәк Фәез ягында. Бу — аңлашыла. Чөнки хәзергә, төзелешнең башлангыч этабында, эш күбрәк вакыт белән дә, сәламәтлек белән дә, күп төрле башка кыенлыклар белән дә санашмый торган энтузиастлар, Фәез кебек фидакарь егетләр җилкәсендә бара. Яшь һәм көчле, вакыт-вакыт дуамал эшләр эшләп ташлый торган Фәез зур төзелешкә бик тә килешеп тора. Аның урыны шушында. Аннары, мәсьәләнең тагын бер мөһим ягы бар. Романдагы төп образларның берсе булу белән бергә, Фәез тагын әле хикәяләүче герой да. Романдагы вакыйгалар эченә, зур төзелеш атмосферасына безне ул алып керә, әсәрдәге төрле эпизодларны, күп санлы персонажларны бер-берләре белән ул тоташтыра. Телибезме-телә-мибезме романдагы бөтен нәрсәгә — төзелеш мәйданында барган эреле-ваклы вакыйгаларга, күп санлы мәсьәләләргә һәм геройларга, алар арасындагы мөнәсәбәтләргә — без Фәез күзләре аша карарга мәҗбүр. Шуңа күрә әсәрдә ул катнашмаган вакыйга, ул булмаган эпизод юк диярлек. Хәтта иң югары даирәләрдә, дүрт-биш кеше катнашында уза торган киңәшмәдә дә ул булмый калмый. Бәхеткә каршы, ул үз эшен әйбәт башкара торган, зур төзелешнең колачына һәм характерына ятышып, килешеп торган герой булып чыккан.

Хикәяләүче геройга тагын Кама — Камилә образлары булыша. Берсе — елга, икенчесе — чибәр кыз. Еш кына бер-берләренә кушылып, бер образга әйләнеп киткәләсәләр дә, романдагы вакыйгаларны, әсәрнең идея-проблемасын ачыклауда аларның һәркайсының үз урыны, үз вазифасы бар. Иделнең кызы гүзәл Кама борын-борыннан кешеләргә тугрылыклы хезмәт итеп килгән. Килә бер көн, җитә вакыт, Фәез кебек көчле егетләр килеп, аны буып, күпер салырга тотыналар. Су утка әйләнергә, электр энергиясе бирергә, шул ук вакытта Каманың гүзәллеге дә сакланырга тиеш. Ә. Баянов бүгенге Каманың, индустриаль елганың шактый үзенчәлекле һәм истә калырлык образын тудыра алган. Шул образдан башка романда сурәтләнгән вакыйгаларны, төзелешнең характерын һәм колачын күз алдына китерү, Фәезләр башлаган эшнең мәгънәсенә төшенү шактый кыен булыр иде.

Камилә образының роле башкарак. Ул барыннан да бигрәк композиция төзү чарасы буларак кирәк. Роман Фәезнең әле Кама, әле Камилә дип йөртелгән серле кызны эзләве рәвешендә язылган. Безне дә әсәр буена шул кыз үзенә тартып тора. Шул кыз белән нык кызыксынганга күрә, романның катлаулы производство мәсьәләләренә багышланган бүлекләрен дә җиңел генә «йотып җибәрәбез». Игътибарны шул кыз тота.

Көннәрнең берендә Фәезләр, көймәгә утырып, матур бер утрауга ял итәргә чыгалар. Шунда Камиләне агулы елан чага. Роман, шул күренештән башланып, Фәезнең шул күңелсез вакыйгага хәтле булган хәлләрне искә төшерүе рәвешендә язылган. Автор серне ахырга кадәр саклап килә. Сер менә-менә ачыла дип торганда, иң кызык моментка җиткәч кенә, сүз башка мәсьәләләргә күчә. Шул сер булмаса, тормышның кайнар эзләре буенча язылган бу әсәрне укуы шактый авыр булыр иде. Камилә укучының игътибарын җәлеп итү өчен кирәк.

Серлелек пәрдәсе алып ташлангач, сер ачылгач, ул шактый гадәти бер кызга әйләнеп кала. Образның мавыктыру көче нык кими. Романтик буяулары коелып төшкәч, реаль кызга әйләнгәч, автор вакыйгаларны түгәрәкләргә, романны тәмамларга ашыга.

Ә. Баяновның күпчелек әсәрләре кебек үк, «Ут һәм Су» романы да бик тә эффектлы, матур сүзләр белән тәмамлана. Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, кыз тиз арада терелеп чыга. Фәез белән Камилә бер-берләренә нык иялешеп китәләр, аерым яши алмаслык хәлгә җитәләр. Менә җылы, матур төннәрнең берсе. Киң урамнар, тын ярлар буйлап егет белән кыз — Фәез белән Камилә атлый.

— Мин синсез яши алмыйм! — ди Фәез.

— Ә мин — синсез! — дип җавап кайтара Камилә.

«Ут һәм Су»ның дәвамы булган «Таш китап» романын (1983) укый башлауга, моның тагын, авторның башка әсәрләрендәге кебек үк, укучыны юату һәм тынычландыру өчен әйтелгән матур сүзләр генә булганына төшенәсең. Кая ул бергә тору. Фәез белән Камилә хәтта бер шәһәрдә яши алмас, бер-берләрен күрәлмас дәрәҗәгә җитә-

ләр. Шуны алдан ук сиздереп, автор, ихтимал, ялгыш эшләгәндер. Сер беткәч, кызыксыну да кими. Шуңа күрә булса кирәк, яңа романның баштагы өлешләре шактый авыр укыла. Хәмитов килеп кереп, Фәез белән алар арасында көрәш башлангач кына, әсәр җанланып һәм мавыгып укырлык булып китә.

Вакыйгалар эченә бу романда да Фәез алып керә, геройлар белән ул таныштыра. Ләкин ул инде нык үзгәргән. Романтик егеттән реалист иргә, бәхетле, фартлы кешедән фартсыз кешегә әйләнгән. Семья корып җибәргән, басылган, сүрелгән. Шул нәрсә романның гомуми яңгырашына да үз эзен салган. «Ут һәм Су» романындагы күтәренке рух кими төшкән.

Бу юлы романның эчке конфликтын Фәез белән Хәмитов арасындагы дошманлык билгели. Хәмитов — Бориска караганда күп тапкыр явызрак, әшәкерәк кеше. Ичмасам, Филинов әлә эш кешесе, сәләтле инженер иде. Хәмитов — башкалар эшләгәнне үзләштерүче, кеше данын урлаучы. Хәмитов эшне кечкенәдән — зур түрәләрнең ваграк йомышларын үтәүдән башлый. Киенгәндә, пальто һәм эшләпәләрен биреп тора, портфельләрен күтәреп йөри. Шул юл белән горком секретаре Аппаковның ышанычын яулый. Аның каршында ышаныч казангач, Хәмитов җиң сызганып «эшкә керешә». Үз ялгышларын башкалар өстенә аудара, аларның уңышларын үзенеке итеп күрсәтә бара. Шулай капитал туплый, карьерага үрмәли.

Проблемасы һәм идеясе ягыннан караганда, «Таш китап», «Ут һәм Су» романыннан бигрәк, «Тавыш — табигать бүләге»нә якынрак тора. Анда күтәрелгән проблемалар башкарак тормыш материалы җирлегендә биредә тагын да үстерелеп, тирәнәйтеп бирелә. Шул ук Хәмитов, «Ут һәм Су» романындагы Борис Филиновтан бигрәк, «Тавыш — табигать бүләге» повестендагы Мөдир образына охшашрак. Хәтта аның игезәк туганы дип атарга мөмкин. Әгәр Мөдир үз максатына күбрәк акырбайлык ярдәмендә ирешсә, Хәмитов адъютантлыкны төп корал итә. Әмма икесе дә — кеше хисабына яшәүчеләр, намуслы кешеләр хезмәтен үзләштерүчеләр, шул юл белән шөһрәт казанырга, властька менәргә тырышучы карьеристлар. Моның белән генә чикләнсәләр бер хәер иде, алар намуслы кешеләрнең гаделлеккә булган ышанычын, иманын какшаталар, күңелен төшерәләр. Мөдирләрнең, Хәмитовларның төп зыяны шунда. «Таш китап» — үзенең төп рухы, бөтен яңгырашы белән Хәмитов кебек карьеристларга каршы юнәлдерелгән әсәр.

Күбесе «Ут һәм Су» романы буенча таныш геройлар булсалар да, «Таш китап»ның үзенчәлеген һәм яңалыгын алар билгеләми диярлек. Камилә һәм Фәез образлары, алар арасындагы мөнәсәбәтләр хакында сүз булды. Яңа заводларга җылылык трассасы сузганда һәм, ГЭС төзелешенә күчеп, күпер салганда Фәез ике тапкыр башын кискәгә куеп, егетлек эшләп ала. Ләкин автор аның бу эшләрен күрсәтеп бирми, нигездә хәбәр генә итә. Укучы мәхәббәтен казанырлык башка эшләрен күрмибез диярлек. Хәмитовтан кала, романның үзенчәлеген билгели торган кызыклы һәм яңа образларның тагын берсе — Гафур Садретдинов. Заманында кеше паспортын һәм паспорт хуҗасының исем-фамилиясен үзләштереп, ул Сафа Байгуҗинга әйләнә. Байгуҗин буларак, күп төрле хаталар, җинаять эшләре кыла. Себер якларында эшләгәндә, чак кына Фәез Насыйбуллинны үтерми кала. Байгуҗин булып өйләнә, балалар үстерә. Шул ук исем-фамилия астында туган якларына кайтып, Якты Яр шәһәрендә барган зур төзелешнең бер каһарманына әйләнә. Шул кеше әсәр буена үзенең чын исеменә кайтырга, Гафур Садретдинов булып йөрергә тырыша. Ләкин һич кенә дә үзенең Сафа Байгуҗин түгеллеген раслый алмый. Шул уңайдан романга кешенең исеме һәм җисеме дигән зур, яңа проблема килеп керә. Бу — бер Гафурга гына кагыла торган, аңа гына карый торган мәсьәлә түгел. Ул романның күп геройларына, Аппаков белән Хәмитовка да, хәтта эш өчен янып-көеп яшәгән, башын күп тапкырлар кискәгә салган Фәезнең үзенә дә кагыла.

Мәгълүм бер хәлләрдә үзеңнең кем булуыңны, нинди кеше икәнлегеңне раслау да җиңел түгел икән. Эш башында, Аппаков кебек, кеше турында гамәле буенча түгел, сүзе буенча фикер йөртә торган түрәләр утырганда — бигрәк тә. «Таш китап» романында җитди һәм кыю рәвештә куелган мәсьәләләрнең тагын берсе — әнә шул. Ләкин ул романның төп темасына органик төстә үрелеп китә алмаган, бер читкә чыгып, бүселебрәк тора. Тагын да дөресрәге, төп тема тәгәлләнгәч кенә башлана.

* * *

Алда әйтелгәнчә, Ә. Баянов прозага шигърьдән килде, проза өлкәсенә шагыйрьлеген дә алып килде. Ул безнең әдәбиятта эчке монологка корылган лирик прозаны үстерү эшенә күп өлеш кертте. Бу — аңа геройларының катлаулы рухи дөньясын тирәнрәк ачарга булышты. Аның роман, повестьларында шигърият белән проза, эпик проза белән лирик прозаның шартлы алымнары үзара үрелеп, чиратлашып килә. Укышлы чыккан очракта, бу аның әсәрләренә үзенчәлекле төс, үзгә яңгыраш бирә. Язучының прозасын кызыклы һәм оригиналь иткән сыйфатларның иң мөһиме шул булса кирәк.

Ә. Баянов әсәрләрендә әдәбиятның мәңгелек темасы саналган мәхәббәт мәсьәләләренә зур урын бирелә. Әмма ул аларга үзенчә якын килергә, аларны башкарак, яңарак ноктадан карап хәл итәргә тырыша. Я ул мәхәббәтнең яңа якларын ача, я булмаса, гашыйклар арасындагы интим мөнәсәбәтләрнең башка язучылар кузгатырга кыенсынырак йөргән четерекле якларына мөрәҗәгать итә.

Ә. Баянов прозасы фикергә, фәлсәфи уйлануларга бай. Ул җитди проблемалар кузгатырга ярата. Әзер тезисларны иллюстрацияләүдән баш тартып, үзенчә яңалыкка омтылып яши. Аның геройлары арасында төрле кешеләр бар. Аларның күбесе — шигъри җанлы, нечкә күңелле, интеллектуаль һәм эмоциональ табигатьле хис кешеләре, шул ук вакытта артык кызу канлы, тиз җәрәхәтләнүчән, импульсив геройлар. Кызып, кабынып киткәндә, еш кына ачы телле тупас кешегә әйләнәләр. Әнис Бадыгин, Наҗар Габбасов, Фәез Насыйбуллин кебек чатаклы-ботаклы геройлары гына шулай кыланса бер хәер иде. Хәтта Тәбрик белән Исәнбәк тә шундыйлар.

Аның әсәрләрендә, әйткәнебезчә, тормышның төрле өлкәләренә караган бик җитди һәм күп төрле мәсьәләләр кузгатыла. Аларның һәммәсе белән дә килешеп бетмәскә мөмкин. Шул ук вакытта язучының бу юнәлештәге кыю эзләнүләренә каршы төшү, кызыклы табышларына күз йому да гаделлек булмас иде. Сәнгатьнең чиктәш төрләре, шулай ук башка халыклар, башка ил әдәбиятлары ирешкән казанышлардан иҗади файдалану җәһәтеннән дә Ә. Баяновның телгә алып сөйләрлек уңышлары бар. Ул үз әсәрләре өчен отышлы ситуацияләр таба, роман, повестьларының сюжет-композициясен оста итеп кора белә. Аның проза әсәрләре тиз ага торган, укучыны үз артыннан ияртерлек киеренке вакыйгаларга корылган була.

Шуның белән бергә, Ә. Баянов әсәрләренең ышандыру көче йомшаграк булуын да әйтеп узарга кирәк. Ул үз геройларының эш-хәрәкәтләрен, бер халәттән икенче халәткә күчүләрен мотивлаштыруга тиешле игътибар биреп җиткерми. Тагын бер җитди теләк бар: киләчәктә ул лирик проза алымнарын эпик проза казанышлары белән органик төстә бәйләү хакында ныграк уйлансын иде. Югыйсә, аның лирик проза өлкәсендәге тәҗрибәләре озаккарак сузылды, нәтиҗәләре һаман да без көткәнчә үк түгел.

Ә. Баянов әсәрләренең теле, китап теленнән бигрәк, җанлы сөйләм теленә якын. Язучының теле әсәрләрендә алынган вакыйгаларның агышына һәм характерына нигездә ятышып тора. Шуңа күрә укыганда теленең ниндилеге сизелми диярлек. Инде аерым максат куеп укый башласаң, русча уйлап төзелгән яки тәрҗемә юлы белән ясалган җөмләләрнең шактый күп булуын күрәсең. «Таш китап» романы шул яктан аеруча нык аерылып тора. Әдәби телебезгә ятышсыз, авыр кытыршы җөмләләрнең очрамавы хәерле.

Әхсән Баянов прозасының иң нык күзгә ташланып торган сыйфатлары менә шулар.

# КУЛЬТУРА ТОРМЫШЫ КӨНДӘЛЕГЕ

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Язучыларның 27 июньда узган ачык партия җыелышында Татарстан язучыларының X съезды нәтиҗәләре һәм язучылар оешмаларының бүгенге бурычлары турында зур сөйләшү булды. Доклад белән Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев чыкты. Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы правлениесе председателе Т. Миңнуллин, тәнкыйтьче Р. Мостафин, прозаиклар М. Хуҗин, Р. Ишморатова, Ж. Тәрҗеманов, М. Хәсәнов, шагыйрьләр Ә. Бикчәнтәева, Г. Латыйп, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис катнашты.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Проза секциясенең 11 январьда узган чираттагы утырышында отчет-сайлау җыелышы булды. Секция председателе М. Мәһдиев ел әйләнәсендә эшләнгән эшләргә йомгак ясады.

Җыелышта секциянең яңа бюросы сайланды.

14 майда поэзия секциясенең чираттагы утырышы булып узды. Ул шагыйрь Рифкать Зәкировның «Шахтер моңы» исемле китабы һәм яңа шигырьләр кулъязмасы турында сөйләшүгә багышланды. Докладчы Ә. Рәшитов, чыгыш ясаучылардан Г. Ахунов, С. Хәким, Н. Арсланов, И. Юзеев, Зөлфәт, Ф. Сафин, Р. Низамиев, Ф. Гыйззәтуллина, Э. Шәрифуллина һ. б. шагыйрьнең үзенчәлекле таланты, бәхәссез уңышлары турында ассызыклап сөйләделәр, шагыйрьгә кызыклы киңәшләр әйттеләр. Җыелыш Р. Закировны СССР Язучылар союзына тәкъдим итте.

Шул ук утырышта секциянең яңа бюросы сайланды.

13 июньда тәнкыйтьчеләр секциясенең отчет-сайлау җыелышы булып узды. Секция председателе Ф. Мусин отчет доклады белән чыкты.

Утырышта секциянең яңа бюросы сайланды.

## ЯШЬ ИҖАТ КӨЧЛӘРЕ БЕЛӘН ОЧРАШУ

23 майда ВЛКСМ өлкә комитетында Татарстан язучыларының X съездында чакырылган яшь иҗат көчләре һәм республикабызның төрле шәһәрләрендә эшләп килүче әдәби берләшмә җитәкчеләре белән очрашу булды.

Яшь әдәбиятчыларны ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Б. Д. Леушин кабул итте. Ул Татарстан язучыларының X съезды йомгаклары һәм республикабызның яшь иҗат көчләре алдында торган бурычлар турында сөйләде. Алабуга, Әлмәт, Брежнев, Түбән Кама, Бөгелмә, Лениногорск, Мамадыш шәһәрләреннән әдәби берләшмә вәкилләре үзләренең иҗат планнары белән уртаклаштылар, фикер алыштылар.

## ТӘТЕШТӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

15—18 майда Тәтеш районында Татарстан язучыларының X съездына багышланып татар әдәбияты көннәре үткәрелде. Әдипләр Р. Ишморат, М. Садри, Р. Гәрәй, Р. Ишморатова, К. Тимбикова, М. Насыйбуллин, А. Хәсәнов, Р. Хәлиуллина терлекчеләр, игенчеләр, механизаторлар белән очрашып, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, бүгенге әдәби хәрәкәтнең торышы турында сөйләделәр.

## ШИГЪРИ ФЕСТИВАЛЬ

21—24 июньда Мари АССРның башкаласы Йошкар-Ола шәһәрендә Идел буе республикалары поэзиясе көннәре үткәрелде. Әлеге шигъри фестиваль Йошкар-Ола шәһәренең 400 еллыгына, данлы комсомолга В. И. Ленин исеме бирелүгә 60 ел, Мари АССР Язучылар союзының оешуына 50 ел тулу вакыйгаларына багышланган иде.

Фестивальдә Татарстаннан шагыйрь Рәшат Низамиев катнашты.

## ӘДИПЛӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ

Казанның Маяковский урамындагы 23 «а» йортында озак еллар күренекле татар совет язучылары Габдрахман Әпсәләмов һәм Мирсәй Әмир яшәделәр, шунда үзләренең үлемсез әсәрләрен иҗат иттеләр.

22 июньда шушы бинага әлеге ике әдип истәлегенә мемориаль такта кую тантанасы булды. Анда республикабызның партия, совет һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, журналистлар, хөрмәтле әдипләрнең туганнары катнашты.

Мемориаль такта куюга багышланган митингны кереш сүз белән ТАССР культура министры И. Н. Алиев ачты. Аннары Татарстан Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев, әдипләрдән А. Расих, Ф. Хөсни, тәнкыйтьче Р. Мостафин чыгыш ясады. Алар Габдрахман Әпсәләмов һәм Мирсәй Әмирнең татар совет әдәбиятын үстерүгә керткән зур өлеше, аеруча Бөек Ватан сугышы елларында халкыбызның фронтта һәм тылдагы батырлыгын тасвирлаудагы эшчәнлекләре турында сөйләделәр.

Мемориаль такталарга (авторы — Брежнев шәһәрендә яшәүче скульптор П. П. Захарчук) рус һәм татар телләрендә Габдрахман Әпсәләмов һәм Мирсәй Әмирнең бу йортта торган еллары язылган һәм аларның барельефлары төшерелгән.

# ХӨКЕМ АЛДЫННАН

Совет сынлы сәнгатенең иң төп уңышларыннан берсе яңа кеше образын иҗат итүдә күренә. Социалистик революция яңарышы тарафыннан тудырылган бу кеше совет халкының иң яхшы сыйфатларын үзендә кристаллаштыручы, бөек тарихи казанышлар яулаучы революцион рухлы шәхес буларак күзаллана.

СССРның халык рәссамы, СССР Художество академиясе член-корреспонденты Харис Якуповның «Хөкем алдыннан» (1954) исемле күренекле картинасында нәкъ менә шундый көрәшче, үз язмышын ил язмышы белән бәйләгән коммунист образы гәүдәләндерелгән. Каһарман шагыйрь Муса Җәлил батырлыгына багышланган әлеге әсәр, бик хаклы рәвештә, күпмилләтле совет сәнгатенең казанышы буларак кабул ителде.

Киеренке сюжетка корылган бу картинаның үзәген капма-каршы ике идея көрәше, аерым алганда, шагыйрь белән катыйль арасындагы бәрелеш тәшкил итә. Рәссам үзәк фигураның шундый отышлы сурәтләнешенә ирешкән ки, аның кыяфәтендә пәм карашында совет җәмгыяте тарафыннан салынган һәм геройның коммунистик идеал өчен шәхси көрәшендә чыныккан асыл сыйфатлар бик тә калку чагылыш таба. Һәм геройның бөтен күзәнәкләреннән ташып торган көч сорау алучы гитлерчыларның үзләрен дә калтырандыра. Әйтерсең, фашистлар — Җәлилне түгел, ә Җәлил фашистларны хөкемгә тарта. Шунысы да ачык төсмерләнә: Моабит тоткынының йөрәге белән фронтовик-рәссам йөрәген, гүя, ниндидер «рухи күпер» тоташтыра. Теманың якынлыгы, шәхси кичерешләр кайнарлыгы исә картинаның ышандыру көчен арттыра, шагыйрьнең героик шәхесен тагын да зурайта. Йөзенә сирпелгән яктылык дулкыны Җәлилнең рухи ныклыгын, идея инанганлыгын, җиңүгә ышанычын ачыграк итеп күрсәтә.

Картинаның тагын бер уңышлы ягы шунда да күренә: илленче елларда иҗат ителгән күп кенә әсәрләрдән аермалы буларак, анда дошман образлары, ниндидер карикатура алымнары белән түгел, ә үз карашларын үҗәтлек белән алга сөрүче шактый ук көчле реаль персонажлар итеп гәүдәләндерелгән. Җәлил менә нинди дошман белән көрәшкән! Ә мондый бирелеш исә шагыйрь батырлыгының әһәмиятен бермә-бер арттыра.

Һәм әсәр шул ягы белән отышлы: аның идея эчтәлеге, сорау алу яки тарихи факт кысаларыннан чыгып, ике идеология, ике дөнья арасындагы каршылык, социаль коллизияләр дәрәҗәсенә кадәр үстерелә. Әсәрнең яшәүчәнлеген һәм заманчалыгын нәкъ менә шундый сыйфатлар билгели.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

Тышлыкның дүртенче битендә: Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисткасы Вафирә Гыйззәтуллина.

Рөстәм МАНСУРОВ фотолары.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1985 ЕЛДА

Укучыларыбыз, көз айлары җиткәч, журналның алдагы ел планнары белән кызыксына башлыйлар. Әдәбият сөючеләрнең бу кызыксынуы бик табигый, һәм без сезгә үзебезнең «серләр»не ачып салабыз икән, дуслыкны дәвам итү җәһәтеннән монысы да гаять дөрес булачак.

Татар совет әдәбиятының иң күренекле әсәрләре, гадәттә, укучыларыбызга иң элек «Казан утлары» аша барып ирешә. Журнал сәхифәләре шаһит: СССР һәм РСФСР дәүләт премияләре һәм Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган әсәрләр үз вакытында иң беренче журнал битләрендә басылып чыккан. Социаль һәм әхлакый проблемаларга багышланган, заманча яңгырашлы роман һәм повестьларга, пьеса һәм хикәяләргә, поэма һәм шигырьләргә журнал киләчәктә дә киң урын бирәчәк.

1985 елда совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 40 ел тула. Әлеге тарихи вакыйга уңаеннан да күп кенә материаллар, фронтовик әдипләрнең истәлекләре биреләчәк. Журнал битләрендә иң яхшы хикәяләргә «Батырлык дәвам итә» конкурсы бара. Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган әлеге конкурска май аенда йомгак ясалачак.

Әлбәттә, журналның йөзен иң беренче чиратта күләмле проза әсәрләре билгели. Алдагы ел нинди яңа әсәрләр белән сөендерер соң? 1985 елда «Казан утлары» үзенең укучыларына берничә роман тәкъдим итәчәк. Алар арасында, мәсәлән, Хисам Камаловның «Безне өйдә көтәләр», Гөлсем Мөхәммәдованың «Эзләнүләр», Чиләбедә яшәүче язучы Рөстәм Вәлиевнең Габдулла Тукай турындагы «Дөнья гаме» дип исемләнгән романнары бар. Алдагы ел өчен повестьларыбыз киштәсе дә буш тормый. Шундый әсәрләрдән Аяз Гыйләҗевнең «Тәмәкене ташладык, рәхәт чигә башладык», Нәби Дәүлинең «Без дөньяга килдек», Гамил Афзалның «Юл башы», Сәет Шәкуровның «Артист» исемле повестьларын әйтеп китәргә мөмкин.

Билгеле булганча, 1986 елда сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 100 ел тула. Бу олы юбилейга әзерлекне журнал быел ук башлаган иде. Киләсе ел саннарында да, алда әйтелгән романнан тыш, халык шагыйре турындагы истәлекләр, әсәрләр урын алачак. Күренекле революционер Мулланур Вахитовның тууына 100 ел тулу уңаеннан, шулай ук Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлына кагылышлы эзләнүләр, Х. Туфан, Ш. Маннур һ. б. турында биреләчәк истәлекләр укучыларыбызда зур кызыксыну уятыр.

«Бүгенге татар поэзиясе һәм аның илкүләм яңгырашы» дип исемләнгән түгәрәк өстәл янындагы сөйләшү дә күпсанлы укучыларыбыз күңелендә тирән эз калдырыр дип ышанабыз.

Журнал киләсе елда да татар халкының килеп чыгышы һәм культура тарихыннан кызыклы яңа материаллар бирүне дәвам итәчәк.

Кыскасы, 1985 елда да «Казан утлары» күпмеңләгән укучыларның йортына һәм йөрәгенә һаман яктылык һәм игелек нурлары илтәчәк! Безнеңчә, дуслыкның көче нәкъ менә шунда да инде.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ